
ISSN 0206—4189

# КАЗАН УТЛАРЫ

10.2001



# ÇAL TARİXLI QAZANIM!





2001 yılğı arxeologik qazınular waqıtında Kreml' territoriəsendə tabılğan bina qaldıqları. *XV–XVI ğasırlar.*

Казан утлары
Qazan utları

2001

10

(948)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*

**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Харрас Әюпов**
**Зилә Вәлиева**
**Фоат Галимуллин**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Салих Маннапов**
**Мирза Мәхмүтов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Гәрәй Рәхим**
**Факил Сафин**
**Ренат Харис**
**Зиннур Хөснияр**
**Розалина Шаһиева**

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

---

✉ 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
☎ Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда

### ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Сафа САБИРОВ. Алтын балдаклы абыстай. *Документаль повесть* ... 5

Рөстәм МИНГАЛИМ. Кылыч йөзе буйлап. *Шигырьләр* ... 41

Гарифҗан МӨХӘММӘТШИН. Тургайларга иш булып... *Шигырьләр* ... 81

Нәҗибә САФИНА. Ут белән су елгасы... *Шигырьләр* ... 87

Марсель ЗАРИПОВ. Агымсу ташуы. *Хикәя* ... 91

Вәзыйх ФАТЫЙХОВ. Мин бит... *Шигырьләр* ... 99


### ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ


Ризван ХӘМИД. Тигезәкләр. *Заман трагифарсы (Илдар Юзеев кереш сүзе белән)* ... 45


### КАЗАН ДӘҮЛӘТ ПЕДАГОГИКА УНИВЕРСИТЕТЫНА 125 ЕЛ


Озын юл, нурлы юл *(Университет ректоры Рүзәл Йосыпов белән әңгәмә)* ... 102


### ПУБЛИЦИСТИКА


Миргазиян ЮНЫС. «Чит җирләргә йөреп гыйбрәт ал...» ... 108


### ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ


Рафаэль СИБАТ. «Йөгез, бер дога!» *Эссе* ... 121


### ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ


Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. «Могикан»нар кисәтә ... 132


### СӘНГАТЬ


Шамил МОНАСЫЙПОВ. Назлы моң *(Рөстәм Яхинның тууына 80 ел)* ... 135

Рәйсә ЮСУПОВА. Моң һәм тәүге мәхәббәт *(София Гобәйдуллинага 70 яшь)* ... 172


### ФӘН


Илбарис НАДИРОВ. Телен белгән—иленә юл табар ... 145

Окан ТАҺИР. Финляндия татарларының алфавиты һәм орфографиясе тарихыннан ... 148

Сәлам АЛИШЕВ. Татар халкының дәүләтчелек өчен көрәш елъязмасы ... 152

Исрафил НАСЫЙБУЛЛИН. Казан ханлыгының чикләре каян узган? ... 156


### КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ


15—Хиҗр (Хиҗыр иле), 16—Нәхел (Бал корты) сүрәләре ... 161


### ӘДӘБИЯТЫБЫЗ ТАРИХЫНА


Рәйсә МУСАБӘКОВА. Кешеләр арасында яшәп тә ... 179


### ЮМОР—САТИРА


Камил Кәримов. Шаян хикәяләр ... 182

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ... 191

# В НАШЕМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*

«Проза и поэзия»: повесть С. САБИРОВА «Женщина с золотым кольцом», рассказ М. ЗАРИПОВА «Белое половодье»; стихи Р. МИНГАЛИМА, Г. МУХАММЕТШИНА, Н. САФИНОЙ, В. ФАТЫХОВА.
«Драматургия»: драма Р. ХАМИДА «Совки».
«125 лет Казанскому государственному педагогическому университету»: беседа с ректором университета Р. Юсуповым.
«Публицистика»: М. ЮНУС. Путевые заметки «Мелодии Египта».
«Литературная критика»: Р. СИБАТ. Эссе-размышления о творчестве писателя А. Гилязова.
«Книжное обозрение»: А. ЗАКИРЗЯНОВ рецензирует ровесть В. Имамова «Могикан».
«Искусство»: Ш. МУНАСЫПОВ. «Нежная мелодия» *(к 80-летию композитора Р. Яхина)*; Р. Юсупова. «Музыка и любовь» *(к 70-летнему юбилею композитора современности С. Губайдуллиной)*.
«Наука»: И. НАДИРОВ. «Язык—путь к сердцу народа»; О. ТАГИР. «Финские татары и татарский алфавит»; С. АЛИШЕВ. «Летопись освободительной борьбы».
«История»: И. НАСЫБУЛЛИН. «Границы Казанского ханства».
Коран на татарском языке.
«К истории литературы»: Р. Мусабекова анализирует творчество поэта С. Сунчалая.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: мечеть «Казан нуры» работа Н Исмагилова; литературовед Фарит Хатипов.

# IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*


"Prose and Poetry": S. SABIROV'S poetry «The woman with golden ringlet», M. ZARIPOV'S story «The white spring flood»; the verses of R. MINGALIM, G. MUKHAMMETSHIN, N. SAFINA, V. FATIKHOV.
"Dramatics": R. KHAMID'S drama "The scoops".
Commemoratung the 125th Anniversary of Kazan State pedagogical University: a talk with rector of university R. Usupov.
"Journalism": M. Unus notes "The Egypt's melodies".
"Literary criticism": R. SIBAT'S essay about writer A. Giliazov's creative works.
"Book review": A. ZAKIRZIANOV'S review of V. Imamov's narrativ «Mogican».
"Art": SH. MUNASIPOV "The tender melody"; R. Usupova "The music and love".
"Science": I. Nadirov "The language is the Key to heart of people"; O. Tagir "Finland Tatars and Tatar alphabet"; S. Alishev "The chronicle of liberation struggle".
"History": I. NASIBULLIN "The borders of Kazan state".
"Life and religion": Koran in Tartar language.
"Literary history": R. Musabekova about S. Sunchalay's creative works.
Humor and satira: K. Karimov's story.
The diary of social and cultural life.
In our covers: Ismagilov's work - the mosque "Kazan noury"; the specialist in literature Farit Khatipov.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-34-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 28.09.2001 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 1/16.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 8219 Заказ А-404
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2001 ел.



**Сафа Сабиров**

# АЛТЫН БАЛДАКЛЫ АБЫСТАЙ

ДОКУМЕНТАЛЬ ПОВЕСТЬ

Хәрби диңгез флотында хезмәт иткәндә утыз сигезенче елның көзендә, мин Владивосток порты эшчесе Шакир исемле бер агай һәм аның хатыны Фәгыйлә апай белән танышкан идем. Хезмәттән буш көннәрдә аларга барып-килеп тә йөри башладым. Казанда бергә укыган дус кызым килеп төшкәч, без өйләнештек һәм өч ай аларда фатирда тордык. Үз куышыбыз булганнан соң да жиде ел дәвамында дусларча йөрешеп яшәдек, сугыш вакыты кыенлыкларын үзара ярдәмләшеп бергә үткәрдек.

Фәгыйлә апай иренә караганда зыялы, укымышлы, әдәбият белән кызыксынучан, базарда очраса гарәп хәрефләре белән язылган иске китаплар алып кайта, гомумән дә укырга ярата, Тукайның күп кенә шигырьләрен яттан белә, шагыйрьне еш телгә ала иде. Сөйләшә торгач, сүз арасында мин аның кайчандыр Тукай белән шәхсән таныш булганлыгын, уникенче елның жәендә Троицк шәһәреннән ерак түгел казакъ даласына кымыз белән дәваланырга килгән авыру шагыйрьгә ике ай ярым дәвамында аш-су пешереп торганын, керләрен юганын, ара-тирә аның белән сөйләшеп утырганын да белдем.

Дөресен әйтим, моны белү миңа бик кызык, бик мөһим тоелды. Ул вакытта әдәбият дөньясыннан ерак торсам да жай чыккан саен Фәгыйлә апайдан сораштырып, ул сөйләгәннәрне истәлек дәфтәремә терки бардым.

Бөек Ватан сугышы вакытында Владивосток янындагы хәрби-һава частенә очучы һәм шагыйрь Салих Баттал килде. Аның белән мине «Калинин» крейсеры тупчысы Локман Бадыйкшанов таныштырды. Шуннан бирле Салих абый бер көнлек коры азык паегын кыстырып, безгә куна килгәли башлады... Тиздән мин аны Фәгыйлә апайларга алып бардым.

Революция елларында һәм азактан да күптөрле нахак гаепләүләргә,

---

Сафа САБИРОВ *(1915)—язучы, «Яшь диңгезчеләр», «Якты агым», «Утлы фарватердан», «Идел йолдызлыгы» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

допросларга дучар булган Фәгыйлә апайга погонлы офицер Салих Баттал шикле тоелды бугай. Беренче очрашуда әңгәмәбез теләгәнчә жанланып китә алмады. Тик бераздан, якынрак танышкач кына, Фәгыйлә абыстайның теле чишелде. Тукай белән очрашкан көннәрне кабат кичергәндәй, гадәтенчә дулкынланып сөйләде. Аның хатирәләренең Тукай белән бәйле өлешен язып, без кырык икенче елның башында Казанга Татарстан Язучылар союзы идарәсенә жибәрдек.

Дүрт ай чамасы вакыт үткәннән соң Казаннан С. Баттал исеменә җавап килде. Кыскача эчтәлеге түбәндәгечә иде:

«Шагыйрь Г. Тукайның рәсми расланган, дәреслекләрдә басылган тулы биографиясе бар. Кайчан кая барганы, кайда күпме торганы, кемнәр белән очрашуы,ниләр сөйләшүе—барысы да замандашларының истәлекләреннән билгеле. Троицк шәһәре янында казакъ даласында булуын раслый торган бернинди дә чыганак юк.

Аннары, заманында Тукай шигырьләренә охшатып язучы дилетантлар, халык арасында хәтта «Мин—Тукай» дип йөрүче самозванецлар да булуы билгеле. Сезгә бу вакыйганы сөйләүче ханым да әнә шундый махинаторга тарыган булса кирәк. Шунлыктан сезнең бу язганнарыгызны чын реаль факт дип кабул итеп булмый».

Әмма аңа карап Фәгыйлә апайның авыр тормыш юлы, Г. Тукай турындагы хатирәләре минем башымнан чыкмады, һаман хәтердә сакланып, миемне өзлексез «бораулый» килде. Ул хакта мин илле сигезенче елның башында Мәскәүдә нәшрият хезмәткәрләре курсында укыганда шагыйрь Әхмәт Фәйзигә дә сөйләдем.

Аның «Тукай» романының икенче томын яза башлаган вакыты иде. Ул мине игътибар белән тыңлады, сораштырды. Тукай Троицк шәһәренә мулла Рахманкулов чакыруы буенча барган, шул хакта ул үзе газиттә язып та чыккан, ә Казан кызыл авызлары шул мулланы Тукайга ярдәмче итеп күрергә теләмәгәннәр булса кирәк, диде.

Берничә көннән тагын очрашып сөйләшкәндә, Әхмәт абый миңа: «Ул әби исән вакытта тизрәк, икәү бергә Владивостокка барып, аны ничек тә күрергә, жентекләп, сөйләтергә кирәк. Юл расходларын Язучылар союзы түләмәсә, үзем түләрмен. Бу миңа бик мөһим»,—диде.

Үкенечкә каршы, бу ният гамәлгә ашмый калды. Әхмәт абый тиздән каты авырып китте һәм, жәй уртасында Казанга кайтып, Аккош күлендәге Язучылар дачасында вафат булды.

Хәер, Фәгыйлә апай белән очрашуны Салих абый Баттал да онытмаган, ерак Владивостоктан Язучылар союзы идарәсенә җибәргән хат караламасын машинкада бастырып алган булып чыкты, шуның бер нөсхәсен миңа да бирде. Ул нөсхәне миннән шагыйрь Әхмәт Исхак алып торды. Чөнки аның либретто өстендә эшләгән, композитор Әнвәр Бакиров белән бергә Тукайга багышлы опера язып йөргән чагы иде. Аларның ул эшләре никтер барып чыкмады. Әхмәт абый алган нәрсәне кире кайтарып бирмичә үлеп китте.

Салих абый Батталның исә—тар милләтчелек карашы өчен дип, партиядән чыгарылган бик кәефсез вакыты иде. Шунлыктан булса кирәк, ул бу эштә бүтән катнашырга кыймады шикелле.

Мәгълүм ки, Тукайга азмы-күпме ярдәме тигән замандашларын ихтирам белән искә алабыз. Ә кара реакция вакытында авыру шагыйрьне курыкмыйча казакъ даласына кымыз белән дәваланырга чакырып китергән, аңа уңай шартлар тудырган, аның иминлеге турында кайгыырткан Рахманкулов Габдрахманны әдәбиятчылар арасында жылы сүз белән телгә алучы да юк. Хәтта, киресенчә, яманлаучылар да булган. Г. Ибраһимов, мәсәлән, үзенең егерме бишенче елны чыккан «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» дигән китабында башка иттифакчылар белән беррәттән, Рахманкуловка да «буржуаз милләтче» дигән мөһер сугып үтә.

Әнә шундый каршылыклы мөнәсәбәтләргә карамастан, ерак Тын океан буенда Фәгыйлә апай белән очрашу минем күңелемдә һәмишә онытылмас якты хатирә булып саклана. Мин ул хакта Г. Тукай истәлегенә багышлы кичәләрдә, әдәбият сөючеләр белән очрашуларда еш сөйлим, кешеләрнең кызыксынып тыңлаганнарын күрәм. Бөек шагыйребез Габдулла Тукайның

әлегә тикле беркайда яктыртылмаган соңгы сәфәрен, замандашы Фәгыйлә апай сөйләгәннәрне һәм аның үз башыннан узган гыйбрәтле мажараларны кин катлау укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

*Автор*

Беренче мәртәбә күргәндә Фәгыйлә апай инде кырыклардан узган, әмма үзе әле һаман яшьләрчә төз гәүдәле, җинел сөякле, тиз аралашучан, ачык чырайлы бер ханым иде. Тик шунысы сәер, бистә мөселманнары аны үзара никтер Алтын балдаклы абыстай дип йөртәләр иде.

Абыстай дип гадәттә мулла-мөәзин хатыннарына, балалар укытучы мөгаллимәләргә генә ихтирам белән, олылап мөрәҗәгать итә торган булганнар. Ә хәзер, революциядән соң бу сүзләр ничектер гайре табигый яңгырый. Фәгыйлә апайдан астыртын көлү, кимсетү кебек тоела. Болар гына җитмәгән, чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, хәтта бармагына алтын балдак киеп йөрүен гайбәт итүчеләр дә җитәрлек иде. Минемчә, монда ниндидер аңлашылмаучылык, үзенә бертөрле гаделсезлек бардыр сыман.

Бу хакта мин Фәгыйлә апайның үзенең дә кылларын тартып караган идем. Әмма ул мона әллә ни игътибар итмәде бугай, берни дә әйтмәде. Үз уйларына чумган хәлдә сүзсез генә йөри бирде.

Шулай да өйдә үзе генә калган беркөнне, самавыр янында тәмле пәрәмәч белән чәй эчеп утырганда, ул төрле сүз арасында көтмәгәндә нидер хәтерләгәндәй:

—Бүген иртән синең теге соравың башыма килде дә, кинәт аптырап калдым әле,—дип әйтеп куйды.—Минем баштан үткәннәрне көн-төн өзлексез сөйләсәң дә очына чыгарлык түгел. Аларны искә төшерсәм, бәхетсез яшүсмер елларым, авыру Тукайның бездә булган көннәре, аннары менә бу алтын балдак аркасында күргән бәла-казаларым, эзәрлекләү, җәберләүләр—һәммәсе дә кабат баштан кичергән кебек күз алдына килеп баса. Йөрәгем әрни, сулышым кысыла башлый.

Фәгыйлә апай дулкынланудан тынып калды. Савыт-сабаны җыештыргач, өстәл янына килеп утырып, гадәтенчә ашыкмыйча сөйләвен дәвам итте.

—Мин мөгаллимнәр гаиләсендә туып-үстем, уникe яшькә хәтле шунда үзебездә укыдым. Безнең Пүчинкәдә мәктәп булмаганлыктан, әти фатирыбызның ал ягында төшкә хәтле малайларны, әнием өйләдән соң кызларны укытты. Шуның өстенә бушрак вакытларда сабак биреп, алар мине дә киләчәктә мөгаллимәлеккә имтихан тотарга әзерләргә тырышалар иде. Тормышыбыз бик муллдан булмаса да, болай әйбәт кенә яши идек. Икесе дә яраткан эшләреннән канәгать. Аларның бердәнбер иркә тае мин дә бәхетле идем.

Гөнаһ шомлыгына каршы, эпидемия вакытында, алар икесе дә бер атна эчендә ваба чиреннән вафат булды. Унөч яшемдә—япа-ялгыз башым ятим калдым. Кытлык вакыт. Ачтан үлмәс өчен еш кына хәер сорашып җан асрарга, кайда туры килсә, шунда кунарга туры килә иде.

Шундый авыр көннәрнең берсендә, күрше авыл базарында мәрхүм әтидән калган хәтфә каләпүшне биш кадак арыш онына алмаштырып, көзге пычрак юлдан кайтып барганда мине җигүле тимеркүк ат узып китте. Тарантаста байларча киенгән өлкән яшьләрдәге ирле-хатынлы бер пар утыралар иде. Тышкы кыяфәтләре белән безнең мөселман әһеленә охшаганнар—йөзләрендә иман нуры бар шикелле. Миңа таба карый-карый болар нәрсәдер сөйләшәләр кебек тоелды.

«Шат яратса да, җиһанга, ят яраткан Раббысы»,—дип, авыз эчемнән көйләп бара идем. Ирексездән:—«И, Раббым, дөньяда нинди рәхәттә һәм шул ук вакытта минемише коточкыч михнәттә яшәүче бәхетсез адәмнәрең бар»,—дип нәүмизләнеп артларыннан карап калдым.

Мәгәр алар ерак китмичә никтер туктадылар. Кызгандылар бугай, чакырып алып, мине тарантаска утырттылар. Сораша торгач, абзый кеше минем мәрхүм әтиемне якыннан белүче булып чыкты.

—Әйбәт мөгаллим, милләтпәрвәр мөселман иде, авыр туфрагы җиңел, урыны җәннәттә булсын, ә син игелекле тырыш кыз булып үс,—дип кызганды һәм, садака итеп, бер тәңкәлек көмеш акча бирде. Ә карчыгы, авыз эченнән дога укый-укый башымнан сыйпады.

Көнозын аягөсте йөреп бик алҗыган, ачыккан идем инде. Тарантас читенә сөялеп утырган җирдән оеп йокыга киткәнмен һәм үзебезнең Пүчинкә янында үткәнебезне сизми калганмын. Уянып күземне ачканда инде кичке эңгер куерып килә, ат тугарылган, тарантас ишек алдындагы ике катлы йорт болдыры каршында тора иде. Онлы капчыгымны култык астына кыстырып, тиз генә ычкынмакчы булсам да, хуҗабикә мине җибәрмәде. Вакыт соң инде, караңгы төште дип кунарга калдырды.

Тамак туйганчы ашаган-эчкәннән соң, өйнең аскы катында хезмәтче түти белән бер бүлмәдәге буш караватка урын җәйдереп, мине шунда төн кунарга калдырдылар.

Ә иртәгесен мин уянганда шактый өлкән яшьләрдәге хезмәтче хатын авыр сулый-сулый нидер эшләп йөри иде. Тиз генә торып, аңа булыша башладым. Икәү бергә өйалды тәрәзәләрен, идәнне юып чыгардык: өске катка менә торган баскычның паласын чыгарып кактык. Шулчак үз бүлмәсеннән чыккан хуҗабикә минем җиң сызганып эшләгәнемне күрү белән: «И, эш сөючән уңган кыз икәнсен»,—дип мактап алды. Хезмәтче хатын да мине мактап берничә җылы сүз әйтте.

Шуның унай тәэсире тиде бугай. Иртәнге аштан соң, онлы капчыгымны алып һәм барысы өчен дә рәхмәт әйтеп, Пүчинкәгә кайтырга кузгалгач, хуҗабикә юлыма аркылы төште:

—Фәгыйлә кызым, менә нәрсә: әгәр үзең разый булсаң, без сине асраугa алырга телибез. Ялгыз башың мохтаҗлыкта ач-ялангач җәфаланганчы, бездә тамагың тук, өстең бөтен булыр. Хезмәтче апаңа булышырсың. Икәү бергә шул бүлмәдә торырсыз. Берничә елдан, балигъ булгач, күз күрер, нишлисен үзең хәл итәрсең.

Ярдәмчел хуҗабикәнең бу киңәшенә шундук күнеп, мин аларда асрау кыз булып калдым һәм башка хезмәтчеләр белән беррәттән һәртөрле йорт эшләрендә катнашып, моңарчы күрмәгән-белмәгән бүтән мохиттә яши башладым.

Шәһәрдән егерме чакрым читтә, кечерәк кенә чишмәле матур үзәнлектә урнашкан бу утар—безнең хуҗабыз Әхмәтҗан агай биләмәсе. Ул—шәһәр мулласы белән кәсептәш. Хәзрәт үзе гел дин, мәчет, мәдрәсә, мөтәвәллият мәшәкатьләренә чумганлыктан, ширкәт эшләре белән күбрәк Әхмәтҗан бай шөгыльләнә икән. Хуҗабикәбез Әсмабану абыстайның сәламәтлеге шәптән түгел икән—тыны бетүдән зарлана. Үзе еш кына ун яшендә үк йөрәк авыруыннан гүр иясе булган мәрхүм кызын сагынып искә ала. Шуңа күрә булса кирәк, ул мине үз баласы кебек якын итә, Фәгыйлә кызым дип кенә йөртә. Кайчандыр ерак шәһәрдә укучы улыннан хат килсә, күзләрем начар күрә дип кабат-кабат миннән укыта торган иде...

* * *

... Кече яшьтән хезмәт эчендә кайнап, өй мәшәкатьләрендә әнкәсенә булышып үскән Фәгыйлә яңа урында да кушканны көтмичә, һәр эшне үзе белеп, җиренә җиткереп башкара. Һәрчак таләпчән, әмма киң күңелле, гадел Әсмабану абыстайның ана булган ышанычын акларга тырыша. Авыр югалту кайгы-хәсрәтеннән акрынлап арына төшкәч, чандыр кызчык аш-суга мул тормышта яшәп, озакламыйча зифа буйлы, төскә-биткә чибәрмәләем кыз булып үсеп житлегә. Эштән бушаган араларда Әхмәтҗан байның китапханәсендәге әдәбиятны, газета-журналларны караштыргаларга да вакыт таба. Ул бигрәк тә Габдулла Тукай әсәрләрен яратып укый, аның күп кенә

шигырьләрен бер укудан күнеленә сендереп, эш арасында авыз эченнән көйләп йөри.

Фәгыйлә монда тора башлауга тугыз ай чамасы үткәндер шәт. Җәй башында Әхмәтҗан байның ерак шәһәрдә укучы улыннан хат килеп төшә, тиздән аның җәйге каникулга ялга кайтачагы мәгълүм була. Шуның өстенә Әхмәтҗан агай тагын бер көтелмәгән хәбәр алып кайта: шәһәр мулласы Габдрахман хәзрәткә Казаннан бер авыру мөгаллим килгән, тиздән шул монда кымыз эчеп дәваланырга рәхим итәчәк ди. Габдрахман хәзрәт аны мөмкин кадәр кадерләп тәрбияләүне, савыктыру өчен кулдан килгәннең барысын да эшләүне бик үтенгән. Тырышыгыз, савыктырсагыз, савaплы булырсыз дип кат-кат әйткән.

Шул сөйләшүдән соң утарда кадерле кунакларны каршыларга ашыгыч рәвештә хәзерлек эшләре башланып китә. Хәер, шәкерт егетнең бүлмәсенә әллә ни кул-көч түгәсе юк, хуҗасы әлерәк кенә чыгып киткән кебек, һәрнәрсә үз урынында, тәртиптә. Ә аның күршесен, авыру мөгаллимгә дигән буш бүлмәне рәткә кертү өчен Әсмабану абыстай белән Фәгыйләгә шактый тырышырга, көнозын маташырга туры килде. Бигрәк тә тәбәнәк мичкәдәге кыяклы фикус һәм түшәмгә сузылган үрмәле гөлне әйбәтрәк итеп урнаштыра алмыйча аптырап беттеләр.

Хәер, бик ашыкмаска да мөмкин булган икән. Кунаклар өч көн үткәч кенә кайтып төштеләр. Алар шәһәрдә Габдрахман хәзрәт өендә очрашып танышканнар, шуның кучеры аларны утарга китереп куйган. Шәкерт егет әтисе кебек буйга сузан булса да, төскә-биткә күбрәк әнисенә тартым. Почык борынлы, очлы иякле, житез хәрәкәтле. Әнисе болдырда күренүгә аны каршы барып кочаклады, маңгаеннан үбеп, хәл-әхвәлен сорашты. Аннары ике куллап әтисе белән күреште.

Аның белән килгән мөгаллим кунак уртачадан тәбәнәгрәк буйлы, чандыр гәүдәле.Сәламәтлеге шәптән түгеллеге күренеп тора, яңаклары суырылып кергән. Ул кара тужурка, тар читле соры эшләпә кигән. Какча йөзле булгангамы, тышкы кыяфәте белән бераз яшүсмер шәкерткә охшаган иде. Әхмәтҗан абзый аны олылап каршылаганнан соң, хәл-әхвәл сораштыра-сораштыра өске катка үз бүлмәсенә озата менде.

Кунаклар юлдан соң юынып, өс-башларын алмаштырып, аш бүлмәсендә табынга җыелгач та, мөгаллим гел ихтирам үзәгендә булды. Әле берсе, әле икенчесе төрле сорау белән аңа мөрәҗәгать итә. Әсмабану абыйстай, барысыннан бигрәк тырышып, аны сыйлый. Әхмәтҗан бай да, улы шәкерт тә аңа Габдулла әфәнде дип эндәшәләр. Фәгыйләгә бу бик сәер тоела. Әдәбият әһелләре, китаплар, газета, журнал исемнәре еш телгә алынгач кына бу мөгаллим дигән кешенең яраткан шагыйре Габдулла Тукай икәнен ниһаять аңлап ала һәм хәйран кала.

Әхмәтҗан бай белән Габдулла әфәнде балконга чыккан арада кунак шәкерт әнисенә һәм Фәгыйләгә сер итеп кенә сөйләгәндәй: «Бу кунакның хатын-кыздан читләшүчән бер сәер гадәте бар. Аның тирәсендә күп чуалмаска, юк-бар сораулар белән борчымаска тырышыгыз»,—дип искәртү ясый. Шуның өстенә аның «мөгаллим» дип аталуы да очраклы түгел икән. Чөнки соңгы вакытта аның исеме тирәсендә кара болытлар куерган, күзәтүләр башланган. Шуңа күрә, кымыз эчеп дәвалану форсаты белән, ул рәсми һәм яшерен шымчылар күзеннән югалып торырга мәҗбүр булган. Шәһәр мулласы Габдрахман хәзрәт, шул максат белән, аны бирегә аулаграк тарафка чакырып китергән. Гомумән ул турыда күп сөйләшмәү хәерле. Берәрсе кызыксынып сораштырса-нитсә, кымыз эчеп дәваланырга килгән авыру мөгаллим дип әйтергә кисәтеп куя.

* * *

Әхмәтҗан утарыннан дүрт чакрым чамасы читтә, иркен далада, берничә казакъ Габдрахман хәзрәтнең бияләрен савып, терлекләрен көтеп яши. Саф һавада күбрәк булсын, кымызның яңа өлгергәнен эчсен, итнең яңа

суелганын ашасын дип шунда, казакъларның киез өйләре янында, хәзрәт кушуы буенча, Тукайга да бер чатыр корып куелган. Монда килеп, көтүче казакъларда кунак булган шагыйрь барысыннан канәгать, күтәренке күңел белән берничә шаян җыру язып ташлый:

> Валлаһи, и валлаһи, и валлаһи,
> Бәхете барлар кырда җәйли, валлаһи!
>
> Ак күмәч берлән ашарлык саф һава;
> Җир яшел, кошлар да сайрый, валлаһи!
>
> Ак болыт, күчмә казакълардай күчеп,
> Бер куанычлык күкне сайлый, валлаһи!
>
> Аз гына бер җил исү берлән, үлән
> Җирдә уйный кайный-кайный, валлаһи!

Кичкырын Тукай утарга кайтып кергәндә хуҗалар өстәл өстендә җырлап торган җиз самавыр янында чәй эчеп утыралар иде.

Әсмабану аңа чәй ясап бирә, чәшкесенә лимон кисеп сала, җиләк-җимешне якынрак этәреп куя. Кунак бераз чәй эчеп сусавын баскач, Әхмәтҗан бай үзе сүз башлый:

—Габдулла әфәнде, сезгә бер соравым бар. Әгәр урынсыз санасагыз, җавап бирмәскә мөмкин. Исемдә чакта, онытылганчы сорап калырга кирәк дип саныйм. Кыскасы, зур талантлы мәшһүр Галимҗан Ибраһимовның сезгә тискәре карашы, тырнак астыннан кер эзләп, урынлы-урынсызга мәкаләләр чыгаруы миңа һич аңлашылмый. Моның сәбәбе нәрсәдә?

Тукай сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куя, чәшке төбендә калган чәй йотымы белән иреннәрен чылатып ала да:

—Мондый сорауны миңа еш бирәләр, моның белән күпләр кызыксына,—дип сөйләп китә.—Бу күңелсез сүзне озынга сузмас өчен, җавабым күптән әзер. Галимҗан әфәнденең серкәсе су күтәрми, ул үзен мактаган, тәлинкә тоткан иярченнәрне ярата, әз генә тәнкыйтьләүчеләрне дә өнәми, читкә кага. Аның минем бакчага таш атуы да башлыча шуннан булса кирәк.

Шагыйрьнең күп шигырьләрен яттан белгән Фәгыйлә, үзен-үзе инандырырга теләгәндәй, эчтән кабатлый:

> Кузгатмакчы булсаң халык күңелләрен,
> Тибрәтмәкче булсаң иң нечкә кылларын,
> Көйләү тиеш, әлбәт, ачы хәсрәт көен,
> Кирәк түгел мәгънәсе юк көлке, уен.

Габдулла Тукай килгәннән бирле кичләрен мондый сөйләшүләр, соңгы вакытта әдәбият, дин әһелләрен әзерлекләүләр көчәюе турында фикер алышулар еш булгалый. Шул арада ул өлкәннәрнең сөйләгәнен дә колак салып, игътибар белән тыңлый, дөнья хәлләрен ишетә һәм Тукай шигырьләренең эчтәлеген, мәгънәсен тагы да тирәнтенрәк ачкандай була.

* * *

Утарга көтмәгәндә тагын ике кунак: шәһәрдән бер татар баеның буй җиткән улы белән кычыткан чыпчыгы кебек тиктормас кызы килеп төште. Икесе дә Әхмәтҗан улының кечкенәдән бергә уйнап үскән дусты, икесе дә кайдадыр укыйлар; егет юрист булырга, сеңлесе, маена чыдый алмаудан, ниндидер лекцияләр тыңлап йөри икән. Бәхтиярның каникулга кайтканын ишеткәч тә, үзләре әйтмешли, дуслык визиты белән рәхим иткәннәр.

Әтиләре Әхмәтҗанның ширкәтчесе булганлыктан, яшь кунаклар хөрмәтенә җинел кулдан тиз генә табын әзерләделәр. Өлкән хуҗалар үзләре катнашмаса да, аш-су шактый мулдан булды. Иш янына—куш, дигәндәй, Әсмабану абыстай кунаклар күңелен күрү өчен кирәк санап, Фәгыйләгә дә рәтлерәк киенеп, табында катнашырга һәм хезмәт күрсәтергә кушты.

Кунак егетнең сул күз өстендә никтер кашы юк. Шуны яшерү өченме, тузгак җирән чәче маңгаена салынып төшкән. Күренеп тора, ул бераз кызмача. Табындашлар үрнәгендә туган телдә сөйләшергә керешеп караса да, татар һәм «урыс сүзләрен бергә бутаудан»: кушать итәбез, гулять итәбез, кебек тозсыз кабатлаулардан ары китә алмады. Моны шундук абайлап өлгергән Бәхтияр кинаяле шаярту белән җыру сузды:

> Без алай да итәбез,
> Без болай да итәбез.
> Без итә дип сез итмәгез,
> Без заманча итәбез.

Ә сеңлесе абыйсы кебек әштер-өштер генә киенмәгән. Кыска җинле, ачык изүле ефәк блузка астыннан яртылай шәрә күкрәк йомрысы, тулы беләкләре юри күрсәтергә куйган төсле күзгә бәрелеп тора. Бармакларына күп итеп алтын, көмеш йөзек-балдак кигән. Сөрмәле күзләрен Бәхтиярдан һич алмый. Аз гына да тартынмыйча, гел шуның янында төчеләнә, әледән-әле беләкләренә кагылып, үзенә каратырга көчәнә. Моны күреп торган Фәгыйлә Тукайның дүрт кенә юллык көлдергеч шигырен хәтерләп, авыз эченнән кабатлый:

> Ундыр җаный бармагы,
> Уникедер балдагы,
> Тагын берне кияр иде,
> Инде урын калмады.

Тукай табыннан ялыкты бугай, беравык утырганнан соң, сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтеп, акрын гына үз бүлмәсенә чыгып китте. Бәхтияр шәкерт ябышкак кунак кыздан арына алмый. Юрист Куртай Фәгыйлә янында төчеләнә, татар, урыс сүзләрен бутый-бутый тозсыз мәзәкләр сөйләүдән туктамый. Күзләре белән эзләнеп өстәлдә хәмерле шешә таба алмагач:

—Юк, болай гына булмый, пить хочу,—дип, күрше бүлмәгә чыга да саквояж белән ике шешә шампан хәмере алып керә.—Сезнең өйдә сухой закон бит, настроение күтәрә торган напиток булмый. Поэтому специально үзебез алып килдек. Әйдәгез, картлар күрмәгәндә бераз кайфовать итеп алыйк.

Фәгыйләгә гел чыгып-кереп йөрергә туры килә. Табынга утырса, тагын Куртай килеп бәйләнә, мәгънәсез мәзәкләр белән йөдәтә башлый.

Кичкырын ишек алдында саубуллашканда коляскасына утыргач та һаман телен тыя алмыйча:

—Бахти дус, секрет булмаса, әйт әле, мондый соблазнитьльный прислуганы атаң табып бирдеме, әллә үзең таптыңмы,—диде әшәке көлеп.—Аны кара, берәрсе урлап китмәсен. Синең урыныңда булсам, мин моны кулдан ычкындырмас идем.

Бәхтиярның ачуы йөзенә чыкты, әдәпсезлеге өчен оялгандай: кунакны тыярга ашыкты һәм капканы ачты.

—Тсс, алай ярамый, зинһар, тозсызланма...

Кичке эңгердә адашмагайлары дип, Бәхтияр белән Фәгыйлә җилбәзәк кунакларны ярты чакрымдагы олы юл чатына хәтле озата чыктылар. Бәхтиярга елышып утырган чытык кызый һәмишә төчеләнеп бара.

Юл чатында тарантастан төшеп калгач, Бәхтияр белән Фәгыйлә кирегә чокыр-чакырлы тар сукмак буйлап турыдан гына кайттылар. Әлегә тикле аларның болай аулакта икәү генә калганнары булмагангамы, кинәт уңайсыз тынлык туа. Бераз дәшми барганнан соң, сүз юктан сүз булсын дигәндәй, Фәгыйлә кеткелдәп көлеп җибәрә:

—Һи-һи-һи-и шул тикле дә тигәнәк кебек ябышкак булыр икән. Теге кунак кыздан көлүем, гел сезнең янда сайрап кына торды.

Бәхтияр бу шаяртуны өнәмәгәндәй:

—Ә абыйсы синнән күзен алмады, нинди генә ширбәтле сүзләр әйтмәде,—дип, борын астыннан мыгырдап куйды.

Менә аларга сай гына коры ерганак аша үтәргә туры килә. Бәхтияр асрау кызны кулыннан тотып, каршы яктагы тәбәнәк текә ярдан менәргә ярдәм итә. Караңгыда чокыр-чакырлы тар сукмакның калган өлешен дә алар кулга-кул тотынып, бер-берсенең уч җылысын тоеп, күңелле сөйләшеп кайттылар.

* * *

Атна-ун көн ял иткәннән соң, Әхмәтҗан бай варис улын, рессорлы тарантаска утыртып, шәһәрдәге, бистәләрдәге кибетләрен, тире эшкәртү, тун тектерү, кымыз әчетү цехларын күрсәтергә, компаньоннары, урыннарда алыш-биреш итүче агентлары белән таныштырырга алып чыгып китте. Иртәдән кичкә хәтле бәйрәм кебек гөрләп торган утарда тормыш тынып калгандай булды, нәрсәдер җитмәгән сыман тоелды.

Тукай көнозын кымызчы казакълар янында, яки үз бүлмәсендә язу-сызу, газета-журналлар уку белән мәшгуль. Кайвакытта ул акрын гына ишекле-түрле атлап йөри, яисә моңлы көйгә ишетелер-ишетелмәс кенә сузып җырлый. Ара-тирә, хастасы кузгалган минутларда, буылып кых-кых йөткерә башлый. Коридордан үткәндә-барганда моны ишеткән Фәгыйлә аның ишеге янында ирексездән туктап кызгана, балаларча беркатлылык белән шагыйрьгә ничек тә булса ярдәм итәсе, авыр уйларыннан азат итәсе килә. Вәләкин бу коры хыял гына, һичкайчан гамәлгә аша торган түгел. Аннан Габдулла әфәнде хатын-кыз белән ләчтит сатып утырырга яратмый, урынлы-урынсыз сораштырулар белән комачауламагыз, дип, Әхмәтҗан бай үзе каты кисәтеп куйган иде бит.

Мәгәр аның шагыйрь белән якынрак танышуы һич уйламаганча-көтмәгәнчә килеп чыкты. Беркөнне иртән бүлмә җыештырырга кергән Фәгыйләгә шагыйрь үзе сүз кузгатып, аны-моны сораштыра башлады. Аның ятим калган асрау кыз икәнен белгәч, ихласлы кызгану белән:

—И-и, шулаймыни?!—дип гаҗәпләнде.—Алайса без икебез дә рәхимсез язмышның бәхетсез үгиләре икәнбез,—диде.—Хәер, мин моны беренче күрүдән үк төсмерләгән идем. Чөнки йөзендә барча ятимнәргә хас нәүмизлек галәмәте бар. Андый тамга үсеп буй җиткәч тә бетми, күңелдә сүнмичә пыскып, сызлаган теш кебек, һаман бәгырьне өзгәләп тора.

—Хак сүз, дөрес әйттегез, мин моны үземнән дә беләм,—диде Фәгыйлә дә җанланып.—Ялгыз калган минутларда мәрхүмә әнкәм күз алдыма килеп басканда, бигрәк тә кыен була, күзләр яшьләнә.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы,—

дип моңланып күңелемне бушатам.

Тукай колакларына ышанмагандай гаҗәпкә калды, кинәт зур булып ачылган күзләрен Фәгыйләгә төбәде:

—Чү, син бу шигырьне каян беләсең?

—Әти исән чагында без «Вакыт» газетасын алдыра идек, бу шигырьне шуннан укып беләм. Бик авыр минутларда аны күңелдән кабатласам, әнием белән сөйләшкәндәй бераз җиңеләеп калам.—Чак кына дәшми торганнан соң Фәгыйлә отыры җанланып китә:—Габдулла абый, мин сезне ничектер бүтәнчәрәк күз алдына китерә идем бит. «Су анасы» әкиятен укыганда кеше әйберен чәлдерүче шук малай кебек булсагыз, «Шүрәле»дә кыргый урман сарыгын төп башына утырткан баһадир егеткә охшата идем. Сез аларны чынлап булган хәл итеп, үз башыгыздан кичергән кебек, килештереп язгансыз.

—Күрәм, кызый, син үзең дә кибәк башка охшамаган, төшеп калганнардан түгел бугай. Яшьли әдәбият укырга ияраткансың, укыганың-ның мәгънәсен аңларга тырышкансың, уйлана, хыяллана беләсең. Бу исә—бик мөһим, адәм баласына гаять кирәкле шәйдер.

Җылы сүзләре белән ятим кызның күңелен күтәрсә дә, Тукайның кәефе юк, чырае төссез. Әледән-әле кыһ-кыһ ютәлли. Авыруын сиздер-

мәскә тырышуы күренеп тора. Йөткерүе басылмаса, акланырга теләгән сыман: «Юлда килгәндә бераз жил тиде бугай, шул йөткертә»,—дип, камзул кесәсеннән дару алып каба.

Аларның мондый очрашу, әңгәмәләре алга таба да еш булгалый. Берәр эш белән бүлмәсенә асрау кыз керсә, шундук Тукайның йөзе яктырып китә, каләмен куеп, хәл-әхвәл сораша, сөйләштерә, тапкыр шаярту ишетсә, рәхәтләнеп көлә.

Кәефе әйбәтрәк бермәлне, кичке чәй янында, күнелле генә гәп корып утырганда, Габдулла әфәнде үзе дә:

—Инде күптән, туган авылым Кушлавычка кайткач булган хәл,—дип, мәзәк сөйләргә тотынды.—Шунда тегермәнче улы, шәһәрдә укучы егет белән таныштым, ара-тирә аларга баргалый башладым. Эш юктан эш булсын дигәндәй, бу егет мине ауга, бытбылдык атарга чыгарга үгетли башлады. Гомеремдә бер тапкыр мылтык тотканым булмаса да бик кыстагач, ризалык бирдем. Икебез дә мылтык һәм бытбылдык алдый торган сыбызгы белән коралландык. Мина ата бытбылдык сыбызгысы бирде ул, ә үзенә ананыкын алды.

Басуда дугалы ат күмелерлек булып үскән куе арышның өлгереп килгән вакыты иде. Авылдан чыгып беравык баргач, юл икегә аерыла. Тегермәнче улы мина унга китәргә кушты, үзе сулга борылырга булды. Бытбылдык атсак-аталмасак та, кичкырын шушында очрашып, бергә кайтырга сүз куештык.

Ярты чакрым чамасы барганнан соң, кулымдагы ата бытбылдык сыбызгысын сузып-сузып сызгырттым да колак салып тыңлауга күчтем.

Озак көтәргә туры килмәде, мина жавап кайтаргандай, каяндыр ана бытбылдык сайраганы ишетелде. Сыбызгымны сызгырта-сызгырта арыш арасыннан шул тарафка юнәлдем. Ишетәм—ана бытбылдык та мина таба якыная. Әһә, бу мескен кош минем сабызгыга алдана, мәйтәм. Ә үзем, як-якка карана-карана сак кына атлап, һаман барам да барам.

Чү, каршымда якында гына нәрсәдер кыштырдаган кебек булды, каралжым шәүлә күренде. Әһә, бытбылдык шул икән дип, мылтыгымны төзәп атып жибәрсәм, куе арыш арасыннан... тегермәнче улы атылып килеп чыкты. Мескеннең куркудан коты алынган, мылтыгы мина төбәлгән иде.

Бермәл, күзгә-күз шаккатып карап торганнан соң, исән калу шатлыгыннан кычкырып көлеп жибәрдек һәм юл буе бер-беребезне шаяртышып кайттык. Шулай да адәм көлкесенә калмас өчен, без бу вакыйганы беркемгә дә сөйләмәскә дип сүз куешкан идек...

Әммә Тукайның андый көр күнеле сүзчән көннәре сирәк була. Ул әледән-әле буылып-буылып йөткерә. Күрсәтергә теләмәгән сыман, читкә борылып, сәдәп хәтле генә ак дару йота. Ютәле басылып торган чакларда да күнеле күтәрелми, ахрысы. Бүлмәсендә үзе генә калды исә, гел бер үк шигырен көйли:

> Яшь вакытта яшьнәдем, көчле вакытта күкрәдем,
> Яшьнәмим дә, күкрәмим дә, утсыз инде күкрәгем!

Асрау кыз Фәгыйлә аның өчен үлеп тора: кадерләп кайгырта, мунча кергән саен керен юып үтүкли, урын-жирен, бит сөлгеләрен алыштыра. Кымызын вакытында эчертеп, тәмлерәк ашатып, аны үзенчә тизрәк савыктырырга, тазартырга тырыша. Әммә ике айга якын дәвалануга карамастан, шагыйрьнең хәле жиңеләйми, савыгу сизелми...

Нәкъ шул көннәрдә Әсмабану абыстайны дәваларга шәһәрдән чакыртып китерелгән врачка бер уңайдан Тукайны да күрсәткәннәр иде. Мәгәр ул тынычландырырлык берни дә әйтә алмады. Авыруны игътибар белән тыңлап караганнан соң, ютәлдән эчәргә дип аспирин гына биреп калдырды. Бары тик ишегалдына озата чыккан Әхмәтжан байның үзенә генә, бик кичегеп кузгалгансыз, элегрәк кайгыртырга кирәк иде, ашыгыч рәвештә диспансерга салырга кирәк, дип әйтеп киткән.

Бу хакта үзенә һични әйтмәсәләр дә, Тукай барысын да сизә һәм

әлләни игътибар итми шикелле. Хастаханәләр, дарулар турында андыймондый сүз чыкса, гадәтенчә игътибарсызлык белән: «Врачларга күренмәвең хәерле, алар еш кына булмаган сырхауны да һичшиксез уйлап чыгаргалыйлар,—дип шаяртырга ярата.—Аларга ышанып, кайчак авыртмаган әгъзаң да сызлый сыман, чынлап сырхауга сабышасың».

Ә үзе, бүлмәсендә ялгыз калган чакларны, бу арада монсу көйгә сузып-сузып һаман бер җырны кабатлый:

Быелгы җәйләр үтәрме,
Киләсе җәйләр җитәрме?
Киләсе җәй рәхәтен
Ходай насыйп итәрме?..

* * *

Нәкъ Тукай врачлардан шаяртып көлгәнчә, рас килеп чыкты: әлегә тикле азмы-күпме ярыйсы гына кыймылдаган Әсмабану абыстай табибка күренгәннән соң, тыны бетүдән ешрак зарлана, хәлсезләнә башлады. Шуңа күрә өй эшләренә бик кысылмый, вакытын күбрәк намаз укып, тәсбих тартып үткәрә. Эштән иртәрәк бушаган кичләрне Фәгыйләне дә үзе белән бергә намаз укырга чакыра. Атна көннәрне, ахшам намазыннан соң, аңа кулдан күчереп язылган «Йосыф китабы»н яки берәр мөнәҗәтне көйләп укыта.

Монда килүенә ике ай чамасы үткәч, Тукай аулак тормыштан зарыга башлады шикелле. Сүз арасында Казанны, китап нәшриятларын, газетажурнал редакцияләрен, әдәбият әһелләрен ешрак телгә алгалый, озакламыйча кайтып китү, юлга әзерләнү турында сөйләнә. Шулай да артык куырмый, тагын атна-ун көн сабыр итәргә, тиздән Бәхтиярнең каникулы беткәч, аның белән бергә китәргә исәп тота.

Чынлыкта исә, вакыйгалар кинәт һич тә көтелмәгән борылыш ала. Һич көтмәгәндә, уйламаганда утарга Троицк шәһәре мулласы, Тукайны монда кымыз белән дәваланырга чакырып китергән Габдрахман хәзрәт үзе рәхим итә. Бик ашыккан ахрысы,юртак шабыр тиргә баткан иде.

Ишегалдында тарантастан төшеп хуҗалар белән исәнләшкәндә әйтүенә караганда, шунысы мәгълүм булды—Габдрахман хәзрәт далада терлек көтүче казакълар янында булган, шуннан кайтышлый берничә минутка авыру шагыйрьнең хәлен белешергә генә кергән икән. Шунлыктан атын туарырга да рөхсәт итмәде.

—Бәйдә килеш кенә бераз тын алсын, суынсын. Вакытым тар, юл уңаеннан берничә минутка гына сугылдым,—дип сөйләшә-сөйләшә, алар өске катка, Тукай янына менеп киттеләр.

Әмма, аның берничә минутка гына дигәне бик тиз үтеп, Әсмабану абыстай кушуы буенча, Фәгыйлә лимонлы чәй әзерләп керткәндә саубуллашыр чак житкән була.

—Менә шуңа күрә дә бу четерекле йомышны беркемгә дә ышанмыйча, үзем килеп ирештерергә булдым,—дип хөрмәтле хәзрәтнең әйткән азаккы сүзләре генә ишетелеп кала.—Ярый, мин кузгалам. Икенде намазына кайтып житмәсәм, кайда, нинди йомыш белән йөргән, дип төпченә башлаулары бар. Хәзерге шөбһәле заманда дөнья хөсетле затлар белән тулы. Кешеләр бер-берсен күзәтеп, иснәнеп йөриләр, әләкләшергә генә beləләр. Ялган бәла-гайбәтләрдән тәңрем, берүк, үзең сакла!..

Хәзрәт китеп бару белән Тукай шундук кайтып китәргә җыена башлый. Әсмабану абыстай белән Фәгыйлә бөтен эшләрен ташлап, ашыгыч рәвештә юл кирәк-яракларын хәстәрли. Кичкырын, барысы бергә җыелып, хушлашып дигәндәй ашап-эчкәч, Тукай асрау кызны үз бүлмәсенә дәшеп, кәрҗиненнән юкарак кына китапчык ала да, беренче битенә тиз генә нәрсәдер язып Фәгыйләгә бирә:

—Менә сиңа бәләкәй генә бүләгем. Киләчәктә дә үзлегеннән укып, халкыбызга аң-белем таратучы мөгаллимә булып үс.

Шул ук кичне Бәхтияр Тукайны жинел тарантаска утыртып станциягә илтә һәм бәла-казасыз төнге поездга утыртып жибәрә.

Ә Габдрахман хәзрәтнең ни белән килгәнен Фәгыйлә Әсмабану абыстайның колактан-колакка гына бик яшерен сер итеп сөйләвеннән белде. Инде байтактан бирле шомлы хәбәр йөри, Лена дигән елга буендагы алтын прискаларында йөзләрчә баш күтәрүчеләрне атып үтергәннәр ди. Шуларның байтагы каты эзәрлекләүгә түзә алмыйча, бу тарафка качып килгән, имеш. Хәзер шәһәрдә аларны эзләү, аулау бара икән. Шикле тоелган һәр кешене кулга алып, бәйнә-бәйнә тикшерәләр, төпчеләр ди.

Былтыр кыш Казанга барган чакны Габдрахман хәзрәт тагын бер күңелсез хәбәр ишетеп кайткан булган. Әмма ул хакта беркемгә дә әйтмәгән генә. Властьлар Тукайга кырын карый башлаган ди, аны яшерен күзәтү астында тотулары хак икән. Шуңа күрә авыру шагыйрьне кымыз эчертеп дәвалау белән беррәттән, шымчылар, жәберләүчеләр күзеннән югалып торсын, жаны тынычлансын дип монда килергә чакырган булганнар.

Тукайны озатканнан соң ике атна үткәч, Бәхтиярның да каникулы бетеп, укырга китеп барды. Жәй башыннан бирле бәйрәм кебек күңелле тормыш, гөрләп торган утар, хужасыз торак кебек тынып калды. Иртәдән кичкә тикле аш-су пешерү, бүлмәләрне жыештыру, кымыз китертү белән мәш килгән, бер минут та буш вакыты булмаган Фәгыйләгә көннәр эчпошыргыч озын тоела башлады, ул хәзер күңелсез уйларга бирелә, моная.

Әхмәтжан бай һәрдаим сәфәрдә, кәсеп эшеннән бушамый. Әсмабану абыстайның исә хәле хөртиләнә бара, телдән бик зарланмаса да, ничектер, авыр сулый. Ә үзе ике сүзнен берендә исән-сау барып житте микән, хәбәре озак юк дип, һаман улы турында борчыла. Бүген иртән аннан хат килеп төшкәч кенә, рухы күтәрелде, көнозын шул хакта сөйләнеп йөрде. Бәхтияр хатның азагында Фәгыйләгә дә сәлам язган. Әсмабану моны асрау кызга берничә тапкыр әйтеп үтте, соңыннан түзмәде, хатның ул юлларын кызның үзенә дә укытты әле. Кичен улына хат язганда:

—Фәгыйлә кызым, әйдә, синнән дә сәлам жибәрик,—дип сөендерде.—Ул анда бер ялгызы бит, ямансудыр, безне сагынадыр. Әйдә, язийк, күңеле булсын, балакайның.

Егеттән хатлар атна саен килеп, һәркайсында Фәгыйләгә кайнар сәлам, сагыну сүзләре язылган була. Бераздан егет хатларны турыдан-туры кызның үзенә адреслап та жибәрә башлады. Соңгы хатында аны чын күңелдән яратуын, бик сагынуын һәм, нәкъ утардагы кебек, еракта да аның кул жылысын тоеп яшәвен әйткән иде.

Эшләр болайга киткәч, Фәгыйлә кинәт шиккә төшеп, мин аңа тиң түгел бит, яманатым чыгудан Ходай сакласын, дигәндәй, Бәхтиярның хатларына жавап язуны туктатты. Мондый очракта бередә калырга ярамавын ул яхшы аңлый һәм үзенең шик-шөбһәсен егетнең әнисенә дә житкерә. Төрле имеш-мимеш, гайбәт сатулар тудырмас өчен кызый хәзер үк моннан китәргә карар кыла.

—Әсмабану абыстай, мин сезне туган әнием кебек якын итәм, игелегегезне беркайчан да онытмам, шуңа күрә китәм дә. Башкача мөмкин түгел. Зинһар, мине дөрес аңлагыз, гаеп итмәгез.

Кыенсыну белән һәм бераз читләтеп-читләтебрәк әйтелгән бу хәбәрне Әсмабану абыстай башта аңына сыйдыра алмыйчарак аптырап торды. Ахыр чиктә төшенеп алгач, үз колакларына үзе ышанмагандай:

—Авызыннан жил алсын, тфү-тфү. Берүк, андый сүзне бүтән әйтә күрмә,—дип кызның авызын япты.—Үзең дә күрәсеңдер, Бәхтияр бозык түгел, тәүфикълы егет, сине үлеп ярата, сина өйләнергә өмет баглый. Әхмәтжан абыең белән мин дә үз кызыбыз кебек якын итәбез. Безгә килеп, малаема үзе тагылып йөрүче, яртылаш каферләшкән ташкурчактан Раббым үзе сакласын. Син минем үз кызым кебек якын киленем, картлык көнемдә караучыбыз булырсың. Һәркемнең киләчәк тормышы, кайда, кемнәр белән ничек яшисе үзе туганчы ук Ходай Тәгалә тарафыннан тәкъдирдә алдан ук язылган була дип әйтер иде безнең әти. Фәгыйлә кызым, синең

язмышың безнең гаилә, безнең улыбыз Бәхтияр белән бәйле. Мин моны гарәфә кич төшемдә күрдем, тормышта да шулай булсын диеп садака адарындым. Берүк фәрештәләрнең амин дигән сәгатенә туры килсен.

Фәгыйлә йомшак күңелле карчыкның бу кинәшен шундук кире кагарга җөрьәт итми. Башта уйлаганча көне-сәгате белән шундук чыгып китми, беразга түзәргә була. Шул арада абыстайның бу саташулы хыялы да, бәлкем, басылыр әле дип, тынычланырга тырыша.

Әмма ләкин Әсмабану абыстайның уйлары басылмый. Киресенчә, хәле хәл булуга карамастан, башында туган ниятен гамәлгә ашырырга ашыгуы сизелә. Бу эштә ул ире белән уртак фикердә булса кирәк. Иң әүвәл Фәгыйләне өйнең өске катына Тукайдан бушаган бүлмәгә күчертә, аңа ярдәмче итеп Пүчинкәдә бергә укыган Җәмилә исемле кызны ала. Кышкы каникул башлангач, Бәхтиярны чакыртып кайтаралар да озын-озакка сузмыйча яшьләрне кавыштырырга керешәләр. Шәригать кушканча булсын дип, шәһәрдән Габдрахман хәзрәтне китертеп никах укыталар, никахлашу галәмәте итеп, бер-берсенең бармагына алтын балдак киертәләр. Кайчандыр хәер сорашып нужа күргән, аннары асрау кыз булып хезмәт иткән Фәгыйлә бай егет хатынына әверелә.

Инде моңарчы ук бу гаиләдә үз кеше булган яшь килен яңа әхвәлгә тиз күнегә, әмма борын чөеп йөрми. Әсмабикә абыстайга элеккечә ихтирамлы булып кала, әни дип үлеп тора. Хезмәтчеләр һәм аш-су пешерүче авылдашы берәр ялгышлык җибәрсә дә, аларга каты бәрелмичә, аңлатып бирә, йә үзе эшләп күрсәтә.

* * *

Әсмабану абыстай, якыннарын артык интектермәскә теләгәндәй, Ходайдан сабырлык сорап, мыштым гына үлеп китте, үз бүлмәсендә җомга намазы укыганда намазлык өстендә җан тәслим кылды.

Газиз әнисе кебек якын булган, күп ярдәме тигән йомшак күңелле каенанасын югалту Фәгыйләгә бик авыр иде, ул үзен икенче тапкыр ятим калган кебек хис итте.

Бәла ялгыз йөрми дип тикмәгә әйтмәгәннәр, ахрысы. Әсма абыстайны югалту хәсрәте басылырга өлгермәде, язгы кояшлы көннәрнең берсендә яңа бәла—бөтен татар халкын тирән кайгыга салып, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның яшьли вафат булуы турында хәбәр килеп төште. Бу хакта барча газета-журналлар язып чыкты, илне матәмле моң-зар басты.

Бу кайгылы хәбәр Фәгыйләне кинәт миңрәтте, күз алларын томалады, Тукайны юк итеп һич аңына сыйдыра алмады ул. Әле кайчан гына ул монда булган, бергә сөйләшеп, бер табында ашап-эчеп утырганнар иде. Менә шушы бүлмәдә Фәгыйлә аны:

Татар бәхте өчен мин җан атармын:
Татар бит мин, үзем дә чын татармын,—

дип хәйран калдырган иде бит.

* * *

Тормыш мәңгелек агым кебек, бер генә минут та тукталып тормый. Эреле-ваклы көндәлек мәшәкатьләре, шатлык-кайгылары, туу һәм югалтулары белән үз юлыннан өзлексез дәвам итә.

Казакъ даласындагы ялгыз утарда да гомер үз җаена акрын гына бара бирә. Әхмәтҗан агай елдан-ел сизелерлек картая бара. Хуҗалык белән идарә итүне аз-азлап улына тапшыра, үзе күбрәк тирә-юньдәге авыл, мәчет, мәктәпләргә; мохтаҗ хәлфә-шәкертләргә ярдәм күрсәтү һәм биш вакыт намаз укудан бушамый. Бәхтияр укуын тәмамлап кайтуга җиң сызганып эш йөртә. Яшь бичәсе белән иркенләп чәйләшергә, күнелен күрергә вакыты да калмый.

Ерак Көнбатышта зур сугышлар башлангач, эшләр тагын да уныш-

лырак бара. Ширкәт житештергән жылы тун, киез итекләргә, хәтта кымызга да бәяләр көннән-көн күтәрелә тора. Күптән түгел генә пайга кергән алтын приискасы да ярыйсы гына эшли, хәтсез табыш бирә.

Хәзер үзе байбикә булып калган Фәгыйлә Әсмабану абыстайны еш искә төшерә, үз урынына асрау кыз булып килгән Җәмилә белән теге яки бу эш турында сөйләшкәндә: мәрхүмә абыстай менә болай итә, тегеләй итә иде, дип, еш телгә ала. Эштән буш вакытларда алар Габдулла Тукай шигырьләрен, Галимҗан Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән хикәясен, башка әдипләрнең әсәрләрен укыйлар. Ара-тирә Пүчинкә зиратына барып, күргән-белгән корткаларга сәдака биреп, әти-әниләре рухына дога кылдыралар, авылдашлары белән очрашалар, халыкнын елдан-ел бөлә барганын, коточкыч мохтажлыкта яшәгәнен күрәләр.

Утарга килә торган газета берсеннән-берсе шомлы хәбәрләр белән тулы. Шәһәрләрдә ачлыкка түзә алмаган меңнәрчә эшчеләр эш ташлап протест белдерә. Авыл халкы алпавыт урманын кисә. Фронтта солдатлар командирларына буйсынмый, күбесе коралын ташлап качып китә.

Ул да түгел, тагы да тетрәткечрәк яналык: Петербургта патшаны тәхеттән бәреп төшергәннәр, илдә власть әкренләп халык кулына күчә икән, дигән хәбәрләр йөри. Бөтен ил кырмыска оясына таяк тыккан кебек, кая карама—ыгы-зыгы. Шәһәрдә завод-фабрикалар да гади эшчеләр кулына күчә бара. Күп урыннарда алпавыт утарларын талаулар башланган. Хуҗалары кайсы качып котыла, кайсы каршылык күрсәтеп, бәрелештә вафат була.

Әнә шундый дәһшәтле көзге көннәрнең берсендә Фәгыйләнең шәһәргә киткән ире белән каенатасы да кире әйләнеп кайтмады, җир йоткан кебек икесе дә юкка чыкты. Шәһәргә барып эзләү, сораштырулар бернинди нәтиҗә бирми. Күргән-белгән танышларнын күбесе төрле якка таралып беткән. Шәһәрдәге йорт та, аскы каттагы кибет тә пран-заран китерелгән, сораштырырга дисәң хезмәтчеләр, приказчиклар да юк—барысы да кайсы кая китеп юк булган.

Тиздән Әхмәтҗан байның даладагы утарына да чират җиткән. Пүчинкә кешеләре иртән килеп мал-мөлкәтне үзара бүләчәкләр имеш. Кичен бу хәбәрне озын колактан ишетеп белгән Фәгыйлә шул ук төнне Габдрахман хәзрәтләргә юл тотарга карар кыла. Хезмәтче кыз Җәмилә дә ана иярә.

Фәгыйлә исә билгесез сәфәр алдыннан чак кына уйланып тора да, башта иң кадерле нәрсә итеп—шагыйрь үзе вафат булгач чыккан китапны яулыкка төрә. Аннары соңгы тапкыр бүлмәләрне йөреп чыкканда затлы бизәнү әйберләренә, көмештән ясалган, алтын йөгертелгән савыт-сабага күзе төшә. Элек боларга аның бер дә исе китми иде. Хәзер исә, мондый авыр заманда боларның да кирәк булуы ихтимал дигән фикергә килеп, озын-озак уйлап тормастан, хәзинәдә барын зур гына бер футлярга тутыралар һәм кучер малайның чанасына салып бәйлиләр. Хәтәр сәфәргә төнгә каршы чыгып китәләр.

Ул вакытта төрле сәбәпләр аркасында әйберләрен күтәреп төн карасы астында каядыр шылучы качаклар күп булгангамы аларны аулау, мөлкәтләрен конфискацияләү нияте белән юлларда өч-дүрт кешедән гыйбарәт булган коралды дозор отрядлары йөри торган була.

Моны белмәгән Фәгыйлә белән Җәмилә дә, таң алдыннан шәһәргә барып житәрәк, бәхетсезлеккә каршы, әнә шундый отрядка очрый. Башлыклары булса кирәк, кыска тун, колакчын бүрек кигән базык гәүдәле берсе: «Кто такие, что везете?»—дип боларны туктата. Фәгыйлә урысча азрак сукаласа да, берни дә аңламаганга сабышып, ык-мыклап тизрәк үтеп китмәкче була.

Отряд командиры аны туктатып, сүгенә-сүгенә чананы тибеп аудара, асты өскә әйләнгән футляр эчендәге әйберләр чәчелеп китә. Шырпы яндырып карасалар: кар өстендә жем-жем итеп яткан асыл ташлы бизәнү әйберләрен күреп, дозорчыларның күзләре дүрт була. Ачулы командир зур хәзинә табу шатлыгыннан хәтта юашланып китә, әдәпләнә төшә.

Артык сүз куертып тормастан, дозорчылар шырпы сыза-сыза кар

өстендәге әйберләрне жыеп футлярга тутыра башлыйлар. Ут сүнеп торган арада әле берсе, әле тегесе берәр әйберне тиз генә үз кесәсенә салып куя. Эш тәмам булгач, котлары алынган ике бичара юлчыны, куркыныч юлбасар тоткандай, кораллы сак астында шәһәргә, элеккеге полиция участогы бинасына яна милиция бүлегенә китерәләр.

Монда Фәгыйлә белән Җәмиләне ярым чишендереп, култык asларын, күкрәкләрен оятсызларча капшый-капшый жентекләп тентиләр, футлярдагы хәзинәгә опись ясыйлар. Фәгыйлә Тукай китабын сорап караса да кире кайтарып бирмиләр. Аннары аларны күрше бүлмәгә аерым-аерым чакырып икесеннән дә допрос алалар. Фәгыйлә үзе турындагы барлык сорашуларга да чын булганча, дөресен җавап бирә. Төрмәгә утыртуларыннан куркып, үзенең буржуй хатыны икәнен генә әйтми калдыра. Допрос алучы күпме төпченсә дә:

—Алар мин ятимәне асрау кыз итеп алдылар, бераз үскәч хезмәтче булдым,—дип Фәгыйлә үз сүзендә нык тора.—Дөнья бозылгач, ягъни бу чуалышлар башлангач, аталы-уллы хуҗаларыбыз шәһәргә киткән җирдән юкка чыктылар. Ике көн көтеп тә хуҗалар кайтмагач, без дә хуҗасыз утарда калудан курка башладык, шыпырт кына тайдык. Шайтан котыртты бугай, комсызланып бу шылтыравыкны үзебезгә бәлагә алганбыз. Тфү, тфү, башы-ахыры шул булсын!

Шунда көтмәгәндә тагын бер бәла килеп чыга: допрос кәгазенә кул куйганда дозорчылар башлыгы Фәгыйлә бармагындагы никах балдагын күреп ала да, каракны җинаять өстендә тоткан кебек, кабат җикеренеп ташлана:

—Әһә-ә, эләктеңме?!. Әле генә комсызлануың өчен үкенгән булып, тәүбә итеп кыланган идең. Ә үзең әнә ничек! Халык милке булырга тиешле алтын балдакны безгә тапшырмыйча, яшереп калгансың. Таш кебек катып торма, хәзер үк бармагыңнан балдагыңны салып өстәлгә куй.

—Юк, юк, мин берни дә яшереп калмадым, балдакны аны һич тә бармактан салып булмый, бары тик шуннан гына.

—Әһә, шулаймы? Салдыру дигәндә безгә куш. Без аны хәзер, күз ачып йомганчы...

Дозорчы әнә шулай шапырына-шапырына эшкә керешә. Әмма таш кебек каты куллары белән Фәгыйләне кычкыртып күпме генә газапласа да, бармакка тирән батып кергән балдакны барыбер салдыра алмый. Борын астыннан мыгырдый-мыгырдый туктарга мәҗбүр була. Чөнки кияүгә чыкканнан соңгы дүрт ел дәвамында Фәгыйләнең бармаклары шактый тулыша төшкән, тирән батып кергән алтын балдак сары тегәрҗепкә охшашлы сызык кына булып күренә иде.

Дозорчылар, ахыр чиктә, җәфалауны туктатып торырга булалар һәм Фәгыйлә белә Җәмиләне коридорның аргы башындагы салкын камерага илтеп ябалар.

* * *

Иртән милиция түрәләре эшкә килгәч, камерадагы тоткыннарны берәм-берәм чакырып тикшерү—фильтр аша үткәрү башлана. Эшне тиз тоталар бугай, бераздан камера шактый бушап кала. Менә утар качакларына да чират җитә. Башта хезмәтче кыз Җәмиләне чакырып алалар. Милиционер бераздан Фәгыйләне чакырып чыгара. «Өлкән тикшерүче» дип язылган ишектән кыюсыз гына атлап кергәч, зур өстәл янында кәгазьләр актарып утырган тикшерүче күтәрелеп карамыйча гына:

—Кайдан, кем буласың? Садись, рассказывай,—дип, артсыз урындыкка ымлап күрсәтә.

Фәгыйлә төнлә дежурныйга ни сөйләгән булса, бу юлы да сүзгә-сүз шуны кабатлый, бары тик үзенең бай хатыны икәнен генә әйтмичә яшереп калдыра. Тикшерүче рәтләп тыңламаган кебек булса да, аны шып туктата.

—Ник скрывать итәсең? Менә бу допрос протоколында, хезмәтче кызыгыз әйтүенә караганда, син есть бай хатыны бит, значит буржуйка,

классовый дошман,—дип алдындагы кәгазьгә төртеп күрсәтә. Шунда ул Фәгыйләгә күтәрелеп карый һәм кинәт гажәпкә кала:—Чү, кемне күрәм мин. Хәтерем ялгышмаса, син Бәхтиярларда прислуга идең бит. Хатыны да булгансың икән. Алайса ник скрывать итәсең?

Беркайчан алдау-йолдауны белмәгән Фәгыйлә комач төсле булып кызара, абына-сөртенә кыенлык белән:

—Юк, ялганчы түгел мин,—дип акланырга тырыша.—Ул йортта асрау кыз булуым да, аннары хәдимә булуым да хак сүзләр. Фамилиям дә дөрес, тумыштан килгән чын фамилиям. Ә монысы, допрос протоколында язылганы, куркудан, буталудан килеп чыккан. Алла хакы өчен, зинһар, гафу итегез.

Бу көтелмәгән очрашудан Фәгыйлә бик аптырап һәм, әле һаман ышанып бетмәгәндәй, күз кырые белән генә ирексездән тикшерүчегә карап ала. Әйе, бу һичшиксез шул, моннан биш ел элек утарга кунакка килгән ябышкак Куртай иде. Хәзер ул сизелерлек калынайган. Элеккечә туган телендә сөйләшә белми, сул кашы юк. Чыгар күзләре йотардай итеп комсыз карый. Ул, Фәгыйлә ишетерлек итеп кенә, авыз эченнән мыгырданып утырды:

—Менә бу чынлап та удивительно! И, кызганычка каршы, поздно очрашу, помогать итәргә авыр булачак. Чөнки барысы да инде дежурный журналына язылган, әйберләргә официально опись ясалган—значит, яшереп калу мөмкин түгел. Аннары, Әхмәтҗан бай бер алтын приискасында пайчы иде бит, димәк, аның кайдадыр яшереп куйган алтын запасы бар. Точно беләбез, качып киткәндә алар ул запасны урлап өлгерә алмадылар. Ул алтыннарны табарга ярдәм итсәң, без сине шундук чыгарып җибәрербез. Разумеется, табылган запастан үзенә дә бераз эләгер. Төнге допрос протоколында бармагыңдагы алтын балдагын бирмәде, салдырып алырга кирәк дип язылган. Алай ярамый, балдакны хәзер үк салып бир.

—Алтын запасы турында бер кәлимә сүз ишеткәнем, күргәнем булмады, шуңа күрә һични әйтә алмыйм. Ә балдакны аны яшереп калмадым. Менә ул, тирән батып кергән. Допросчылар салдыра алмадылар. Балдакны оста кайчысы белән генә кисеп алып була диделәр.

—Ярар, анысы калып торсын, соңыннан хәл итәрбез. Ә хәзер безнең өчен иң важные—алтын запасы. Син шунын кайда икәнен әйтергә, безгә булышырга тиеш.

—Бик булышыр идем, әмма мин берни дә белмим бит. Шунлыктан һични әйтә алмыйм.

—Ашыкма, бәлкем, хуҗаларыңнан куркасыңдыр.—Тикшерүче яшерен сер әйткәндәй, тавышын акрынайта төште.—Бер дә курыкма, алар юк инде, кире кайтып булмый торган дөньяга бөтенләйгә киттеләр.

Кинәт коты алынган Фәгыйлә моны аңына сыйдыра алмыйча:

—Ничек киттеләр, кем әйтте аны?—дип кычкырганын сизми дә калды.

—Син нәрсә, ишетмәдеңмени? Безнең изолятордан качкан унике подследственный арестант, төнге карангыда елга аша үткәндә, барысы да юка боз астына батып погибать иттеләр. Алар арасында Әхмәтҗан бай белән аның улы Бәхтияр да бар иде. Значит, алтынның кайда икәнен курыкмыйча әйтергә мөмкин.

Моңа бик ышанып бетмәсә дә, Фәгыйлә кинәт миңгерәп китә, күз аллары томанлана. Куртайның соңгы сүзләре сабакташы Бәхтиярның һәлакәтенә шатлангандай мәкерле тоела, рәхимсезлеге белән җанны өшетә. Фәгыйлә шундук, бисмилласын әйтеп, мәрхүмнәр рухына дога кылырга керешә.

Тикшерүче эшне ашыктырмакчы. Түземсезлек белән тамак кыра:

—Монда мәчет түгел, соңыннан молиться итәрсең.—Ул, Фәгыйләнең догасын бүлдереп, допрос алуын дәвам итә.

Ул бөтен тырышлыгын куеп допрос ала. Турыдан-туры да, төрлечә уратып-уратып та сораштыра, тасма телләнеп үгетләп тә карый. Әмма, көткән җавапны һич әйттерә алмыйча, ярсып бетә. Ахыр чиктә чамасыз ризасызлык белән:

—Бар, яхшылап уйла, хәтерләргә тырыш,—дип җикеренеп, тоткынны камерага илтергә куша.

Ул Фәгыйләне иртәгесен дә, берсекөнне дә бүлмәсенә чакыртып озак-озак допрос ала, аның кичә сөйләгәнен бүгенгесе белән жентекләп чагыштыра. Дөресен әйтмичә барыбер чыгармыйбыз, дип тагын кисәтеп карый. Өченче очрашуда да тоткынның телен чишә алмагач, түземен жуеп, ачулана башлый:

—Ярар, черт с тобой. Алайса синнән бүтән жирдә башка кешеләр допрос алыр! Анда болай гына үгетләмәсләр, телеңнән тартып сөйләтерләр. Безнең кебек жәлләп тормаслар, балдагыңны бармагың белән өзеп алырлар.

Шул ук көнне, кәгазенә Фәгыйләне буржуй хатыны дип, алтын хәзинәсе кайда икәнен әйтмәвен һәм хәзер дә бармагындагы алтын балдакны бирмәгәнен өстәп, кораллы сак астында шәһәр төрмәсенә жентекле тикшерү үтәргә жибәрделәр.

* * *

Шәһәр төрмәсендә бай хатыны Фәгыйләне, шөкер, хатын-кызлар камерасына ябалар. Кием-салымнарына, үзләрен тотышларына караганда, тоткыннарның күбесе яна власть тарафыннан жәберләнгән мул тормышлы зыялыга охшаганнар. Араларында байларча купшы киенгән яшь ханымнар да, рәнжүләре йөзенә чыккан әбиләр дә бар. Кайберләре инде атна-ун көн тикшерүче күрмичә чират көтеп тора, бу кандала оясында озак тотудан зарланып шау-шу кузгата.

Монда тик тотмыйлар, төрле эшкә жигәләр икән. Ябылуның икенче көнендә үк, солдат кебек сафка бастырып, Фәгыйләне дә тимер юл станциясенә ташкүмер бушатырга алып киттеләр.

Тынчу, сасы камерада аз сүзле булып тоелган тоткыннар саф һавада жанланып китеп, эш арасында кайгы-хәсрәтләрен уртаклашып, башларыннан үткән мажараны, ишеткән-белгәннәрен сөйләп күнел ачалар. Фәгыйлә аларны сизгер колак белән тыңлый. Бу зинданда тикшерү үткәч, күбесен төрле срокларга хөкем итеп, Чиләбе шәһәрендәге хезмәт-тәрбия колониясенә жибәрәчәкләр икән. Ә менә мондый эш арасында кайчак ул бәладән качып котылучылар да булгалый имеш.

Станциядә поездлар бер-бер артлы үтеп тора. Барысы да халык белән тулы, дәһшәтле туфаннан куркып качкан кебек, барысы да бер тарафка—Көнчыгышка таба агыла. Менә тагын, шундый поездларның берсе, тоткын хатын-кызлар эшли торган ачык платформа янына килеп туктады. Вагоннардан сикереп төшкән пассажирлар вокзал эчендәге буфетка, азык базарына ташланып, берсен-берсе этә-төртә, чәйнекләренә кайнар су ала. Бераздан, чың-чың итеп кыңгырау чакыргач, итәкләренә ут капкандай, һәммәсе дә вагоннарына чаба башладылар.

Буфетта артыгын эчкәннәр, күрәсен, бер-берсенә кизәнә-кизәнә вокзалдан ике исерек баш килеп чыга да, перронда чынлап торып сугыша башлый, жиргә егылып рәхимсез кыйнашалар, начар сүзләр белән сүгенәләр. Сәгате-минуты белән жыелган халык тын да алмыйча шаккатып тамаша кыла. Тоткын хатын-кызларны саклаучыларның икесенең дә күз карашы шунда төбәлгән.

Күрше юлдагы поезд менә-менә кузгалып китәчәк бугай, паровозы моржасыннан очкыннар бөркеп, соңгы пассажирлар вагоннарга күтәрелә. Фәгыйлә ирексездән: «Их, шуның белән качып китсәң иде»,—дип, эчтән ниятләп куя һәм йөрәгенең ешрак тибә башлаганын сизә. Ә аның кулдашы, Наташа исемле яшь кенә чая хатын, акрын гына:

—Мин тәвәккәллим, ычкынам. Әгәр теләсәң, әйдә, миннән калма,—дип күмерле вагоннан жиргә сикереп төшә.

Озын-озак уйлап торырга вакыт юк. Кулындагы тимер көрәген ташлап, Фәгыйлә дә аның артыннан йөгерә һәм инде кузгалып китә башлаган сары вагонның асылмалы баскычына тотына. Наташа һәм шунда якында булган тагын бер егет аны вагон эченә кулыннан тартып күтәрәләр.

Йөк ташый торган вагон халык белән шыгрым тулган. Болай да

тыгыз бит, ник тагын кеше утырттыгыз дип, ризасызлык белдерүчеләр дә бар. Әмма Наташа аларны ишетмәгәндәй, тимер мич янындагы ташкүмер ящигына утыра, бераз кысыла төшеп, Фәгыйләгә дә урын бирә. Шунын белән шау-шу да басыла.

Тиздән Фәгыйлә үзе дә бераз тынычлана һәм кызу тимер мич янында жылыда башкалар сөйләшкәнгә мыштым гына колак салып тынлап бара. Сөйләшүләренә караганда, бу халык арасында караклар, документсыз шикле кешеләр дә бар, аларны аулау максаты белән әледән-әле тикшерүләр үткәрелә, документсыз кешеләрне шундук кулга алалар икән. Бу капкынга эләгүдән ничек котылырга белмичә Фәгыйлә тәмам куркуга төште, поезд туктаган саен ишек ягын күзәтте. Үзенен хафалануын ул янында йокымсырап барган юлдашына да сиздерде. Икесенен дә һичнинди документы юк бит, монда бер генә минутка да калырга ярамый.

Алар уртак карарга килеп тиздән, поезд Чиләбе станциясендә туктагач, тавыш-тынсыз гына вагоннан төшеп калдылар.

Ярымкаранғы перронда халык мәш килә. Төрле багаж, төенчек күтәргән кешеләр, сонга калудан курыккандай, бер-берсен этә-төртә шәһәргә чыга торган капкага тыгыла. Кемнәрдер киресенчә агымга каршы—поездга ашыга. Дүрт-биш минут дәвам иткән ыгы-зыгы арасында Фәгыйлә юлдашы Наташаны күздән югалтты. Ул кинәт аптырап, як-ягына иләс-миләс каранып, шәһәр урамына китүчеләр артыннан ташланган иде. Арлы-бирле сугылып йөргәннән сон, кире вокзалга кайтып, поезд көтүчеләр арасында гына эзләнергә булды. Ниһаять, тәмам алжып, тез буыннары калтырый башлагач, залда буш урыннарнын берсенә хәл алырга утырган көе ул авыр йокыга талды.

Күпмедер вакыт йоклаганнан сон, улниндидер тәмле искә уянып китеп үзенен түзә алмаслык ачыгуын сизде. Күзләрен ачып караса—ул вокзал ашханәсе янында гына утырганын, кемнәрнендер ачык ишектән кереп-чыгып йөргәнен абайлап ала һәм аларга ияреп эчкә керә. Кешеләр акча түләп кухня тәрәзәсе янына барып баса, ә Фәгыйлә исә өстәлләрдәге ризык калдыкларын ашарга керешә. Ул иртәгә дә, аннан сон да шулай көн күреп, төннәрен залда поезд көтүче пассажирлар арасында йоклап жан асрый башлый.

Көндезләрен жай туры килгәндә ул ашханә идәнен жыештыручыларга, кухняга ташкүмер кертүчеләргә булыша. Кухня эшчеләреннән берәрсенен вак бәлеш яки пилмәнне матур итеп ясый белмәве күзенә чалынса, ничек бөгәргә кирәген шундук күрсәтеп бирә. Фәгыйләнен бу һәвәслеген тиздән шеф-повар Анастасия түти дә сизеп ала һәм аны үзенә булышчы итә. Вокзалда кунып йөрүче ялгызак икәнен белгәч, икәү бергә күнеллерәк булыр дип, үз өенен кечерәк кенә буш бүлмәсенә алып кайта. Өстенә киярга иске халатын, йон оекбашын бирә.

Күренеп тора, Анастасия эш йөртә белән торган булдыклы хатын. Төннәрен идән астында самогон кудырып еш кына сату итә. Өй артындагы сарайда симертергә куйган зур-зур ике дунгызы бар. Ашханәдән аш-су калдыкларын алып кайтып, дунгызларны ашату, сарайны чистарту, төрле өй мәшәкатьләре—барсы да Фәгыйлә жилкәсенә күчә. Авыр булса да Фәгыйләгә түзәргә туры килә, чөнки дөньянын асты өскә килгән бу фетнәле заманда паспортсыз беркая барып булмый.

Настя түтинен ялгызлыктан зарлануы күз буяу өчен генә булган икән. Милиция бүлегендә писер булып хезмәт итүче сөяркәсе бар. Бик эчкече бәндә, гел самогон сорап аптырата, эчәренә бирмәсән, гауга куптара, тавышлануы такта стена аша ишетелеп тора. Пасха бәйрәме көнне дә кич белән ашап-эчеп, күнелле генә жырлап утырганнар иде.

—Беләм мин сине, үтәли күрәм, паспортсыз качакларны, сукбайларны жыеп, ярты бәягә эшләтәсен,—дип жикеренә башлады писер.—Ачуымны китерсән, якташым дип кызганып тормам, тотармын да иртәгә үк житкерермен.

Көн буе эшләп тәмам алжыган Фәгыйләнен ятып йокларга жыенган вакыты иде. Күрше бүлмәдән милиционернын янавын ишеткәч, нишләргә

белмичә куркуга төшеп, менә хәзер кереп кулга алмагае дип, коты алынып ятты, куркуын җинеп, бераз тынычлангач, күрше бүлмәгә колак салып тыңларга тотынды. Аннан бернинди хәрәкәт, тавыш ишетелмәгәч, барлы-юклы кием-салымын җыеп төйнәде дә, шыпырт кына чыгып качты.

* * *

Төнге тынлыкка чумган шәһәр читендәге зур тимер юл станциясе, үзгә бер дөнья кебек, гөр килеп тора. Рәт-рәт тезелгән поездлар арасында әледән-әле паровоз кычкырткан, сузып-сузып сыбызгы сызгырткан тавышлар ишетелә. Әле анда, әле монда утлы фонарь тоткан кеше күренеп үтә. Вокзал каршындагы пассажир поезды янында чемодан, сумка тоткан кешеләр тыз-быз килә. Кемнәрдер китүче, кемнәрдер озатып калучы.

Ерак Көнчыгышка Владивосток шәһәренә юл тотарга тиешле тиз-йөрешле поезд менә-менә кузгалып китәчәк икән. Фәгыйлә тиз генә билет алып, төрле ярлы-ябагай йөри торган иң арзанлы вагонга кереп утырды.

Вагон эче икегә бүленгән. Беренче бүлек чуар халык һәм төрле чемодан, кәрзин, капчыклар белән тулы, эчкә үтәрлек түгел, басып торырга да урын юк. Боларның күбесе инкыйлап үгиләре, яңа власть белән килешә алмыйча, бәхет эзләп чит җирләргә күченүчеләр. Туган-үскән җирдән бөтенләйгә аерылу кыен булса кирәк, йөзләрендә әмәлсез гаҗизлек галәмәте күренеп тора.

Вагонның икенче бүлеген бер төркем дингезчеләр—Петербургтан Владивостокка, хуҗасы ташлап качкан пароходка эшкә баручы команда арендага алган. Монда иркенрәк, әмма бүтән беркемне дә кертмиләр. Башка урын булмагач, Фәгыйләгә шунда—бүлмә ишегенә аркасы белән сөялеп торырга, һәр чыккан-кергән кешегә, читкә тайпылып юл бирергә туры килде.

Команданың капитаны, җиз якорьлы фуражка, зәңгәрсу китель кигән урта яшьләрдәге дингезче, юл өстендә басып торган Фәгыйләне җәлләде бугай, аталарча кайгыртучанлык белән.

—И, матурым, тынгысыз урында кунаклагансың. Болай ярамый, төенчегеңне ал да, әйдә безнең якка кер,—дип, ян утыргычтагы берничә чемоданны өске киштәгә күчереп, бушаган урынны аңа бирде.

Инде күптән җылы сүз ишетмәгән Фәгыйлә, мондый ягымлы мөнәсәбәткә сөенеп, киң күңелле капитанга кабат-кабат рәхмәтләр әйтте. Аннары төенчегенә башын куеп, кырын яткан хәлдә оеп күзләрен йомды.

Ул иртәгесен якында гына кемнәрдер сөйләшкән тавышка уянып һәм бераз тыңлап яткач, шуны белеп алды: команданың повары тиф белән авырып, юлда хастаханәгә кереп калган. Шуның аркасында менә өченче көн инде кешеләр җылы аш күрми, ресторанnan тукланырга күбесенең кесәсе сай икән.

Капитан белән сөйләшкәннән соң бу эшкә Фәгыйлә үзе тотынды. Артельче үлчәп биргән азык-төлектән вагон-ресторан кухнясында төш вакытына менә дигән тәмле аш, итле карабодай боткасы, йөзем компоты пешереп, бөтен команданы сөендерде. Барыннан да бигрәк, капитан мактады:

—Көймә комга утырган иде, ярый әле син коткардың... Алайса, матурым, менә нәрсә: әйдә, без сине штатка алабыз, дингезче повар-кок булырсың, чит илләрне күрерсең.

—Юк, юк, дингезче булмыйм, йөзә белмим мин,—дип көлеп, Фәгыйлә кул гына селтәде.

Чиксез-кырыйсыз киң дала, куе урманнар аша поезд ыжгырып алга бара. Меңнәрчә чакрымнарга сузылган юл һич бетмәс кебек, ялыктыра башлый. Күңелсезлектән котылу өчен кешеләр домино, шахмат уйныйлар, дингезне сагынгандай, барысы бергә моңлы көйгә сузып җырлыйлар.

* * *

Күп газаплы авыр сәфәр азагына якынаеп килә. Менә Хабаровск шәһәре дә артта калды.

Иртәгә иртән Тын океан буендагы ин ахыргы шәһәр Владивостокка барып житәчәкләр.

Кая барып бәрелергә белмәгәндәй кангырап утырган карангы чырайлы дингезчеләр, ниһаять, жанланып, бердәм тату гаилә кебек күнелләре күтәрелеп уйный-көлә башлады. Тузгый чәчле шадра егет кенә сүзгә катнашмыйча башкалардан читтәрәк утыра һәм күз кырые белән генә әледән-әле Фәгыйләгә ничектер шикле каранып ала.

Чү, астыртын күзәтүче түгелме бу дип борчуга төшә Фәгыйлә. Каушавын сиздермәс өчен ул калтыраган куллары белән төенчеген актарырга керешкән булды. Менә утардан киеп чыккан йон кофтасы ин өстә ята, анын ашханәдә эшләгәндә туплаган барлы-юклы акчасы шунын кесәсендә саклана. Мәгәр, гөнаһ шомлыгына каршы, куйган урынында акча юк. Фәгыйлә үзәк ачыну белән:

—Ах, акчамны урлаганнар,—дип кычкырып жибәрде.—Бая кухняга аш пешерергә чыкканда гына булавка белән эләктереп куйган идем бит. Берәрсе күреп торды микәнни?!

Бу күнелсез хәбәрдән, бөтен команда авыр хәлгә калып, кинәт киеренке тынлык туды. Кешеләрнен, ни әйтергә белмичә, бер-берсенен күзенә карарга унайсызланганын күреп, мона сәбәпче булган Фәгыйлә үзе дә: һай, ялгыш артык кычкырдым, ахрысы, дип үкенә үк башлады.

Шулчак, капитан аяк үрә торып басып, бөтен команданы ашыкмыйча күздән кичерде:

—Моннан күп вакытлар элек, жилкәнле флот заманында, төзәлмәс каракларны, корабта коткы таратучыларны дингездә кеше яшәми торган кыргый утрауда төшереп калдыра торган булганнар. Әгәр ымсынып алган кеше акчаны хәзер үк кайтарып бирмәсә, без аны беренче тукталышта үк поездлдан куып төшерәчәкбез. Чөнки андый ышанычсыз кеше белән дингезгә чыгып булмый.

—Шулаен шулай да, әмма урлаучынын кем икәнен ничек беләсен? Шунсыз төшереп калдырып булмый бит,—дип сорау ташлый бер түземсезе.

—Балтикада пароходыбыз минадан шартлап һәлак булганчы без барыбыз да бергә эшләгән кешеләр, бер-беребезне яхшы беләбез, бер-беребезгә ышанабыз. Аз таныш булган бердәнбер кеше, юлга чыгар алдыннан гына кадрлар бүлеге жибәргән яна кочегар бар. Әйдәгез, сорыйк әле, акчаны кем алганын шул күрмәгәнме яки үзе нәфес коткысына бирелмәгәнме? Ул шунда якында гына утыра бит. Әгәр дөресен әйтсә, без дә анын хәленә керербез.

Яна кочегар дигәннәре Фәгыйләгә шикле күренгән әлеге тузгый чәчле егет икән. Үзе турында сүз кузгалгач, башы түбәнрәк иелде, таяныч эзләгәндәй аптырап әйләнә-тирәгә каранды.

Сорау ташлаган теге матрос әле һаман тынычлана алмыйча, каршы чыга:

—Жәмәгать, акчаны кем чәлдергәнен тәгаенләми торып, гаепсез кешегә яла ягабыз, ялгышабыз түгелме?

Тузгый чәчле егет исә ниһаять Фәгыйләгә таба борылды:

—Мадам, сезнен акчагызны мин алдым, зинһар, кичерегез.—Һәм ул акчаны күкрәк кесәсеннән алып Фәгыйләгә бирде.—Алтын балдаклы булгач, калын кесәле дип уйлаган идем. Төенчек эченнән күренеп торган кәгазьне ничек алганымны сизми дә калдым. Сукбайлыкта өйрәнелгән начар гадәт онытылып бетмәгән, күрәсен. Бүтән беркайчан кеше әйберенә тимәскә, тырышып эшләргә сүз бирәм. Минем бүтән беркемем дә, беркая барыр жирем дә юк. Мине үзегездән аерып, тагын сукбайлыкка дучар итеп ташлап калдырмавыгызны зинһарлап сорыйм!..

Катгый чырайлы капитан күзләре белән генә сизелер-сизелмәс елмаеп

куя. Үз власте белән хәл итәргә хокукы булса да:

—Йә, нишлибез, егетләр! Кем ничек уйлый?—дип бөтен командага мөрәҗәгать итә.

Вагонда тирән тынлык туды. Бер-берсеннән киңәш көткән сыман үзара карашып шактый торгач, арадан берсе үзалдына уйлангандай гына әйтә куйды:

—Да-а, авыр язмышлы сукбай, ташлап калдырырга ничектер кул бармый.

Ана тагын берничә кеше кушылды:

—Дөрес әйттең, чынлап та кызганыч.

—Куып чыгарсак, тагын юлдан язмагае.

—Әйе, әйе, егет кызганыч...

Шуның белән хөкем вәссәлам. Егетнең хәленә кереп һәм каты кисәтеп, бер юлга аны гафу итәргә булдылар.

Бу күңелсез вакыйганың шулай уңай хәл ителүенә Фәгыйлә дә канәгать. Тузгый чәчле егетнең шат йөзенә карап утырган шәпкә: «Минем хәлем дә нәкъ аныкы кебек, таянырлык беркемем дә, барып ышыкланыр җирем дә юк бит. Әгәр алсалар, әллә шул пароходка повар булып керим микән»,—дип икеләнә калды.

* * *

Мәңге бетмәс кебек озын тоелган күп газаплы ялыктыргыч юл, ниһаять, бетте. Төрле сәбәпләр аркасында туган-үскән җирен ташлап чит-ят җирләргә бәхет эзләп китүчеләр белән шыгрым тулы поезд океан буендагы иң азаккы шәһәр—Владивостокка барып житте. Чит илләргә юл тотучылар вагоннардан төшү белән, сонга калудан курыккандай, абына-сөртенә якындагы дингез вокзалына таба ташлана, һәркайсы дингез корабына билет алырга ашыга.

Ә Балтикадан күчеп килүче диңгезчеләр командасы пароходчылык идарәсенә юнәлә, кичә генә повар булырга ялланган Фәгыйлә дә алар белән бергә. Әлеге дә баягы, һаман бер киртә: кадрлар бүлегендә паспортың юк дип, аны эшкә алмадылар. Инде нишләргә, бөтенләй таныш түгел ят шәһәрдә ялгыз башың кая сугылырга?! Байтак вакыт каңгырап йөри торгач көтмәгәндә генә башына бер уй килде. «Чү, читкә китүчеләрдән берәрсе, гаилә әгъзасы итеп үзенә ияртмәс микән? Поездда бер кызның ыгы-зыгы арасында әнә шулай вагонга утыруы турында кемдер сөйләгән иде бит?»

Әнә шул үзе уйлап чыгарган хыялый ният белән Фәгыйлә портка тәпили. Анда, тимер-бетон причалга яңы белән туктаган зур пароход янында, халык мәш килә. Барысы да палубага менә торган асылмалы баскычка таба омтыла. Һәркемнең паспортын, билетын җентекле тикшереп үткәрәләр. Чират торучылар арасында кәләпүшле мөселманнар да бар. Фәгыйлә сүз катып караган агайлардан берсе тыңлап та бетермичә, инбашларын җыерып кына тискәре җавап биреп читкә борылды. Икенчесе—акылга зәгыйфь мәзәкче күргәндәй күзләрен шар итте.

Беркатлы балаларча мәгънәсез эш белән шөгыльләнгәнен Фәгыйлә, ниһаять абайлап, үзен-үзе кызганудан күз яшьләренә буылды. Каргышлы илне ташлап китүчеләр барысы да, аңа бик канәгать, бәхетле кебек тоелдылар.

Акрын гына кузгалган зур пароходны Фәгыйлә күзләре белән озатып ерактагы томансу пәрдә эчендә эреп югалганчы онытылып карап торды. Бераздан аңына килеп, әйләнә-тирәсенә караса, причал инде бушап калган. Әлерәк кенә киткән пароходның чалкаларын тумбадан ычкындырган ике эшче генә якындагы склад ишегеннән аны гаҗәпсенеп күзәтеп тора иде.

Фәгыйлә төенчеген култык астына кыстырып порттан чыкты да, кай тарафка юл тотканын уйлап тормастан, тротуар буйлап башын аска иеп китеп барды.

Үзәк урамнан бара торгач, аяклары алҗуга түзә алмыйча, тимер юл вокзалына килеп керде. Буфеттан кыздырылган балык белән бер кисәк

икмәк алып тамак ялгагач, бөтен гәүдәсе авыраеп, күзләре йомыла башлады. Бу төнне ул шунда, пассажирлар залында, урындык артына сөялеп утырган хәлдә йоклап үткәрде.

Фәгыйлә иртәгесен, җыештыручылар дөбер-шатыр эшләгән тавышка уянып, күзен ачып караса, кояш инде шактый югары күтәрелгән, әлерәк кенә Мәскәү поезды килеп туктаган. Юлчыларның күбесе мөһаҗирләр икәне күренеп тора, вагоннан төшү белән ашык-пошык сорашалар да, дингез вокзалына пароходка билет алырга йөгерәләр. Фәгыйлә дә аларга иярә, берәр якташ, ирен, каенатасын белгән-ишеткән кеше очрамасмы дип өметләнә. Пароходка утырырга да ниятләп карый.

Әмма аны бу юлы да утыртмыйлар. Мөһаҗирләр тулы зур пароход кузгалып китә. Нәүмиз Фәгыйлә причалда ялгызы торып кала, күзләре томанлана.

Мәгәр причалда ул үзе генә түгел, аны кичә күреп калган ике кеше бүген дә шунда якында гына ни турындадыр сөйләшеп, сәерсенү белән күзәтеп тора икән. Берсе куш иякле, бик тыңгысыз булса кирәк, юлдашының терсәгенә кагылып, саф татар телендә:

—Шакир, карале, бу кичәге пароходны озгәләнеп озатып калган мәткә ич,—ди.—Бүген дә кемнедер озатты. Кием-салымы шәптән булмаса да, үзе җиләк кебек, күз төшмәслек түгел.

Шакир дигәне зур таза гәүдәле сазау егеткә охшаган. Әчке ризасызлык белән:

—Т-с-с! Әдәпсезләнмичә чамалабрак сөйлән,—дип искәртү ясады.

Фәгыйлә аларның сөйләшкәнен ишеткәч, котмәгәндә иң якын кешеләрен очраткандай шатланды гына:

—Һи-и, колакларыма ышанмый торам, чынлап та үзебезнең мөселман әһелләре икән. Әссәламегаләйкем, мөхтәрәм милләттәшләр!

Әмма милләттәш агайлар якты чырай күрсәтмиләр. Яшь чибәр хатынның артык ачылып китүен өнәмәделәр, җилбәзәкләрчә әрсезлеккә санадылар бугай, теләр-теләмәс кенә, ничектер ягымсыз исәнләштеләр. Чалыш авызлысы Фәгыйләне баштанаяк җентекләп күздән кичерде дә, өнәмәвен яшермичә, мыгырдап куйды:

—Мөслимә башың белән шамакайланып йөрмә монда, бар, юлыңда бул, китә бир!

Икенчесе дә, алай каты бәрелмәсә дә, җинелчә әрнү белән:

—Дөрестән дә, бер дә килешкән эш түгел,—дип шелтәләгәндәй итте.—Бармагында алтын балдак, ә өстендә керләнеп беткән иске халат. Болай бер дә килешми. Бераз чистарак, пөхтәрәк киенеп йөрергә кирәк бит!

Моны ишетү Фәгыйләгә бик авыр иде. Шулай да үзенең тышкы кыяфәте өчен йөзенә оялу катнаш ачыну чыгарып, тирән дулкынлану белән җавап кайтарырга теләде ул.

—Әгәр минем хәлемне белсәгез...

Әмма ул башлаган сүзен әйтеп бетерә алмыйча, күз яшьләренә буылып причалдан чыгып китте.

Бу көнне ул аеруча авыр кичерде. Кая сугылырга белмичә, күңелсез уйларга чумган хәлдә урамнарда йөри торгач, ул шәһәр кырыендагы кечерәк кенә базарга барып чыгып, юл читендә китап сатып утыручы ак сакаллы карт янында ихтыярсыздан тукталып калды. Ашъяулык хәтле генә кечкенә җәймә өстендә яткан төрле китаплар арасында берсе аның күзенә таныш чалынды. Инде шактый таушалган, тышлыксыз булса да, үзенең шактый зур форматы, калынлыгы һәм кәгазенең саргайган төсе белән нәрсәнедер хәтерләтә, кайдадыр күргән кебек тоела. Фәгыйлә китапны кулына алу белән үк аны таныды һәм битен ачып карауга ук, шигырьне укып та тормастан, күңеленнән кичерде:

Якын дустым! Сиңа миннән киңәш шул:  
Кешеләргә серенне сөйләмәс бул.  
Эчендә нәрсә янганын үзең бел.  
Үзең кайгыр, үзең егла, үзең көл.

Бу—Тукай әсәрләренең беренче зур җыентыгы икән. Акчасы юклыбарлы гына булса да, Фәгыйлә аны кулыннан бирмичә сатып алды. Сөекле шагыйрен күргәндәй күңеле күтәрелеп китте. Вокзал каршындагы кечкенә бакчада сәгатьләр буе кангырап утырган авыр вакытларда ул шуны укып юанды, рухи таяныч тапты.

* * *

Причалда, зур складтан сулдарак, порт эшчеләренең ашханәсе бар. Фәгыйлә аны узып барышлый очраклы рәвештә генә күреп алды һәм бераз тамак ялгарга булды. Чиратка басып кухня тәрәзәсеннән балыклы аш белән икмәккә ирешкәч, кая барып төртелергә белмичә аптырап, әйләнә-тирәгә шактый каранып торганнан соң гына ул иң аргы өстәлдә буш урын күреп алды.

Фәгыйлә тиз генә барып, ашын, икмәген өстәлгә куйгач, үзе табуреткага утырып, төенчеген тез өстенә урнаштырам дигәндә, башын күтәреп караса—каршында өченчекөн аны кимсетеп әрләгән ике татар аш ашап утыра иде.

Аны күрү белән тегеләр дә, үз күзләренә үзләре ышанмагандай, сәерсенеп калды. Өлкәнрәге—ялан башлы, чал кергән сирәк чәчлесе, Фәгыйлә алдындагы төенчеккә бермәл карап торгач:

—Ник аны гел үзең белән йөртәсең, бирнәң түгелдер ич?—дип, йөзенә чәнечкеле елмаю чыгарды.

Фәгыйлә әрем телле агайга күтәрелеп карамастан:

—Юк, бирнә түгел, төрле чүпрәк-чапрак кына, дип, кашыгын кулына алды.—Калдырырга урыным булмаганлыктан, менә, үзем белән йөртергә туры килә.

Милләттәш агайлар ничектер уңайсызланып калды. Яшьрәге бу күңелсез әңгәмәне икенчегә борып җибәрергә теләде бугай:

—Тукта, анда чүпрәк-чапрак кына түгел шикелле. Төенчегеңнең ачык кырыеннан китапка охшаган нәстә күренеп тора түгелме?

—Әйе, китап. Тукай шигырьләре. Кичә генә базарда сатып алдым. Мин аны яраткан шагыйрем төсе итеп саклыйм. Халкыбызның тиңдәшсез зур талантлы шагыйре бит ул. Аның:

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!
Дөньяда күп нәрсә белдем син туган тел аркылы,—

дип башланган шигырен һәр мәктәп баласы кечкенәдән яттан белеп үсә, гомере буе хәтерендә саклый!

Яңа танышларның яшьрәге ризасызлык белән:

—Акыллым, сөйләвенә караганда син йомры башлы, укымышлы күренәсен—диде. —Ә тормышта үзенне-үзең кимсетеп йөрисең. Барып сыеныр оям да юк, диден. Мондый сукбайлыктан нинди рәхәт табасың?

Бу ихласлы кызыксынудан Фәгыйләнең кинәт күңеле тулып, бик нәүмизләнде. Ул акланырга теләгән сыман әйтә куйды:

—Рәхәт эзләүдән түгел, мин зур бәхетсезлеккә дучар булдым. Хәзер исә кем икәнемне яшереп йөрергә туры килә.—Фәгыйлә башлаган сүзен әйтеп бетермичә телен тешләде, артык әләкләп үзен тоттырудан шикләнде.

Шунлыктан ул ашык-пошык ашап, тиз генә амин тотты да моннан чыгып качты. Причалдан киткәч тә әле һаман тынычлана алмыйча Габдулла Тукайның шигырен такмаклады:

Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,
Үзең кайгыр, үзең егла, үзең көл.

Бу шигырь гыйбрәтле кинәш иде, гүя, Фәгыйләне моннан соң уйлабрак сөйләшергә, артыгын ычкындырмаска, дип, каты кисәтә иде ул.

Шул көннән башлап яңа танышларның Фәгыйләгә карашы сизелерлек йомшарды. Ашханәдә кассага чират торганда үзләре янына чакырып алалар,

бергә утырып ашаганда сүз арасында читләп-читләп аның үткәне, кайда туктавы, бу тирәдә нишләп тулгануы белән кызыксыналар.

Инде хәзер Фәгыйлә аларның агалы-энеле брадәрләр икәнен, портта килгән-киткән пароходларның чалкаларын кабул итеп, тумбага эләктерүче-ычкындыручы булып эшләгәннәрен белде.

Бер анадан туган бала булсалар да, алар бер-берсенә охшамаган. Өлкәне, Закирҗан исемлесе, кыска буйлы, салынкы кашлы ир уртасы кеше. Тормышка кара күзлектән караучы, урынлы-урынсызга төрттерүчән икәнлеге сүз саен сизелеп тора. Менә бүген дә ашханәдә очрашу белән үртәп көләргә тотынды ул:

—Ә-ә, алтын балдаклы хәерче, тагын мөһаҗирләр пароходын озатырга килдеңме? Әллә үзең дә китәргә телисең инде?

Аның энесе Шакирҗан, киресенчә, ягымлы елмаеп исәнләшә, абыйсының тозсыз төрпәлеген йомшартырга теләгәндәй итә:

—Кәефләрең ничек? Ыгы-зыгылы тынчу вокзалда төн үткәрү кыен булгандыр инде?!

—Мин төнемне ачык һавада, вокзал каршындагы бакчада утырган көенчә йокылы-уяулы килеш үткәрдем. Вокзал кешеләре минем поезд көтүче пассажир түгел икәнемне беләләр. Хәзер миңа сукбай итеп карыйлар, залга кертмиләр.

Фәгыйлә моны артык сыкранмыйча әйтсә дә үзе бик алҗыган, тәмам хәлсезләнгән, нәүмизлеге йөзенә чыккан иде. Брадәр швартовчылар аны кызгандылар, күңелләрендә ничек тә ярдәм кулы сузу теләге туды бугай. Үзара күзгә-күз карашып алалар да, Фәгыйлә белән якын таныш кебек җанланып сөйләшә-сөйләшә, өметсез уйларын таратырга тырышалар. Ә кичкырын, эш вакытлары беткәч, әйдә, бездә кунарсың дип, аны да ияртеп китәләр. Башта бераз икеләнсә дә, йортсыз-җирсез Фәгыйлә, Аллага тапшырып, барырга мәҗбүр булды.

Шакирҗанның өе бистә читендә дингез култыгына караган сөзәк тау итәгенә урнашкан. Түбәсендә калайдан кисеп ясалган горуранә кыяфәтле әтәч кукраеп тора. Капкадан керүгә чылбырга тагылган көлтә койрыклы зур сары эт хуҗасын сырпаланып каршылый. Абзар ишеге янында күшәп яткан ак кәҗә, кунак белән танышырга теләгәндәй, килеп Фәгыйләгә сыена.

Тәүлек буе вахтада торып кайткан хуҗаларның арыганлыгы күренеп тора. Шунлыктан, җинелчә ашап-эчкәч тә Закирҗан одеал, мендәр ала да чоланга йокларга чыгып китә. Шакирҗан түр яктагы ян тәрәзә кырыендагы караватта Фәгыйләгә урын җәеп биргәннән соң, үзе мич артындагы тапчанда урын әмәлләп ята.

Күпме вакыт йомшак урын-җир күрмәгән һәм тәмам хәлдән тайган Фәгыйлә башын мендәргә салу белән изрәп китә, күз кабаклары авырая, йокыга тала башлый.

Ләкин ул, кемдер төрткәндәй, сискәнеп уяна. Тукта, бу чит-ят ирләр янына мин ник килдем әле, дип, шомга төшә. Төнге караңгылыкта кыштырдаган тавыш ишетелгән саен кемдер йөргән, акрын гына аяк очларына басып якынайган кебек тоела аңа.

Ул таң алдыннан гына, ниһаять, каты йокыга китә.

* * *

Фәгыйлә ниндидер сәер ят тавышка уянып, кайда икәнен, кем борчыганын абайлый алмыйча, бермәл йокылы-уяулы ятты. Күзләрен ачып караса, иртәнге эңгер сыегая башлаган, яна көн туып килә. Карават янындагы яртылаш ачык тәрәзә каршында ак кәҗә мәэлдәп тора. Шундук йокысы ачылды Фәгыйләнең, көтелмәгән гаҗәпсенү белән ихтыярсыз елмаеп куйды:

—И, сакалбай, син уяттыңмыни мине?!

Ул, Шакирҗанны уятмас өчен аяк очларына басып, акрын гына ишек алдына чыга. Ак кәҗә аны күрү белән килеп сыена, түземсезләнеп

мәэлди-мәэлди сырпалана. Шунда гына Фәгыйлә, аның сөт тулып шешенгән жиленен күреп, казык башында эленеп торган чүлмәкне ала да тынгысыз кәҗәне сава башлый.

Уянгач Шакирҗан хәйран кала:

—Һи, миннән дә алданрак керешкәнсең икән! Гомер булмаган хәл, кичә кәҗәне саварга онытканмын. Күземне ачуга шул исемә төште. Ашыгып чыксам, син инде савып утырасың...

—Җилене авырткан булса кирәк, тәрәзә каршында мәэлдәп ул мине үзе уятты,—ди Фәгыйлә.

Шакирҗан кәҗә белән сугымлык үгез бозауны өй каршындагы яшел чирәмгә чыгарып арканлый. Фәгыйлә тагарак янында чыр-чу килгән тавык-чебешкә көрпә болгатып бирә. Аннары өйгә кереп, бергәләшеп иртәнге аш әзерлиләр.

Алар чүкердәшеп ашап утырганда чоланнан Закирҗан да килеп керә һәм үзалдына сөйләнгән сыман:

—Әһә, борчаклары пешкән икән, юкса болай сайрашмаслары,—дип, астыртын төрттереп ала.

Әмма, аның кинаясен ишетмәгәндәй, Шакирҗан сүзсез ашый бирде. Болар агалы-энеле икесе дә балта осталары, портта бер тәүлек дежур торганнан соң, буш көннәрендә тагын кайдадыр эшләштергәлиләр икән. Бүген дә ашап-эчкәннән соң, эш кораллары тулы сумкаларын иңбашларына асып, юлга кузгалдылар.

Капкадан чыккач, Шакирҗан өйгә кире борылып керде:

—Әйтергә оныта язганмын, мунча бездән ерак түгел, күрше урам чатында гына. Теләсәң, чабынып, юынып кайтырга мөмкин. Сабын, мунчала, сөлге алып барырга онытма. Каен себеркесе чоланда эленеп тора.

Инде күптән мунча күрмәгән, керләнеп беткән Фәгыйлә бер дә кыстатып тормастан, бик рәхәтләнеп мунча кереп кайтты. Чәй эчеп, әзрәк ял итеп алгач, беренче мөмкинлектән файдаланып, иң әүвәл өйлә намазы укыды. Аннары бөтен хуҗалыгын ышанып калдырган Шакирҗанга рәхмәт йөзеннән мендәр тышларын, тәрәзә пәрдәләрен, шул уңайдан үзенең иске халатын юып киптерергә элде, идәнне юып чыгарды. Шакирҗан әйтеп калдырган ит, карабодай ярмасы белән кичкә аш, ботка пешереп куйды.

Кичкырын түр тәрәзәдән дингез култыгына карап утыра торгач ул тагын ниндидер борчулы уйга чумды. Закирҗанның иртәнге кинаяле сүзләре исенә төшеп әрнетте. Хәер, чит ир белән аулак өйдә кунган хатын турында башкаларның да шулай уйлавы бик ихтимал бит. Юк, юк, моңа юл куярга ярамый. Шакирҗан кайту белән рәхмәт әйтеп, моннан тизрәк ычкынырга, фатир һәм эш эзләргә кирәк.

Фәгыйлә әнә шулай борчулы уйларга чумып йөргәндә төштән соң, һич көтмәгәндә, Шакирҗанны атлы арбада шифаханә кучеры кайтарып куйды һәм култыклап өйгә кертергә ярдәм итте. Көтелмәгән бәла: ул тар тактага басып биектә эшләгәндә таеп егылып, сул сыйрагын сындырган. Шифаханәдә гипслап, өйдә дәваланырга кайтарганнар.

Аның чырае көл кебек, иреннәре кара көйгән. Әз генә кыймылдаса да, сызлануы йөзенә чыга, ишетелер-ишетелмәс кенә сыкранып куя. Өйдә үзен генә калдыру мөмкин түгел. Шуңа күрә Фәгыйләгә китү турындагы ниятен кичектереп, яралы авыруны караучы булырга, аш-су әзерләргә, йортта барча эшне башкарырга туры килер.

Төнне авыр үткәрсә дә, иртән Шакирҗанның газаплы сызлавы бераз басылды шикелле. Гипслы аягын борчымас өчен саклык белән торып утыргач, тамагына капкалап, даруын эчте.

—Бик белеп әйткәннәр: саулык—иң зур байлык. Сәламәт булмасаң, тормышның яме китә, берни эшли алмыйсың,—дип, ачыну катнаш шаяртү белән үзеннән-үзе көлгән була бит әле, бичара.—Фәгыйлә, ярый әле син бар, югыйсә бөтенләй ярдәмчесез калачак икәнмен.

Фәгыйлә көнозын аяк өстендә, эш артыннан эш гел табылып тора. Шулай да, юк вакытны бар итеп дигәндәй, бүген төштән соң бер бушрак

арада ул түр тәрәзә янына утырып, беркөн базарда сатып алган китабын актара башлады. Үзе яттан белгән шигырьләрнен исемен күргән саен, якын танышын очраткан кебек, сизелер-сизелмәс кенә көлемсерәп куя.

Аны күзәтеп яткан Шакирҗанга бу сәер тоелса кирәк, дусларча шаярту белән кызыксынгандай итә:

—Һәр сәхифәсен ачкан саен елмаясың. Нинди китап ул, бик хикмәтлемени?

—Менә үзен тынлап кара,—ди Фәгыйлә һәм җанланып укый башлый:

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан,
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

Көрәш угрында[1] ар, тал, тирлә, имгән:
Өмит итмә булышканны ләимнән.

Сәгадәт талына менсән, үзең мен;
Ни ярдәм кылсә дә килсен үзеңнән.

—Ә менә монысы тагы да хикмәтлерәк, тагы да тирәнтенрәк уйлар уята:

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безненчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзелеп-өзелеп кенә әйтеп бирә
Татар күнеле ниләр сизгәнен,
Мескен булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

—Дөрес әйтәсең, чынлап та тирән эчтәлекле, уйландыра торган шигырьләр.—Шакирҗан яткан җиреннән торып утырып, кызыксыну белән сораштыра башлый:—Фәгыйлә, карале, боларны аңларга, болай баш йөртә белергә сине кем өйрәтте? Әллә тумыштанмы, үз тырышлыгың белән ирештеңме?

—Кем әйтмешли, анысы да, монысы да булгандыр инде. Минем әтиәнием мөгаллимнәр иде. Узганда-барганда күрше авылларның мөгаллимнәре дә кергәлиләр, чәй янында халкыбызның фаҗигале язмышы, туган тел, әдәбият, мәгърифәт турында әңгәмә коралар. Мин аларны кызыксынып тыңлыйм. Китапларда, газета-журналларда басылган шигырьләрне, хикәяләрне килү белән ябырылып укый идем. Боларның тәэсире, мөгаен, булмый калмагандыр.

Мондый әңгәмәләр аларга бер-берсе белән якынрак танышырга форсат тудыра. Фәгыйлә үзе турында барысын әйтеп бетермәсә дә Шакирҗанның бирегә моннан җиде ел элек, Лена елгасы буендагы алтын прискаларында забастовкалар бастырылгач, эзәрлекләүдән качып килеп, оя корганын белә. Хатыны былтыр көз йөрәк авыруыннан вафат булган. Шуннан бирле ялгыз яши. Үзе эштә вакытта йортны эте Актырнак саклый, күрше балыкчы карт күз-колак була. Аннары Мәкәрҗәдә йөкче булып көн күрүче абыйсы Закирҗан да, күчеп килеп, монда төпләнә. Гомумән, шәһәрдә татарлар байтак, базарда, кибетләрдә еш очрыйлар, үзара йөрешәләр, аралашалар...

* * *

Җәй уртасында, болытлы караңгы төннәрнең берсендә, таң алдыннан һич тә уйламаганда-көтмәгәндә, портка дистәләрчә япон кораблары керен, кораллы гаскәр төшерә. Шуның катнашы белән шәһәрдә власть акгвардиячеләр кулына күчә, эш башында утыручыларны кулга алулар, атулар башланды. Бик күпләр хәзер төн карасы астында шәһәр тирәсендәге урманнарга кача, моторлы баркасларга төялеп чит илләргә олага. Югыйсә

[1]Угрында—юлында *(иске китапча сүз).*

корал тотарлык һәр ир затны ирексезләп армиягә алалар. Ә аягы төзәлеп бетмәгән Шакирҗан анда-монда чыкмыйча күбрәк өйдә утыра, вак-төяк эшләрдә Фәгыйләгә булышкалый.

Көндезге мәшәкатьләрдән соң кичке аш әзерләгәндә ишегалдында кинәт Сарбайның ярсып өргәне ишетелде. Тәрәзәдән карасалар, капкадан урта буйлы, чигә сакаллы дингезче кергән, эт яныннан үтеп китә алмыйча басып тора. Җиз төймәле күгелҗем китель кигән, шактый зур сумка тоткан. Төп кебек базык гәүдәсеннән, бөтен килбәтеннән көч-куәт бөркелеп тора. Шакирҗан аны күрү белән шундук таныды:

—И-и, кунгас[1] капитаны Борһан ич бу! Күптән күренгәне юк иде, кайдан калкып чыккан тагын?—дип чыгып каршылады ул кунакны. Өйгә кергәч, Фәгыйләгә карап сагаеп калганын сизепме, ул аны тынычландырырга ашыкты:—Борчылма, чит кеше түгел, бертуган абыем кызы. Фәгыйлә сеңлем, әйдә, табыныңны җәй.

Кунак буш кул белән килмәгән. Сумкасыннан тозлаган балык, бишәр банка кызыл уылдык һәм кысла консервасы чыгарды. Өстәл тирәли җыелып утыргач, Борһан ашыккан кешедәй, тиз-тиз сөйләп китте:

—Шакир абый, мин зур йомыш белән әле. Киңәш сорап килдем. Үзең беләсең, бу мәхшәргә, җәберләүләргә түзә алмыйча хәзер күпләр чит илгә күчеп китә. Бу зәхмәтле чир безнең командага да йокты. Иртәдән кичкә хәтле һаман шул хакта бәхәсләшү бара—китәбезме, юкмы? Шакир абый, син күпне күргән башлы кеше. Синең акыллы киңәшләреңне тыңлап, без бу кунгасны шалкан бәясенә генә сатып алдык. Әле дә, тоткан балыгыбызны порт ашханәсенә сатарга ярдәм итәсең. Менә тагын киңәшең кирәк. Безгә нишләргә—китәргәме, юкмы?

—Туганкаем, тиктомалдан болай җинел генә хәл итә торган мәсьәлә түгел бу,—ди Шакирҗан.—Мин аны үзем дә байтактан бирле уйлап йөрим, әмма һич тә очына чыга алмый идем. Атаклы шагыйрь Габдулла агай Тукаев ул хакта инде күптән йөрәккә үтәрлек ачык итеп әйткән:

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне тәңребез (гыйззе вә җәл).

Бу акыллы шигырьне мин Фәгыйлә сеңлем авызыннан ишеттем. Хикмәтле вәгазь кебек әледән-әле искә төшеп тора. Соравыңа җавап итеп ал шуны...

—Әһә, бу җиргә безне тәңребез бәйләмеш, китмибез, дигәнме?! Бик дөрес әйткән. Алайса без дә китмибез, вәссәлам!—Капитан Борһан, өстеннән авыр йөк төшкәндәй, җинел сулап куя.—Шакир абый, белми идем, укымышлы мөлаем сеңлең бар икән. Хәерле киңәшегез өчен икегезгә дә зур рәхмәт.

Кунакны озатып кергәч, Шакирҗан унайсызлану белән:

—Бая сеңлем дип әйткән өчен ачуланма инде, ничектер ялгыш, үзеннән-үзе килеп чыкты,—дип гафу үтенгәндәй итте.

—Зарар юк, ул хакта бер дә борчылма.—Фәгыйләнең авыз кырые белән генә сизелер-сизелмәс елмаюы чалынды.—Алайса мин дә сине Шакир абый дип йөртермен. Күрше-күлән алдында да уңайлырак булыр.

* * *

Шакирҗан балыкчы капитан алдында «сеңлем» дип атаганнан бирле, Фәгыйлә яңа урында үзен иркенрәк тота башлады. Әйткәнне көтеп тормастан, йорт эшләрен үз белдеге белән башкара. Буш араларда берәр эш табылмасмы дип сирәк-мирәк шәһәргә дә чыккалый. Ире Бәхтияр турында ишеткән-белгән берәр якташы очрамасмы дип, төньяктан поезд килгән сәгатләрдә вокзалда булгалый.

Ә базарга барган беркөнне, ул теге ак сакаллы картның борыңгы

[1] Кунгас—14-15 метр озынлыктагы моторлы судно, балык тотуда файдаланыла.

китаплары арасында шәмәхә кара белән гарәпчә кулдан язылган калын дәфтәргә тап була. Алып караса, атаклы «Йосыф китабы»! Шактый таушалган булса да, танып укырлык әле. Фәгыйлә шатлыктан чут кычкырып җибәрми. Ул кулъязма китапны шундук сатып алып, урамда укый-укый кайта.

Ә эш һаман табылмый, ялкау әрәмтамак кебек һаман чит кешедә яшәргә туры килә. Бу хәл шактый озакка сузыла. Вак-төяк йомыш белән кергәли торган күрше-күлән дә, йөрешә торган таныш-белешләре дә Фәгыйләгә инде Шакирҗан хатыны итеп карыйлар. Хәтта сирәк-мирәк килгәләүче абыйсы Закирҗан да болар турында, никахлап өйләнешмичә генә ир белән хатын кебек торалар, дип уйлый. Фәгыйлә моны авыр кичерә, бу гайре табигый кыенлыктан ничек котылырга белмичә көенә.

Җитмәсә, уч иткән кебек, Шакирҗанның да кәефсез вакыты. Аягы күптән төзәлүгә карамастан, эшсез йөри. Чөнки портта японнар хуҗа, һәркайда шулар башбаштаклык итә.

Мәгәр замана ыгы-зыгылы, авыр булса да, тормыш тукталып тормый. Эреле-ваклы мәшәкатьләре, кайгы-шатлыклары белән үз юлыннан өзлексез бара бирә. Әнә, һичнигә карамастан, капитан Борһан да мәш килеп, хатыны Салисәнең туган көнен бәйрәм итәргә әзерләнеп йөри. Шакирҗан белән бергә кунакка Фәгыйләне дә чакырганнар иде, ул каршы төште:

—Һич бара алмыйм, кеше көлкесенә калырга теләмим!—диде.

—Юк, бармыйча ярамый, сеңлем,—дип, Шакирҗан аны күндерергә тырышты.—Очраган саен Салисә гел сине сораштыра, танышырга тели. Кабат-кабат әйтеп чакырды, алып килмәсәң, бик үпкәлим диде.

Әлбәттә, Фәгыйлә теләмәсә дә барырга мәҗбүр. Шуның өстенә, хәстәрле Шакирҗан, юбилярга бүләккә, япон халаты—кин итәкле, кыска җиңле, сары чәчәкле матур кимоно алып куйган икән. Ядкарьне кинәшмичә үзе генә әзерләгән өчен уңайсызланган сыман:

—Салисә буйга синең белән бер чамада, шуны күздә тотып алдым. Кая, ничек ята икән?—дип затлы халатны Фәгыйләнең инбашына салып, җиңелчә шаяртып алды.

Алар барып кергәндә кунаклар инде җыелган була. Тәрәзәдән күзәтеп торган, ахры, ишектән керүгә хуҗа хатын Салисә беренче булып ачык йөз белән:

—Әйдәгез, әйдә, рәхим итегез. Килеп бик яхшы иткәнсез, алга узыгыз,—дип аларны ягымлы каршылап һәм олылап түр башына утыртты.

Кунаклар барысы да диярлек бер даирә кешеләренә охшаган—яшь гаиләле парлар. Өлкәнрәк яшьтәгеләрдән бер үзе килгән Закирҗан гына.

Табын тиз җанланып китте. Шау-гөр килеп юбилярны тәбрикләүләр башланды. Салисә Шакирҗанның халатын шундук кия, җылы сүзләрен, дустанә теләкләрен дулкынланып тыңлый, бүләге өчен рәхмәт әйтә.

Аннары, тост күтәргәннән соң, Фәгыйлә белән Шакирҗан янына барып басты да:

—Менә сезгә карап торам да шаккатам, бер-берегез өчен яратылган кебек, бигрәк тә пар килгәнсез. Сер булмаса, без дә белик әле, сез ничек табыштыгыз?—дип әйтте дә салды.

Болар ничек җавап бирергә белмичә икесе дә аптырап тора. Телдән язган кебек сүзсез утыру озакка сузылгач, Фәгыйлә чарасыздан:

—Мин берни дә әйтә алмыйм, әнә ул сөйләсен,—дип Шакирҗанга күрсәтергә мәҗбүр булды.

Дәресен хәзерләмәгән шәкерт кебек, Шакирҗан да ык-мык итә, авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс нидер мыгырдап, җавап бирүдән котылырга ниятли.

Салисә исә һаман үзенекен тукый:

—Тартынып торма, ничек булган булса, шулай әйт тә бир,—ди.

—Алай икәнен мин үзем дә беләм. Ә менә юкны, булмаганны ничек сөйләмәк кирәк.

—Чү, туктале, мина барып җитми бу. Нәрсә югын, нәрсә булмаганын, зинһар, кеше аңларлык ачыграк итеп әйтеп бир...

Табында тынлык. Барысы да әсәренеп кала. Фәгыйлә, юк йомышны бар итеп дигәндәй, мыштым гына почмак якка чыгып сыза. Шакирҗан, каршындагы тәлинкәсенә карап утырган хәлдә, үзалдына сөйләнгән сыман:

—Бернинди табышу, пар килү юк. Фәгыйлә бездә болай гына, вакытлы фатирчы булып кына тора,—дип, бөтен серне ачып бирде.

Ишетелер-ишетелмәс кенә әйтелгән бу сүзләр кунакларга аяз көнне яшен суккандай тәэсир итте, үз колакларына үзләре ышанмыйча һәммәсе дә шым калды.

Әлеге дә баягы дигәндәй, иң әүвәл хуҗа хатын Салисә күз кырые белән генә Шакирҗанга кырын карап ризасызлыгын сиздерде:

—Ничек инде болай гына, фатирчы булып кына?!—Аннан соң ул Закирҗанга ташланды.—Ә син безгә нәрсә сөйләгән идең? Уйдырма, гайбәт тарату гына булдымыни ул?..

—Билләһи менә, һич тә гайбәт таратудан түгел, ялгышканмын мин,—дип каргана-каргана Закирҗан акланырга тотынды.—Бер өйдә яшәгәч, уртак табактан ашагач, алар инде гаилә корган, ирле-хатынлы булган шикелле иң. Ә Фәгыйлә анда тулы хокуклы хуҗа хатын кеби, йорт эшләре аның кулында.

Шакирҗан да шуны кабатлый:

—Хак сүз, дөрестән дә шулай. Мин йөри алмыйча хаста ятканда бердәнбер ярдәмчем Фәгыйлә иде. Бөтен өй эшләрен үз өстенә алып, үзе белеп, җиренә житкереп башкарды. Күрәсез, килбәте, шулай ук табигатехолкы да тел-теш тидерерлек түгел.

—Соң шулай булгач, син, акыллы баш, ник өйләнмисең аңа?—ди Салисә.—Әллә өнәмисенме, әйбәтрәкне эзлисеңме?

—Юк, өнәүдән дә, әйбәтрәкне эзләүдән дә түгел. Бүтән мөһимрәк сәбәбе бар аның.—Шакирҗан әйтер сүзен таба алмагандай тукталып, бермәл ык-мык итеп торганнан соң гына, абына-сөртенә дәвам итте:—Фәгыйлә мөгаллимнәр гаиләсендә туып-үскән укымышлы, зыялы зат. Шагыйрь Тукай шигырьләрен күнелдән белә. Борынгы мөнәҗәтләрне, тарихи бәетләрне көйләп сөйли. Ә мин кем?.. Шуңа күрә өйләнү турында сүз кузгатырга һич телем бармый. Урынлы-урынсыз сүз ычкындырып, хәтерен калдырудан шикләнәм.

—И-и, тәти абыем, бигрәк тә куркак куян икәнсең,—диде Салисә юри уфылдап.—Турысын әйтим, синең ише баһадирга артык кыюсызлык бер дә килешми. Һаман шулай тәвәккәлсез йөрсәң, гомергә карт буйдак булып калуың ихтимал.

Әлегә тикле сүзсез генә елмаеп утырган Борһан үтә житди кыяфәт белән сүзне икенчегә борды:

—Салисә жаным, синең бу хикмәтле вәгазьләреңә Шакирҗан абый, мөгаен, колак салмыйча калмас. Шулай да татлы телеңә аз гына ял биреп тор. Әйдә, җырга күчик әле. Син миңа булышырга тырыш.

Аннары ул комод өстендәге бәләкәй тальян гармунын алып, сагыну көенә, моңлы тавыш белән үзәк өздереп җыру сузды:

Үз илләремдә чагында
Киң урамнар тар иде...

Салисә һәм башкалар да, аңа кушылып, жырны бергәләп дәррәү күтәреп алдылар:

Кин урамнарны тар итеп
Йөргән чаклар бар иде.

Борһан бик тә оста гармунчы икән. Кунакларны күп төрле көйләргә жырлата, хатын-кызны такмак әйтә-әйтә биетеп тә ала. Азакка таба, табын тынып торган берарада, Шакирҗанга таба борылып үртәп алырга да өлгерә:

—Синең хәйләкәрлегеңне беләм мин, әмма мин дә ачык авыз түгел. Теге чакны сездә булганда Фәгыйлә апайны сенлең итеп таныштыруга шундук шигем туды. Чөнки күзләрең бүтәнчәрәк сөйли...

Көтмәгәндә унайсызланып калган Шакирҗан ирексездән, май кап,

күп шаулама, дигәндәй, бармак янап куя. Бу шаяртуны почмак якта шыпырт кына тынлап торган Фәгыйлә ирексездән елмаеп, берни дә ишетмәгәндәй, сүзсез генә табынга чыгып утыра.

Хуҗалар аларны иң азактан ирле-хатынлы икәүләшеп озата чыктылар. Тынгысыз Салисә Шакирҗанга акыл өйрәтүдән туктый алмады:

—Караңгыда абынып, егыла күрмәсен, Фәгыйлә апайны менә болай култыклап алып кайтырга тырыш. Бер-берегезгә ышанып тормыш юлдашы булыгыз, исән-имин кайтып житегез...

* * *

Япон самурайларның дүрт ел дәвам иткән башбаштаклыгы исәпсез-хисапсыз бәла-каза китерде. Шәһәрнең дошманнан азат ителүе хезмәт халкы өчен, ниһаять, зарыгып көтеп алган тыныч тормышка ирешү иде.

Аягы төзәлгәннән соң байтак вакыт беркая урнаша алмыйча йөргән Шакирҗан да портта элекке урынында эшли башлады. Шуның өстенә Борһан командасы тоткан балыкны ашханәләргә, базар харчевняларына сатарга булышып та бераз файда күрә ул.

Салисәләр мәжлесендә уен-көлке арасында аларның ирле-хатынлы да, агалы-сеңелле туганнар да түгеллеге ачылу бигрәк тә Фәгыйләне уңайсыз хәлгә куйды. Иң яманы—бу төрле имеш-мимеш гайбәтләргә азык бирәчәк. Оятсыз күз, буйдак ир белән ачыктан-ачык никахсыз тора, дип, бөтен бистәгә яманат таратачаклар.

Такта тротуарлы караңгы урамнан култыклашып кайтканда Шакирҗан бу зарга әллә ни игътибар итмәскә кушты:

—Барысына да төкер, юкка борчылма! Әгәр теләсәң, барысының да авызын көне-сәгате белән капларга мөмкин. Бар эш синнән генә тора.

Аның тел төбендә ни ятканын—үзенә тормыш юлдашы булырга үтенгәнен Фәгыйлә белеп тора һәм шул фикерне тагын кабатлатмас өченме җавап бирергә ашыкты:

—Ул хакта хәзергә авыз да ачма, кыстама. Йә, үзең уйлап кара, никахлы хәләл җефетле башым белән ничек икенче иргә чыгыйм мин? Әгәр ул исән булып табылса, Ходайга ни әйтербез?

—Инде күптән бакый йортта бит ул. Аларның аталы-уллы икесе дә боз астына батып һәлак булганын беләсең ләбаса.

—Ул хакта мин үз күзләре белән күрмәгән, чит-ят кешенең башка берәүдән ишеткән хәбәреннән генә беләм. Аның замана үзгәргәнне көтеп кайдадыр аулакта яшеренеп ятуы, көне-сәгате белән калкып чыгуы бик ихтимал. Күп гаиләләр әнә шулай табыша. Сиңа инде ияләшеп, тәмам үз итсәм дә, мин иртәгә үк берәр таныш-белешкә күчәргә, эш эзли башларга мәҗбүрмен. Мин синең яхшылыкларыңны онытмам, гомерем буе рәхмәтле булырмын.

* * *

Фәгыйлә бүген гадәттәгедән иртәрәк уянды һәм йокыдан арыну белән кичәге карарын хәтерләде. Шакирҗанның берничә мәртәбә: «Мине ялгыз калдырып китәргә ник ашыгасың? Беркая китмә»,—дип ялварып әйткән сүзләрен кабат ишеткәндәй, күңеле йомшарды. Әмма ул йомшаклыкка бирешмәскә, сүзендә нык торырга карар кылды. Кичтән әзерләп куйган кечерәк кенә төенчеген култык астына кыстырды да, Шакирҗанны уятмас өчен аяк очларына басып, акрын гына өйдән чыгып китте. Ишегалдында аны күреп сөенгән Сакалбай кәҗә белән бәйдәге эт Актырнак янында да озак тукталып тормады, башларыннан сыйпап кына саубуллашты һәм күңеле тула башлавын сизеп, тизрәк китеп барды.

Эш эзләп кая булса да барырга, фатир турында белешергә, күргән-белгән кешегә керергә әле иртә иде. Шәһәр үзәгенә житәрәк тукталып калды ул. Кая юл тотарга белмичә, бераз уйланып торганнан соң, таныш

урамнан тимер юл вокзалына төште. Стенадагы расписаниедән карап ике сәгатьтән Мәскәү поезды килеп житәчәген белде. Безнең яклардан берәр күргән-белгән таныш кеше очрамасмы дип шуны көтәргә булды.

Поезд нәкъ вакытында килеп житте. Вагоннардан төшкән халыкның күпчелеге шәһәргә тарала. Пароходларга төялеп чит илләргә китүчеләр, багажларын күтәреп, баераклары йөкчеләр яллап, портка таба борылды. Фәгыйлә дә берәрсен очратырга өметләнеп шунда юнәлде. Юл уңаенда бер аксак картның чемоданын күтәреп илткән өчен азрак акча да төшерде. Һәм элегрәк, бер тиенгә тилмереп йөргән авыр көннәрдә, шушы һөнәрдән файдалана белмәгәне өчен хәтта үзен-үзе җинелчә шелтәләп тә алды.

Причалда якташларыннан беркем дә очрамагач, ул кичә Салисәләрдә танышкан хатын—ресторанда официантка булып эшләүче Җамалияне эзләп китте. Әмма ул, үч иткәндәй, бүген көндез ял итә, кич белән генә эшкә чыгачак икән.

Башка барыр жире булмаган Фагыйлә күрше урамдагы «талчук» базарына китте.

Китап өчен акча түләп маташканда, алар янына кара җилән, киң читле эшләпә кигән өлкән яшьләрдәге ир кеше килеп, китапчы бабай белән ике куллап күрешкәч, хәл-әхвәлен сорашкан арада Фәгыйләне тиз генә күздән кичереп өлгерде:

—Кыяфәтең белән мөслимәгә охшагансың, әссәламегаләйкем, кызым. Болай сау-сәламәт күренәсең, әнә китап алырга җыенасың бугай. Бу якларга кайдан, ничек килеп чыктың? Әтиең, әниең кемнәр?

Кара-тутлы агай бераз колакка катырак бугай. Фәгыйлә үзенең кайдан, кем икәнен әйткәч:—Троицк шәһәреннәнмени?—дип кабатлап сорады.—Мин үзем дә шул яктан. Ирең Бәхтиярны да, кайнатаң Әхмәтҗан байны да күреп белә идем. Алар, аталы-уллы икесе дә давыллы-фетнәле көннәрдә, тоткынлыктан качып киткән төнне, Уй елгасында көзге юка боз астына батып харап булдылар... Уникe кешедән бары тик берәве генә исән котылган. Бөтен шәһәр халкын тетрәткән коточкыч фажига булды бу. Аларга багышлап бәет тә чыкты. Мәрхүмнәрнең авыр туфрагы җиңел булсын, амин!

Ул саубуллашып китә башлагач, кинәт нидер исенә төшергәндәй, Фәгыйләгә борылды:

—Без, туган-үскән жирдән еракта яшәүче татарлар, үзара элемтәдә торабыз, бер-беребезгә кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Кирәк булсам-нитсәм, минем адресны менә шушы бабайдан белешерсең...

Хәзрәт үзе күздән югалса да, аның: «Алар икесе дә харап булды»,—дип әйткән шомлы сүзләре, Фәгыйлә колагында озак чыңлап торды. Алайса теге чакта таралган ул хәбәр дөреслеккә туры килә. Димәк, алар инде моннан биш ел элек үк гүр иясе булганнар.

Бермәл мингерәеп торганнан соң, Фәгыйлә һушына килеп, якында басып торган мөслимә хәерче карчыкка мәрхүмнәр рухына атап садака бирде.

Базардан чыгып, кая барырга белмичә, күңелсез уйларга чумган хәлдә урам буйлап йөри торгач, кичкырын бистә читенә, бүтән кире кайтмаска дип киткән таныш йорт каршына килеп басты.

* * *

Алар өйалды бусагасында кара-каршы очраштылар. Шакирҗанның портка төнге сменага чыгып барышы икән. Фәгыйләне күрү белән җәенке кашлары күтәрелеп, уйчан йөзе яктырып китте:

—И-и, кайтып бик әйбәт иткәнсең. Озын гомерле булырсың, әле генә сине юксынып утыра идем. Синсез өйдә күңелсез, табынга утырып ашыйсы килми... Кемнәрдер гаеп итмәгәе дип, мине ялгыз калдырдың да киттең. Кая барып эзләргә белми аптырадым,—дип өтәлә ул.

Моны күреп Фәгыйлә дә, ярый әле кайтырга булдым дип ягымлы елмаеп куя. Ә Шакирҗан исә, әле һаман куанычын тыя алмый:

—Якын итеп кайтуыңа бик шатмын! Үз өең итеп урнаш, чишен, аша-

эч. Кичке аш мич алдында. Мин сина да әзерләгәнием, суынмагандыр әле. Бер дә борчылмыйча, күнелсез уйларга бирелмичә, иркенләп ял ит. Ә хәзер минә сменага төшми ярамый. Үзем генә калдым дип, күнелсезләнмә.

Фәгыйлә аны капкадан чыгып киткәнче тәрәзәдән карап озатып калыр.

Шул ук җәйне, бераз вакыт үткәч, алар загста язылышып һәм Әдһәм хәзрәттән никах укытып, гаилә төзиләр; берничә пар дус-иш белән күнелле генә туй мәҗлесе үткәреп, ирле-хатынлы буларак әйбәт кенә яши башлыйлар.

* * *

Ятим балалар йорты, хәрби казарма режимы сыман, махсус эчке тәртип кагыйдәләре буенча яши. Хәзер монда көн уртасы. Дәресләрдән бушаган балалар көндезге аштан соң бүлмәләргә, көндезге ялга таралды. Шау-гөр килеп торган спортзал, вестибюль, коридорлар бушап калды.

Иртәдән бирле аяк өстендә йөреп шактый алҗыган Фәгыйлә дә, бераз ял итәргә теләп балконга чыгып утырды. Кәрниз өстеннән булса кирәк, якында гына үзара серләшкәндәй күгәрченнәрнен күнелле гөрләгәне ишетелә.

Әле кайчан гына ул күгәрченнәр алар алтау булып, малайлар ясаган иркен кетәктә әйбәт кенә яшиләр иде. Былтыр, бер явызы ут төртеп яндыргач, икесе шунда харап булды. Икесе кыр күгәрченнәре белән каядыр китеп юкка чыкты. Өченче пары туган-үскән урынын ташлап китәргә теләмәде, ахрысы. Шунда калдылар, сарай очырмасында оя әмәлләп гомер итәләр. Аларнын ягымлы гөрләгәненә тәэсирләнеп утырган Фәгыйлә үзе дә көтмәгәндә эчке дулкынлану белән: менә без өйләнешкәнгә дә егерме биш ел үтте дип уйлап куя.

Шөкер, алар, бер-берсенен кадерен белеп, тату яшиләр. Фәгыйлә эшкә керергә теләвен әйткәч, Шакирҗан аны бер якын танышы ярдәме белән балалар йорты ашханәсенә урнаштыра. Паспорты булмаганлыктан, аны вакытлы рәвештә савыт-саба юучы, җыештыручы итеп алалар. Һәр эшне тырышып, җиренә җиткереп башкара. Үз вазифасыннан тыш, Борһан командасы китергән балыкны һәм бәрәңге чистартуда җиң сызганып катнаша.

Өч айлык срогы беткәч, ана бүтән килмә дип әйтүче булмый, ул эшли бирә. Ай артыннан ай үтә, ел тула, эшләү һәмишә дәвам итә. Кешелеклеге, эшкә унганлыгы өчен хезмәттәшләре аны үз күрә профсоюз комитетына әгъза итеп сайлыйлар.

Көннәрдән бер көнне, стена газетасында, китапханәнен эшләмәве, ниндидер чиновникнын китапханәче штатын кыскарту аркасында йөзләгән баланың матур әдәбият укудан мәхрүм ителүе турында борчылып язылган имзасыз мәкалә чыга. Күләме кыска гына булса да бу язма директор бүлмәсендә зур сөйләшү кузгатырга этәреш бирә. Һәрьяклап уйлашкан-кинәшкәннән сон профком әгъзасы Фәгыйләне, кухня штатында саналган хәлдә, вакытлы рәвештә китапханәче итеп күчерәләр.

Балачактан әдәбиятны яратып үскән Фәгыйлә бу эшкә бик теләп алына. Сукбайлыкта йөреп тупасланган балаларны әдәби әсәрләр укырга җәлеп итеп, саф күнелле героик образлар үрнәгендә дөрес юлга бастырырга тырыша ул.

Болар арасында татар, башкорт, казакъ, төркмән балалары да бар. Кайберләре урысча начар белә. Шунлыктан башта авыр укысалар да тора-бара шомаралар. Акрынлап телләре ачыла, дәресләрне җинелрәк үзләштерәләр. Фәгыйлә аларга Тукай шигырьләрен укып күзләрен ачарга, киләчәкләре турында уйлый белергә өйрәтә.

Ә былтыр көз, бер мөселман мәрхүмне искә алу кичәсендә, Әдһәм хәзрәт авырып килмәгәнлектән, анын өчен Коръән аятьләрен Фәгыйлә укый һәм тынлаучыларда әйбәт тәэсир калдыра. Шуннан сон берәрсенә ясин чыгарга, дога кылырга, мәрхүмне искә алырга кирәк булса, яисә уразада авыз ачу—ифтар мәҗлесе үткәрсә, күбрәк Фәгыйләне чакыра башладылар. Үзара сөйләшкәндә сүз чыкса, аны «Алтын балдаклы абыстай»,— дип ихтирам белән телгә алалар.

* * *

Утызынчы еллар азагында япон милитаристларының басып керү куркынычы тугач, Тын океан хәрби флотын ныгыту башлана—ул Идел, Кама, Агыйдел елгачылары белән тулыландырыла. Алар арасында махсус югары һәм урта белемле татар яшьләре дә байтак була. Шундый хәрби дингезчеләрдән Мөхәммәтвафа исемле бер егет портта Шакирҗан белән якыннан таныша, бәйрәм көннәрендә, эштән буш вакытларында аларга килгәли, тиздән үз кеше булып китә. Ул Тукай шигырьләрен бик ярата, шагыйрьнең яңалифчә басылган китабы да бар, кая барса да, аны үзе белән йөртә, күңеле төшенке минутларда шуны укып җан азыгы ала икән. Фәгыйләнең кайчандыр Тукай белән таныш булганын, ике айдан артык вакыт дәвамында ана аш-су әзерләгәнен, бүлмәсен җыештырганын белгәч, ул, үз колакларына үзе ышанмагандай тәмам мөкиббән була, килгән саен кызыксынып сораштыра.

Бу хакта Мөхәммәтвафа хәрби авиациядә хезмәт итүче танылган шагыйрь Салих Батталга да сөйләгән икән. Менә шуны Фәгыйлә абыстай белән таныштырырга алып килгән. Тукайның казакъ даласына кымызга баруы турында Баттал элек бераз хәбәрдар булса да, Фәгыйләне игътибар белән тыңлый, күп сүзләрен, кабат-кабат әйттереп, барысын да кесә дәфтәренә язып бара.

Боларга Баттал икенче тапкыр рәхим иткәндә, аның белән бергә шәһәрнең үзәк почтасында эшләүче урта яшьләрдәге сөйкемле генә бер татар хатыны Әмирә дә килә. Ачык йөзле, тасма телле, җинел аралашучан икән үзе. Бусаганы атлап исәнләшү белән, күптәнге якын танышларына кергәндәй бәйнә-бәйнә сөйләп китте:

—Баттал Мәскәүдән, Казаннан килгән хатларны безгә почтага үзе кереп ала, мин аның белән шунда таныштым. Сезнең хакта да анардан ишетеп белдем. Тере Тукай белән таныш булган, азмы-күпме аралашкан кешене күрү—чынлап та бик кызык бит. Ә сезнең өчен, Фәгыйлә апай, ул очрашу, мөгаен, онытылмас истәлекле зур вакыйга булып калгандыр.

Йомшак күңелле Фәгыйлә бу җылы сүзләрдән эреп киткәндәй, аны якты чырай белән кабул итә, хәзинәдә булган аш-суы белән кыстый-кыстый сыйлый.

Шакирҗанның эштә вакыты иде. Баттал дингез култыгына су коеныргa төшеп китте. Табын янында икәү генә калгач, кинәт теле чишелеп киткән Фәгыйлә игътибар белән тыңлый белүче Әмирәгә Тукай турында да, үз башыннан кичкәннәрне дә сөйләп эчен бушатты.

Тиздән алар якын сердәш, ахирәт дуслар булып китәләр. Әмирә аларга еш килгәли, өйдә икәү генә булган вакытларда Фәгыйләнең Габдулла Тукай шигырьләрен, «Йосыф китабы»н көйләп укыганын тыңларга ярата. Берничә тапкыр ул, каяндыр кайтышлый, Фәгыйләнең эшләгән җиренә дә кереп чыга. Аның урысча начар белүче мөселман балаларга дәрес хәзерләргә, үсә төшкәннәренә һөнәр сайларга, намуслы тормыш юлына басарга аналарча эчкерсез булышканын күреп таң кала.

Шуннан соң күп тә үтми, Фәгыйлә белән Шакирҗан эштә вакытта, боларның өенә кемнәрдер кергән, бөтен әйбер асты өскә актарылган була. Тентү ясаганнар, нәрсәдер эзләгәннәр бугай. Болай бернәрсә дә урланмаган шикелле. Фәгыйләнең комод өстендәге Кол Гали, Тукай китаплары һәм «Идегәй» дастаны басылган «Совет әдәбияты» журналы гына юкка чыккан.

Алар моны ничек аңларга, нәрсәгә юрарга белмичә аптырашка төшсәләр дә, һәрьяклап уйлаганнан соң ул хакта хәзергә беркая хәбәр итмәскә, башы-азагы шул булсын дип, эчкә йотып калырга булалар.

* * *

Бу арада Фәгыйләнең колагына һаман бер сүз—юбилей дигән сүз чалына башлады. Шуның белән янәшә еш кына аның исемен дә телгә алалар. Аннары профком рәисе белән бер фотограф керә дә китапханәдә

өстәл янында утырган хәлдә аны рәсемгә төшереп ала.

Рәсемнең мактау тактасына куелырга тиешлеген ул соңыннан, фотограф чыгып киткәч кенә белә һәм катгый рәвештә мона каршы килә. Профком рәисен көндерә алмагач, әсәренеп директор янына керә:

—Мин гади бер тәрбияче-китапханәче, мактау тактасына куярлык берни дә эшләгәнем юк. Рәсемемне шунда куеп мине кеше көлкесенә калдырмагыз, ди ул зинһарлап үтенгәндәй.

Балалар йорты директоры, керәшен татары, кайчандыр Фәгыйләне ашханәгә җыештыручы итеп алган, тәрбияче-китапханәче итеп күчергән, айлык курска укырга җибәргән карт педагог Александр Николаевич, гадәтенчә игътибар белән тыңласа да, аңа каршы килә:

—Үзегез дә беләсез, бездә балигъ булган балаларыбызның һәм түгәрәк датасы тулган хезмәттәшләребезнең юбилеен бергәләп үткәрү йоласы бар. Бездә эшли башлавыгызга егерме биш ел тулуны бергәләп бәйрәм итәргә булдык, шул хакта радио аша да хәбәр иттек. Сез карышмагыз инде. Югыйсә кыланчыклану, үҗәтләнү сыман килеп чыга.

Фәгыйлә үз сүзеннән чигенергә теләмичә:

—Сез дөрес әйтәсез, мин мона риза, әмма мине тагын бер шомлы вакыйга борчый,—диде һәм кичә көндез үзләре эштә вакытта өйләренә кемдер кереп тентү ясавы турында сөйләп бирде.—Шунысы сәер, бөтен әйберне актарып, астын өскә китерсәләр дә бернәрсәне дә урламаганнар. Гарәпчә язулы борынгы берничә китабым һәм журналым гына юкка чыккан. Шымчылар эшенә охшаган. Кемнәрдер казына, иснәнә бугай. Берәр күңелсезлек килеп чыкмагае дим.

Директор бераз уйланып торганнан соң үзалдына сөйләнгәндәй:

—Әйе, шулай булса кирәк,—диде.—Күптән түгел миңа телефоннан бер ир кеше шалтыратып, бездә ялган фамилияле динче, милләтче хатын эшләгәнен хәбәр итте. Мин кайдан, кем шалтыратуын сорагач, җавап бирмичә, телефон трубкасын элеп куйды. Әмма без, күп еллар кулга-кул тотынып эшләгәч, бер-беребезне яхшы беләбез. Кемнәрнендер итәк астыннан ут йөртүләренә карап, паникага бирелмәскә, ятимнәребезне аякка бастырырга бурычлыбыз.

* * *

Кичкырын эштән соң өенә кайтып житәрәк Фәгыйлә үзләренең капка төбендәге эскәмиядә ике хәрби диңгезче утырганын күреп шиккә төште. Һәм ихтыярсыз тукталып калды. Тик бераз якынрак килгәч кенә ул аларның үз кешеләр—шагыйрь Салих Баттал белән Мөхәммәтвафа икәнен танып жиңел сулап куйды. Каушавыннан тиз генә арынып, күтәренке күр тавыш белән кунакларны өйгә дәште:

—Күптән күренгәнегез юк, кая югалдыгыз? Әйдә рәхим итегез!

Хәл-әхвәлләрен сораштыра-сораштыра Фәгыйлә самавыр куеп җибәрде.

—Фәгыйлә түти, зинһар, мәшәкатьләнмәгез, без берничә минутка гына бер йомыш белән килдек, ашыгабыз,—дип Баттал туктатмакчы булган иде.

Әмма Фәгыйлә, аңа авыз ачарга да ирек бирмичә, сәгате-минуты белән табын әзерләде. Шакирҗан кичке сменага китәр алдыннан итле пылау пешереп калдырган икән. Шуны тиз генә җылытып китерде, башка тәм-том куйды, чынаякларга чәй ясады.

Тамак ялгап, берәр чынаяк чәй эчкәч, Баттал кул сәгатенә карап алды да, сый-хөрмәт өчен рәхмәт әйтте.

—Миңа китәргә вакыт, юкса поездга соңга калам. «Совет әдәбияты» журналының «Идегәй» дастаны басылган санын мин Мөхәммәтвафага укырга биргән идем. Үзе укыгач, ул аны сезгә биргән икән. Без шуны алырга килдек.

Фәгыйлә телдән язган кебек тынып калды, әйтер сүзен эзләгәндәй стена буендагы комод өстенә карады:

—Тукай шигырьләре, «Йосыф китабы» белән бергә журнал да минә шушында тора иде. Үзебез юк вакытта кемнәрдер кереп өйдә тентү ясаган, нәрсәдер эзләгән. Болай бер әйбергә тимәгәннәр шикелле, комод өстендәге журналны, китапларны гына алып чыкканнар.

Кинәт шаккатудан Мөхәммәтвафаның күзләре шар булды:

—Нинди гөнаһ шомлыгы бу! Үзебез юк вакытта нәкъ шундый тентү безнең фатирда да булган. Бигрәк тә китап киштәсендә казынганнар. Бер яраткан китабымны—Садри Җәләлнең «Дим буенда» дигән повестен алып чыкканнар.

—Бу әсәрләр хәзер икесе дә тыелган санала, аларны укучы, таратучылар буржуаз милләтчелектә гаепләнә,—диде Салих Баттал.—Димәк, безнең тирәдә чуалучылардан кемдер моны белгән, тиешле власть органнарына җиткергән. Хәзер шул сигналны дәлилләп исбатлар өчен материал җыялар булса кирәк.

Бу әләкче кем булыр икән дип барысы да аптырап калдылар, аралашкан һәр милләттәшне күздән кичерделәр, фикерләштеләр. Уйлап-уйлап та очына чыга алмагач, Мөхәммәтвафа үзалдына сөйләнгәндәй әйтә куйды:

—Беркөн сездә булганда, Фәгыйлә апай, синең ахирәт дустың, Әмирә Тукай китабын да, «Идегәй» дастаны басылган журналны да кабат-кабат актарып, укып утырган иде. Ул ханым почтада цензор булып эшли, хәрби корабларда хезмәт итүче татар егетләренә килгән-киткән хатларны шул тикшереп үткәрә. Тыюлы саналган хәбәрләр, хезмәттән зарланулар очраса, власть органнарына сигнал җиткерә. Андый хат авторларын яшертен күзәтү башлана. Бу китапларның югалуларына да шунын кулы уйнамаганмы дип шикләнәм.

—Ихтимал, аның шундый шикле тип булуы бик мөмкин,—дип Салих Баттал да сүзгә кушылды.—Узган сишәмбедә вокзалга кичке поездга төшеп барганда Әмирәнең шәһәр эчке эшләр бүлеге болдырыннан төшеп килгәнен үзем күрдем һәм бу монда нишләп йөри икән дип гаҗәпкә калган идем. Ул да мине ерактан күреп алды һәм, кинәт коты чыккандай, яшен тизлеге белән кире кереп күздән югалды.

Фәгыйләнең чыраена ризасызлык чыкты, беравык уйга чумып утырды да:

—Сез икегез дә артык шикләнәсез, гаепсез кешегә нахак бәла тагасыз шикелле,—диде.—Әмирә белән без турылыклы ахирәтләр, ул миңа каршы андый явызлык кылмас дип ышанам.

* * *

Эчке эшләр бүлекчәсенең хатын-кызлар камерасы коридор кебек озынча тар бүлмәдә. Стена буйлап сузылган такта сәке төнлә кулга алынган исерек маржалар белән тулы. Һавасы тынчу, күңел болгаткыч сасы, кандалалары усал, бер минут та тынгылык бирмичә аяусыз талый.

Кичтән кулга алынган Фәгыйләне, шунда төн кундырганнан соң, иртән допроска чакырып чыгардылар. Ул тикшерүчене күрү белән: «Чү, кайчандыр безгә утарга кунакка килгән Куртай ич бу! Кәҗә тәкәсе кебек тагылып тенкәгә тигән иде»,—дип гаҗәпләнде ул һәм таныш кешесен очратудан эченә җылы кергәндәй булды. Әмма Троицк милиция бүлегендә рәхимсез каныгуын хәтерләү белән өмет чаткысы шундук сүнде.

Куртай сизелерлек калынайган, чал чәче элеккечә кашсыз мангаена салынган. Кайчандыр уйнак күренгән йөзе, көзге яфрак төсле саргайган. Сүнек күзләре белән көчәнеп күрергә теләгәндәй беравык текәп карап торганнан соң, яшь чаклары исенә төште бугай, үчле елмаю белән:

—Әһә, хәтерлим, сез теге чакны Троицк төрмәсеннән качып эзсез югалдыгыз бит,—диде ул урысчалап.—Монда килеп оялагансыз, «Алтын балдаклы абыстай» булып начар дан казангансыз, монда җинаятьле юлга баскансыз. Сез хәзер, погранзонадагы ябык шәһәрдә ялган фамилия астында күп еллар пропискасыз торуда, дини мәҗлесләрдә молитвалар укуда, детдомда мөселман балаларын аерым җыеп, яшерен рәвештә дини рухта тәрбияләүдә, тыелган

китаплар пропагандалауда гаепләнәсез.—Куртай өстәл тартмасыннан «Идегәй» дастаны басылган журналны, Кол Гали, Габдулла Тукай китапларын тартып чыгарды.—Менә болар барысы да сезнен совет строена каршы идеологик диверсант икәнегезне исбат итә торган кире кагылмаслык нигезле дәлилләр.

Фәгыйлә аны тыныч кына тынлый алмыйча:

—Болар барсы да нахак гаепләү,—дип ачыргаланып акланырга тотынды.—Беренчедән, мин хәзер икенче ирем фамилиясендә, егерме ел буенча бу шәһәрдә даими пропискада торам. Мөселман балаларны жыеп ярдәм итүдә дә бернинди диверсия юк. Русча начар белү аркасында алар укуда артта калалар, дәресләрне авыр үзләштерәләр иде. Шуна күрә мин аларга дәрес әзерләргә, фәннәрен үзләштерергә ярдәм итәм. Монда бернинди яшерену юк. Ул хакта мәктәптә класс житәкчеләре дә, безнең дирекция дә яхшы белә һәм хуп күрә. Сезнен кулдагы бу китапларда совет властена каршы пропаганда юк. Алар барысы да татар әдәбиятынын алтын хәзинәсе булып саналган мәшһүр китаплар.

—Житте, туктагыз, барыбер аклана алмассыз. Югарыда әйтелгән жинаятьләр буенча сез жавапка тартыласыз. Тиздән суд булачак, дәлилләрегезне шунда сөйләрсез.

Фәгыйләнен башында: «Боларны ничек белгәннәр, кем житкергән?— дигән сорау туды. Ахирәтем Әмирәдән гайре бу китапларны бүтән беркемгә дә күрсәткәнем юк иде бит. Баттал белән Мөхәммәтвафанын шикләнүе нигезле, доносчы шул микәнни?!».

Суд булганчы көтеп торырга Фәгыйләне тагын кандалалы сасы камерага илтеп ябалар. Ул берсеннән-берсе дулкынландыргыч уйларга чума... Ятимнәр йортынын бүген илле еллыгы бит! Хезмәттәшләре һәм балалар бәйрәм итәчәкләр. Шуның өстенә бүген анын үзенә дә илле яшь тулган көн ләбаса. Ә ул, явыз жинаятьче кебек, сасы кандала оясында жәфа чигеп утыра. И, Раббым, нинди гөнаһ шомлыгы булды бу? Тагын нинди бәла-казаларга дучар буласым бар икән?!.

* * *

Бүген бүтән борчымаслар кебек иде, мәгәр төштән сон Фәгыйләне тагын чакырып чыгардылар. Тикшерүче Куртай бу юлы аны жылы каршылады һәм кул ишарәсе белән каршыдагы буш урындыкка утырырга тәкъдим итте. Анын үзен тотышында ниндидер үзгәреш бар, сизелер-сизелмәс кенә унайсызлану, тынгысызлык төсмерләнә. Алдында жәелеп яткан «Красное знамя» газетасын тиз генә бөкләп читкәрәк куйды да:

—Карагыз әле, без земляклар, күптәнге знакомыйлар бит,—дип ярым татарча, ярым урысча сөйләп китте.—Поэтому жәлләдем, ягъни сезне судка бирмәскә, освободить итәргә булдым. Монда булганыгызны беркемгә дә әйтмәскә расписка язгыгыз да кайтып китәрсез,—диде.

Фәгыйлә моны башына сыйдыра алмыйча: «Нинди тамаша бу?! Урынсыз шаяртумы яки кимсетеп үч алумы?»—дип аптыраган иде. Бары тик ирекккә чыккач кына анын чынлыгына инанды. Мәгәр шундук башында яна шик туды: тикшерүче ник болай кисәктән генә үзгәрде? Аны көтмәгәндә азат итүнең сәбәбе нәрсәдә сон, дигән шомлы сорау борчый башлады.

Башта туп-туры өйгә кайтырга уйласа да Фәгыйлә бу ниятеннән кинәт ваз кичте. И-и, бөтенләй исеннән чыккан, анын кичә кич кулга алынганын эштә белмиләр бит әле. Хәзер үк кереп күренергә, әйтергә кирәк.

Директор газета укып утыра иде. Фәгыйлә ишектә күренү белән үк ягымлы елмаеп каршылады:

—Әйдүк, керегез... Хуш киләсез, рәхим итеп утырыгыз!

Ул бу шомлы хәбәрне инде белгән, иртән Шакиржан килеп әйткән. Хәзер шул хакта сөйләшергә край башкарма комитетына барырга жыенган икән.

—Юк, болай булгач бармыйм инде. Аллага шөкер, котылгансыз. Мона

канәгать булыйк. Шулай да ничек болай жиңел котыла алдыгыз, сөйләгез әле.

—Тикшерүченең ничек болай тиз чыгарганын һич анламыйм,—диде Фәгыйлә,—иртә белән беренче тапкыр допрос алганнан соң, суд булганчы сак астында көтәргә дип, кире камерага озаттырган иде. Ни күзем белән күрим, ике-өч сәгать үткәч, тагын чакыртып алды: «Мин сезне жәлләдем, судка бирмәскә, освободить итәргә булдым», дип, төче телләнеп иреккә чыгарды. Мондый кисәк әверелешнең хикмәте нәрсәдә икәнен мин анлый алмыйм әле...

Александр Николаевич беравык уйланып торганнан соң, ниһаять, нидер абайлагандай:

—Анын сере биредә түгел микән?—дип, кузлеген киеп, өстәлдә яткан газетага төбәлде.—Менә монда ике материал басылган. Аларның берсе сезне мактау грамотасы белән бүләкләү турында партия крайкомы һәм край башкарма комитеты карары. Икенчесе—әдәби язма. Авторы Вафа Зәбиров, бәлки, беләсездер. «Ятимнәрнең игелекле тәрбиячесе» дигән очеркында сезне күккә чөеп мактаган. Молодец! Ә тикшерүче, мөгаен, шушы газетаны укыганнан соң куркуга төшкән, баштагы явыз хөкемен кинәт аклауга үзгәртергә мәжбүр булган, күрәсен.

—Әйе, әйе, нәкъ шулай, сез әйткәнчә булса кирәк! Мин икенче тапкыр кергәндә шушы ук газета анын өстәлендә ята иде.

—Ярар, монысы ачыкланды. Мин сезне зур бәйрәмегез—бу бәладән хәвеф-хәтәрсез котылу, тууыгызга илле яшь һәм бездә егерме биш ел намуслы хезмәтегез белән котлыйм!—дип директор Фәгыйләнең кулын кысты.—Ә калганын кич белән клубта тантаналы кичәдә дәвам итәрбез. Сез шуңынчы барыгыз, өегезгә кайтып ирегезне шатландырыгыз. Мәгәр онытмагыз, сез килеп житмичә кичәне башлап булмаячак. Сәгать биштән соңгармыйча клубта булырга тырышыгыз.

* * *

Адәм баласы үзе бәхетле, көр күңелле булганда әйләнә-тирәдәге мохиткә алсу күзлектән карый, тормышны якты, матур итеп күрә. Фәгыйлә абыстай белән дә бүген нәкъ шундый хәл булды. Кичә кич кулга алынгач, тоткыннарны йөртә торган «кара козгын» машинасында китеп барганда бу бер яклы таныш урам аны үгисетеп озатып калган шикелле иде. Ә бүген бәла-казадан котылып кайтып барганда анын йөзе шат, йөреш-килбәте яшьләрчә жиңел. Кояш нурына балкыган урам ягымлы елмаеп каршылый сыман.

Иш янына куш дигәндәй, өстәвенә бүген аңа илле яшь тулды бит. Шул гомернең яртысы балалар йортында эшләп үткән, ярдәмчесез ачялангач ятимнәрне һәлакәттән саклап калуга, жәмгыятькә файдалы кешеләр итеп тәрбияләп үстерүгә багышланган.

Махсус педагогик белеме булмаса да, Фәгыйлә абыстайның бу мәсьәләдә ныклы үз мәсләге бар: укыту, тәрбия эшендә балага белем, мәгълүмат бирү белән бергә, аны уйларга, киләчәге турында кайгырта белергә өйрәтү—аеруча мөһим максат. Даһи Тукай соңгы шигырьләренең берсендә:

Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
Алга барганнарга тик табла табылса: Алла ул,—

дип васыять әйтеп калдырган...



## Рөстәм Мингалим

### КЫЛЫЧ ЙӨЗЕ БУЙЛАП...

*(Казанның 1000 еллыгы уңаеннан)*

Мин—Казанның һаман барлыгына
ышанып та җитмәс бер кеше,
тик аның зур юлын—елмаюын,
көрәшләрен таныйм, күз яшен.

—Мең ел гомер!—
кылыч йөзе буйлап?!
Ничек узылган ул?
дигәндә,—
томырылып Казан үргә менгән,
үрмәләпләр...
төшкән...
түбәнгә;
калыр гына иде үр өстендә—
тәкъдиренә башка язылган...
...Өстә—Мәскәү,
денсез татар калган,
Иблис калган көлеп—кул болгап.
Тормыш, әйе, кызык—
чыны шулмы,
миңа гына шулай күренәме?
Ул үтәли һәм шәп-шәрә күренә,

Рөстәм МИНГАЛИМ *(1937)— шагыйрь, драматург, балалар язучысы. Егермедән артык китап авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

кендегеннән генә көлмәге.
Мең ел элек монда мин юк идем,
бүген мин бар—бу шәп...
шәт начар?!
Казаныма тагын мең ел теләп,
дога кылып яшим татарча.
Тик җәл, әнә, хәер җыючылар
үзәгемә
утырып,
төртенеп—
гәрчә, алар инде мең яшәмәс,
хәтта Бауман исеме сөртелер.
Чал Казанның яшь байрагын карыйм,
чынлыгына бераз шигем бар;
һәм җилләр дә алып бугазыннан,
җилтерәтеп—аны сыныйлар.
...Иртән ачсам Казан радиосын—
ишетәм татар гимны газабын:
Авызын Мәскәү учы кыса сыман,
кысылып... тына... көйнең азагы.
Көйне кысу—нәрсә...
Телне синең,
җанны кисеп була! Бик була!—
Тотып язмыш газиз илкәеңне,
бирсә башкисәрләр кулына...
Татар сүзен—үзен һәм Казанын
ташламаган бөек Мәрхәмәт,—
кылыч йөзеннән дә бүгенгәчә
исән китергән бит, и рәхмәт!
Мең ел элек, ярый, мин юк идем,
бүген мин бар—ярый анысы да:
—Үрдән урын сорыйм Казаныма,
ишетә күр мине, бер Хода?!
Бир Казанга гомер, бир, Хода?!

## Татар түбәтәе ник кара төстә яки Ходай яза...

Ходай яза, әгәр язса—
бирә бит ул байлыкны:
татар иле—татарныкы,
рус иле дә аныкы!

Зур урыска—бер генә ил,
һәм шунысы кыенрак:
ил үзәге томанлырак,
чикләре—артык ерак!

...Татарның—иле икәү дә...
җиңел түгел аңар да:
ике илгә ярый торган
көй һәм бию табарга!

Ике илнең шатлыгы да,
кайгысы да икәү ич:
...Бу илләрнең шатлыгыннан
кайгысы зур икән ич!

Кайгырып ике ил өчен,
башы кайный татарның:
түбәтәен дә каралткан
кайгылы башы аның!

Ходай яза, бәндә күрә
тәкъдирендә ни барын:
күрик әле, түзик әле,
яшик әле, дусларым!

## Әй, шаян тормыш...

*(Сәяси үзгәрешләр уңаеннан)*

**Сәясәтләрен сатыйм,**
**аны күп ишеттек.**
**Искесен ишеттек,**
**тыңладык яңасын.**
**Авызларын гына**
**этләр яласын!**
**...Килеп җиттек.**
**Шушында—**
**гомер ахырында,**
**калдым төнге юлда.**
**Дөм караңгы монда.**
**Халык—кайнаша,**
**әллә кемнәр**
**кыймылдый**
**янымда:**
**һаман өмет өзмәүчеләр,**
**бәхет эзләүчеләр,**
**өметсезләр,**
**алдакчылар,**
**әчкечеләр,**
**караклар,**
**үтерүчеләр**
**үлүчеләр...**

**...Мин урлый алмам,**
**үтерә алмам.**
**Качкын бәхетемне**
**язып табалмам—**
**дөм караңгы монда!**

**...Ул кайда,**
**кайда ул—**
**чын кыйбла?!**

**Нишлибез, халык?**
**Юлдашлар!**
**Эчкечеләр!**
**Караклар!**
**Безгә кай тарафка?!**
**Кай якка узабыз,**
**бәгырькәйләрем,**
**үтерүчеләр, үлүчеләр?!**

**Әй, шаян тормыш,**
**якамнан**
**кулыңны ал әле,**
**буасың бит, җибәр?**
**Җибәр!**

## Бакчасарай

Бакчасарай—Кырымда. Анда елый торган һәйкәл бар. Ханнар сараендагы бу фонтан-һәйкәлне 1764 елда Гәрәй хан эшләткән.

Гәрәй ханның Диләрә исемле яшь хатыны була. Диләрәнең Кырым ханы кулына кайсы сугышта, ничек төшүе билгесез. Берәүләр аны—грузин кызы, икенчеләр—поляк кызы, өченчеләр—чиркәс кызы, имеш, диләр. Ханның иң көчле мәхәббәте шушы гүзәлдә булган. Тик кыз бу язмышы белән килешә алмаган, бик тиз сулган һәм тиз арада дөнья куйган. Гәрәй хан үзенең чиксез кайгысын сурәтли торган һәйкәл эшләргә әмер биргән... Ул һәйкәлне Иран остасы Гомәр эшләгән.

Бу һәйкәлгә кайчандыр А. С. Пушкин кызыл чәчәк куя. Шул истәлекне яңартып, нәкъ Пушкин куйган урында, хәзер дә гел кызыл чәчәк тора.

**Саумы, Пушкин язган Бакчасарай?**
**Шаккатарлык серең—юк сыман.**
**Күккә карап баскан һәр манарaң**
**сызгырмыйча калган ук сыман...**
**Шушындамы яхшы атлар булган?**
**Илләр курыкканмы шушыннан?**
**Әйтерсең лә моңа җавапларның**
**чынына да ялган кушылган...**
**Өзек-өзек килгән аваз кебек**
**ерак ята инде ул заман.**
**Шул заманда инде Гомәр оста**
**Гәрәй ханны никтер алдаган.**
**Һәйкәл итәм дигән хан кайгысын,**

Яшьле итәм дигән күзләрен:
ә мин беләм, жанын һәйкәл иткән
ул Диләрә дигән гүзәлнең...
Жанга кушылып елый кызыл чәчәк,
Бакчасарай кушыла боларга.
Төне-көне елый яшь Диләрә,
ярыймы соң шулай еларга?!
Ике йөз ел буе яше тама—
күңелләрне уя икән лә!
Жирдән, юкса, аның көндәшләре
һәм Гәрәй дә күптән киткәннәр.
Болай озак елау авыр ич ул,
заман хәзер үзгә—бүтән бит.
Диләрәгә һаман куркынычмы?
Инде татар тавышын күтәрми...
Мин ханнарга хәбәр китермәдем,
хан булырга монда килмәдем.
Күреп кенә йөрдем
узганнарның
әкерен генә жиргә иңгәнен...
...Сау бул, Пушкин язган Бакчасарай,
без белмәгән серең юк сыман.
Күккә карап баскан һәр манараң
сызгырырга әзер ук сыман.

Әйе,
жилгә—
жайлы аңа
Русия киңлегендә.
Жил мәңгелек уй
йә жандыр,
бардыр мин-минлеге дә.

Килегез—кил әле, жилләр,
уртаклашыйк уйларны!
...Күп уйларым—
жил юлына
байрак итеп куярлык.

Туфрактан түгел бугай без,
жилләрдән яралганбыз.
Урысча сибелгәнбез дә
татарча таралганбыз

Безнең бүген артка карап,
алга барган чагыбыз.
Чын хәлебез—
гимныбызда,
гербыбызда чагылыр...

Життек жиде юл чатына,
юлны япкан... төнмедер?
Тагын нинди сугыш уты
төнъяпманы күтәрер?!

Күзләребез, башларыбыз
тагы ниләр күрерләр?
...Төнлә дә...
килегез, жилләр,
хәлебезне белергә.
Исән булсак—
аңлашырбыз
урысча, хет татарча...
Хет жилләрчә,
хет жennәрчә
сөйләшербез таңгача.
Хәтәр төндә русияле—
йокламыйча да чыдар.
...Алда бит—
жил дә сизмичә—
мәңге йоклыйсыбыз бар.

## КИТМӘСКӘ КИЛГӘННӘРНЕҢ БЕРСЕ

*Болай була. Бик тә инде драматург буласы килә Ризванның. Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи кебек. Шагыйрьләр дә, прозаиклар да күп әдәбиятта, ә драматурглар бармак белән генә санарлык. Үзенә остаз эзли Ризван. Армиядән кайтып Казан педагогия институтында укып йөргән чагы. Яңа гына язган пьесасын күтәреп, китә бу «Татарстан яшьләре» каршындагы иҗат түгәрәгенә. Әмма монда да шагыйрьләр, прозаиклар буа буарлык,—драматурглар остазы юк. Гәзиттә әдәбият бүлеген җитәкләүче Шамил Маннапов аңа язучылар союзы консультанты драматург Әнәс Камалга барырга киңәш бирә. Галиәсгар Камалның улы аны, пьесасын уку өчен, өенә чакыра. Татар драматургиясе үзе пьесаларын язган өйгә! «Шәп! Шәп!» дип утырган консультант икенче актны «Булмады бу!» дигән сүзләр белән тәмамлый. Картының яшь авторына чыгарган хөкем карарын ишетеп торган Сәлимә апа Ризванны якларга алына: «Карама, энем, аның сүзләренә, синнән алда, ачулары килеп, бер-ике егет бүрекләрен ташлап киттеләр инде,»—ди ул. Әнәс Камал исә болай өсти: «Матәшма, энекәш, болай язсаң, синнән барыбер драматург чыкмый!» Ризванга үзеннән алда килгәннәрнең батырлыгын кабатларга туры килә. «Драматург булмасам, шушы бүрегемне башыма кимим!»—ди дә бу, бүреген атып бәреп, өйдән чыгып китә. Бәлки, бу музей-йортта бер экспонат арткандыр, анысы әлегә билгесез.*

*Әллә инде кырык пьеса язган драматургның сүзләре тәэсир иткән, Ризван «болай язмыйча», башкачарак матәшырга тотына. Башына яңа бүрек сатып алырлык гонорар ява башлый, Аллага шөкер! Ниһаять, яшь драматурглар семинарында, кырык пьеса язган Аяз Гыйләҗев үзе, аның пьесаларын укыганнан соң: «Ризван тумыштан драматург!» дип белдерә.*

*Остазның сүзләрен раслап, «тумыштан драматург»ның әсәрләре бер-бер артлы театр сәхнәләрен яулый. Бүгенгесе көндә Ризван Хәмид аз да түгел, күп тә түгел— утызлап пьесаның авторы. «Синең урыныңа кайттым» драмасын Татар дәүләт академия театрында 1978 нче елда Марсель Сәлимҗанов сәхнәләштергән. Кәрим Тинчурин исемендәге, Минзәлә, Әлмәт, Оренбург шәһәрләрендәге театрлар аның әсәрләренә бик еш мөрәҗәгать итәләр. Башкортстандагы Сибай дәүләт театры аның дүрт пьесасын тамашачыларга күрсәтте. Камал театрында уңышлы барган «Китәм инде» («Под знаком Марса») драмасы элеккеге Советлар илнең егермеләп театрында куелып, олы аренага күтәрелде. Ул пьесаны күренекле драматург, Мәскәүнең югары әдәби курсларында Ризванның семинар җитәкчесе Виктор Розов үзе тәрҗемә иткән. «Современная драматургия» журналында һәм Мәскәүнең башка басмаларында Ризванның җиде пьесасы басылган.*

*Шуларга драматургның киносценарий жанрындагы актив эшчәнлеген дә өстик: Р. Мингалим белән бергә иҗат ителгән «Идегәй» исемле киносценарийның да, «Тукай» телевизион фильмының да бер авторы—ул!*

*«Чабаталы чәүчәлек» дигән яңа комедиясе Казан дәүләт яшьләр театры репертуарында сәхнә күтә.*

*Күптән түгел үткәрелгән яшь драматурглар семинарында шундый бер фактны*

*игълан иткәннәр: татар драматургларыннан пьесалары иң күп куелган автор—Ризван Хәмид икән. Аның әсәрләрен иллидән артык театр сәхнәгә мендергән.*

*Егерме биш елга якын иҗат чорында Ризван Хәмид театрлар һәм әдәбиятыбызны үзенә генә хас алымнары, яңача конфликтлары, үзенчәлекле геройлары белән баетты.*

*Татар әдәбияты, театры, режиссерлары, тамашачылары бөтен талантын, көчен, гомерен театр сәнгатен үстерүгә багышлаган шундый олы драматурглары булу белән горурлана алалар.*

*Ризван безнең—Язучылар берлегенә керергә рекомендация язган абзыйларының өметен дә aклады. Кайчандыр үзенә остазлар эзләп йөргән егет хәзер үзе остаз. Яшь талантлар җыелган семинарларга хәзер аның үзен җитәкче итеп чакыралар, иҗат тәҗрибәсен уртаклашуны үтенәләр. Әле һаман шулай: шагыйрьләр дә, прозаиклар да җитәрлек, ә драматурглар бармак белән генә санарлык. Олы драматургларга бөрекләрен ташлап китүчеләре юк та юк инде.*

*Шундый олпат шәхесне алтмыш яше тулган көннәрдә эш өстәле янында—драматургия тәхетендә күрү үзе бер сөенеч. Безне әле яңа спектакльләр, яңадан яңа ачышлар көтә.*

*Кышкы салкыннарда Ризванның башында яңа бүрек күрсә, Әнәс Камал да сөенеп, «Тәки драматург чыкты бит бу малайдан!» дип әйтер кебек...*

**Илдар ЮЗЕЕВ**
*2001 ел, 17 июль.*



## Ризван Хәмид

# ТИГЕЗӘКЛӘР

ЗАМАН ТРАГИФАРСЫ

**Катнашалар**

Минһаж Бадакшанов—ил өстендә иләмән карт
Тәүсигә—аның карчыгы
Ленар—уллары, урманчы
Лениза—киленнәре, дунгыз караучы
Илшат—Ленарларның өлкән улы
Баян—Ленарларның кече улы
Сара—Баянның классташы
Гөлшат Дикаянова—яшь укытучы, кала кызы
Разалия—Илшатның яшьлек дусты
Будик Минһаж—авыл диванасы, Разалиянең бабасы

# Беренче бүлек

## Беренче күренеш

**Беренче сентябрь иртәсе: көн тамырланып кына маташа.**

**Каравыл тавы куенында төн кунган куе томан, сөт аклыгын җуеп, сыекланып кына килә әле. Зәңгәрсу-тоныкк күк гөмбәзендә сирәк кенә бәрәнчекләр һәм каурый болытлар яралгалаган—кояш Каравыл тавы артыннан калкып чыгуга эссе көн башланачак, димәк. Авылларда иртәләрен бермәлгә тынлык урнашып ала торган кыска буш ара бу: таң тишегеннән эшкә яки бүтән ашыгыч йомыш белән китәселәр китеп беткән инде, ә икенче чиратта кузгалучылар өчен бераз иртәрәк чак.**

**Бадакшановлар ишегалдында җылымса тынлык черем итә.**

**Ниһаять, купшы верандалы яңа йортның болдырына 16—17 яшьлек үсмер егет чыга: Ленар Бадакшановның төпчек улы Баян ул. Аның уң кулы кара яулык белән муенына асылган, сул култыгында инвалидлар таягы—чөнки сул аягы да имгәнгән, ансының очына гына басып йөри. Ул җилкәсенә япун видеотөшерү аппараты аскан. Кемнедер күрми калмагаем, дип шикләнә ахрысы, әледән-әле бәйдәге кулына тоткан сәгатенә күз салгалап, урам ягын күзәтә. Менә ул җиңел сулап куя һәм сәгатен кесәсенә тыгып, кызыксынган кыяфәт белән «нейтраль бер урынны», ягъни урам ягына исе дә китмәгәндәй, «видигына» төшерә башлый. Шулвакыт түрдәге каралтылар эченнән «Чеп-чеп-чеп!», дип кош-кортларын ашарга чакырган хатын-кыз тавышы ишетелә, шуның артыннан ук урам капкасының зәһәр чыңлавы яңгырый.**

Сара *(әлегә үзе күренми).* Абау! Һаман ияләшә алмыйм шушының ачы шалтыравына... Нихәл, «билгесез сугыш» инвалиды!

**Ишегалдына, шырык-шырык көлә-көлә, классташы килеп керә: аның бер кулында дипломат сумка, икенчесендә яңа гәзит.**

Баян *(битараф кына кызга таба борыла һәм төшерүен дәвам итә)* Чыпчык чыркылдый дисәм—син икәнсең әле, Сар-ра... Киенеп-ясанып, кая бик иртәләдең болай, чеплә кигәвене? *(Төшерүдән туктый.)*

Сара *(көлә).* Ә син—аяк-кулы өзеп ташланган выжан, алайса, Баянчик! *(Иске йорт ягына ымлый.)* Күрдеңме әле: Минһаҗ бабаннарның тәрәзәсен бүген төнлә дә кемдер ватып киткән? Алашы нишләптер килеп куярга өлгермәгән... Рәхәт синең бабаңа: тәрәзәсенә кем генә таш бәреп качмасын—Будик килеп төзәтеп тора! Алдан килешеп куйганнар диярсең. Бүген нишләп килмәгән икән?

Баян. Пыяласы беткән чагыдыр...

Сара. Кызык... Ә нигә ул куеп йөри?

Баян. И в небе и в земле сокрыто больше, чем снится вашей мудрости... Сар-рацио!

Сара. Шекспирны яттан белә берәү... Шулай да?

Баян. Сорашканым юк. Син беләсеңме, Испания чигендәге бер авылга французлар менә сигез гасыр инде ел саен бушка өчәр сыер илтеп бирәләр икән? Ә сәбәбен хәзер беркем дә белми, имеш!

Сара. Сигез гасыр элек испаннардан өркеп калганнардыр.

**Көлешәләр.**

Баян. Таң тишегеннән кая теркелдәдең, дим?

Сара. Ну син нахал, Баянчик... *(Егетне тирәләп чыга.)* Буен-сынын үлчәп кенә калмаганнар, башына да контузия ясап җибәргәннәр моны, дисәм... Тишелгән-ниткән җире күренми. Харап итә күрмәсеннәр үзеңне: безнең авылга бер тиле Будик та бик таманга туры килә әле! Авыл саен икешәр дивана була башласа, кая китә ул?! *(Көлә башлый һәм кинәт бүленә.)* «Не хочу учиться, хочу жениться» мәллә?

Баян. Тукта, беренче сентябрьмени инде бүген?

Сара *(гәзите белән суга).* Үзем контужен итәм мин сине хәзер!

Баян *(култык таягын «мылтык» итеп).* Ну-ну-ну!» Култык таягы гына

түгел бу... Менә бу төймәсенә бассам—классташ малайларның күзләрен-башларын әйләндерер өчен шомарткан каурыйларының йоннары пыр тузып очар!

Сара. Ә син—көнләшәсеңме?

Баян. Замнем для ясности. Нинди газит ул?

Сара *(артына яшерә)*. Кемнәр кыйнаганын әйт—күрсәтәм? Йә—биеп күрсәт! *(Көлә.)*

Баян *(болдыр идәненә утыра)*. Сара Садыйкова үзе килеп ялынса да—селкенмәс тә идем мин... Ә син—авыл мокытларыннан туган гап-гади Сар-ра гына әлегә!

Сара. Син үзең—мокыт: каберең-нән торып килсеңме? Шагыйрь, имеш! Мә, пачулкы гение: район газите тагын синең бер кочак килдем-киттем көенә язылган опусларыңны бастырып чыгарган.

**Баян газитне ваемсыз гына кыяфәт белән болдыр идәненә ташлый.**

Кыланышы!.. Мин китүгә—кабалана-кабалана үз шигырьләрен эзләргә тотыначак бит инде үзе... Ыслушай, татар Байроны: срочны бер шәп псевдоним табарга кирәк сиңа. «Унынчы класс укучысы Бадакшанов Баян шигырьләре», имеш! Эч пошудан әремгә асылынырсың... Тукай, дигән кебек яңгырап торырга тиеш ул! «Баян Бадакшанский», мәсәлән, ә?.. «Чатра Баян» да начар яңгырамый!

Баян. Киңәшегез өчен эр-рәхмәт, халык артисткасы Сар-ра ханым: сездә акыл—күкәй эчендәге тавык итеннән дә күбрәк икән! Ә нишләп: «Кызылтауский» яки—«Каравылтауский түгел?

Сара. Чөнки—серлелек юк! Колагыңны куй әле: Чатра Баян! Әллә нинди ишерен серләр сыйган сыман монда. Ә Каравыл тавында?! Ленин рәсемен үз атаң ясап куйганга ишарә итәсең килсә генә инде!

Баян. Алайга китсә—«Чаптыра Баян» тагы да мәгънәлерәк!

**Көлешәләр.**

Юк инде, Сар-ра актриса булып алгач—үзең «Сара Пачулковская» булып йөр! Бөтен күренекле кешеләре «Волжская», «Иманский», «Минский» булып йөргәнгә татарның хәтерен кәҗә кимергән дә... Исеме үзебезчә генә булса—яңгырамый, янәсе! Син дә тигезәк булма, ичмасам.

Сара. Кем булма?!

Баян *(иҗекләп кабатлый)*. Ти-ге-зәк. Урысча «совоклар» дигән сүзне ишеткәнең бармы? Татарчасын мин үзем уйлап таптым аның: игезәк белән тигез дигән сүзләрне бергә куштым да.

Сара. Мин—совочка инде синеңчә, алайса?

Баян. Булма, дим ич. Тигезәкләрнең төп сыйфатлары, беләсең киләме, нинди? Мин-минлекләре Чатра тавыннан да биегрәк, ә үзләрендә чеп-чи коллар психологиясе! Кемнәрне генә гаепләмәсеннәр—любой пычрак ялага ышанырга әзер торалар. Гомерләре буе бер кашыктан ашап яшәгән кешеләрне гаепләсәләр дә! Тигезәкләр өчен бер мәкаль дә ясап куйдым инде мин: «Тигезәк яласы тизрәк.»

Сара. Мин—шундый кешеме?!

Баян. Бик ерак йөрмисез, мадмуазель.

Сара. Әйтер идем инде мин сиңа бер сүз... Беренче сентябрь хакына гына түзәм. Кайчан укырга йөри башлыйсың? *(Сәгатенә карый.)*

Баян. Ша! Аудиенция тәмам, кызый.

Сара. Пинук булып калырсың, дип куркам. Надан шагыйрьдән дә мин-минле бәндә юк бу дөньяда! Бигрәк тә... ата-аналары Ленар, Ленизаише ясалма исемнәр йөрткән татарлар арасында, ди.

Баян. Ә Шекспирның кем икәнлеген дә белмәсә дә, Гамлет исеме таккан адәмнәрнең сеңелләре нциндиерәк актриса була, ди?

Сара. Андыйлар... минем шикеллерәк үпкә белмәс шыр тиле булалар.

**Икәүләп пырхылдап көлеп җибәрәләр.**

*(Сәгатен колагына куя.)* Әллә туктаган инде?.. Сәгать ничә әле?

Баян. Кешенең үз организмында вакыт тойгысы булырга тиеш. Мин үзем, мәсәлән, хет кара төн уртасында уят—вакытны секундка секунд төгәл әйтеп бирәләм.

Сара *(елмая)*. Шуна сәгатеңне, кулыңа такмыйча, кесәңдә генә йөртәсеңме?

**Баян ирексездән кулы белән сул кесәсендәге сәгатенең каешын каплый.**

Кемнәрдер белән, аяк-кулларыңны сындыра-сындыра, сугышып, шул

кадерле тойгыннан колак кактынмы әллә? Нигә миннән дә яшерәсең аны? Кемнәр белән чәкәләштегез? Гамлет абый әйтә: Чатра астындагы комлыкта сугышканнар алар, ди.

Баян. Гамлет абыена әйт: быргы болгап йөрмәсен, титарай! Будик Разалиясе турында да әллә ниткән тузга язмаган нәрсәләр таратып йөри икән.

Сара. Нәрсә дип?

Баян. Муеныма сарылырга әзер ул, дип!

Сара. Тәүсига әбиегез әйтмешли, пычагымны белә ул... Синең Илшат абыеңнан бүтән егетләр күзенә күренми ул Разалия апаның! Нигә күзләреңне чагырландырасың? Бергә уйнап үскәннәр ич алар... Ой, беренче дәрескә соңга калам! Быел немец теленнән яңа укытучы кирәчәк, имеш... Каладан килеп төшкән, диме... Өйләнмәгән егет булып чыгып, чибәрлеге дә бизмәннән артса—иң башлап үземә гашыйк иттерәчәкмен мин аны! *(Көлә.)* Валлаһи дип әйтимме?

Баян. Миңа димәгәе... Мимечең белән икәүләп... цум тауфель! *(Култык таягы белән урамга күрсәтә.)* Әйдә выжт—сыптыр юлың такыр чакта. Буявыгыз унгач—минем катка кабат әйләнеп кайтмагыз түлке, принцесса Сар-ра!

Сара. Менә ничек? Зер гут, ду бист дубина! *(Урамга ташлана: капка келәсе бик зәһәр чыңгылдап кала.)*

**Кыз киткәч, Баян канәгать төс белән иләндә аунаган гәзитне ала һәм җәһәт үз шигырьләрен эзләргә тотына. Табып, тиз-тиз генә карап чыга һәм шатлыгын уртаклашырга кеше булмагач, аны кеше күзенә иң алда чагыла торган урынга—ишек тоткасына кыстырып, алма бакчаларына кереп югала. Ишегалдында тагын тынлык урнаша. Ләкин озакка түгел: урамнан койма такталарын «таяк белән санаган», кычкырып сөйләнгән һәм бүтән шуның ише авазлар ишетелә башлый. Күршеләр эте карлыккан тавыш белән өрә һәм кинәт чәчәп туктый. Кемдер урам күтәреп такмаклап килә:**

«Эштиплавай,
Эш давай!
Эш тапмасаң—
Әлки-сәлки,
Ләбән җүки.
Бәндә гуж-ж!..»

**Койма тыкырдау тына һәм ишегалдына табаныннан тузган кәтәнә гәүдәле, чамадан тыш зур борынлы бер сәер карт килеп керә: аның артыннан урам капкасының келәсе бигрәк ямьсез чыңгылдый. Авыл диванасы Будик Минһаҗ бу. Ул кайсы ягы беләндер әкиятләр гномын хәтерләтә: көн ярыйсы гына җылымса булуга карамастан, өстендә хатын-кызларныкына охшаган кыштыр күрпә тун, төсе уңып сизерәгән галифе чалбар, яланаяк-яланбаш. Очлы башлы галушлары бар, шулай да—ул аларны бил каешына кыстырган. Чаларган сирәк чәчләре бик күптән тарак күрмәгәнгә охшый. Шактый түгәрәкләнгән капкорсагы өстендә футлярсыз иске бинокль, ул аны гади сүс бау белән генә туп-туры җиерчыклы муенына аскан. Аркасында—бөкеле уенчык мылтык. Уң кулында—чукмар башлы озын таяк: ул аны этләрдән саклану өчен генә йөртә, аксавы сизелми, ә нечкә очы кимерелеп агарып беткән. Сул кулында каралган яулыктан ясалган төенчек. Картка ничә яшь икәнлеген тәгаен генә әйтеп биреп булмый: һәрхәлдә, аңа 75—80 тирәсе бар инде. Яшенә карамастан, ул ут борчасы кебек җитез хәрәкәтле, һәрвакыт бөтерелеп кенә тора.**

Будик *(кергән шапкә)*. Тпру, малкай—бүрегә азык булгыры! *(Таягы белән кизәнә: «атын» урамга куа, янәсе.)* Тоз бәйләп куймаганнар анда сиңа... *(Туп-туры яңа йорт верандасының урам ягы өлешенә таягы белән иләп кенә кага.)* Линәрмү-ү!.. Син өйдәме-ү, Линәрми апаем? *(Җавап бирүче булмагач, таягының чукмарлы башы белән бик каты суга.)* Нишләп шайтан симертеп, көпә-көндез җоклап ятасың, курва? *(Шундук веранданың түрге өлешенә бара һәм шулай ук башта таягы—нечкә очы белән иләп кенә кага.)* Линәзәү-ү!.. *(Юан башы белән бик каты сугып.)* Линизә дим, пәри катыны!

Лениза *(каралтыларның берсеннән чиләк тотып чыга)*. Монда мин, монда, Минһаҗетдин абзый!.. Ишексез җирдән ишек тишмә. Ленар нигә кирәк булды тагын?

Будик *(күзләрен чылт-чылт йомып, үз телен суыргандай төрле хәрәкәтләр ясый)*. Катын кеше булсаң, Линизә килен—катын кеше бул! Низашту аллан төшеп, ирләргә чаклы сүз башлама!

Ирең кая, дип сораган кеше жук ич? Иренең кайда икәнлеген тол катын гына әйтәлә чөнки. Андый катыннарның ирләренең әдрисе бер генә—әнә теге Каравыл тавы итәгендәге зират!

Лениза *(елмая).* Туры сүзенә жавап юк, Минһажетдин абзый. Ни эшләр бетереп йөрү?.. Бәрәч, күрми дә торам: бетеркә тун тектереп кигәнсең икән бит... Котлыйм, өстеңдә тузсын! Бераз гына хатын-кызларныкына охшаса да—бик ятып тора үзеңә.

Будик *(коры гына).* Эрәхмәт. Игәч бәрәннәрнең үзләренә дә бик килешеп тора иде ул. Җарар, аларга хәзер сырауну... Менә нәрсә, Линизә килен, бүген минем нык мәшәкатьле көнем! *(Кулындагы сәгатенә карап ала.)* Һу! Синең белән ләчтит сатып... *(Иске йортка ишарәли.)* Абызәби Тәүсига бианаңа әйт...

Лениза. Нишләп пышылдап кына сөйлисең, Минһажетдин абзый?

Будик *(бармагын иреннәренә куя).* Чү! Нигә саумаган сыер шикелле урам тутырып бакырасың?! Монда ил өстендә иләмән картлар җәшәгәнен белмисеңмени, пәри катыны?! *(Әмма үзе бик каты кычкырырга кучә.)* Бианаңа әйт... Матри—үзе торгач! Хәзер үк уятма!.. Үз бүлесе белән торгач кына—кара аны!.. Болай диген: Будик Минһаҗ кергәние—иртәнге чәйне өйдә чәйләп килдем, дип әйтергә кушты, диген. Бүтән чакта кыстауларына да үләр чама жук! Җаныма тиде... Монсын әйтмә, матри! Аңлык кына акылың эшлидер. Адаш җәштигә дә жакшылап әйт... Берәгәйле итеп! Тәрәзәсен тагын ватканнар. Пыялам бар—вакытым тар! Бу жулы үзе куйса да кулы өзелеп төшмәс! Кемгә нәрсә дип әйтергә бутама, матри, Линизә килен! Хәзер жавап тотсаң да була: Линәрмиең кайда адашып жөри, комсыз ябалак? Налуг палицайларыннан качып, биглайдамы әллә?

**Авызын зур ачып исни-исни, таушалган кыяфәтле яңа йорт хуҗасы Ленар чыга: ул ир уртасы кеше, көчкуәте ташып торган чагы әле, ләкин салырга яратканлыгы сизелә—көчле махмырга охшаган. Ишек ачылганда Баян кыстырган гәзит идәнгә төшә—ул аңа игътибар итми.**

Ә, менә үзе!

Ленар *(бу мизгелдә Будик аның өчен—арбаның бишенче тәгәрмәче урынына гына).* Кычытмаган жирне кәшәләп йөрмәле, адаш агай... Бердән икегә аерылырга әзер чак. *(Сәгатенә күз сала.)* Лисхуздан әбьящик килергә тиеш, пенте что... Әйе. Чатра тавында землянка казып ятуыңны белеп алса... корыган карама ботагына асып куяр үзеңне, пенте что. Мин түзгәнгә рәхмәт әйт!

Будик. Сабыр, Линәрми апаем! Нәчәлник кәмәшләре күп булыр бу дөньяда. Кигәвен тешләгән ат шикелле тибенмә, дивана! Бишекле матаең хуттамы?

Ленар. Кая бармакчы буласың?

Будик. Киттек! Җулда аңлатырмын... Кәнүшнәй гаражыңны моннан гына ач—мин сине тыкрыкта көтәм. *(Эшлекле кыяфәт белән урамга юнәлә.)*

Ленар *(Будикның кылануына исе дә китми).* Яшереп тоткан берәр нәмәрсәң юкмы анда, Лениза? Баш үтереп чатный, пенте что... Әйе.

Лениза. Обьездчик киләсе дисең бит үзең?

Будик *(күз койрыгы белән генә карап).* Нәрсә артыңны корчаңгы тай шикелле эстинәгә терәп каттың?! *(Бакча ягыннан чыгып килгән Баянны күрә һәм биноклен җәһәт кенә күзенә күтәреп, аңа төбәлә.)* Уң кулы сынган... Сул аягы чатанланган... Шулайрак бетәр бу, дип прагнуз җасаган идем аны! *(Бинокльне шап итеп корсагына ташлый.)*

Баян. Кем монда безнекеләрне утлы табага бастыра икән, дисәм—син икәнсең әле, Буд... адаш бабай!

Будик *(чатыр чабып кире борылып килә).* Ыступ! шакысторыну—шарт маңгаеңа! *(Бөкеле мылтыгы белән яный.)* Живы әйт: Чатра тау астындагы комаякта нишләп жердең беркөннәрне, ә, сабакы эт баласы?! Шәрә кызлар күзләпме? Туты—кызарасың! Сүзем бетмәде әле. Пригаварны җәренгә ишетерсең! *(Баянны аптыраушта калды-рып, Ленарга кырт борыла һәм төенчеген суза.)*

Ленар *(алырга ашыкмый).* Нәрсә ул?

Будик. Чишеп кара—кулларын кормагандыр! Әллә сине дә, камыр батыр малаеңны тукмаган төсле, сөякләреңне санап кайтардылармы? Мондый байлыкны күргәнең жук әле синең, Линәрми апаем.

**Ленар теләр-теләмәс кенә төенчекне ала.**

Лениза. Нәрсә такылдый ул, Баян улым?

Баян. Кем аңлаган аны...

Будик *(Баянга мылтыгын күрсәтә)*. Авызына су кап, абзыкаем Фәрхетдин, түбәтәең бәрхетдин! Һәр кырын эшне катын-кызга докладать сөйләп җөрмиләр. *(Ленизага.)* Буш-буйдак Илшатыгызны кайчан башлы-күзле итәсез инде? Кызыл кар җаугачмы?!

Баян *(аңа да төрттерергә җай чыга)*. Нәрсә, Минһаҗ абзый: кияүгә бирәлмәгән карт кызыгыз бар мәллә? *(Көлеп куя.)*

Будик. Син үзең дурак! Разалия апаң сине бик акыллы балага санап җөргән була тагын! Илшат абыең өчен кәшәнке җөзем җимеше әле ул... Крылов мәсәлендәге виноградка буе җитмәгән төлке шикелле!

Баян. Шаяртам гына, адаш бабай.

Будик. Хәзер җарпачлана, кунарсыз куптарай! *(Ленарга.)* Җә—нәрсә, дәшмәки апаем?

Ленар *(төенчеген кире бирә)*. Шуннан?

Будик. Күзләреңнең исерек чабаталарын салып, җакшылап кара, дивана! Ташкүмер ич бу! Җөз прасинт җанып бетә торганы. Аяк астында гына җата ул. Чатра тавында. Иелеп аласы гына бар. Эченне тишәме?!

Ленар *(тынгылык бирмәгән чебенне куагандай, кулын гына селти)*. Ышанган тауда бар, пенте что... Әйе, география укытучысына сөйлә син бу әкиятеңне! Ул—кайда таш күрә, шуны музеена ташый. Сиксән яшь тула бит инде сиңа, Минһаҗетдин абзый! Башыңны юләргә салып йөрү һаман туйдырмадымы?

Лениза. Кешегә алай бик каты бәрелмә инде, атасы.

Ленар. Ни әйтергә теләгәнне бик шәп аңлый ул. Тегe заманнарда Кызыльяр авылына качып, малай үстереп ятырга акылы бик җиткән ич.

Будик. Кешенең билдән аскы ягында акыл булмый, Линәрми апаем!

**Баян кычкырып көлеп җибәрә һәм болдыр идәнендә аунап яткан газитне кире тоткага кыстырып, сәвәзгә кереп китә.**

Лениза. Сүзеңне үлчәбрәк сөйлә, Минһаҗетдин абзый.

Будик. Синнән-миннән күбрәк белә ул! Катыннар сүзе түгел безнең—бар, савыт-сабаларыңны шалтырат. *(Ленарга.)* Кәтелниегезгә ни җагасыз? Черек усак утыны! Ә бу—әнтрәтсит дип атала. Пырдапаска чокыган димләнкәмнен иләнен тирәнәйткәндә килеп чыкты! Сизәсеңме минем сүзнең кай җакка барганын? Олау-олау булып җатадыр анда, бәлкем?!

Ленар *(аның йөзендә кызыксыну билгеләре күренә башлый)*. Тагын берәрсенә күрсәттеңме син моны? *(Төенчекне кабат ала.)*

**Лениза да, кызыксынып, якынрак килә.**

Будик. Мине диванага санныйсынмы әллә, апаем?! Анда! Кансасыкырые җук бугай монын, Линәрми энем. *(Тавышын баса төшә.)* Урман сатып рәхәт күргән лисникне күргәнем җук әле минем... Көнчеләре күп булалар чөнки потамушты!

**Хуҗалар мәгънә белән бер-беренә карашып алалар.**

Сезгә төрттерүем түгел, Линизә килен! Лисник кешенең учына шырпы кадалып изәреп кайтмый булмыйдыр... «Чалмалы баш» күтәреп, ирең тирәсендә буталучылар буа буарлык! *(Ленарга.)* Усак нәрсә ул? Ә бу—кетер-кетер ашарлык әнтрәтсит күмер! Җакында гына үзе... *(Юлбашчы сурәте ягына бер кулын суза: бу мизгелдә ул үзе дә күп урыннарда басып торган һәйкәлләрне хәтерләтеп ала.)* Менә шушы Каравыл тавына чаклы тагын ике-өч кенә урау ара булса булыр. Чатра тау урманы синең частыкмы? Синеке! Шулай булгач, апаем? Кабыз матаеңны! Киттек, эштиплавай... *(Ленизага.)* Ә син дәшмә, чәчби! Әмерикәнең бер ыштатында катыннарны айга бер тапкыр кыйнарга бүлә куйганнар, ди, әнә! Мин сине тыкрыкта көтәм, Линәрми апаем! *(Төенчеген алып, урамга юнәлә.)*

Лениза. Шуның сүзенә ышанып барасыңмы? Дуамалга йөреп кайтырсың—шул булыр.

Ленар *(ул әлегә хәл итмәгән)*. Туксан сигезлесен сигезле дә. Ике авылда менә дигән ике йорт тота бит әнә, пенте что... Әйе.

Лениза *(өйләре ягына карап ала)*. Син лутчы аннан сораштырып карале: Баянны кемнәр кыйнаганын белә, ахры, ул? Үзе юкса—бер сүз ләм-мим!

Ленар *(кул гына селти)*. Кирәк

тапса—бер сөйләр әле... Мин болай итәм, анасы: Чатра тау кардонына болай да барасы барие... Менеп карарга кирәк, кем белә, пенте что... Әйе. Әбьящик мин югында килеп керсәнитсә—кая киткәнемне әйтмә. Берике сәгатьтән урап кайтырга тиеш, диген. Бер сүз белән шайтаныңны су астыннан чыгара ул!

Лениза. Бәй, нишләп үзең телефоннан сөйләшмисен?

Ленар. Бая бер кат шалтыраткан идем—трубканы алучы юк. Кантурында да, өендә дә... Көтәр—берни булмас! Мине күпме көттерде... *(Аркылы тимерләрен шалтыр-шылтыр китереп ачып, гаражына кереп югала.)*

**Лениза ишек токтасындагы гәзитне ишек башына кыстырып кереп китә.**

**Гараж ягыннан мотоцикл кабызган гөрелдек ишетелә башлый һәм ерагаеп тына. Ишегалды тагын тынычлап кала. Бераздан урам келәсе ишетелер-ишетелмәс кенә шылт итеп ачыла һәм Бадакшановлар ишегалдына Будикның баласының баласы Разалия килеп керә. Аңа 25 тирәсе, мөлаем гына кыз, ләкин оялчанрак табигатьле булуы күзгә ташланып тора: бабасының дивана дигән даны аркасында туган кимчелек комплексы ул. Ишегалдында беркем дә булмагач, кыз нишләргә белми аптырабрак басып тора: ике өйнең әле берсенә, әле икенчесенә керергә омтылыш ясый. Бәхетенә, шул вакыт Баян болдырга чыга.**

Баян. Нихәл, Раза туташ? *(Басымны юри аның исеменең беренче иҗегенә куя.)* Нишләп, татар авылына килен булып төшеп, ике каенэнесе арасында адашкан маржа кызы төсле ишегалды уртасында таптанасың? *(Үз итеп йомшак кына көлеп куя.)*

Разалия *(аны күрүенә шатланып)*. Нәкъ син кирәгиең, Баян үскәнем. Тик бүтән беркайчан да «туташ» димә миңа, яме? Раза да түгел мин. *(Баян янына якынрак килә.)*

Баян. Бәтәч, кызыл әтәч—көн дә тавык өстендә, дип әйтте, ди, берәү...

Раза, Раза, Раза, Раза—
Раза гөлнен сачәге:
Хәзерге матур гомернең
Күнелле киләчәге,

—дигән җыр синең турыда түгелмени?

Разалия *(елмая)*. Тинтерәтмәле, зинһар, Баян акыллым...

Баян. Менә монсы—нәкъ синең хакта инде, алайса:

Канәфер каптым—ачы икән,
Бадиян каптым—төче икән.
Буйларың буйдан кече икән—
Куеның оҗмах эче микән? *(Көлә.)*

Разалия. Белми генә тор әле, үскәнем!

Баян. Миңа—нәрсә? Нугай Гамлеты шуны белергә теләп төннәрен йоклый алмый динкеп чыга, имеш!

Разалия *(җитдиләнә)*. Безнеке булмадымы монда?

Баян. Адаш бабаймы? Булды.

Разалия *(икеләнеп)*. Әлләниләр сөйләнмәдеме ул?

Баян. Белми генә тор әле, Разалия апа. Бер әп итсән—әйтәм.

Разалия. Мин чынлап сорыйм, Баян үскәнем?

Баян. Чәчрәп китим—берни сөйләмәде, Разалия апа. Ә нәрсә сөйләргә теләгән иде ул? Килгән саен сине үтереп мактый—яңалык түгел безгә монсы.

Разалия. Башына берәр уй төшсә—тутыккан кадак кебек бит аның.

Баян. Безнең кыз да бер кияү күрер әле, дип сөйләнүен әйтәсеңме?

Разалия. Булды инде, булды, Баян акыллым! Гел-гел уенга борып тормачы, зинһар.

Баян. Миңа берәр ачуың бармы әллә, Разалия апа?

Разалия. Нигә алай дисең?

Баян. Гел-гел уенга борып тор, мачы, дисең ич?

Разалия. Телеңә шайтан төкергәндер синең, Баян үскәнем! *(Көлгәндәй итә.)* Сине кемнәр кыйнаганын күреп торган ул... Тик... гадәтенчә—әллә нәрсәләр белән бутап бетергән бугай. Чынга алмагыз берүк... Шуны сиңа әйтергә килгән идем, үскәнем.

Баян *(шаярып сөйләшсә дә, җитдиләнә)*. Ә нишләп—миңа?

Разалия. Синең сугышканыңны күреп калган ич?

Баян *(тагын да ныграк сагаеп)*. Ә сиңа ниләр сөйләде?

Разалия. Барын да миңа әйтеп тормый бит ул... Әллә нинди җүләр планнар корып йөри, ахрысы, ул... Болай кеше көлдерүе житмәгән иде бит!

Баян *(серле итеп)*. Аның... сине Илшат абыйга бирергә теләвенә минем сугышуның ни катнашы бар?

Разалия *(кинәт югалып)*. Кем әйтә аны?

Баян. Нәрсәне? Илшат абый белән икегез турындамы?..

Разалия. Бүтән шаяртма болай, Баян үскәнем... Илшат абыеның планнары башка аның!

Баян *(елмая)*. Шылды, Разалия туташ: бездән хата, сездән—ката! Кисәтүең өчен рәхмәт.

Разалия *(уенга борган була)*. Сиңа да рәхмәт... Әйтә белүенә рәтләп! Хуш әлегә... *(Китә: аның артыннан капка киләсе шылт та итми.)*

Баян. Ничек шулай киләне чыңгылдатмый яба ала икән бу?!. Сара файдасына бер ноль: Илшат абыйга март песие шикелле ташы кызган монын! Илшат абыйга буең житмәс шул, кызыкай...

**Иске йортның урам тәрәзәсеннән пыяла кисәкләре ыргыткан тавыш ишетелә: шушы күренеш беткәнче анда челпәрәмә килеп пыяла ватылуы өзелми.**

Лениза *(болдырга чыга)*. Кем кергән иде, Баян улым?

Баян *(ваемсыз гына)*. Будик Разалиясе... Бабасын эзләп йөри. Тәүсига әбкәйгә пыр тузынып өчен тагын бер сәбәп табылды!

Лениза. Шаккатасы юк, улым, инде ничәмә-ничәнче кат ватып китәләр. Кемнәрнеңдер бабаңнан үч кайтаруы инде бу.

Баян. Туксан яшьлек карттанмы?!

Лениза. Минһаж бабаңның гаярь чакларын белмисең син, улым. Сәвит чорында аннан да абруйлырак кеше юк иде авылда... Авылда гынамы? Кайбер район секретарьларын да бармагы очында биетә иде ул! Ил өстендә иләмән карт, дип атамаслар иде үзен... барын да бердәй күрә иде... Көтүчене дә, персидәтелне дә... Берсенә дә баш бирмәде! Кемнәрнеңдер үзәкләренә үткәргәләгән чаклары да булган, димәк...

Баян *(көлә)*. Юк ла инде, әни! Колхоздан калган бер карт кәҗә тәкәсе гел безнең урамда куна—шул ышкынып, мөгезе белән ватып китә, бугай...

Лениза. Нишләп соң, атуса, бүтәннәрнекен ватмый?

Баян. Башкаларныкына буе житми—шунар... *(Гәзитне әле генә күргән булып кыланып.)* Oho! Яна гәзитме ул, әни? *(Алып актарып карый.)* Яңа шигырьләремне басканнар! Берьюлы биш шигырь... Укып карыйсыңмы, әни?

Лениза. Әниең берәр нәрсә анлый, дип уйлыйсыңмы...

Баян. Заманында жырчы булырга хыялланган кеше лә син, әни!

**Өйләренә кереп китәләр, ишегалды кабат бушап кала.**

## Икенче күренеш

**Шул ук вакыт. Иске өйдә эңгер-меңгергә тартым сүлпән караңгылык хөкем сөрә: пыяласы ватылган өлгеле тәрәзәне тыштан капкачын ябып куйганнар. Җиһазлар күп түгел, әмма барысы да заманында затлы саналган—куллан сырлап-сырлап ясалган әйберләр.**

**Күкеле дивар сәгате туктап калган, ахры, хуҗабикә Тәүсига әби шуның белән булаша. Карты Минһаж бабай чыбылдыклы агач караватта черем итеп ята. Тынлык.**

Минһаж *(чыбылдыгын ачып, тамак кыра)*. Сәгать ничә?

Тәүсига. Пычагыма кирәкме ул сиңа... торасың да сәгать ничә, дип сораган буласың... Тагын туктады бу киребеткән нәмәрсә.

Минһаж *(аякларын идәнгә салындырып утыра)*. Нишләтмәк буласың аны, жен корткасы?

Тәүсига. Мин—жен корткасы булгач, син үзең кем булып чыгасың соң, тиле карт?

**Алар шулай бер-берсенә каты гына төрттергәләсәләр дә, «Бадакшановлар» икәннәрен бер минутка да онытмыйлар—ике горур затның тел чарлашуы гына бу.**

Герен авырлаткач, йөреп китмәсме, ичмасам.

Минһаҗ. Күптән чүплеккә чыгарып томырасы гына нәрсә ул.

Тәүсига. Үз урдиннарыңны чыгарып ат... Бригадир чакларын оныткан теге... шушы сәгатькә карап халыкны яшелчә бакчасына эшкә каулап чыгара идең бит... Унжиде яшемдә биючеләр смотрында катнашып алган иң беренче бүләгем бу... Әтәч кычкырганга ияреп дөнья көткән чаклар иде әле. Бөтен авылга бердәнбер сәгать булды... Шул язны башымны-күземне әйләндермәсәң—Ысысысыр халык әртисте дигән биюче буласы кыз идем мин... Уланова шикелле... Башсыз бала! Янымда акыл бирүчем булмаган инде, күрәсең... *(Сәгатен эшләтеп җибәрә һәм торып баса: сәгать герена зур кургашын кашык тагып куйган икән.)* Менәтерә... майлаган төсле йөреп китте... Тәүсига әбиегез тотынса, нибуч... Баяныңны дәшеп дөресләтерсең үзең... Вакытны бик төгәл белеп торасың кила икән.

Минһаҗ. Кургашын кашык тагып куйган инде әллә, юләр карчык?

Тәүсига. Таксам—ансы да үзем биеп алган бүләк... бер дистәдән ничектер сакланып калган соңгысы сандык төбеннән килеп чыкты бая. Менә хәзер эшкә ярап куйды. И, юләр булынган да инде! Бию-миюләр качмас—авылда ныклы яңа тормыш корасы бар башта, янәсе...

Минһаҗ. Кормадыкмыни?

Тәүсига *(ачылып китә).* Кайда соң ул без корган «яңа тормыш»?! Ельцин ручкасы белән бер сызуда юкка чыгарып ташларлык булгач? Чүплек башына бу сәгатьне түгел, икебезне илтеп ыргытасы!.. Барыбер юкка әрәм иткәнбез икән бердәнбер гомеребезне... Ленарыңа әйт кенә-- эһ тә итми, матаеның бишегенә салып илтеп ташлаячак!.. Ничә көн кереп хәлебезне дә белгәне юк... Өлкәнрәкләреннән хат-хәбәр дә көтмим инде хәзер... Элегрәк Сафиясы белән Нәһирәсе язгалыйлар иде—хәзер алары да әллә оныттылар, әллә...

Минһаҗ. Бар да, кешегә ияреп, байлык артыннан куалардыр... Айны да учлап тотарларие—буйлары гына җитми.

Тәүсига. Яшь чакларымыни? Нәрсә такылдап утырасың?! Үз хәлләре хәлдер, диген... Авызыңа бер кашык су салыр кеше дә калмас әле тирәңдә берзаманны... Кайбер кешеләргә озын гомер биреп, Ходай бик дөрес эшли: үзләренең асыл бәяләрен ахирәткә чаклы ук белеп китсеннәр, ди... Сират күперен фани дөньяда чакта ук ясап куя.

Минһаҗ. Чәйнәргә сагыз булды бераүгә.

Тәүсига. Ярым дивана Будик та кергәләмәсә—һаман жир өстендә икәнлегебезне дә сизми башлар идек, мөгаен... Сәлжерәгән ике карачкы булып серәйдек тә калдык икәүләп... Будик кына басымчак иткән була инде... Пыяла кую хәйләсе белән!

Минһаҗ. Тәрәзәңне ваталар—дөньяда барлыгыңны онытмыйлар, димәк! Күтәрәмгә калмаган ич әле—нигә зарланасың, вакытлы-вакытсыз?

Тәүсига. Кемнәр онытмый?! Будик үзе, махсус кара төн сайлап, алдан ватып китә ич тәрәзәңне! *(Картын өнсез калдырып, ишегалларына чыгып китә.)*

**Ялгызы калгач, Минһаҗ карт «пистон» кесәсеннән көмеш чылбырлы сәгатен алып капкачын ача һәм ярым пышылдап укый: «Бадакшанову Мингазетдину Бадакшановичу—за вклад в строительство новой жизни.» Авыр көрсенеп, күкеле сәгатьне барып дөресли.**

Минһаҗ *(тере җан иясе белән сөйләшкәндәй).* Син кешенең вакытын санап суккан буласың, ә вакыт кешене санга да сукмый... *(Түр тәрәзә катына барып, Каравыл тавына карап тора.)*

**Ишегалдында Тәүсига карчык белән оныгы Баян очрашалар.**

Баян. Ай-һай бүген йокының кирәген бирдегез сез, әбкәй!

Тәүсига. Бабаң дәшә әнә: бар, күкеле сәгатьне турылап чык.

Баян *(көлә).* Син өйдән чыгуга сикереп торып төзәткәндер инде—социализм төзегәндә алган көмеш сәгате бар ич аның!

Тәүсига. Ә син—күпне күрмә! Кирәкмәгән җиргә тыгылып йөрмәсән, аяк-кулың да исән булырие... Бар-бар, ишегалдын каравыллап торма монда—урлап китмәсләр. Кем белән тел чарларга белми утыра анда бабаң. Әниең үзе генәме өйдә?

Баян. Мәче баласын санамаганда. *(Бабасы янына керә.)*

**Тәүсига карчык кергәндә килешнәре Лениза, үзалдына моңаеп, сөян гөбедә май язып маташа. Картларныкы белән чагыштырырлык та түгел аларның өй эче: бай җиһазлы, биек түшәмле, күп тәрәзәле. Бигрәк тә заманча төрле телевизор, видео ише аппаратлар—бары да япуннар ясаган.**

Лениза *(моңлана)*.

Чыбылдыккаем чуп-чуар,
Чебен кунса кем куар?
Ирекле илкәемне сагынганда
Елама, дип кем тыяр?

Тәүсига *(өстәл кырына килеп утыра)*. Каян отып алдың әле бу борынгы җыруны, килен?

Лениза. Әллә инде.

Тәүсига. Ленарың нишләп, кичәле-бүгенле, бер дә атасы кырына кереп күренми?

Лениза. Күренергә оялып йөрүедер... соңгы көннәрдә бераз шешә урманында адашкалап алды бит... Кайсы—утын сорый... Кайсына—Кыдаш ярыннан читкәрәк күченер өчен нигез бүрәнәләрен сипләргә имән агачы кирәк. Көн дә шундый бер мәшәкате чыгып тора бит лесник кешенең. Ташларие—кая барсын хәзер.

Тәүсига. Әллә ниткән кирлеморлы булды бу дөньясы... Уланова кебек балерина буласы идем мин үзем дә. Биатаң да—айраплан ясаучы булам, дип хыяллангание—кул селтәде заманында... Без ярый инде: бүген бар, иртәгә юк, дигәндәй... Яшьрәкләргә кыен—бүрек кигән тавыклар чоры туры килде. Барсының да хатыннары ирләрен ничек телиләр шулай муеннарыннан борып кына йөртәләр!

Лениза *(гаҗәпләнеп)*. Миңа төрттерүеңме бу, әни?

Тәүсига. Упшым әйтәм.

Лениза. Сез дә зарлансагыз инде, әни... Гомереңә мәктәптә чиста эштә булгансың... Җылы... Җил-яңгыр тими... Әткәй дә—гел түрәләрчә вирхум да, трантаста гына йөргән.

Тәүсига. Йөрде пычагым!.. Күрмештән узып, түрмеш кемгә дә тими... Арты трантас мендәренә тигәнче, ничәмә-ничә еллар резин итекләрдән фермы пычрагын ерырга туры килгәнен ул үзе генә белә.

Лениза. Ә мин? Ә Ленарыгыз? Үземне белә-белгәннән бирле мырыкмырыклар сасысын иснәдем... мин дә синең шикелле сәхнәдән сәхнәгә күчеп кенә җырлап йөрисе кеше идем бит! Ленарыгыз художник булмаслык идемени? Кемне генә алма—үзе теләгәнен эшли алмаган.

Тәүсига. Шуңар дөньясының рәте-чираты күренми дә һаман, килен.

Лениза. Бәрәч? Кем гаепле соң? Үзегез шулай коргансыз ич дөньягызны!.. Карт-корыларның әле дә, кызыл флаг күтәреп, элекке тәртипне кайтарыгыз, дип бугазларын киерүләренә шаклар катам мин. Ис-акылларың китәр...

Тәүсига *(ташның үз бакчасына атылуын чамалап)*. Бездән сорап тордылар ди!

Лениза. Мин дә упшым әйтәм.

Тәүсига *(бераз дәшми утыра)*. Илшатыгыз бирәр нәрсә ачыклый алмаганмы? Баянны кемнәр кыйнаганын, дим?

Лениза. Бик исе китте... Өйләнергә йөри, ахрысы, ул... Шулайрак икеле-микеле сөйләнгәләп киткән иде... Күренми әле һаман да.

Тәүсига. Нишләп Баянның үзеннән әйттермисез соң сез? Үз итәгеннән төшкән бала ич ул!

Лениза. Әйттерерсең аны... Балакшанов булсын да... *(Кинәт.)* Балакшанов булганы өчен имгәтеп ташламадылар микән аны, дип уйлап куям мин кайчак.

Тәүсига. Юкны сөйләмә, килен! Балакшановлар махау чирлеме әллә?!

Лениза *(бианасын тыңламый)*. Бик булуы мөмкин. Атасына кагылырга куркалар—лесник кешегә бүген йомышы төшмәсә, иртәгә йөз ертып киләсе була... Илшат белән дә әллә ни кыра алмыйлар—ул үзе өч кешене бер тишеккә бөтереп тыга торган егет... Үч алырга кулай шул Баян гына кала инде! Буыннары катып бетмәгән сыеграк чагы... Чыркылдыгын чыгарганчы тукма!

Тәүсига *(шаккатып)*. Нинди үч?! Нәрсә өчен?

Лениза. Балакшанов нәселеннән булган өчен, дип торам ласа. Бер аягы кабер якасына баскан карттан үч алудан ни файда хәзер? Тәрәзәсенә таш бәреп киткәннәре дә бик житкән... Тыныч кына йокламаска шул да бик таман... Теге заманнарда, өстеннән донослар язып, башын юкка ашатырга

маташканнардыр, дисеңме... Калхуз төзүдә башлап йөрүчеләрдән булган ич... Кемнәрнедер рәнжеткән чаклары да булгалагандыр... Көпә-көндез, акыр-тып-бакыртып, сыерларыңны утарыңнан талап алып чыгып китсеннәр дә...

Тәүсига. Юкны сөйләмә, килен! Биатаңның беркем сыерына да тигәне булмады! Рәттән кәҗә-сарыкларны да кырып җыя башлагач, ул аяк терәп каршы төште!.. Данусларның иң зурысы да шул иде бит инде.

Ленизa. Халыкка ни аерма... Шул талап җыйган мал исәбенә авыл түрәләренең типтереп ятканнарын күрмиләр идемени алар... Әткәй дә шулар тирәсендә чуалучыларның берсе булган бит.

Баян *(иске йортта бабасына)*. Ишеттеңме, өлкән Бадакшанов? Фермер оныгың кулдан американский джип сатып алган... Нугай Гамлеты белән яшелчә бакчасын арендалауны рәсмиләштерергә киткәннәр иде алар. Нишләптер алып кайтып күрсәтми һаман.

Минһаж *(ул Даниель Дефоның «Робинзон Крузо»сын актарып утыра)*. Аренда кәгазенме? Машинасынмы?

Баян *(көлә)*. Ике төрле мәгънәдә әйттеммени? Машинасын, кәнишне.

Минһаж. Язучы булам, дисең үзең.

Баян *(китабының тышын күтәреп карый)*. «Робинзон Крузо»?.. Балалыгыңа төшүеңме бу, бабкай? Әллә үзеңне Робинзон шикелле ялгыз итеп тоя башлавыңмы? Кеше, картайгач, иң әшәке дошманнары үлсә дә авыр кичерә башлый, дип әйткәнең бар иде.

Минһаж *(елмая)*. Икесе дә бар-дыр, оланым.

Баян *(каршысына утыра)*. Ташла, бабкай! Әйдә—берәр житди темага гәп куертыйк, ичмасам.

Минһаж. Куерткычың үзең беләнме соң?

Баян *(маңгаена төртеп ала)*. Нәрсә-нәрсә, бабкай—бу чүлмәкне теләсә кайчан үт өстенә куяласың!

Минһаж. Чүлмәгеннеме?.. Җәле, әйтеп бир, алайсам: Робинзон, утраулга эләккәч, кайчан беренче кат шулпалы аш пешереп ашаган?

Баян *(көлә)*. Бу китапны кулыма алмаганга биш былтыр бит инде, бабкай!

Минһаж. Ярар, синенчә булсын—үзем әйтәм: уночении ел киткәч кенә! Нәрсә дигән сүз бу?

Баян. Җае чыкмагандыр?.. Аш пешерер өчен савыт тапмагандыр йә.

Минһаж. Иштең ишәк чумарын! Бу китапның милли йөзе юк дигән сүз ул. Мә, алып чыгып, тагын бер кат укы!

Баян. Туктале, бабкай... Ничек инде милли төсе булмасын?! Даниель Дефо—инглиз язучысы, герое да инглиз... Гел үз заманыча яши, фикер йөртә... Тагын нәрсә җитми?

Минһаж. Робинзон урынында берәр татар баласы булса—икенче көнне үк рәхәтләнеп кайнар ит шулпасы чөмерер иде! Миңа нәрсә җитми...

Баян. Савытсыз-нисезме?!

Минһаж. Савытсыз-нисез. Ә моның—дарыдан бушаган тыгыз тәпәннәре дә булган, җитмәсә! Булмаган очракта да...

Баян. Тәпәннәре агачтан ясалган булган бит!

Минһаж. Ясалса ни? Синең борынгы татар бабаларың, беләсеңме ашны ничек пешергәннәр? Каян тузыннан тузказан ясаганнар да, шуңа су тутырып ит салып, учакта кыздырылган чуер таш батырып тотканнар. Бер-ике таш учакта кыза тора, бер-икесе—ашны кайната... Төгәл бер сәгать чамасы дигәндә—кайнар шулпалы ит әзер! Тузказанга чуртым да булмый.

Баян. Беренче кат ишетәм мин мондый нәрсәне!

Минһаж. Шыр наданнар булыр өчен туасыз чөнки сез хәзер... Робинзон да, әйдә, синең төсле надан булсын, ди. Ә язучысы ни караган? Әнгличәннәрнең борынгы бабалары татарлар сыман берәр җай тапмаганнар, дисеңмени? Дөньяга яралган көнне иртүк чуен казан тоттырмаганнардыр ич аларга? Бер дә булмаса—таш чокырда пешереп була... Юан агач кәүсәсен казан сыман яндырып карарга... Ә Робинзонның балтасы-өтергесе, ышкысы-мышкысы—барысы да кулы астында... Шуңар милли төсе юк, дип әйтәм мин, бу китапның, олан.

Баян *(үйланып)*. Даниель Дефоны бетереп ташлаган булып, миңа акыл бирден әле син, өлкән Бадакшанов!.. Зату—Баян оныгын да төшеп калганнадан түгел икән, бабкай: торыпша мангайлы генийларың бер якта торсын!

Мировой ачыш ясадым мин бүген. *(Елмая.)*

М и н һ а ж. Әйтеп кара?

Б а я н. Вәзенләп тормыйм... Кыскасы, болай: хәзерге вакытта кешелек дөньясы көрчеккә килеп терәлгән. Әдәбиятта булсын, сәнгатьтә... Мүкләк сыер кебек өч глобаль тема тирәсендә чуалалар: галимнәр аларны **табигать, кеше һәм табигать, кеше һәм кешенең үз табигате**, дип атыйлар. Бөтен язылган китап—шушы өч темага сыя. Ә дүртенчесен табалмыйлар. ЮНЕСКО, хәтта, дүртенчесен тапкан кешегә алтыннан һәйкәл вәгъдә иткән, имеш!

М и н һ а ж *(елмая)*. Ә син—таптыңмы?

Б а я н. Чынлаптыр әгәр, бабкай! Тик әлегә беркемгә дә әйтми торам.

М и н һ а ж. Чәлдерүләреннән куркасыңмы?

Б а я н. Алтын һәйкәл куйсыннар да! *(Көлә.)* Сина гына тишәм серемне, өлкән Бадакшанов—чөнки син минем ышанычлы сейф, бабкай! **«Табигать һәм мәңгелек»**, дип атадым мин аны. Язучы булалсам—гел шушы темага иҗат итәчәкмен. Толстой булып, Толстой да кагылып кына киткән бу темага... Нишләптер, овациягә күчкән көчле алкышлар ишетмим, өлкән Бадакшанов?

М и н һ а ж *(җитди)*. Алла да—ышанганга бар, ышанмаганга юк, оланым.

Б а я н *(кычкырып көлеп җибәрә)*. Алла да?! Кемнән ишетәм мин? Синме бу, партейгеноссе Бадакшанов?! Иртәгә кояш Чатра тау ягыннан чыгачак икән, болай булгач!

**Ишегалды тынлыгын бозып, Яңа йорт артындагы тыкрыктан мотоцикл килеп туктаган тавыш ишетелә. Шул арада ишегалдына урамнан, келәне бик каты чыңгылдатып, кутәренке кәефле Будик килеп керә: аның төенчеге дә, бөкеле мылтыгы да, таягы да юк бу юлы. Ул, Яңа йортка карап, йодрык күрсәтә һәм: «Кур-рва!»—дип Иске өйгә кереп китә.**

**Бераздан гараждан ишегалдына Ленар чыга һәм үз йортына кереп китә.**

Л е н а р. Нихәл, әнкәй... бүген күрешмәгән идек, бугай, пенте что... Әйе!

Т ә ү с и г а. Нишләп бик сөмсерең коелып кайттың, Ленар улым?

М и н һ а ж *(ишектән кереп килгән Будикны күреп)*. Чистый аптыраш!.. Бүген дә моның чырае сыер ялагандай ялт итеп тора... Менә кемгә—ике дөнья бер кәнди. Төкерә ул синең мәңгелегенә, олан...

Л е н а р. Сәбәп беткәнмени бу дөньяда... Юкны бушка аударып йөреп арылды. *(Хатынына.)* Малаең өйдә түгелме? Икәү генә сөйләшсә сүз барие, пенте что... Әйе.

Л е н и з а. Олысымы, кечесеме?

Л е н а р. Баян, дим!

Т ә ү с и г а. Бабасы белән ләчтит сатып утырадыр... Хәзер эшереп чыгарам.

Л е н а р. Ашыктырма—утырсын. Киленең белән сүз бар минем.

Т ә ү с и г а *(үзенчә аңлап)*. Әниләрен бер күрмәскә әллә ниләр бирерләр иде! *(Үпкәләп чыгып китә.)*

Б у д и к *(Баянга)*. Бар әле, апаем, ишегалдыгызда гуләйт ит. Картлар усрагын иснәп утырма монда!

Б а я н *(бабасына күз кыса)*. Син килеп керүгә үзем дә шуны уйлап алган идем, алаш бабай! Чыгып китсәм: божыр өтеп чыгып китте бугай бу егет, дип гаепне мина тагарсыз, дип шикләндем. *(Култык таягын алып, көлә-көлә чыгып китә).*

**Әбисе белән икесе ишегалдында очрашалар.**

Б а я н. Будик килеп керде анда, әбкәй, мине куып чыгарды! Бабкайга ниндидер сере бар, ахры.

Т ә ү с и г а. Атаң белән бергә булмаганнардыр ич алар?

Б а я н. Иртүк Чатра тавына менеп киткәннәр иде.

Т ә ү с и г а. Аңлашылды, алайса... Син үзегезгә керми тор, Баян улым—әтиең мине дә куып чыгарды.

Б а я н *(көлә)*. Икебезгә дә урын калмаган икән, әбкәй!

Т ә ү с и г а *(коры гына)*. Ана нигә шайтаның куана—авызыңны ерасың?

Б а я н *(әбисенең кәефсезлегенә гаҗәпләнеп)*. Кызык ич... *(Алма бакчасына кереп югала.)*

**Тәүсигә әби үз өйләренең алгы ягына керә һәм ике картның лыбыр-лыбыр сөйләшүен ишетеп, эчкә үтмичә туктый.**

Б у д и к. Нишләп дөнҗа хәлләрен сорашмыйсың, алаш җашти?

М и н һ а ж. Сорады, дип исәплә.

Б у д и к. Сорашмавың җакшырак!

Кур-рва... Оланыннын ничек көлүенә колак салдынмы? Жылауга тарткан! Анын белән ниләр булганын белмисез шул сез, эштиплавайлар! Чатра тавы астындагы комаякта өч ирдәүкә кыз әдәм мәскәрәсе итеп ташлады аны!

Минһаж. Ничек?!

Будик *(карт тирәсендә орчык кебек бөтерелеп йөри)*. Ничек... ничек! Ә син—Лилиненнең ничә ташы кубып төшкәнен санап жатасың! Үгез күрмәгән сыерлар нәрсә эшлиләр? Болар да шулай! Аяк-кулларын бандитлардан бәйләтеп, комга салдылар да... дүрт тал төбенә тарттырып бәйләп! Колагынны жакынрак куй... Түлке тих-ха! Ленарыгызга барын да әйтмәдем мин... Ничек тукмауларын гына! Матри—катыннарга чүпрәк авыз булмасаң гына сөйлим сиңа да! *(Минһаж карт өстенә иелә һәм пышын-пышын сөйләргә тотына: тик ара-тирә генә, алгы яктагы Тәүсиганы карчыкны сискәндереп, «Кур-рва!» дип кычкырып-кычкырып куя.)*

Ленар. Безнең малай өчен кытаклап йөрүе икән Будикнын... *(Хатыны куйган ризыкны ашый.)* Әнтрәтсит ташкүмер тапкан, имеш! Чатра тауга менеп житүгә, коляскадан сикереп төште дә көлә, мәнсез карт: жүләр сүзенә ышанып монда менгән син үзең тиле, ди... Ярар, чукынып катмасмы... барыбер бер менәсе барие...

Лениза. Әйткән идем мин сиңа, атасы... алданып йөрмә шул дивананың сүзенә, дип. Малай турында нәрсә ди соң?

Ленар. Кыйнаганнарын чынлап та күреп торганга охшый ул, пенте что... Әйе. Өч ят ир-ат бәйләнгән аңа... ниндидер кызлар өчен, бугай... бер иптәше белән Чатра тау комлыгына кызынырга барган булган ул. Якындагысы ярамаган, имеш!

Лениза. Андагысына кала кызлары өзелми бит... Ажаган кыйнаган урын кебек—машина-машина килеп төшәләр. Шулар белән аралашасылары килгәндер.

Ленар. Бик шәп аралашканнар! Аяк-кулы бер ай инде төзәлми жәфалана, пенте что... Әйе. Сизәм: тагын ниләрдер булган анда... Күпме кысып карадым—Будикнын телен чишеп булмады... Ярар, сабак булыр үзенә икенче!

Минһаж *(каян көч килгәндер—кинәт Будикның якасыннан ала)*. Ялганлыйсын, акылга туймаган Алла бичарасы!

Будик *(картның хәлсез кулларын жиңел генә ычкындыра)*. Жакшылап тыңла, диләр ич сиңа, дивана карт... *(Тагын кызу-кызу нидер сөйләргә керешә.)*

Лениза. Илшаты да каядыр башала китте дә югалды.

Ленар. Сиңа әйтмәдеме ул? Яшелчә бакчасына коттедж салырга чамалап йөри икән. Подвалын да кертеп санаганда—өч оятажлы итеп, ди... Әти, син лесник чакта очсызракка яхшы материал әзерләп каласы иде, баш бәясе булмасын түлке, имеш...

Будик. Кур-рва!

Лениза. Башы бәс кичкәнче өйләнергә бит исәбе! Бик әйбәт булырие... Син нәрсә диден соң?

Ленар. Начар булмас, мин әйтәм... Шунсын онытмагыз: минем абынганны күтәп кенә торучылар буа буарлык хәзер, пенте что... Әйе. Кырмыска оясына таяк тыккан шикелле булмагае... Кәгазь-мәгазьләренә черки дә борын кыстыра алмаслык итәрбез ансы... Әллә нигә төшмәс!

Лениза. Эш нигә терәлде сон, алай булгач?

Будик. Кур-рва!

Ленар. Нәрсәгә терәлсен... Барып торган чакта үзебезгә дә шундыйрак берәр нәмәрсә әмәлләп булмасмы әкренләп, дип уйлабрак йөри идем. Малайга—сама сабуй, пенте что... Әйе.

Будик. Кур-рва!

Лениза *(көлә)*. Булганына бәрәкалла диген, атасы! Бар өстенә яңаны салып кергәнебезгә дә дистә ел юк ич?

Ленар. Юләр син, әнисе... Төпчегебезгә калыр монсы. Дөньясы гелгел генә болай жай чыгарып тормас, пенте что! Күп халыкның әлегә, үз бүлесез мал көтүе сыман, чыбыркы шартлаганны көтеп йөргән чагы. Моңарчы сукыр тычкан да тота белмәгәннәр күсе аулый башладылар әнә! Форсат килгән чакта авыз ачып тормаска кирәк, пенте что... Әйе. Булганнан зыян юк. Терсәкне тешләрдәй булырсын—соң булыр!

Лениза *(елмая)*. Бай бул, тегермән сал—онны сатып ал, ди торгание безнең әти, артык күпне өмет иткән сүз ишетсә.

**Ишегалдына берьюлы ике яктан, алма бакчасыннан—Баян, урам капка-**

**сыннан—Сара килеп керәләр. Капка келәсе чыңгылдый.**

Сара *(кергән шәпкә).* Угадай, Баянчик: немец теленнән безгә, представляешь, кем керәчәк?!. Илшат абыеннын каладан кайтып төшкән кәләше!

Баян *(ваемсыз гына).* Чираттагы саескан хәбәредер әле?

Сара. Немканың абыеннын яна машинасына утырып киткәнен үз күзләрем белән күреп калдым! Чәчрәп китим менә! Чибәрлеген күрсәң! Ул прическасы!.. Кәз-кәз генә басып, чеметтереп атлаулары!.. Һөд-һөд кошымыни... *(Көлә).* Бөтен класс малайлары поголовно гашыйк булдылар... Илшат абыең белән бер институтта укыганнар икән алар: абыең бишенче курста, ул—беренчедә... Кара, чыраен да үзгәртмәде бу! *(Сәгатенә карый.)* Калганын кичтән сөйләп бетерермен әле... *(Урамга чыгып сыпыра.)*

Минһаж *(ул, бар гәүдәсе белән бөрешеп, кечерәеп калган).* Башка сыймый...

Будик. Каравыл тавындагы җансыз сурәткә карап кына җатасын чөнки! Борынын астынданиләр эшләнгәнен күрәсең килми! *(Аның сөйләшүе бөтенләй нормаль тоела.)* Бабил манарасы кормыйлар аны!

Минһаж *(кинәт айнып киткәндәй).* Кагылма!.. *(Торып баса.)* Будик башы гына җитәрлек нәрсә түгел ул...

Будик. Оланыгызның мәсхәрәпазурын әчегезгә җәшәреп җәшәгез инде, алайсам! *(Тышка юнәлә.)*

**Алгы якта аларны тыңлап торган Тәүсигә карчык җәһәт кенә ишегалдына ташлана. Аның янына, аксый-аксый Баян килә, ләкин сүз катарга өлгерми—урам капкасы төбенә машина килеп туктый. Аннан ир-ат белән хатын-кыз сөйләшкәне ишетелә.**

Минһаж *(кинәт исенә килеп).* Бүтәннәр алдында авыз чайкый күрмәсен бу аңгыра катык! *(Ишегалдына ашыгып чыга.)*

Баян *(әбисенә).* Илшат абый кәләшен күрсәтергә алып кайткан! *(Тиз генә яңа йорт янына барып, таягы белән верандага кага.)* Әй! Бадакшановлар! Чит бавырны каршыларга чыгыгыз! Әни, видикны әлектерергә онытма!

**Бер үк вакытта диярлек, Ишегалдына бер яктан Минһаж карт белән Будик, икенче яктан—Ленар белән Лениза чыгалар.**

Лениза *(Баянга видеоаппарат бирә).* Нәрсә булды, улым?

Баян. Их, кыз сикертергә мендәр алып чыкмагансыз—Илшат абый килен алып кайтып килә сезгә! Өйләнми картая инде, дип хафага төшкән илегез бөтенегез! *(Капка келәсе чыңгылдый башлауга, авызыннан гармун ясап, Мендельсон маршы уйный башлый һәм бер үк вакытта видигына төшерә.)*

**Менә, ниһаять, Ишегалдына Илшат белән Гөлшат килеп керәләр: ят кыз беренче адымын ясауга кинәт, аягы астындагы кечкенә таш кисәгенә абынып, җиңелчә сөрлегеп ала. Баян, шуны күрепме, шаярып уйнавыннан туктый. Әмма ят кыз үзен бик тиз кулга ала һәм, берни булмагандай, елмаеп, Илшатны култыклый. Алар, тынлык саклап, Ишегалды уртасына үтәләр.**

Илшат. Чү! Иплэп атла, Гулечка...

Гөлшат. А что—ты веришь приметам?

Илшат. Шучу... *(Көлемсери.)* Держи хвост пистолетом! Тем более—Баян энекәш безне тарих өчен видеога язып ала!

Будик *(бинокле аша карап, үзалдына).* Бәрәкалла—бәрән сыйрагы... Теге битсез гурт маржаларынын берсе ич бу! Кемне иярткән бу гидай малай?!. Нәкъ үзе! *(Биноклен корсагына ташлый.)*

**Будикнын мыгырдануы Минһаж карт белән карчыгына яңакларына чапкандай тәэсир итә. Баян, тасмага төшерүе белән мавыгып, бернәрсәгә дә игътибар итми. Әтисе белән әнисе дә берни сизми калалар.**

Гөлшат. Тәртәмне кире борырга соң түгелме әле, Илшат? *(Елмая.)*

Илшат. Ни за что, Гөлшат! *(Якынрак килгәч, туктыйлар: ул бер кулын кәләшенең җилкәсенә сала.)* Менә, Гөлшат, таныш бул: син куышыласы данлыклы Бадакшановлар шушылар була инде! *(Будикның, авызын зур ачып, телен кашыгыдай кыланганын күрә.)* Бәрәч, күрми торам—адаш абзый да монда икән.

Будик. Саташма, апаем: мин—Бадакшанов түгел!

Илшат. Кайчан кайтып төштең? Кызыльярда малаенда кунакта, дигәннәр иде бит сине? Түрә сые—бер генә көн: диңгез капитаны биноклен

биреп, алдалап кире кайтарып жибәргән, ахры? *(Әкрен генә көлеп куя.)* Бер кызык әйтәчәк ул хәзер... *(Гөлшатның колагына нидер пышылдый.)*

Будик *(китеп барган җиреннән кайтадан борыла).* Үз туганнарың белән исәнләш башта, юләрбаш! Син кәттиж саласың икән—хак сүзме ул? Хак булса, идәнен түшәмгә, түшәмен—идәнгә җәйдер! *(Тагын урамга юнәлә.)*

Илшат *(көлеп).* Нишләп, гадук?

Будик *(туктап тормыйча).* Чөнки патамушты, катын алгач, барыбер бар дөнҗаң асты өскә киләчәк! *(Кәләшенә.)* Ә сине, кызый, күргәнем бар минем! *(Урамга чыгып китә—аннан ваемсыз такмаклавы ишетелә.)* Эштиплавай! Эш давай! Эш бирмәсәң—ләбән җуки, әлки-сәлки бәндә гуж-ж...

**Баян видеотасмага төшерүдән туктый.**

# Икенче бүлек

## Өченче күренеш

**Икенче сентябрь иртәсе.**

**Төнен көчле генә яңгыр явып узганга охшый: Бадакшановларның ике йорты да, каралты-куралар да—соргылт-кара төстә, әмма һәрнәрсә сурыгып килә, ахры. Күк болытлы—көзгә хас тоташ юеш, күгелҗем.**

Илшат *(Яңа йорт болдырына чыга: ул кешелеккә кигән киеме өстенә майга буялган халат сымаграк юка эш киеме киеп алган).* Бр-р!

**Аның янына Гөлшат чыгып баса: ул да эшкә китәргә әзер.**

Зерә чыккансың—эшенә бик иртә әле, Гөлшат... Мин машинаны караштырам—кичә бераз барахлить итеп алган иде. Һава бик дымлы да бүген, салкын да—бар, бар кереп тор!

Гөлшат. Төн буе... яңгыр яуды ведь.

Илшат *(кинаяле елмая).* Жалко!

Гөлшат. Нәрсә—жалко?

Илшат. Йоклый алмый изаланып яткансың икән бит! Белмәдем.

Гөлшат. Белсәң нишли идең?

Илшат. Ничек тә... бер чарасын тапкан булыр идек әле, старуха! *(Көлә.)* Кирәксәм—мин гаражда гына! *(Түфлиләре өстеннән зур резин галушлар өстерәп, гаражларының аркылы тимерләрен шалтырата-шалтырата эчкә кереп югала.)*

**Кунак кызы янына Лениза чыга.**

Лениза. Монда салкын түгелме сезгә, Гөлшат?

Гөлшат. Түзәрлек, Лениза ханым. Борчылмагыз. Иртәнге һава сулыйм, дип кенә мин... Искиткеч матур икән сездә!

Лениза *(сүзләре бар, ахры, кулында чиләк булса да, болдырдан төшәргә ашыкмый).* Безгә күренми дә ул... Бер ияләшкәч ни... Иркенләп сөйләшеп тә булмады кичә... Синең ата-инәңнәр исәнме?

Гөлшат *(аның бер «сез», бер—«син»гә күчүенә елмаеп).* Әйе.

Лениза. Кайдарак торалар?

Гөлшат. Кама буенда.

Лениза. Кама елгасы бик озын бугай?

Гөлшат. Саралан дигән бер авылда җәй яшәр өчен алган бер йортыбыз бар безнең.

Лениза. Дача кебегрәкме?

Гөлшат. Әйе. Элек күбрәк Казанда бергә тора идек без. Әтиләр хәзер, авылның һавасы яхшы, дип кышларын да почти гел шунда.

Лениза. Синең кияүгә чыгуыңны беләләрме соң?

Гөлшат. Беләләр... Эшкә монда килергә уйламаган да идем мин. Илшат уговорил.

Лениза. Алай икән... Хәерлегә булсын инде әйдә. Язмышыңдыр, бәлки. *(Каралтылар ягына кереп китә: анда аның «Ти-ти-ти-ти!», дип кош-корт ашатуы ишетелә.)*

**Ялгызы калгач, Гөлшат кинәт дертләп урам капкасы ягына борыла—анда... шомлы шәүлә сыман Разалия басып тора. Сүзсез генә, бер-берсен сынашкандай, карашып торалар. Авыл кызы кала кызына бер сүз дә әйтми чыгып китә. Капка келәсе шылт иткән тавыш та чыгармый. Гөлшат, ни булды**

**бу дип гаҗәпләнгәндәй, җилкәләрен җыера. Өйгә кире кереп китәм дигәндә генә каршысына Баян чыга: ул бүген кулын аскан кара яулыгын салып ташлаган.**

Баян *(елмаеп).* Гутен морген, Гөлшат Касыймовна.

Гөлшат. Сиңа да хәерле иртә телим, Баян... *(Елмая.)* Не удивляйся—мин при любой возможности татарча сөйләшергә тырышам.

Баян. Ә минем—немецча бар белгәнем шушы ике сүз! Чөнки әфтияк тә укымаган башы белән берәү укытып яткан иде безне.

Гөлшат. Значит, мина—не очень повезло.

Баян. Аның каравы—мина повезло.

Гөлшат. Как аңларга моны?

Баян. Блат өчен сөенә икән бу, дип уйламагыз—белмәгәннәремне теләсә кайсы вакытта сорый алачакмын, димәк. *(Елмая.)* Кире хәл итеп куймасагыз.

Гөлшат. Почему? Варум?

Баян. Варум?.. Сез абый белән язылыштыгызмы инде?

Гөлшат. Юк, өлгермәдек... Минем Казаннан пропискадан төшәсем бар.

Баян. Шулайрактыр, дип уйлаган идем мин.

Гөлшат. Вас ист дас? Шутка дип аңнаргамы?

Баян. Турысын әйтсәм—ачуланмыйсызмы?

Гөлшат. Битте?

Баян. Авылда торып калуыгызга үзегез дә ышанмыйсыз сез минемчә. Теләмисез дә бугай.

Гөлшат *(бераз тынып тора).* Кызык... Или—син үзең теләмисенме моны?

Баян. Миндә түгел эш... Калада үскән кеше бит сез. Бөтенләй башка дөнья тәрбиясе алган кеше.

Гөлшат. Менә ничек?!. Кала кызлары белән... неудачный танышлыгың бар, видимо?

**Баян аны җавапсыз калдыра.**

Эс ист дер шлюссель цур велт!

Баян. Ялгышасыз. Бернинди дә мировой ачыш түгел бу.

Гөлшат. А говоришь, что немецкий плохо знаешь!

Баян *(елмая).* Случайно гына ул...

Гөлшат. Синең белән... алныартны чамалап сөйләшергә кирәк икән... Ник ошамый сиңа кала кешеләре?

Баян. Калада туып үскән татар—татар түгел инде ул...

Гөлшат. Шулай да... синең белән уртак тел табарбыз, дип надеюсь мин... Кичә без килеп кергәндә бер... чудаковатый старик бар иде. Кем иде ул?

Баян. Будик дип атыйлар бездә аны. Минһаҗетдин исемле ул.

Гөлшат. А почему—Будик?

Баян. Бәләкәй чагында сакау булган, диләр. Бүрекне «будик» дип йөргән. Шуннан калган кушаматы.

Гөлшат. Ул нәрсә... тулы түгелмени?

Баян. Кем белсен аны... Сугыш алдыннан ул авыл советы председателе булып эшләгән икән. Шул елларны ике абыйсын репрессияләгәннәр. Шуның аркасында бераз ычкынып калган, имеш. Бер карасаң—нормаль генә була үзе... Авылда иң «кызыл кеше» шул инде! Ә үзе—тау башында землянка казып, яшеренеп кенә намаз укып төшә. Иде, элек.

Гөлшат *(елмая).* Сезнең Минһаж бабагыздан да кызылракмыни?

Баян. Бабкай—бөтенләй башка кеше! Ул хәтта Сталин чорында да үз фикерен кешедән яшермәгән!

Гөлшат. Осуждать итеп әйтүем түгел, Баян... Гибель старого трагично, когда оно—морально чистое заблуждение.

Баян *(тирән гаҗәпләнеп).* Үзегез уйлап чыгарган афоризммы бу?

Гөлшат *(елмая).* Шулай булса иде... Трагедия темаларының берсе шушы.

**Тынып торалар. Гараж эчендә Илшатның машинасы бер-ике тапкыр чәчәп куя.**

Мина бик ошады сезнең авыл... Тик кояш бик иртә байый икән монда.

Баян *(ул хәзер кунак кызына карата бераз йомшара төшә).* Аның каруы—иртән соң чыга! *(Елмая.)*

Гөлшат. Әнә теге тау каплыймы? Илшат ничек атала дигән иде.

Баян. Каравыл тавы... Ә тегесе, кояш батышы ягындагысы—Чатра тау. Алар турында бер риваять тә бар!

Гөлшат. Риваять? Нәрсә ул?

Баян. Притча. Кайчандыр алар икәүләп бер кызга гашыйк булганнар,

имеш. Кояшсылуга. Шуннан теге шарт куйган боларга: кайсыгыз иртәрәк торып, соңрак ята—шуңа булам, дигән. Шул көннән алып, бер-берсенә комачаулыйлар, имеш: Каравыл тавы иртән Чатра тауны бик озак үз күләгәсендә тота, ә кичләрен, киресенчә—Чатра тау Каравыл тавын кояштан каплый. Ә Кояшсылу инде әллә кайчан кияүдә, имеш! *(Көлә.)*

Гөлшат. Ә сезнең ни гаебегез бар?

Баян. Көн кыскалыкны әйтәсезме?.. Нишлисең бит, ике дөя сугышканда арага кысылып чебен үлә! *(Тынып тора.)* Зато—бездә беркайда булмаган бер спорт тере бар. Кояшлы көннәрне, кич житкәч, тупны күккә чөеп уйныйлар: кем аны иң соңгы мәртәбә кыеклап төшкән кояш нурына мана ала—шул жинүче чыга... Элегрәк безнең Илшат абый беркемне дә уздырмый иде.

Гөлшат. Кызык... Миңа ул, нишләптер, берсен дә сөйләми боларның. Әнә теге Ленин портретын сезнең әтиегез ясаганын да үзем сорашкач кына әйтте.

Баян *(елмая).* Бадакшанов бит!.. Бадакшановларны белеп бетермисез әле сез.

Гөлшат *(суыктан кинәт бөрешеп куя).* Таныша башладым инде. Синең шагыйрь икәнлегеңне белдем, мәсәлән. *(Елмая.)*

Баян. Кем сүзе ул? Илшат абыйның әкиятеме, шалапай авыз?!

Гөлшат. Юк. Район газетасында басылган шигырьләреңне үзем укыдым. Миңа берсе бик ошады!

Баян. Кайсысы?

Гөлшат. Әлегә әйтми торам—үзең угадай... Әнә бер классташың кереп килә, не буду мешать. *(Өйгә кереп китә.)*

Сара *(кулында дипломаты).* Сәлам, Баянчик! Oho! Кулың төзәлде дәмени инде?

Баян. Турайга американский джип белән генә элдертәсең киләме, Сарра?

Сара. Уй! Чынлапмы?!

Баян. Илшат абый кәләшен мәктәпкә машинасы белән илтә.

Сара. Илтеп ташлый, диген!

Баян. Не понял?

Сара. Икесе ике яры ятып йоклаганнар ич! Кала кызының сезнекеләр белән боткасы пешмәгән, ахры?

Баян. Кем гайбәте бу?! *(Гөлшат ишетеп тормыймы дигәндәй, жәлт кенә ишеккә карап ала.)*

Сара. Сөт аертырга кергән хатыннар гөр килә.

Баян. Бар дөнья сасытып, юкны шыкырдарга сез койрыксыз саесканнарга гына куш инде!

Сара. Тәүсига әби нигәдер бер дә ошатмаган, имеш.

Баян. Телләре кычыткан хатыннар ни такылдамас!

**Тынып торалар.**

Бүген нишләп бик иртәләдең? *(Сәгатенә карамакчы була, ләкин ниятеннән кире кайта.)* Жиденче ярты да юк ич әле... Синең өчен шайтан таңы белән бер вакыт инде бу!

Сара. Ә синең өчен?.. Алай мәктәпкә чаклы ук машина илтеп куйгач, нишләп үзең дә бармыйсың?

Баян. Кеше көлдерепме? *(Култык таягына ымлый.)*

Сара. Ә! Чулак Афзал Рәшите белән булгансың икән син Чатра тау асты комлыгында! Дөресме? Шуны да миннән яшергән була!

Баян *(сагаеп).* Монсы кем гайбәте?!

Сара. Рәшит үзе әйтте. Исерекләр бәйләнә башлагач, ул качып котылган, ә син—бер кызга кызыгып калгансың! Шуңа яшерәсең!

Баян *(исән кулы белән кызны жилкәсеннән ала).* Тагын нәрсәләр шапырынды ул куян йөрәк?!

Сара. Авырттырасың ич! *(Аның кулын алып ташлый.)* Бөтенесен дә сөйләп бетермәде әлегә... Бер шартым бар, ди.

Баян. Нинди?

Сара. Минем белән йөрергә риза булсаң—әйтәм, ди.

Баян. Син ни дидең?

Сара. «Звучит заманчиво!»—мин әйтәм. *(Көлә.)*

Баян *(кулларын йодрыклый).* Шартмартлар күрсәтермен әле мин сезгә!

**Веранда эчендә Гөлшат күренә: яшьләр аның анда икәнлеген сизмиләр.**

Ну и—катись Чулак Рәшитен янына!

Сара *(үз итеп).* Алай итәрлек булсам—сиңа әйтеп тә азапланмас идем мин, Баянчик... *(Үзалдына көлеп куя.)* Бер кызык анекдот искә төште! Имеш,

шәһәрдә үскән бер кыз авыл мужикларыннан сорый икән: «Әнә теге сыер—сыермы, танамы?» Тана, диләр тегеләр. «Ә ничек аерасыз сез аны?» «Мөгезләренә карап яшен белеп була—мона ике генә яшь әле.» «Ә, шулай икән—ике генә мөгезле икәнен күрми дә торам!»—дип тел шартлатты, ди кала наданы!

**Көлешәләр.**

Сезнең немка да шундый микән, Баянчик? Үзе ишетеп тормасын тагы... *(Верандаларга карап ала: ләкин Гөлшат читкә тайпылып өлгерә.)*

Баян. Кайгысы синдә түгел аның—Балакшановалар алдында каты сынау тотарга әзерләнәдер.

Сара *(көлә).* Тәүсига әбиеннен жиз иләгенә эләк кенә!

Баян. Кичә мине сораучы булмадымы?

Сара. Мәктәптәме? Класс житәкчесеннән бүтән кемгә хажәтең бар соң синең?!

Баян. Ә егетләр?

Сара. Бик исләре китте! Имгәнүеңне ишеткәч: «Бу—аның проблемасы!»—дип кенә куйдылар, шул булды. Телләрендә доллар да машина хәзер аларның!

Баян. Ә сезнең телдә нәрсә? Кияүгә чыгумы?

Сара. Юк, сезне ничек тә кулга төшерү! *(Көлә.)* Кияүгә чыгу дигәннән, Будик Разалиясе бүген иртүк Илшат абыеңның кәләшен күрергә килеп киткән инде! Ачыктан-ачык сөйләшергә кыюлыгы гына житмәгән.

Баян *(ышанып бетми).* Авылда бер тәлпекәй карчык бар иде, хәзер син—икенчесе булып барасың!

Сара *(верандадан чыгып килүче Гөлшатны күрә).* Чү, немка... Гутен морген, Гөлшат Касыймовна!

Гөлшат. Данке шен, Сара... Низамова бит?

Сара. Әйе, Гөлшат апа. Менә: Турайга укырга барырга чыккан идем—Баян әйтә, ашыкма, машинага утырып барырсың, ди.

Илшат. Кем ул—минем үземнән башка минем машина белән распоряжаться итә? *(Ул машинасын, гараждан чыгарып, капка төбенә куйган.)*

Гөлшат. Без, Илшат. Ничек, Сараны алабызмы үзебез белән?

Илшат. Дисенме? *(Икеләнеп тора.)* Куркып чиңашмасагыз гына. Ышнага турыга Каравыл тавы сыртыннан чыгабыз.

Сара *(коты алынып).* Ленин астыннанмы?!

Гөлшат. Ничек? «Ленин асты» дигән юл да бармыни сездә?

Илшат. Житмеш биш ел буе кем астында йөрдек соң без? *(Көлә.)*

Сара. Әнә теге сурәт янынннан үткәнгә әйтәм мин, Гөлшат апа.

Гөлшат *(шул якка карап).* А это—не опасно?

Сара. Өстебезгә Лениннын берәр ташы кубып төшсә генә инде! Менәсе бар әле анда башта—юл жебегән чак.

Илшат. Төн шыбрае таш жебетә, ансы... Юлга чыгуыңны бел син кызый! Барып житкәч күз күрер... Менә, энекәш—кала кешесе белән авыл мокытларынын аермасын сизденме инде? Кала кызы масштаблы күзаллый—гомумән юл куркыныч түгелме, дип сорый. Ә сары томшыкның бар перспективасы бу минутта—тауга менә алу-алмау гына! Шуңа кала кызына өйләнәм дә мин.

Сара *(бераз үпкаләп).* Кала кызлары бик шәп булгач, нишләп соң син, Илшат абый, авыл мокытлары янында яшәп ятасың?

Илшат. Минем төп ике принцибымның берсе мондый, чибәркәйләрем: кала кызын ярат, әмма тамырыңны авылда тарат! *(Көлә.)*

Гөлшат. Ә икенчесе?

Илшат. Икенчесеме? Ансы да гениальный: бүтәннәр бакчасына яңгыр яудырырга кулыңнан килмәсә—үз бакчаңа су сип! Здоровый эгоизм, дип атыйм мин аны.

Гөлшат. Кызык...

Илшат. Барып житмәде бугай сезгә. Бер яркий пример китерәм, алайса. Франциянең көньягында Монако дигән бер кәрлә ил бар—бүтән жире безнең авылдан чак кына зуррак. Ә шул илне дөньяда белмәгән кеше юк! Үзен цивилизацияле санаган, әлбәттә. Чөнки анда—Монте-Карло бар. Дошло?

Баян. Коттеджыңда, Монако кенәзләре төсле казино ачып, ике куянның койрыгын берьюлы тотмакчы буласың инде, алайса?

Илшат. А что? Отличный идея, энекәш! Ну, кызлар: зитцен зи битте машинага!

**Гөлшат белән Сара кычкырып көлеп җибәрәләр.**

Сара. Яволь, Илшат абый!

Илшат. Нигә көләсез? Акцентым матурмыни?

Баян. Мин шуны уйлап торам әле: бер кечкенә татар авылы чаклы Монако илен ничек 500 ел буе беркем дә басып алмаган микән? Бар гаскәре— бер сержант та ике солдат, ди, бит анда!

Илшат. Рәсәйгә якын булмаганга! *(Үз җорлыгына үзе башлап кычкырып көлә.)*

Лениза *(утар ягыннан чыга)*. Китәсезме, улым? Бик соңламагыз: кичке якка мунча өлгертергә исәп.

Илшат. Шәп булырие ул, әнкәй! «Хорошо после баньки, особенно—в первые три года!»—дип әйтте, ди бер чисталык яратучы карт урыс.

**Көлешә-көлешә чыгып китәләр. Машина кузгалып киткән тавыш. Шуның артыннан ук урамда Будикның ярым такмаклап килүе ишетелә.**

Будик *(үзе әлегә күренми)*.

Гыйнвар, фибрал, март, апрел—
Ачка катырган айлар.
Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран—
Фарситлый җана байлар!

Баян. Бабкайның адашы килеп житте.

Лениза *(ачусыз гына)*. Вакытсыз вакытта йөри ул да.

Будик *(кергә-керешли эшлекле кыяфәт белән)*. Тишек чиләгегез кайда, Линизә килен?

Баян. Нихәл, адаш бабай! Нишләп исәнләшмисең?

Будик *(аңа күз койрыгы белән генә карап)*. Ничә күрешергә була, бәбәлән йомыркасы? Кичә бер исәнләшкән идек бит инде! Бик акыллыбаш булсаң—миңа шуны аңлат: нишләп минем сул аягым үтереп сызлый, ә?

Баян. Өлкәнлек галәмәтедер, Минһаҗетдин бабай.

Будик. .... беләсең син! Нишләп соң уны сызламый, алайсам? Ике аягым да бер җәштә ич минем! Син лутчы Илшат абыеңа әйт: бәхетле көннәренең кадерен белеп калсын.

Баян. Туе октябрьдә генә бит әле.

Будик. Шунар әйтәм дә мин, сантый! Бәхетле көннәре бетәргә ай ярым гына калган... Тишек бидрәгез тагын җукмы дим, Линәрми катыны?!

Лениза. Килгән саен бер кызык китереп чыгарасың син, Минһаҗетдин абзый... Каян булсын ул бездә?

Будик. Ничек булмасын?! Берсе Илшатыгызның машинасында киткәнен үзем дә күреп калдым! *(Кырт борылып, иске йортка кереп китә.)*

Баян. Берәр нәрсә аңладыңмы син, әни?

Лениза. Юләр кайгысы өчен башыңны ватма, улым. *(Өйләренә керә.)*

Баян *(уйланып)*. Нидер мәтәштереп йөри бу дивана карт... Разалиясе дөрес кисәткән, ахры! *(Алма бакчаларына юнәлә.)*

**Шул арада Тәүсигә карчык, үзләреннән чыгып, килене янына керә.**

Тәүсигә. Син үзең генәме, килен? Барын да озатып бетердеңме инде?

Лениза. Әйтмә дә, әни... Арт төртергә дә чират җитми! Туй мәшәкатьләре килеп терәлгәч нишләрсең!

Тәүсигә. Ансы—кысыр хәсрәт кенә булырга охшаган, килен.

Лениза. Бәрәкәт? Ни дигән сүзең бу, әни? Хәл кылынган нәрсә бит инде ул. Кай арада уегыз үзгәрде? Бер төн өстендә нәрсә булды тагын?!

Тәүсигә. Кичә—чүпне читкә чыгармас өчен генә дәшми калдым мин... Җае да туры килмәде, аннан соң. Шайтан аягын сындырырлык хәлләр тора әле каршыда.

Лениза. Кызык кешеләр сез, әни! Ленарыгыз белән мин өйләнешкәндә дәниләр генә кыланып бетмәгән идең! Бу юлы башыңа да кертмә.

Тәүсигә. Ничек—бу юлы?

Лениза. Синең хәтереңне кәҗә кимергәндер дә... Мин берсен дә онытмыйм, әни! Малаеңны миңа өйләндермәс өчен күпме жаныбызны ашадың... Малае йортка керү була, янәсе... Бадакшанов булсын да, имеш! Ике арадагы ихатаны сүтеп аткач кына тешеңне кысып түздең... Хәзер— баласының баласы язмышын үзенчә бормакчы! Җитте. Илшатның үз акылы бар аның. Кай җире ярамады сиңа бу кызның?!

Тәүсигә *(ул мондый һөҗүмне көтмәгән)*. Әстәгефирулла... Нәрсәләр чокып чыгардың, килен?.. Сүзләрең колакка сыярлык түгел! Менә ишетмә-

сәң ишет карт көнендә... Илшатың пазурга калмасын өчен тырышам ич мин!

Лениза. Нинди пазур?!. Бернинди пазур күрмим мин! Менә дигән кызга өйләнә. Үзе тапкан—үзе багар.

Тәүсига *(ачуыннан чишелеп китә)*. Нәрсә беләсен сон син? Илшатын да тома сукыр! Әйтсәм әйтим инде, алайга китсә! Баяныгызны мәсхәрә иткән кәнтәйләрнең берсе шушы икән бит инде!

Лениза. Ничек—мәсхәрә иткән?

Тәүсига *(ул инде туктап калырлык түгел)*. Ир-ат назы күрмәгән ирдәүкә хатыннар, җае чыкса, ялгыз ир-атлар белән нишлиләр—шулай! Элекке лесникны мукшы хатыннары урманда тотып нишләткәннәр иде?.. Әйтүләре генә дә ни оят!

Лениза *(кычкырып җибәрүдән курыккандай, авызын учы белән каплап, урындыкка утыра)*. Әнекәем...

Минһаж *(Будикка)*. Куймаган балны зимнәп йөрүең генә түгел микән бу? Беләм мин сине... Гомергә юри башыңны тинтәккә салып яшәдең син. Кытай мәймүне кебек, боларның көрәше ни белән бетәр икән, дип үзең читтән генә карап көлеп йөрдең... Үзеннән көлдергән булып кыланып!

Будик *(кызыксынып)*. Ниткән кытай мәймүне?

Минһаж. Ул да арыслан белән юлбарыс үгез түшкәсе өчен канга батып сугышканда тау башыннан карап ята, имеш. Кайчан бер-берсен өзгәләп ташларлар инде, түшкә үземә калырие, дип!

Будик. Тә-тә-тә-тә... Без белмәгән аз булыр, Бохардагы таз булыр! Үзе—ике киек-җырткычның берсе, җәнәсе... малаең да бер нәрсә булдымы—гарил мәймүне төсле җонлы күкрәген йодрыклары белән дөп-дөп төя башлый! Кичәгенәк минем мылтыкны кәнфис иткән булды... Тәтеми генә торсын әле! Бүген төннә үк килеп, гаражыннан апчыгып киттем инде мин аны...

Минһаж. Җирле, Минлехарислар эте буыла-буыла өргән иде... Нишләмәкче идең мылтык белән?

Будик. Патамушты сез мылтык белән бозган дөнҗаны мылтык белән генә төзәтеп була, ахмак карт!.. Шәп әйттемме? *(Көлә.)*

Тәүсига. Туртыйдан туры хәбәр, ди... Будик бөтенесен үз күзләре белән күреп торган икән. Адашына сөйләгәндә ялгыш кына ишетеп калдым үзем дә,,, без белгәнне беркем дә белми әлегә! Малаенның корсак тирәсендә пешкән-мазар җәрәхәте бармы?

Лениза *(ул бианасының сүзләрен: «Хәсис нәрсә икән!.. Әй, ходаем!» кебек аһваһлар белән тыңлый)*. Йа, Хода... бар бит, әни!.. Самай кендеге өстендә... Майкасын салдырып алганда күреп калдым!

Тәүсига. Будик бөтенесен Чатра тавыннан бинокль аша карап яткан икән. Сезнеке тәмәке тартамы?

Лениза *(бөтенләй коелып төшкән)*. Юк... Юк, бугай... Уф! Башыма бозлы су койгандай булды... Әдәм рисвае... Туй көне дә билгеләнде бит инде! Нишләп кичә үк әйтмәдең моны?!

Тәүсига. Кичә! Әйтеп торалар ласа—кичә җае чыкмады... Кара аны, килен: белгәненне малайларын сизмәсеннәр! Күрмәгәнебезне күрербез аннан... Баяның өчен шулай әйбәтрәк. Беркем белми, дип җаны тынычрак булыр, ичмасам.

Лениза. Әчтән генә янып йөри икән, йөрәк маем... Тукта, ә Илшат белән нишлибез?!

Тәүсига. Хатынсыз калмас әле! Дүрт саны да исән... Кәнтәенә авыл һавасы ярамый миңа, дип әйтергә кушарбыз. Икәүләп борычлап-тозлап пышкыртырга тотынсакмы? Авылдан ничек чыгып ычкынганын да сизми калыр, хәшәрәт! Әшен судка житкермәгәнгә сөенә-сөенә. Судка бирергә теләмисеңдер ич?

Лениза *(ике куллап кире кага)*. Аллам сакласын!.. Йа, ходай... нинди генә хәшәрәтләр юк бу дөньяда!.. Фәрештә кебек кыз диярсең үзен... Уф! Күз алларым караңгыланып китте... Кая ул суд! Болай да... Илгә таралачитә калса!

Тәүсига. Уфтанудан файда юк хәзер... Уйлашыйк. Бүген үк рәвешен китереп, хәл итәргә кирәк моны! Сасысы чыкканчы сузарга ярамый... Кайсыбыз сөйләшә? Әллә—икәүләпме? Үзең генә хәл итәсеңме әллә?

Лениза *(коты алынып)*. Нәрсә дип әйтермен мин аңа?! Безнең малайны көчләгәнсең икән, дипме?!

Тәүсига. Уйлашырга кирәк, дип торам ич...

Лениза. Йөзенә карап шаркылдап көләр—шул булыр!.. Баянны таныма-

гандыр, дисеңме, ул?! Ыжламый да—берни булмагандай рәхәтләнеп кунак булып ята!.. Ә Баян, мескен, йөзен хәтерләп калмаган, күрәсен, шул битенә олтырак каплаган нәмәрсә белән ачылып сөйләшә, житмәсә!.. Ут йотып яши икән, балакай... эченә йомылып... Әйтәм—соңгы вакытта алма бакчасыннан кергәне дә юк!

Тәүсига. Кемгә ачып салсын ул аны?.. Сиңамы? Атасынамы? Әллә—Илшат абыйсынамы?! Бабасы янына да куып кына керткәндәй керә башлады... Аннан ничек тын алуын да яшермәгән бала!

Лениза *(кинәт)*. Әй! Баштан да чыккан! Будик Разалиясе бик ешлый башлады бу тирәгә... Ул бахыр кызыкай да нидер белә, димәк?! Илшат хакына гына телен аркылы тешләсә инде!

Тәүсига. Ничек—Илшат хакына?

Лениза. Яшьтән үк безнең малай артыннан бер тотам калмый үсте ич ул бала... Илшат кына, нишләптер... күз атып йөрүенә көлеп кенә карый. Хатын-кыз бер үчексәме?! Эшләр харап аннан соң!

Тәүсига. Кылын иплэп кенә тартып карарга кирәк—ниләр белә икән ул?

Лениза. Кит, әни—хужы гына эшләп ташларбыз! Авыздан авызга бер китә башласа...

Будик *(Минһаж карт янында бөтерелә)*. Жук инде, эштиплавай! Чигенергә соң хәзер! Вакытлы гына хәлләр бу, бар нәрсә—элекке тәртәләр арасына керәчәк кире, дип куркып жатасың син! Шуңа—тегеләй дә, болай да кистереп әйтергә куркасың... Артыгын кыланып ташлармын да—жавап тотарга туры килмәгәе, дисең! Мәскәүдә коммунистларның кара китабын бастырып чыгарганнар, ди, әнә... Жир жөзендә барлыгы жөз мульоннан артык бер гаепсез кешене атып үтергәннәр икән сезнекеләр! Эстинәгә терәгәннәре генә әле шулай... *(Тиз генә барып, күкеле сәгатьне туктата.)*

Минһаж. Нишләтәсең аны?! Кагылма.

Будик. Туктаттым! Нигә кирәк ул сиңа? Сәгатегез сукты инде сезнең ишеләрнең! Кала кызы белән эшеңне бетер әнә... Кистереп сөйләшергә жөрәгең житмәсә—үзем жакасыннан алам мин аның! Матри, эштиплавай, катыннарны тыкма бу эшкә.

Минһаж. Син үзең чүпрәк авыз булма, дип әйтелде ич инде сиңа—ничә кат тукырга була? Калганы—минем эш!

Будик *(йөзе ачылып китә)*. Күптән шулай диләр аны, эштиплавай! Илшатыгызга менә нинди шәп кыз табып бирәбез! *(Баш бармагын күрсәтә.)* Бер кашыкка салып жотарлыгын. *(Хужа кеше теге-бу сүз әйтеп өлгергәнче, канәгать йөз белән тышка юнәлә.)* Уйла давай, эштиплавай, әлке-сәлке көлке, ләбән жүки бәндә гуж... *(Болдырга чыккач, биноклен муенынннан салып, күй тәкәсе мөгезенә элеп китә.)*

**Тынлык.**

**Ике йортта да хужалар авыр уйга чумып утыралар. Алма бакчасыннан Баян килеп чыга һәм туп-туры бабасы янына керергә килә. Будикның биноклен күреп, ала һәм Каравыл тавы якларын караштыра. Биноклыне кире урынына элеп, бабасы янына керә.**

Баян. Күрдеңме, өлкән Бадакшанов: бүген төнлә тагын Ленинның берничә ташы кубып төшкән... Бәрәч, туктаган ич бу сәгать. *(Күкеле сәгатьне эшләтеп жибәрә һәм үз сәгатенә карап дөресли.)* Будик тышта биноклен кәбәш мөгезенә элеп калдырып киткән, бабкай. *(Аның янына барып утыра.)* Бүген уртак тел таптыгызмы әллә? *(Көлә.)*

Минһаж *(коры)*. Үз исеме юкмыни аның?!

Баян *(мондый кискен сүз көтмәгән)*. Синең алда гына бит мин.

Минһаж. Минем алда да әйтмә! Акыл булсын моннан ары.

Баян *(уенга бора)*. Бетте, бетте, өлкән Бадакшанов! Тем були—аның белән безнең ике нәсел очы да бер үк чабаталы морзага барып тоташа, имеш. Шәхсән мин үзем моңа бик ышанып бетермим, ансы.

Минһаж *(шулай ук кырыс)*. Шамакайлануыңны да ташларга вакыт. Күпкә китсә—гомерлек гадәткә күчә ул.

Баян. Синең сүз—миңа «руководство к действию», өлкән Бадакшанов! Закон. Сүз жаеннан, бабкай: урысларның «закон» дигән терминнары элек мәскәүләрнең Алтын Урда баскакларына «с нашим удовольствием за канун» дигәннәреннән ясалган, ми-

немчә: за канун да за канун, дия торгач—«закон» булып киткән! *(Бабасы җавапсыз калдыргач.)* Бүген сина, нишләптер, ничек тә ярап булмый әле, өлкән Бадакшанов... Аптыраган үрдәк төсле, хет артың белән Кыдашка чум!

Минһаҗ *(сынап).* Синең урында Илшат абыенның хәлләре белән кызыксыныр идем мин, олан.

Баян. Илшат абыйга ни булган? Дингез тубыктан аңа хәзер! Машинасында, учти—яна американский машинасында!—курчак төсле чибәр кәләш утыра. Атасы, шайтан таңы белән сикереп торып, туй бүләгенә коттедж салыр өчен шәп наратлар сайларга матаена атланып чапты. Әбисе белән газиз әнисе, кырык эшләрен кырык якка ташлап, иртәннән бирле чыш-пыш туй мәшәкатьләрен үзара бүлешәләр. Бар җае көйләнгән аның! Синең белән мина гына дүрт кулга бер эш табылмый әле никтер. Илшат абый урынында мин үзем дә, тома сукырланып, бүрәнә ярыгыннан да көлеп йөрер идем! *(Көлә.)*

Минһаҗ. Тома сукыр? Нигә алай дисең?

Баян. Немкасы... кунакча үгиләгән тавык шикелле рәк. Ә Илшат абыйга—ике дөнья бер кәнди.

Минһаҗ. Кәләшендә берәр шигең-мазар бармы әллә?

Баян *(уйланып).* Абыйга мөнәсәбәте ачык түгел. Грибоедовның итәкле Чацкие сыман, кайчандыр гыйшык-мыйшык уйнап йөреп, хәзер генә, кабат очрашкач, күзе ачылып килми микән ул кызның? Ба! Шул ук Илшат—танырлык түгел, янәсе.

Минһаҗ. Бөтен шикләрең шушы гынамы, олан?

Баян. Эчен ярып карамагач, асылын каян белеп бетерәсең инде, өлкән Бадакшанов... Болай—акыллы гына кеше кебек тоела ул мина. Социализмга чын күңелдән ышанган кешеләр турында, беләсенме, ул, бабкай, нәрсә ди?

Минһаҗ. Ну?

Баян. Урысча әйтте ул аны... татарчасы бик шәп түгел, дип... Әгәр дә мораль яктан ихлас күңелдән эшләнгән ялгышлык булса—үткән гомер тирән фаҗига ул, ди! Син килешәсенме моның белән?

Минһаҗ. Алай... Житди кеше ул, дисең, алайса?

Баян. Ә мин үзем, барыбер, кала кызына өйләнмәс идем, өлкән Бадакшанов!

Минһаҗ. Ник?

Баян. Чөнки шәһәр кешеләре—төрле язулар белән чуарланып беткән кара такта шикелле: күп күрә, күп белә—тик шул язуларның кайсы яхшы: кайсы начар—үзе дә, бүтәннәр дә аера алмый.

Минһаҗ. Ә авыл кешесе?

Баян. Авыл гыйбатларымы? *(Елмая.)* Тактасына аз язылган—за то һәр сүзе ап-ачык уеп куелган. Игътибар иткәнең бармы, бабкай: каладан килеп төшкән кешеләр, ничәнче кат булмасын—беркемне дә юньләп танымыйлар? Яңа капка күргән сарык сыман сиңа күзләрен тозландырып торачаклар. Иткән яхшылыкны да оныталар алар... Шолохов авылда яшәп бик дөрес иткән!

**Урамнан ишегалдына сулышы капкан Сара чабып килеп керә: өсте-башы пычранган, дипломаты юк.**

Сара *(ике якка да борылып кычкыра).* Баянчик! Син кайсы өегездә?!

Баян. Нидер булган, ахры, Сара тавышы!

**Бадакшановларның өйдә булганнары барысы да ишегалдына чыга.**

Сара *(сулышы каба-каба).* Илшат абыйның машинасы суга батты!

Лениза. Ә үзе?!

Сара. Үзенә берни дә булмады... Каравыл тавына менә генә башлаган идек... Салулап, артка чигенеп төшеп китте дә... Юллар бер дә сурыкмаган икән әле... Илшат абый белән икәү яр башында сикереп төшеп калдык... Ә немка, Гөлшат апаны әйтәм, машина эчендә килеш суга чумды!

Тәүсигә *(килененә).* Алла бар ул!

Баян. Ничек инде... Билдән генә ич ул тирәдә?

Сара. Юк... Япьле шомырт астында тирән чоңгыллы яткыллык урын бар анда!..

Баян. Бүрәнкале жирне әйтәсенме?

Сара. Әйе!

Минһаҗ. Шуннан?

Сара. Харап булды бу, дип котларыбыз очты! Күз ачып йомарга да өлгермәдек без... Суда бигрәк тиз бата икән ул машина. Алгы ишекләре дә ачык килеш калган иде, житмәсә!

Баян. Илшат абыйның кәләше ничек чыкты, дип сорыйбыз без синнән!

Сара. Гөлшат апа үзе су астыннан пылт итеп килеп чыкты!

Баян. Илшат абый кәләше батканын яр башыннан карап тордымы?!

Сара. Нишләп инде?.. Артыннан сикермәкче булып, чишенә башлаган иде инде ул... Гөлшат апа йөзү буенча мастер икән... Иделне беррәттән икешәр мәртәбә туктаусыз аркылы чыкканы бар икән!

Баян. Үзе мактанамы әллә?

Сара. Юк ла инде!.. Классташлар каяндыр белгәннәр... Ярый, машинаның ишеге ачык ягы өскә таба карап төшкән—алгы пыяласын ватып чыгарга туры килгән булыр иде, ди Гөлшат апа. Ну йөрәк икән үзендә! Аның урынында мин булсаммы...

Минһаж. Бәхетенә—прабур бала, димәк.

Ләниза. Ә үзләре кайда соң әле?

Сара. Илшат абый трактор эзләп Ышнага йөгерде... Ә мин—Гөлшат апага коры киемнәр алып барырга кайттым. Япьле шомырт төбендә утырып калды ул... Тешләре шык-шык килә үзенең! Бик каты ажгыр җил анда... Өстендә минем юка плащ кына.

Тәүсига. Үз киемнәренә ни булган?

Сара *(ир-атлар ишетмәсен, дип кулы белән авызының бер читен каплый).* Ярым шәрә килеш ул анда, Тәүсига әби: киеме рулгә уралган да—ерткалап шунда салып калдырган. Мин булсаммы?! Көлкегә алган була үзе: муттерларын-фатерларың кәләшеңнән аягы авыр булды, дип әйтерләр инде, ди! *(Кинәт.)* Бәрәч! Дипломатым машинада калган ич минем! *(Баянга.)* Нишләргә инде хәзер?! Бөтен кирәк нәрсәләрем шунда иде!

Ләниза. Берәүләрнең өр-яңа машинасы су төбенә киткән—моңарда нииндидер иске портфель кайгысы!

Баян. Кемнендер бүләге су төбендә калганга кайгыра ул.

Сара. Дурак син, Баян... И—не лечишься! *(Урамга чыгып йөгерә.)*

Минһаж *(елмая).* Исән калганына шөкер итми, чәүчәләк кош.

Тәүсига. Сорамадык та, монда кире әйләнеп кайтамы икән ул кызый? Әйдә, килен, башлаган... эшләребезне бетерик. Имгәккә иләк төшә, ди...

Ләниза. Әйтмә дә, әни... Аның урынында бүтән берәү булса—су төбендә сәгатьлек әҗәле сагалап торган булырие...

**Үзара сөйләшә-сөйләшә яңа өйгә кереп китәләр.**

Баян *(артларыннан көлемсерәп карап кала).* Киленнәре өчен мыеклары да селкенмәде кебек боларның... Сезденме, бабкай?

Минһаж. Киленен җиз иләктән иләмәгән хатын-кыз юк бу дөньяда... Илшат абыең берсе дә йөгереп килмәде, дип үпкәләп йөридер анда.

Баян. Сүзең хак, йөзьяшәр Бадакшанов... Үзе гаепле! Төн буе шыбрай яңгыр өзелмәгәнен белә иде бит... Кем кушкан аңа шушындый юешлектә тауга менәргә? Әти—урманда, әнинең дуңгызларын карарга барасы бар, мин—инвалид! Әбкәйне житәкләп, син үзең йөгерсәң генә инде, бабкай? Әйдә, булмаса, шул үкенечтән бер шәп мат куеп чыгам үзенә!

Минһаж *(көрсенеп).* Син куйган матлар гына нипачум ул, олан.

Ләниза *(болдырга чыга).* Баян улым! Кер әле монда бер генә минутка.

Баян. Нәрсә булды, әни?.. Шахматыңны тезә тор, бабкай... *(Җилкәсен җыерып, әнисе артыннан керә.)*

**Берүзе калгач, Минһаж карт, мөгездә эленеп торган бинокльне алып, Каравыл тавына текәлә. Ленин сурәтенә озаклап карый.**

Ләниза. Менә—әбиең әйтә... Баяныгыз йөзү ярышларында катнашкан кеше, абыйсының кәләше белән очрашырга туры килмәде микән аңа, ди.

**Баян (икесенә дә гаҗәпләнеп карый). Нигә кирәк булды әле ул сезгә?**

Тәүсига. Безнең белән туганлашасы кыз ла ул! Хәзер өенә килеп төшәсе киленне шулай читләп-читләп кенә белешсәң инде... Элегрәк бер-берсенең нәсел-нәсәбен чыбык очларына чаклы ныклап тикшермичә беркем дә кодалашмый торган иде!

Ләниза. Заманы эт ялаган төсле заман булгач ни... Күргән-белгән кешең түгелме, улым?

Баян. Җиз иләкләрегезне эшкә җиктегез, димәк? *(Елмая.)* Каян

килеп?.. Йөзү буенча мастер, ди, ич ул. Ә мин—бака буасында гына чупырдап, ничек кирәк алай йөзәргә өйрәнгән мәктәп баласы! Категорияләребез туры килми... *(Уйланып.)* Йөзе, ничектер, таныш та кебек үзенең!

**Әнисе белән әбисе мәгънәле итеп бер-беренә карашып куялар.**

Ә бәлки—тоела гынадыр... Илшат абыйның машинасы җәлке менә!

Т ә ү с и г а. Ансы гына... хәерле каза булсын! Бар, булмаса, шуны гына сорамакчы идек.

**Баян бабасы янына чыгып китә: ансы, биноклен кире урынына элеп, өйләрендә шахмат тезеп утыра инде.**

М и н һ а ж. Нигә чакырганнар?

Б а я н *(елмая).* Сыер да синең төсле лач итеп нәкъ өстенә туры китерә алмас иде, өлкән Бадакшанов! Булачак киленнәрен җиз иләккә салып маташалар... *(Бабасы каршына утырып, култык таягын диварга сөяп куя.)* Абыенның кәләше элек таныш түгел идеме сиңа, диләр... *(Ике фигураны йодрыклары эченә яшерә.)* Кайсы сиңа?

М и н һ а ж *(сагаеп).* Ә син ни дидең?

Б а я н *(бабасы күрсәткән кулын ача).* Ни дип әйтим... Күргән-ниткән мамзель түгел ул, мәйтәм... *(Көлеп.)* Бүген дә бүрең улады синең, өлкән Бадакшанов! Әпәт—аклар синеке... Гомерең буе кып-кызыл кеше булгансың үзең, югыйсә!.. *(Житдиләнеп.)* Дөресен генә әйткәндә, бабкай, кайдадыр күргәнем бар минем аны... Хәтергә генә төшми! Атаканны башла, әйдә.

Л е н и з а. Кайтып кына керсен!.. Баян хәтерли генә алмый, димәк... Андый чакта кем инде барысын махсус истә калдырырга тырыша алсын?! Тучны шул икәнен белсә—набарут, күргәнем юк, дип кырт кисәрие! Шикләнергә урын калдырмаслык итеп... Нәрсә—шулай түгелме?

Т ә ү с и г а. Чистый аптыраш инде, килен.

## Дүртенче күренеш

**2 сентябрь. Көн үзәге. Кояш чыккан, җылыткан—Бадакшановларның ишегалдында төнге яңгырның эзе дә калмаган. Баян ялгызы үз болдырларында немец теле дәреслеге актаргалап утыра.**

Лениза *(болдырга чыга, өстендә эш халаты).* Күренмиләрме?

Б а я н. Кемнәр, әни?

Л е н и з а *(абына язып, ишегалдына төшә).* Абыеннарны әйтәм... Тоткарландылар болар.

Б а я н. Ай-һай бик тиз син, әни! Аларны кәтә-кәтә күзләрен күгәрер әле. Ышнадан трактор табып, урап киләсе... Су төбенә чумып, машинаны троска тагасы... Кырын ята, ди, өстәвенә... Бил каешым бушады, әни, бирәр нәрсә юкмы өстәлдә?

Л е н и з а. Үзең хуҗа бул инде шунда... *(Эшенә китмичә, икеләнеп тора.)* Кунак кызына бер-ике сүзебез барие... Мин югында китеп бармасын, дим... Чучка балалары ашатып кайтасым да бар.

Б а я н *(җиңелчә төрттереп елмая).* Җырчы чыгар иде микән синнән, әни, билгеле түгел, ә менә шәп язучы була алыр идең, мөгаен! Кыска гына өч җөмләдә рәттән өч тапкыр «бар»ны сыйдырдың! «Сүзебез барие», «китеп бармасын», «ашатып кайтасым да бар»... Бар ачып җиффәрәсең генә бар, әни! *(Көлә.)*

Л е н и з а. Юк-бар белән башымны исәңгерәтмәче, улым. Болай да... бар белгәнегез анагызны оятлы иту!

Б а я н *(көлә).* Тагын ике төрле «бар» тапты!

Л е н и з а. Ярар, булмаса—атлый торыйм. Әбиең сораса әйтерсең—мин тиз... бер сәгать исәбеннән әйләнәм. *(Арт бакчаларына үтә.)*

Б а я н *(артыннан).* Абыйның кәләшеннән су ташыттырып куйдырыйммы? Чишмә юлларын өйрәнгән булып, буй күрсәтәсе дә бар үзенең. Ягып та җибәрергә була!

Л е н и з а. Үзем ягачакмын мин аңа... кайнар мунчаны! *(Югала.)*

**Шул ук мәлдә диярлек, урам ягыннан Гөлшат белән Сара чикы-мики сөйләшеп кайтып керәләр: «немка» әз генә**

**сизелерлек сул аягына аксый, икесе дә алҗыганнар, әмма шулай да кәефләре күтәренке күренә.**

Сара *(керешли)*. Баянчик! Тизрәк кайнар чәй—Гөлшат апа туңып үлә язды!

Баян. Ә портфелең кая, Сара? Агып киткәнмени?

Сара. Илшат абый нишләптер килеп җитмәде... Трактор табалмаганмы? Көттек-көттек тә...

Баян. Нишләп, атуса, машинагызны ташлап кайттыгыз? Чәлдереп китсәләр?.. *(Гөлшатка карап елмая.)*

Сара *(чынга алып)*. Су төбендә ята ич ул!

Гөлшат. Шаярта ул, Сара. Суны бик каты болгатып чыктым мин, Баян—күренерлек түгел.

Баян. Менә ансы—шәп булган... *(Аның аксавына ымлап.)* Миңа да аксакташ коллега булдыгыз хәзер. Берүземә генә күңелсез иде, юкса!

Сара. Уены-чыны гел бергә монын, Гөлшат апа! Ничек әле сезгә «Сихәтле пар белән!»—дип әйтми калды—шуңар шаклар катам... *(Көлә.)* Беркөннәрне миңа әйтә бу—мине балавыз булып эрер дигәндер инде: мәктәпне бетергәч, унбиш ел срок бирәм сиңа, ди бу...

Баян *(әйттермәскә тырышып)*. Сар-ра!

Сара *(икесе бер үк вакытта сөйләшәләр)*. ... шул вакыт эчендә ачыклап бетерәсен...

Баян *(кыенлык белән торып баса)*. Кыланма, дидем!

Сара. ...яратасыңмы мине, юкмы, ди...

Баян *(исән кулы белән аның авызын капларга тели)*. Җитәр диләр сиңа, Сара!

Сара. ...шуңынчы ачыклап өлгерсәң, өлгермәсәң дә—барыбер өйләнәчәкмен мин сиңа, ди! Бүтәнгә чыккан булсам да, янәсе... *(Көлә.)* Чын егет сүзе шушы буламыни инде, Гөлшат апа?!

Баян *(кул селти)*. Бала-чага!.. Хәтереңне саклап кына катырак әйтмим инде, Сар-ра!

Сара. Ә син—әйт! Кеше калдыгы идән юа торган чүпрәккә дә тормаячак, диген!

Гөлшат. Киресенчә, Сара: ул әйткәннән дә житдирәк егет сүзе була алмый. *(Елмая.)* Дежур сүзләр генә булса—15 кенә көн куяр иде ул.

Сара. Шаяртып карасын! Артистлыкка укып, театрда эшли башласам—гастрольгә килеп төшкән саен сыңар тәпиең чиратлап сындырып китәчәкмен мин аның! Моның белән шулай гына таманга туры килә, Гөлшат Касыймовна! *(Кинәт.)* Яңа өегездә кемнәр бар? Тиз булыгыз—Гөлшат апага кайнар чәй кирәк, дип торам ласа!

**Шул сүзләрне генә көткәндәй, Гөлшат төчкерә.**

Баян. Чыннан да, салкын эләктергәнгә ошыйсыз сез... Сара, өйдә беркем дә юк—бар, үзең җәһәт кенә кереп чәй куй! Ә сез, Гөлшат Касыймовна, җылы юрганга төренеп ятып торыгыз. Мин хәзер әбкәйне дәшеп кертәм—төнәтмә-мазары юк микән...

Гөлшат. Зыян юк, Баян... Бүтәннәрне борчыма, пожалуйста.

Сара. Юри кыланган була ул, Гөлшат апа... Ә! Менә аның сере—сез укытасы булгач, немец теле дәреслеген тизрәк эзләп тапкан—сезнең алда яхшатлануы гына! Кеше өчен чыннан кайгыра белә икән бу, дип ышанып куя яздым... *(Баянга тел күрсәтеп кереп китә.)*

Баян. Озын-озак юанма анда—аннан ерак чишмәдән мунчага су ташып куярсың!

Сара *(ишек аша башын суза)*. Килен итеп төшергәч әмер бирә башларсын, яме!

**Ялгызы калгач, Баян дәреслеген веранда эченә томыра һәм бабалары янына керә: Минһаҗ карт анда көндәлек тутырып утыра, ә Тәүсигә әбисе чыбылдык эчендә черем итә, ахрысы—күренми.**

Баян. Немкасы кайтты. Илшат абый үзе күренми әле.

**Тәүсигә әби сикереп тора.**

Син йокламыйсың икән, әбкәй... Киленегез бик каты суык алдырганга охшый—бөкшәеп төшкән. Берәр төрле әзер им-томың юкмы?

**Әбисе бер сүзсез ашыгып чыгып китә.**

Кала киленен бер дә өнәмәгән төсле иде—чирли күрмәсен дигәч, яшьләрчә сикереп торып йөгерде әле бу әбкәй! *(Көлә.)*

Минһаҗ *(язуын дәвам итә)*.

«Беренче сентябрь төнендә, ягъни сөмбелә башында көчле янгыр булды. Шунын аркасында Илшат олан машинасын суга төшергән.» *(Оныгы өчен.)* Быел кыш карсыз булачак, димәк.

Баян *(төрттереп)*. Илшат абыйнын машинасы суга батканга карапмы? *(Көлә.)* Мина ике мәгънәдә әйтәсен, дип гел-гел төрттергән буласың, бабкай!

Минһаж. Мине төзәтергә соң инде, олан... *(Күзлеген салып, амбар кенәгәсеннән ясалган көндәлеген түшәмгә асылган такта башына куя.)* Хатын-кызнын кыланышын беркайчан да турыга аңлама: үлә-нитә калса—газапланып ятканын күрми калам, дип куркып чапкандыр ул, бәлки? *(Кеткелдәп ала.)* Менә, примерга, әбиеннен көн тәүлегендә ким дигәндә бер биюче әртист була алмадым, дип зарланмаганы юктыр. Ә бит юри-мырый кылана ул. Калада яшәүдән үзе өректе. Курыкмаса—кышын көрт өстеннән яланаяк укырга чыгып йөгерәсе иде. Ә болай—ике куяннын койрыгын берьюлы тотты: мине гел битәрләргә сәбәп тә табылды, менә кем буласы кеше идем мин, дип борын чөяргә дә була... Үз ирләрен нәрсәдә дә булса гаепли алмасалар—сарулары ташып чыга аларнын! Ир кеше икәнсен, син шуны аңла да, эчтән генә көлеп йөр. *(Көлә.)*

Баян *(аңа кушылып көлә һәм җитдиләнә)*. Шулай да, өлкән Бадакшанов, баш йөртеп карыйм да—бер нәрсәне аңлап бетерә алмыйм мин... Сез нишләп берегез дә үзегез теләгән юлны сайламадыгыз?

Минһаж. Кайсы планда?

Баян. Кемгә генә карама—башында ыштан, аягында бүрек, дигәндәй... Гомер азакларында үкенеп яталар. Үзебезнең Бадакшановларны гына алыйк: син—авиаконструктор булмагансын, әбкәй—ике сүзенең берендә Улановаңы исенә төшерә, әти—сынчы яки рәссам булырлык сәләтен әрәм иткән, әни—җырчы түгел... Берегезнең дә кулдан килгән эшегезнең кирәге чыкмадымыни шулай?!

Минһаж *(уйланып)*. Тормыш выбор бирмәде, олан...

Баян. Мөмкинлекләр булмадымы, сәләтегез кирәкмәдеме?

Минһаж. Көн калагында бүтән эшләр көтә иде.

Баян. Ничек инде?! Табигать биргән сәләтен һәркем файдаланса—тормыш юньлерәк булмас идемени?!

**Тынып торалар.**

Тәүсига *(Яңа өйдә Гөлшат үзе генә, дип уйлап)*. Аулакта сүзем бар иде сина, кунак кызы... *(Аш бүлмәсеннән кулына чәйнек тотып Сара килеп керә).* Үзең генә түгел икән! *(Кире чыгып китә.)*

Сара *(аның артыннан гаҗәпләнеп карап кала)*. Тәүсига әби белән борчагыгыз бик пешми, ахры, сезнең, Гөлшат апа?

Гөлшат *(бергә кичергән авария аларны сердәшләр иткәнгә охшый)*. Иң беренче күрешүдә үк сиздем мин моны, Сара... Потрогай мой лоб: минем үземә генә кайнар тоеламы?

Сара *(кулын аның маңгаена куеп карый)*. Температура ич сездә, Гөлшат апа! Прәме кулны пешерә... Тәүсига әби төнәтмәсен җәлләде—хәзер куян каны кебек куе чәй ясап бирәм. Тиз генә эчегез дә калын юрганга төренеп ятыгыз! *(Чәй ясый.)* Бездә юкә чәчкәсе бар бугай—үзем кайнатып алып килермен... Тәүсига әби главный кеше түгел хәзер монда, Гөлшат апа... Менә юкә баллап эчегез. *(Чәй бирә.)*

Гөлшат. Рәхмәт...

Сара. Немецча ничек әле?.. Ә, «грендиге фрау» гына ул. Пачутлы йорт хуҗабикәсе шикелле генә.

Гөлшат *(елмая)*. Ә кем—главный кеше?

Сара. Мондый эштә соңгы сүз—Лениза түтәйдә. Ул заманында хәтта Ленар абзыйны үзенә йортка керткән кыз! *(Көлә.)* Ата-инәләре риза булмаганда элек кызлар ябышып кияүгә чыкканнар бит. Ә боларда—Ленар абзый ябышып өйләнгән!

Гөлшат. Варум?

Сара. Йортка керү—кимчелек санала ич... Ә Лениза апа тешетырнагы белән ата-бабаларынын нигезен бетерүгә каршы икән! Шуннан Ленар абзый нишләсен—картлар белән сүзгә килеп булса да, күнгән инде! Шуңамы икән, әлегә чаклы араларында мәче мыраулаштыра, имеш. *(Көлә).* Ә Баян әйтә, кешене төп нигезеннән биздерәсең килсә—Африка сыртланнарыннан үрнәк алырга кирәк, ди...

Гөлшат. Сыртлан нәрсә ул?

Сара. Үләксә ашаучы гиена этләре... Шулар, балаларын еракка күчерергә кирәксә—башта якындарак бер өнгә илтеп куялар икән, аннан—арырак икенчесенә, бераздан—тагын да арырак өченчесенә... Төп өннәренә кире әйләнеп кайтып кермәслек ерагайганчы! Баянның атасы—кырый күршегә генә күчкән, Илшат абыйсы—Ташлы арасындагы яшелчәлеккә коттедж салмакчы, ул үзе—кайларга китеп барыр икән, янәсе! *(Көлә.)* Совет иленең төп кануны шул иде, ди...

Гөлшат *(елмая)*. Бик төпле егеткә охшаган ул Баян... Бәхетеңне ычкындырма! *(Житдиләнеп, тәрәзә аша Каравыл тавына карап тора.)* Моннан бигрәк якын тоела икән бу. Гел өскә җимерелеп төшәр сыман тора.

Сара. Ленин рәсемен әйтәсезме? Минһаҗ бабай юри шулай ясаткан, диләр, аны... Булачак биатагыз Ленар абзыйның художник булам, дип хыялланган чакларында эшләгән бердәнбер иҗат җимеше икән ул!

Гөлшат. Ничек? Ул художник та булганмыни шулай?!

Сара. Илшат абыйның сөйләгәне булмадымыни? Кайчандыр бик өметле рәссам исәпләнгән кеше, имеш, ул... Гафу итегез... *(Укытучысының маңгаен тотып карый.)* У! Төшәргә уйламый да бу температура. Сез барыгыз—теге якта урын ясадым, кереп баш куеп алыгыз. Мин тонәтмәгә чаптым! *(Ишегалдына ташлана һәм үтеп барышлай Тәүсигә әбигә дәшә.)* Гөлшат апаның температурасы тагын да ныграк күтәрелгән, Тәүсига әбкәй! Мин юкә чәчкәсе кайнатып алып киләм. *(Урамга ташлана.)*

Тәүсига. Кат-кат килеп маташма—үзем карармын!.. Кысылмаган жире юктыр бу чытлы кытнең! Агач көясе белән бер чистый... Үз өйләрендә кайнашамыни!

**Капка төпләренә мотоцикл килеп туктый: Ишегалдына арыган кыяфәтле Ленар кайтып керә. Үз өйләренә турыга үтә.**

Башта бызгы Сара аяк чалды, хәзер—монсы кайтып төште инде!

Ленар. Илшат өйдәме, әни? Машинасы күренми.

Тәүсига *(улын кире борып җибәрергә сәбәп табылуына куанып)*. Әй, әле син белмисең ич, улым: Илшатыгыз яңа машинасын суга батырган бит!

Ленар. Кайда?!

Тәүсига *(улы янына килә)*. Япьле шомырт астында, ди... Каравыл тавына менә торган жирдә. Ышна юлында... Үзең барып карыйсыңмы әллә, улым? Юкса, ул берүзе, бугай, анда. Берсе дә килми, дип сүгенеп ятадыр! Кәләшенең исе дә китмәгән—Чупай Нугай Сарасы белән икәүләшеп, чырык-чырык көлешә-көлешә кайтып керделәр... Үзләре дә суга батып үлә язганнар икән. Су буеннан коры кайткан балыкчы белән өсте лычма аучыдан да көлкерәк бәндә юк, дип бик дөрес әйткәннәр!

Ленар *(болдырдан кире төшә)*. Причем монда аучы?

Тәүсига. Улыңа кем тозак корып йөри соң?!

Ленар *(үз уен уйлап)*. Чөй өстенә тукмак икән!.. Мин арыган эт урынына урман сайлап чабам, пенте что... Әйе. Бүгеннән калсаң—бүтәннәр чумырып алырга гына карап торалар анда! Кайтып керүгә, машинасын чыгарганмы, юкмы—минем янга Дүртбога жиләклегенә менсен... Юл чатыннан сулга борылып кергәч тә... *(Сүзен әйтеп бетермичә, өйгә кереп тормый, кире урамга ашыга: бераздан капка артында пытыр-пытыр килеп мотоцикл кузгалып киткән тавыш ишетелә.)*

Тәүсига *(канәгатьлек белән)*. Монсыннан котылдык әлегә...

**Яңа өйдә ялгызы калган Гөлшат Сара әзерләгән урында жылына алмыйча ята.**

**Менә Тәүсига әби, ниһаять, тәвәккәлләп, аның янына керергә кузгала, ләкин бакча ягыннан кайтып килгән киленен күреп, болдырда туктала.**

Тәүсига. Җәһәтрәк атла, килен!.. Теге берүзе калды... Вакытында кайтып керүең шәп булды әле. Юкса—кабат Сара килеп керер дә, сөйләшә алмый калырбыз тагын. Төнәтмә алып киләм, дип өйләренә йөгерде—сәгатенә мең ботакка куна торган кычыткан чыпчыгыннан да ким түгел! Әйдә, ходайга тапшырдык... Син үзең башларсың сүзне.

Ленизa. Бер авыздан булсак, кем башласа да—барыбер түгелме...

**Өйгә керәләр һәм Гөлшатны эзләп табалар: аның күзләре йомык.**

Тәүсига *(кулын иплән кенә кызның*

*маңгаена куеп карый).* Чыннан да тәне шөйлә кайнар моның...

**Гөлшат дертләп күзләрен ача һәм курыккандай түшәгенә сеңә.**

Ят, ят... Без әле монда.

Гөлшат *(аларның визитын ничек кабул итәргә белми, әле берсенә, әле икенчесенә карый).* Простудиться иттем, кажется, мин... Көпә-көндез шушылай... ятып торуым өчен гафу итегез. Тиздән пройдет, минемчә.

Лениза. Җәйге томау нәрсә ул... Синең кебек яшь кеше өчен! Өчәүләп хәл итәсе бер житди мәсьәлә килеп чыкты әле монда. Туп-туры сораганга үпкәләмә: Илшат белән ничек таныштың син?

Гөлшат *(гажәпләнеп).* Институтта укыганда...

Лениза. Ана кеше өчен үз баласыннан да кадерлерәк кеше юк. Мин барын да белергә тиеш...

Тәүсига *(аның янына урындык куеп утыра).* Малаена яратышып чыгасынмы син, дип сорый ул, кызый!

Гөлшат *(кыенлык белән елмая).* Без язылышмаган бит әле... Чөнки... мин үзем дә точно белеп бетермим моны.

Лениза. Сорап торасың, әни! Нинди яратышу, ди, ул? Хәзерге яшьләрдә яратуның «я» хәрефен генә беләләр. *(Ул да утыра.)*

Гөлшат *(аларның бик житди кыланганнарын сизенә башлый).* Как это?

Лениза. Урысчадан! Мин диган сүзләре... Мин бүген шулай телим—и бетте! Ә иртәгә... Яратышу дигән нәрсәне белмәсеннәр дә, әйдә... Бер-берен хөрмәт итү, дигәнне дә аңламыйлар бит алар!

Гөлшат. Ә мин—сезне аңламый ятам әле...

Лениза. Бик аңлыйсың!.. Ярар, ансына да килеп житәрбез. Сыер сава беләсенме?

Тәүсига. Аш-су әзерли аласынмы, дип сора башта.

Лениза. Каз-үрдәк ашатканың бармы?

Тәүсига. Яки—тавык чебешләре карап үстергәнең?

Лениза. Казны кайчан ояга утырталар? Көзме, язмы?

Тәүсига. Таптың кала кызыннан сорар нәрсә! Иртәләрен ничәдә торырга өйрәндең өегездә? Бүген көтүне сәгать ничәдә кудын?

Гөлшат. Мин куарга тиеш идеммени көтүне? Нишләп алдан әйтмәдегез?

Лениза. Ипи салганда күәс камырын ничек башлыйлар? Сарык җоны кырыкканың бармы? Йә—печән чапканың?

Тәүсига. Печән чабу ни боларга, кырку ни!

Гөлшат *(ватылып җавап тотуны дәвам итә).* Кайгырмагыз, гросмуттерлар—үзегез научите всему этому.

Лениза. Без-те научить итәрбез!.. Тик кемне научить итәргә?!. Вузларга да теләсә кемне укырга алмыйлар!

Гөлшат. Все еще аңламыйм: почему кинәт кенә мине упрекать итәсез?!. Илшат уговорить иткәнгә генә монда бит мин!

Лениза. Илшат бер нәрсә дә белми, димәк!

Гөлшат. А что он должен знать?!

Лениза *(бианасына).* Чыраен да сытмый бу!

Минһаж *(Баянга).* Яши-яши ике нәрсәне яхшы аңладым мин, олан: беркайчан да, бернәрсәгә дә яраклашырга ярамый һәм бер-береңне сөешеп торудан да важнырак нәрсә юк бу дөньяда... Калганнары—болар каршында чүп кенә!

Баян. Мин керер алдыннан тормышыңны актарып, ревизия ясап утыра идеңме әллә, өлкән Балакшанов? *(Елмая.)* Иртәрәк түгелме?

Минһаж *(житди).* Йөрәкнең жыерчыгы юк, олан. Тәүсига әбиегезгә яратып өйләнмәдем мин... Үзенә яки берәрсенә әйтә күрмә!

Баян. Көчләп өйләндерделәрмени?

Минһаж. Юк... Аны авылда калдырыр өчен шулай кирәк иде. Авыл культурасын күтәрәчәк, янәсе.

Баян. Хәзер... үкенәсенме?

Минһаж. Үкенүдән ни файда хәзер?

Баян. Үкенмә, бабкай! Баян Бадакшанов дигән шагыйрь дөньяда булмас иде, юкса. *(Көлә.)* Әллә—бүтән оныгына минем исемне биргән булыр идеңме? *(Кинәт исенә төшереп.)* Әй, мин немканы оныткынмын ич! Хәл эчендә ятмасын... Мин хәзер, бабкай—уйлана тор! *(Култык таягын онытып, сикерәатлый үзләренә ашыга.)*

Гөлшат *(ул хуҗабикәләрдән мөмкин кадәр читкәрәк шуышып яткан).* Я понимаю... Илшат өчен мин... не самая лучшая невеста, наверное... Кстати,

ул бу сөйләшүне беләме?

Б а я н *(алар янына керә).* Сез дә монда икәнсез... Хәлегез ничек, Гөлшат Касыймовна?

Г ө л ш а т *(аның килеп керүенә шатланып).* Ничего, Баян... Только... немного баш әйләнә.

Б а я н *(әниләренең кырыс йөзләренә игътибар итә).* Сезнең нәрсә монда? Җитди сөйләшүме әллә?

Л е н и з а. Дөрес әйтәсең, улым! Үзара хатын-кызлар гына аңлаша торган сүзебез барие... Бар бабаң янына чыгып торчы.

Г ө л ш а т. Юк-юк. Безгә мешать итми ул... Син дә тыңла, Баян. Пожалуйста?

**Хуҗабикәләр бер-берсенә карашалар.**

Л е н и з а. Бар, бар... Ничу монда! Сүзегез булса—бераздан керерсең...

**Гөлшат, авыр сулап, күзләрен йома.**

Т ә ү с и г а *(аның хәле авырлануын күреп).* Мин хәзер—төнәтмә кертәм... Ә син үз эшләреңне караштыра тор, килен! *(Ашыгып чыгып китә.)*

**Лениза җилкәләрен җыерып куя һәм аның артыннан икенче якка чыга.**

Б а я н. Берни аңламадым, Гөлшат Касыймовна... Нәрсә булды монда?

Г ө л ш а т *(кыенлык белән башын күтәреп карый: тегеләр булмагач, җиңел сулап).* Ничего... Сара килеп җиткәнче генә монда утырып тор, Баян... Мне почему-то страшно стало! *(Елмая.)* Может, я немного сгущаю краски...

Б а я н. Бадакшановларны һаман белмисез әле сез.

Г ө л ш а т *(елмайгандай итә).* И правда... Мин аларны аңлап бетермәдем, Баян... Кажется, их не устраивает, что я плохо знаю деревенскую жизнь... Татарча яхшы белмәвем дә... *(Ул отыры кыенрак сөйли башлый.)*

**Лениза, ишек катына килеп, тыңлап тора.**

Б а я н *(Гөлшат өчен ныклап борчыла төшеп).* Сезгә күп сөйләшергә ярамыйдыр, Гөлшат Касыймовна?

Г ө л ш а т *(көтмәгәндә чишелеп китә).* Мин сиңа әйткән идем, бугай: үз телемне совсем белми үстем мин... Родители өйрәтергә кирәк тапмаганнар, наверно... Сараланда дача сатып алгач кына... Анда татарлар яши... Казаннан ялга кайтып яшәп китүчеләр дә бар... Гәрәй Рәхим дигән шагыйрь турында ишеткәнең бармы? Знаешь, наверно—и ты поэт...

Б а я н. Кая әле мина, Гөлшат Касыймовна!

Г ө л ш а т. Шуның белән дуслашып киттек ничектер... Анда аның үз йорты бар... Тоже—дача... Вот... Шул Гәрәй Рәхим минем күзләремне ачты. Оказывается, татар теле—один из самых совершенных языков в мире!

Б а я н. Ишеткәнем бар. Безнең тел дөньяда иң камилләшкән 14 телнең берсе икән. Тагын: урыс, гарәп, инглиз, француз, итальян...

Г ө л ш а т. Дойч...

Б а я н. Әйе: немец, испан, португал, кытай, япун, һинд, урду, бенгал телләре керә, имеш.

Г ө л ш а т. Ты не сомневайся, Баян... Дөрес ул: ЮНЕСКО установить иткән. Это я потом специально узнавала. Ә Җир шарында, знаешь, ничә тел бар?

Б а я н. Биш мең ярым, диләр. Диалектларны да кертеп.

Г ө л ш а т. Молодец! Син—бик эрудированный егет... Ә без, татарлар, үз телебезнең кадерен белмибез...

Б а я н. Бигрәк тә—чала татарлар!

Г ө л ш а т. Чала татарлар? Кемнәр алар?

Б а я н. Катнаш гаилә балалары... Шәһәрдә яшәүчеләрнең балалары, күбесенең хәзер шундый!

Г ө л ш а т *(елмая).* Но ты-то, я думаю, не предашь свой родной? Нет, конечно... Вот и я подумала: если я хочу дать своим будущим детям это богатство... *(Тынып кала.)*

Б а я н. Авыл егетенә кияүгә чыгып, авылда яшәргә тиешсез, шулаймы? *(Елмая.)*

Г ө л ш а т. Әйе... Вот и вся моя вина перед вами, Бадакшановыми... *(Тагын хәле бетеп тынып тора.)* Син чыгып китмә, Баян... Сара килсен.

Б а я н *(тәвәккәлләп).* Ә сез Илшат абыйны яратасызмы?

Г ө л ш а т *(елмая).* Они тоже спрашивают... *(Ишеккә таба ияге белән ымлый.)* Этого я и сама не знаю... Абыең яхшы кеше, по-моему.

Б а я н. Говорят, этого не совсем достаточно, Гөлшат Касыймовна!

Г ө л ш а т. Ты прав...

**Тынып калалар. Гөлшат күзләрен йомган, авыр сулый. Баян нишләргә дә белми аптырап утыра. Алгы якка Тәүсига**

**карчык килеп керә: аның кулында үзе әзерләгән төнәтмә.**

Лениза *(бармагын иреннәренә куеп, аңа каршы бара).* Малайның башын әйләндермәкче теге... Үз балаларын татар итеп үстермәкче, янәмәсе! Илшат шуның өчен генә кирәк булган икән хәшәрәткә... Баян шунда утыра бит—нишлибез, әни?

Тәүсига *(юри кычкырып).* Чыгып торыр... Чирле хатын-кыз янында утыру егетләр эшемени?! Хатын-кызга ни кирәкмәс? Оялып ятсынмы?

Гөлшат *(имәнеп дөртләп китә).* Они вернулись?!

Баян. Юкка куркасыз алардан!.. Килен булып төшкәч, ничек бер түбә астында яшәрсез сез? *(Елмая.)*

Гөлшат. Син, пожалуйста, чыгып китмә!

**Хуҗабикәләр алар ягына керәләр.**

Лениза *(каршы төшмәслек итеп катгый).* Бар әле, чыгып тор, Баян улым. Әбиең дару ясап алып керде. Карарга кирәк: ике үпкәсе дә ялкынсынып шешмәсен тагын.

**Баян, Гөлшатка берни дә эшли алмыйм, дип ишарәләп, теләр-теләмәс чыгарга мәҗбүр була.**

**Таянычсыз калгач, Гөлшат, куырып калгандай, бөтен гәүдәсе белән бөрешә.**

Тәүсига *(кискен хәрәкәтләр белән аның маңгаен тотып карый, башын чайкап).* Хәлең шәптән түгел синең, кызый... Мәле—шушыны йотып җибәр. Лениза килен, башын күтәреш әле икенче яктан.

**Кунак кызына дару эчерәләр: бу мизгелдә алар аңа чын күңелдән аналарча ярдәм итәргә телиләр сыман тоелалар, ләкин мондый идиллик тәэсир озакка сузылмый, тиз бетә.**

Гөлшат *(калтырана-калтырана эчеп бетереп).* Рәхмәт. *(Башын кабат мендәргә салып, күзләрен йома.)*

Тәүсига. Ну вәт... *(Гөлшатны әйбәтләбрәк төрә.)* Тагын бер юрган китерче, килен.

Гөлшат. Нык борчыдым сезне, простите.

Лениза *(өстенә икенче юрган китереп яба).* Сиңа ничә яшь, Гөлшат?

Гөлшат. Двадцать второй год пошел... Егерме ике була.

Лениза *(кырыс).* Егерме бер яшь! Кай арада шулай әнчекләнергә өлгерден соң син, кызый?!

Гөлшат *(күзләре йомык килеш).* Ән... Ул сүзне белмим мин.

Лениза *(дилбегәне нык лап үз кулына ала).* Ничек понимать итәргәме?.. Исерек ир-атларга ияреп, үзен шикелле бозык кызлар белән бергә әйтеп әдәм ышанмаслык нәрсәләр эшләп йөргәнеңне күргәннәр синең! Менә ничек понимать ит!

Гөлшат *(күзләрен ачып, шакмакландыра).* О, майн гот... Откуда взяли такое?!

Лениза. Анламаганга салыша хәзер!.. Шайтаннан иман алырсың... Мондый да чамасыз итенгән кыз-кыркыннарны күргәнебез юк иде әле! Ышанычлы эсвидителләребез бар безнең!

Гөлшат *(тормакчы була, ләкин хәле җитми).* О чем вы?!. Пожалуйста, аңлатыгыз миңа?

Тәүсига *(йомшаграк тонда кушыла).* Сине, мир каршына бастырып, фаш итәргә теләмибез без, кызый... Ерткычлар түгел алай... Ләкин каттый шартыбыз шул: монда калмыйсың!

Лениза. И-Илшатны да оныт асың!

Тәүсига. Турайда укытырсыңмы, юкмы—ансы синең үз эшең. Тик мондый хәлләрдән соң—ничек эшләп кала алырсың икән анда?! Мин үзем кырык ел укытучы булган кеше... Синеке ише түгел, бер кечкенә гаебе турында даны читкә чәчелгән кешеләр дә бер көн дә эшли алмыйлар ие мәктәптә. Нәфсенә баш була белергә кирәк иде!

Лениза. Нинди укыту, ди?!. Син нәрсә, әни?.. Ә Баянны кая куясың?!

Гөлшат *(соңгы чиккә җитеп, әле берсенә, әле икенчесенә карый).* Что за чудовищное издевательство?!. Причем монда Баяныгыз?

Лениза. Шул хәлләрдән соң да Баянны укытып ятыр идеңме әлә?! Җирбит икәнсең!

Гөлшат. Почему вы меня оскорбляете?!. Что вам я сделала?! Если не хотите—сегодня же оставлю в покое вашего Илшата! О, майн гот... *(Торырга тырышып карый, ләкин аңа ирек бирмиләр.)*

Лениза. Ят, ят!.. Кем сине шушы ук секундта чыгып кит, ди. Башка берәүләр булса—ике дә уйлап тормаслар иде! Шартлатып артыңа гына тибәрләрие!

Гөлшат. Объясните, пожалуйста: в чем я виновата?!

Минһаж *(ашыгып килеп кергән Баянга)*. Нәрсә—гаепле кеше сыман әрле-бирле сугылып йөрисең, олан? Агачтан ясап биргән самакатын ватып кайтып кергәч, атанның күзләре нәкъ синеке төсле чагырланган иде! *(Көлә.)*

Баян. Иске журналларны эзлим, бабкай...

Минһаж. Тимер гаражыгызда түгелме? Шунда күзгә чалынганнары хәтеремдә.

Баян. Дөрес! *(Култык таягына күзе төшсә дә—алып тормыйча тышка ашыга һәм тыйтаклый-тыйтаклый гаражга кереп югала.)*

**Шулвакыт урамнан пычранып беткән киемле Илшат кайтып керә: кәефе төшкән, борыны салынган—машинасын судан чыгара алмаган, күрәсең. Яңа өйгә керә һәм эчке якта барган «аңлашу»ны ишетеп, ирексездән туктап кала.**

Гөлшат. Я не заслужила ваших оскорблений... Неужели я... Илшатны яраткан килеш шулай... О, майн гот!

Ләниза. Тфү, нәҗес! Пакыч нәрсә... Каян килеп, ярату хисе була алсын, ди, синеңише себеркеләрдә?!

Гөлшат *(өзгәләнеп)*. О, боже... Еще раз прошу вас: объясните мне, чего вы от меня хотите?! *(Сүзләренең соңгы өлешен иҗекләп әйтә.)*

Ләниза. Тәки бөтенесен ачыктан-ачык әйттерә бу нәмәрсә... Чатра тау астындагы комлыкта кайсыгыз башлап Баянны мәсхәрә итте? Синме? Себерке дусларыңмы?! Аякларын-кулларын сөяркәләрегездән бәйләтеп ташлап! Оятсыз икәнсең! Аты-юлы белән әйтергә тел әйләнми хәтта! Әдәм хәшәрәтләре!

**Илшат алар янына атылып кермәкче була, Гөлшатның сөйли башлавын ишетеп, тыелып тора.**

Гөлшат *(соңгы хәлен җыеп, торып баса)*. Что?!. Баян үзе әйтәме?!. Я впервые увидела вашего сына только вчера—когда вы все вместе нас с Илшатом встречали! Оставьте меня в покое! Дайте мне уйти!

Тәүсигә. Юк инде, кызый... Тынгылык пакуе көтмә бездән! Кабәхәтлекне эшли белгәнсең икән—җавабын да тота бел... Әшегезне судка тапшыру берни тормый... Шуны телисеңме син?!

Ләниза. Судка бирмәячәгебезне чамалап масая да ул!.. Эш аңа житсә—бер гаепсез Баянның бөтен мир алдында пазур йөтачагын белә ич ул... Баян кыз бала булса—ике дә уйлап тормас идек! Китә бирсен әйдә!

Илшат *(түзми, атылып килеп керә)*. Это правда, Гөлшат?!

Гөлшат *(аны күрүгә шатланып)*. О, Илшат!.. Прошу тебя: скорее увези меня отсюда!

Илшат. Ашыкма, житешербез... Нәрсә булды монда, әни?

Ләниза *(улы кайткач каушабрак калган)*. Сиңа әйтеп тормабыз, дигән идек моны, Илшат улым...

Тәүсигә. Сандугач тоттым дигәнең—гөберле бака булып чыкты. Ордым-бәрдем генә үзара хәл итеп куйгач—шулай була инде ул!

Ләниза. Баян энекәшеңне, аяк-кулларын бәйләтеп, чыркылдыгы чыкканчы кыйнап, әдәм мәсхәрәсе ясаган кызларның берсе шушы икән бит. Күреп торучы булган.

Илшат. Чынмы бу, Гөлшат?!

Гөлшат *(ул инде ни әйткәнен дә белештермәс хәлдә)*. О, майн гот... И ты—туда же! Я не хочу вас слушать! Отвези меня в Тураево! Что за люди вы?!

Илшат. Погоди орать... Сначала надо тут толком разобраться! Чынмы ул, дип сорыйм мин синнән? Бер генә сүз: да или—нет?

Гөлшат *(шакката)*. Ты?!. Ты—спрашиваешь, Илшат?!

Ләниза. Телеңне әрәм итмә шуңа, улым... Аның тану-танмавыннан хәзер ни файда?! Баянның үзеннән дә сөйләтә аласың...

Тәүсигә. Аны да дөньяга күренмәслек итеп оялтыпмы?!

Ләниза. Шаклар катмалы... Ә бу—кызармый да!

Илшат. Значит, это—правда?

Гөлшат *(үзен-үзе белештермәгәндәй, урынын җыярга керешә)*. Мне теперь все равно. Делайте что хотите!

**Ишегалдына кулына шешә белән төнәтмә тоткан Сара килеп керә һәм туп-туры Яңа йортка юнәлә: ул киемнәрен алмашкан, чистарынган. Шулвакыт гараждан Баян чыга: кулында ниндидер журнал.**

Баян. Сар-ра! Төнәтмә алып килденме? *(Кәефе бик күтәренке.)*

Сара. Рижски бәлзәмле мәтрүшкә чәе бу! Салкын тигәндә шушы әйбәтрәк, ди әни.

Баян. Сонга калгансың: әбкәйләр үзләренчә өшкерделәр инде! *(Көлә.)* Беләсеңме, мин нәрсә таптым?.. Немканың йөзе нишләптер таныш шикелле тоела, дип уйлап йөри идем— менә ул! *(Журнал тышлыгын күрсәтә: анда Гөлшатның зур фоторәсеме урнаштырылган.)*

Сара. Уй! Знаменитый кеше икән безнең немка... «Йөзү буенча спорт мастеры Гөлшат Дикаянова.» Монда— яшьрәк чагы... *(Яңа өйгә сөйләшә-сөйләшә керәләр һәм эчке якта барган киеренке бәхәсне ишетеп туктыйлар.)*

Гөлшат *(хәзер ул үз-үзен кулга алган)*. Хорошо. Скажите: с Баяном когда случилось... это страшное насилие?

Сара. Синең өчен бәхәсләшәләр, Баянчик!

Баян *(аның авызын каплый)*. Тс!

Илшат. Кайчан булды әле ул, әни?

Лениза. Август башында... Әйе— өчесе иде.

Гөлшат *(шулай ук тыныч)*. Третьего августа?.. Ты помнишь, Илшат, где мы были с тобой третьего августа? Өченче августта без синең белән икәү Сараланда идек! С первого по пятое!

**Алар ягында авыр тынлык урнаша.**

Илшат *(көлеп җибәрә)*. Выходит, Гулечка, у тебя на счет моего братишки есть крепкое алиби?!

Гөлшат *(аның бәхәсне уенга боруын кабул итми)*. Понял теперь, что я, как они говорят, с двумя подружками-шлюхами... никак не могла зверски изнасиловать твоего брата?!. *(Бөтенләй коелып тышкән хатыннарга ымлый.)* Они-то ладно... Прости их, Аллах: они сами не понимали—какое унизительное зло творили надо мной!.. Но—ты?! Ты же хорошо знаешь меня... Как ты мог?! С их одного слова поверив в такое гнусное обвинение?!

**Тагын авыр тынлык урнаша.**

Сара *(күзләрен шардай итеп пышылдый)*. Ничек?!. Сине... кызлар көчләдемени, Баян?!.

**Баян аның авызын ябарга тели.**

Кагылма мина! Әйтәм аны... Чулак Афзал Рәшите бик эре кылана хәзер! Хурлыгы ни тора!

**Баян, аның яңагына чабып җибәргә теләгәндәй, исән кулы белән кирәмәйләп кизәнә, ләкин сукмый— кыенлык белән генә тыелып кала.**

**Гөлшат чайкала-чайкала ишеккә таба атлый.**

Илшат *(аңа ташлана)*. Постой, Гулечка...

Гөлшат *(җилкәсе аша карап, катгый рәвештә)*. Руки убери.

**Аны туктатырга кыймыйлар.**

*(Ишек янында торган яшьләрне күрә.)* Вы... все слышали?

Баян *(алга чыга)*. Подлость бит бу!.. Туп-туры үземнән сорарга кирәк иде, ичмасам!.. Ниләр уйлап чыгардыгыз?!. Беркемнең дә... көчләгәне юк мине!.. Анадан тума шәрә килеш бәйләп киткәнгә генә берни сөйләмәгән идем ич мин! Ояты ни тора, дип!

Гөлшат. Вон как?.. Я рада за тебя, Баян.

Лениза *(телгә килә)*. Нишләп соң, алай булгач—Гөлшатның йөзе таныш кебек тоела, диден?

Баян *(журналдагы портретны күрсәтә)*. Менә каян! Хәтердә калган булганга... Баярак кына искә төште! *(Журналны Гөлшатка бирә.)*

Гөлшат *(кызыксынып карый)*. А... Биш ел элек төшкән фото... Поздно, молодой Бадакшанов... Слишком поздно!.. А, может... это и к лучшему! Гамлет абыеңның машинасы бармы, Сара Низамова?

Баян. Кирәкми, Гөлшат Касыймовна... Тигезәкләр ярдәменнән башка да табарбыз! Мин үзем Турайга илтеп куям сезне: күрше Миңлехарис абзыйларның машинасы тик тора. *(Тыйтаклый-тыйтаклый чыгып китә; Сара, ирексездән, аңа юл биреп кала.)*

## Эпилог

**3 сентябрь иртәсе. Хәер, көннең кайсы вакыты икәне чамаланмый: бар җиһан сыек томаннан гына тора сыман—күк тә, һава да аерылмый. Бадакшановларның зур ишегалды да күңелсез соргылт төстә. Томса көн бөреләнеп кенә килүен кайдадыр якында гына авыл кешеләренең «Һәс-һәс»ләп мал-туар кууыннан һәм көтүче чыбыркысы шартлауларыннан көтү китеп барган чак икәнен чамаларга мөмкин.**

**Яңа йорт болдырына кешелек киемнән Баян чыга: ул уң янбашына хәзерге яшүсмерләр яраткан спортчылар сумкасы аскан һәм төзәлеп килгән кулын шуның өстенә җайлап куйган, култык таягы да юк. Сул аягына аксавы шактый сизелә, әмма бик авыр түгел. Баян иртәнге дымсу һаваны бар күкрәге белән рәхәтләнеп сулап басып тора һәм Каравыл тавында нидер күреп, иске йорт янына ташлана. Эленеп торган бинокльне алып, Каравыл тавына карый.**

Баян *(түземсезләнеп бабаларының ишегән шакый).* Өлкән Бадакшанов! Бабкай! Тиз генә чык әле монда!

Минһаж *(күптән торган, ахры—бик тиз чыга).* Ни булды? Нигә урам күтәреп разбуй саласың?!

Баян *(Будикның биноклен суза).* Каравыл тавына карале...

**Оныгы төгәл әйтмәсә дә, Минһаж бинокль аша юлбашчы сурәтенә текәлә.**

Күрдеңме?.. Ленинның ярты башы төнлә кубып төшкән?.. Ә бәлки—җимереп төшергәннәрдер!

Минһаж *(ниһаять, бинокльдән аерыла).* Ә нишләп—җимергәннәрдер, дип исәплисең? Кичәге яңгырдан урыны җебеп, ташлары кубып төшкәндер.

Баян *(бабасының үзен тыныч тотуы аны тирән гаҗәпләндергән).* «Өлкән Бадакшанов үзен Олимпия Аллалары сыман үтә тыныч тотты.» Табигать тә символлар белән эш итә башлаган икән, алайса! Зур ачыш бу, өлкән Бадакшанов! Тагын бер кат карале? Очраклы гына күзе, колагы, авызы тирәсе сайлап жебемәс иде! *(Көлә.)*

Минһаж *(бинокльне тагын күтәреп карый һәм кире урынына элеп куя).* Күрәм: укырга барырга чыккансың... Тархан яту маемлаткан, ахры. Иртәрәк түгелме, олан?

Баян *(елмая).* Чын әгәр—бу тәртибең ошый мина, өлкән Бадакшанов!..

Минһаж. Үзең әйтмешли, замнем для ясности.

Баян. Замнем тек замнем... Конкретно дәресләр башлануын күз алдында тотып сораган булсан—дөрес, иртәрәк әле. Аяк проблемасы кызыксындырса—Ышна юлы тап-такыр, кирәк тапса—туктатыр! Ышна дигәннән, Турайның шул урамы аша ничә ел тәпилим инде—ул сүзнең нәрсә аңлатканын уйлау башыма да кермәгән... Урманы төпләнгән җир дигән мәгънәсе бар икән аның! *(Көлеп куя.)* Әйдәле, өлкән Бадакшанов, утыраек урынча, сөләшәек урысча.

**Болдыр идәненә утыралар.**

Минһаж. Хак сүз әйттең, олан... Без яшьрәк чакларда усак урманы шаулый иде ул тугайлыкта... Ышна—урманны яндырып, җир арчу ул. Турайларның җирләре бәләкәйрәк иде шул элегрәк. Ә синең карт бабаңнар, вакытлыча башкорт сословиесенә язылып, мулданрак әләктереп калганнар басуны.

Баян. Башлары йомрырак булган, димәк?

Минһаж. Йомрысын йомры булгандыр да... Теге карьера өчен үз ата-анасының денен саткан Шакиров заманнарында безне башкортлаштырып маташырга сәбәп калдырганнар шул.

Баян. Парторг: кабат язылыйк әйдә—безгә барыбер түгелмени, дип бик каты кыстый башлагач, син: берәр урыс яки чуваш авылы башкорт булып язылырга ризалык биргәнме—пример китер әле, дип авызын томалагансың, диләр. Шул дөресме?

Минһаж. Төрлесе булгандыр инде, олан... Адаш бабаң, нишләптер, күренми әле бүген?

Баян. Эштиплавай картмы? Төн буе авыр таш актарып алҗыгандыр! *(Көлә.)*

Минһаж. Чү, әкренрәк—әбиеңнең тәмле йокысын бүләрсең, олан.

Баян. Йоклыйдыр, дисеңме син аны? *(Шулай да тавышын баса төшә.)*

Әнкәй дә бүген таң тишегеннән шыпан-шыпан эшенә чыгып сыпырды! Чөнки авызлары пешәрлек булды кичә... Әбкәй дә шуңа бөтәү яталыр.

Минһаж. Дүрт аяклы ат та бер абына, олан... Әбиең әнә, төнлә, үз анасыннан калган намазлыгын сандыгы төбеннән актарып алып куйган... Үзләренчә яхшылык эшлибез, дип тырышулары булган инде ул. Атаң белән абыең иртүк ая чыгып сыздылар?

Баян *(көлемсерәп)*. Әти һаман берьюлы ике куян койрыгын тотарга өметләнеп чаба, бугай, пенте что... Әйе! Илшат абый—төн озыны динкеп, кырыкка боргаланып ятты-ятты да, чиркәү чәүкәсе сыман үз парын эзләргә тәпи-тәпи теркелдәде бугай... Автокран артыннан йөгермәгән булса!

Минһаж. Напрасны... Авызыңны напрасны ерасың! Берничә мәгънәдә әйтәм мин.

Баян *(эченнән нидер санап, бармакларын бөкли)*. Бер... ике... өч... дүрт... биш... Син напрасны дип әйтерлек алты мәгънә таптым, өлкән Бадакшанов! Әти—напрасно гел мал артыннан куа. Мин—напрасно аның «понимаете что... Әйе»сеннән көләм. Илшат абый напрасно кәләшенә ялынырга йөгергән... Кыскасы, тагын бер нәрсәнең «напрасно» эшләнү мөмкинлеген беләм әле мин үзем, бабкай.

Минһаж. Илшат абыеңны кәләшенең гафу итүеме? Терәүсез калса, нишләр икән соң ул?

Баян *(көлеп җибәрә)*. Бер дә кызык түгел синең белән, ил өстендә иләмән карт Бадакшанов! *(Житдиләнеп.)* Немкага таккан нахак гаепне алдан белә идеңме син, бабкай?

Минһаж. Ничек белмәскә... Тик әбиеңнәрнең шайтан туе әзерләгәннәрен абайламый йөргәнмен!

Баян *(шакката)*. Миңа нишләп сиздермәдең соң син?!

Минһаж. Нахакмы, түгелме икәнлеге ачык билгеле булмаганга. Картлыкның хата эшләргә хакы юк: төзәтергә өлгәшмәве мөмкин.

**Капка келәсен гадәттән тыш каты чыңгылдатып, Разалия килеп керә: хуҗалар, нииндиләр житди хәбәр белән килгәнен сизенеп, торып басалар.**

Разалия. Безнең картны таш баскан, адаш бабай!

Минһаж. Кайда?!

Разалия. Каравыл тавындагы сурәтне сүтеп маташкан булган. Кичәгенәк, сездәге хәлләрне ишеткәч, үзенүзе кая куярга белмәгәндәй, бәргәләнеп йөрде-йөрде дә... Төнгә каршы, лум алып, каядыр чыгып киткән иде.

Баян. Әйттем бит, бабкай!

Минһаж. Сабыр, олан: бүлдермә хатын-кыз сүзен. Үзе нихәлдә?

Разалия. Район больницасына алып киттеләр. Исән калырмы, юкмы—билгесез. Бик нык имгәнгән ул... Аяклары да, куллары да эшләми!

Минһаж. Анында идеме соң?

Разалия. Мин барып житкәндә ушында иде... Үзе сиңа кереп әйтергә кушты ул. *(Әйтергәме, юкмы, дип икеләнеп, Баянга карап куя.)* Илшатның кәләше турындагы... әшәке хәбәрне үзе, диваналанып, уйлап чыгарган икән ул, адаш бабай.

Баян. Ни өчен?!

Разалия. Уйлап, дип... Бөтенләй үк алай да түгел. Сине бер маржа кызы чытлыклануы аркасында кыйнаганнарын чынлап та күреп торган ул... Анык шулайрак бит инде... Ике-өч нәрсә күрә дә—бөтенесен бергә кушып бетерә... *(Бер иске гәзиттән кисеп алынган мәкалә суза.)* Менә—кайчандыр бер гәжиттән шундыйрак әшәкелек турында укыган ул. Синең кебегрәк бер яшь малайны кызлар мыскыл иткән булганнар... Бик күптән инде. Тотып, суд ясаганнар инде үзләренә.

Баян *(кыз биргән гәзит кисәген алып)*. Ә минем ни гаебем бар?! Нишләп ул булмаганны миңа япсарып маташкан?

Разалия *(ничек җавап бирергә белми тора)*. Сиңа начарлык эшләргә теләүдән түгел, ул, Баян үскәнем...

Минһаж. Илшат белән икегезне өйләндерергә тели ул, кызым.

Разалия *(башын ия)*. Әйе... Тик моңа минем бер катнашым да юк! Илшат өчен... дөньяда юклыгымны беләм мин.

Минһаж. Кайчак үзе кылган эшләренә исәп-хисап тота алмаслык булгалый шул. Нишләтәсең аны.

Разалия *(көтмәгәндә катгый рәвештә)*. Юк! Берегез дә белеп бетермисез сез аны, адаш бабай! Гомергә үз акылында булды ул. Соңгы вакытларда сезнең тәрәзәне вата башлагач кына... бераз шиккә төшкән идем! Ансы да—кылануы гына... Үзе

сөйләп бирде миңа. Сталин заманнарында исән калыр өчен юри башын юләргә салган булган. Бер ияләшкәч, дивана булып кылану берни түгел иде аңа! Зату—үз бүлемә яшим, дип рәхәтләнеп күкрәгән киереп йөргән булды. Исәпләп-уйлап карыйм да—исләрем китә хәзер! Илерепләр жыларлыгы бар...

Минһаж. Монсын да—бабаң үзе әйтергә куштымы, кызым?

Разалия. Әйе... Карт Бадакшановны тагын бер күрәсем барие—язмаган, күрәсең, диде. Бәхил кылсын мине, дип бик ямансылап китте. Мин шушыларны житкерергә генә кердем, адаш бабай. Зинаһар, син дә аңа үпкә саклама, Баян акыллым... *(Бабасы калдырган биноклъгә ишарәли.)* Ә биноклен сиңа калдырып киткән ул...

**Капка келәсе чыңгылдый һәм анда мәктәпкә барырга чыккан Сара күренә.**

Баян *(күз кырые белән генә карап).* Кем хәерсезе йөри анда.

**Сара шундук юк була.**

*(Разалиягә.)* Рәхмәт, Разалия апа... Бабан үзе терелеп кайткач сөйләшербез.

Разалия. Атлый торыйм әле мин... Бабкайга бирәр нәрсә илтмәкче идем. Иртәнге автобус кире борылып килеп житкәнче өлгерергә кирәк.

Минһаж. Ярый, кызым... Адашын бәхил кылам, дип әйтте диген бабаңа. Тизрәк терелсен!

Разалия. Булмаска охшаган инде... *(Башын иеп чыгып китә.)*

Баян *(бераз тынып торганнан соң).* Инде нәрсә әйтерсең, карт Бадакшанов?

Минһаж. Дөрес иттең—хуплыйм.

Баян *(усал итеп).* Шайтанга авырлык, миңа—жиңеллек!

Минһаж. Шартлап сынарлык каты бөкләмә түлке.

Баян. Без өстенә бастырам әле мин ул тигезәк чәчбине... Сара турында сорамыйм мин, бабкай.

Минһаж. Минем өчен яңалык китермәде бу бахыр бала... Атаң ясаган сурәт турында да. Сәгатеңә күз сал әле: дәресеңә соңгы калмыйсыңмы син, олан?

Баян *(кәефе күтәрелеп).* Минем сәгать тойгысы һәрвакыт уяу, патер фамилиас Бадакшанов! *(Шулай да сәгатенә карый.)* Вакытым күп әле.

Минһаж *(сөеп-яратып, оныгын жилкәсеннән этәреп).* Барыбер карт бабаң белән ярыша алмыйсын, оланым: үзең әйтмешли, минем алда—«мәңгелек» вакланмаган көе тора... Бар—һич югында, «Япьле шомырт» кебек ялгыз агач бул!

**Ул оныгының ничек атлавын артыннан карап кала: ансы, моны сизеп, аксавын киметергә тырыша. Бөкрәя төшкән озын гәүдәле йөзьяшәр карт тураебрак баса.**

*2000 ел, гыйнвар*

## ТУГАН ҖИР ГАМЕН ТОЕП...

*Бу исемне куюым һич тә юкка түгел. Әйе, яшьтәшем, каләмдәшем, Балтач егете, шагыйрь Гарифҗан Мөхәммәтшин турында сөйләгәндә бу—бик табигый, җанга ятышлы. Чыннан да үз ягын, туган җирен, аның ямен һәм гамен күрә, тыңлый һәм җырлый белүче ул! Илдус Гыйләҗев, Әнәс Исхаков, Вәзыйх Фатыйховлар турында да шулай әйтеп булыр иде. Чөнки язганнары нәкъ менә үз төбәкләреннән, җир-туфрак биргән моңнан, гамьнәндер... Туган җирдән аерылмыйча, шунда яшәп, тир түгеп, төрле вазифалар башкар, ян да—шигырь язып та кара әле! Әллә шулай булганга, Бернсларны кумир иткән күңелемә аеруча якын тоела, ышандыра микән аларның язганы?*

*Сүзем әнә шундый шагыйрьләребезнең берсе, инде 60 еллык бәйрәмнәрен билгеләүче «кырык беренчеләр»нең октябрьдә туганы (Ризван Хәмид тә «октябрь баласы»!), тыйнак һәм мөлаем замандашым хакында. Гарифҗан Садыйк улы Мөхәммәтшин безнең әдәби даирәгә соңлабрак килеп керде кебек... Гәрчә яшьтән үк язса да, пединститутта укыганда ук шигырьләре басылгаласа да...*

*Мамадыш һәм туган районында укытучы булганда да язуын ташламаган ул. Балтачта райбашкарма комитеты рәисе урынбасары сыйфатында эшләгәндә язучы Габдрахман Минский аның шигырьләре белән кызыксына һәм яңа шагыйрь «ачу» шатлыгын Хәсән Туфан белән бүлешә. Олуг шагыйрь Гарифҗан шигырьләренә кереш сүз язып, безнең журналга җибәрде—һәм алар басылып чыкты... Шуннан башланды: 1980 ел иде булса кирәк, Язучылар берлегеннән махсус семинар белән иҗатын тикшерергә дип, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев һәм мин (ул чакта шагыйрьләр секциясе җитәкчесе) Балтачка киттек. Андагы Райбашкарма (һәм райком!) йортын үз иттек; Гарифҗанны да... Ул—әдәбият-сәнгать өчен янып яшәүче,тирән белемле, соңрак истәлекләрендә Мөхәммәт абый Мәһдиев язганча, «бик мөлаем егет икән»... Сибгат ага Хәким, Равил Фәйзуллиннар турында кат-кат сорашты (аларны яратуы, өйрәнүе турында соңрак радио һәм матбугат аша еш сөйләде ул!), «Чаян»да эшләүче Зөлфәт, Фаил Шәфигуллиннарга сокלануын белдерде... Ул чакта аның юмор-сатира шигырьләре күп иде. Балалар өчен дә яза булып чыкты. Кыскасы, бу «күчмә» утырышта аның «Килегез, дусларым» исемле беренче китабына нигез салынды. Балтачта «Янар чәчәк» әдәби берләшмәсе дә эшли башлады. Ә «түрә-шагыйрь» нең (сүз җаеннан: Гарифҗан без белгәннән бирле шул урында. Хәер, хәзер—җирле идарә рәисе урынбасары дип атала аның вазифасы. Социаль-мәдәни мәсьәләләр буенча. Шуңа да Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре ул. РСФСРның халык мәгарифе отличнигы...) китабы басылып чыккач, секциядә аны Язучылар берлегенә тәкъдим иттек. Утырыш мәҗлес төсен алып, бик күңелле узды—азак Камил Кәримов аннан «кызык ясап», язучылар стена гәзите «Тынгысыз каләм»дә мәкалә «бастыргач», үпкәләшеп тә алдык... Әмма бик ихлас сөйләшү иде ул. Дуслыкны дәвам итү өчен шул ук елда Роберт Миңнуллин (ул да баштан ук Гарифҗанның якын кешесенә әйләнде), Зөлфәт, Фаил, Ризван һәм мин очрашулар өчен янә Балтачка киттек... Аннан Балтачта И. Юзеев, Ш. Галиев һ. б. шагыйрьләрнең иҗат кичәләре узды. Гарифҗан үзе дә Казанга юбилейларга еш килде: Илдар абыйга да, миңа да, Равилгә дә, Робертка да... Кыскасы, әдәби бер пост, мәдәни бағланышлар! Житмәсә, «Казан утлары»н күбрәк таратуын да үтенәбез, «наказ бирәбез»... Башка йомышлар да чыга...*

*Әле бит композиторлар (Сара апа Садыйкова бик якын итте бу тарафны!), җырчылар да үзелми. «Керим әле урманнарга» дип нәкъ шул төньяк район урманнарын күздә тотып җырладык... Ә җырлары күп Гарифҗанның: «Яшьлегем кайтавазы», «Унсигез яшем язы», «Ак җыр», «Кичке уен», «Аулак өй»... Ә көйләрен, Сара ападан башка, Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәт, Луиза Батыр-Болгари, Мәсгудә Шәмсетдинова һ. б. язды. Ә Хәйдәр, Зилә, Салават, Зөфәр, Зәйнәп кебек җырчыларның башкаруы? Гамьле, моңлы туган җир җырлары, халыкчан көйләр алар!*

*Инде алты китап авторы («Гомерлек язым», «Керим әле урманнарга», «Бер уйласаң» һәм балалар өчен «Уеннан уймак», «Серләвек» китаплары—берничәсенә рецензияне үзем яздым...) Гарифҗан татар һәм башка халыклар иҗаты үрнәкләрен җыя, тәрҗемә дә итә. Төрек халык җырларын зур бәйләм итеп «Казан утлары»нда бастыруын әйтми кала алмыйм... Аннан гарәп әдәбияты, Коръән һәм аның тәрҗемәләре, тәфсирләре белән күптәннән кызыксынуын, күп китаплар җыюын да... Ә 1998 елда дустым Гарәбстанга барып, Хаҗ сәфәре үтеп, чын мәгънәсендә хаҗи да булды. Хаҗи-шагыйрь булу—бик матур фал безнең көннәрдә! Җөмләдән: аның өч баласы бар; кече улы да Гарәбстанда укып кайтып, тел өйрәнде, хәзер—гыйлем юлындагы пишкадәм...*

*Балтач—Мирхәйдәр Фәйзи (Шодада), Муса Җәлил (Карадуганда) музейлары булган төбәк. Тукаебызның газиз әнкәсе Мәмдүдә күмелгән Сасна Пучинкәсе авылы да Шигырь бәйрәме көннәрендә әдипләр килә торган изге бер урынга әйләнде. Шагыйрьләребез һәр язда барып, Гарифҗанны да күреп, сөйләшеп кайта. Күп аның дуслары, бик күп!*



*1994 елда Балтачта узган әдәбият атналыгы истәлеге. Гарифҗан Мөхәммәтшин Шодадагы М. Фәйзи музей-утары каршында, бертөркем әдипләр арасында (сулдан тугызынчы).*

**Рәдиф ГАТАШ**



# Гарифҗан Мөхәммәтшин

## ТУРГАЙЛАРГА ИШ БУЛЫП...

### Бәхет

Тынгысызланганда йөрәк,
Битәрләнгәндә җаным,
Туган кырларыма чыгып
Тыңлыйм туган җир гамен.

Басар өчен борчуларым,
Җанымның мең ярасын,
Йөрәгем аша үткәрәм
Табигать манзарасын.

Савыктыра андагы моң,
Якты гамьле тантана,
Юкка чыга сызланулар,
Күңелем канатлана.

Канатлана да талпына
Тургайларга иш булып,
Күңелемә тула шатлык
Дулкын-дулкын ишелеп.

Әле дә син бар, туган ягым,
Моңлы аһәңең белән.
Мин бәхетле синдә туып,
Синдә яшәвем белән!

Өзгәләнәм,
Үзгәләнәм
Әнкәй танымас булып:
Күңелем—әле таң кояшы,
Әле—караңгы болыт.

Битәрләнәм,
Бөтәрләнәм—
Хисләрем сыймый җанга,

Хыялның ак җилкәннәрен
Киерер давыл кайда?

Канатланам,
Кабатланам
Ел да килгән язлар күк.
Җан җылытыр назлар җитми,
Тән җылытыр назлар—күп...

Моңсуланам,
Мең соңарам
Бәхеткәем янына:
Мин бер дулкын, хәлсезләнгән—
Җитә алмый ярына.

Кайнарланам,
Каударланам,
Мең үлеп, мең тереләм.
Кайда соң син,
Кайда соң син?
Бир кулыңны,
Үреләм...

Син һаман ишарәлисең
Минем сүрәнлегемә...

Коенган саен сөенәм
Идел тирәнлегенә,
Күз салган саен сокланам
Күкнең зәңгәрлегенә,
Сабый бала күк иярәм
Таңның бәллүр җиленә.
Яккан саен бер табынам
Учак кайнарлыгына,
Һәм инанам уттан кайнар
Мәхәббәт барлыгына.
Атлаган саен көнләшәм
Үлән яшеллегеннән,—
Тик эчемдә барысы да,
Бары да яшерен генә.

Йөз хисемдә—йөз ялкында
Көям, янам, көйрим мин.
Мәхәббәттән гакылын җуйган
Мәҗнүн кебек йөрим мин.

Тик эчемдә барысы да,
Бары да яшерен генә,
Тышкы кыяфәтем минем
Бары рәсемем генә.
Чыгармыйм тышка, шикләнәм
Чәчелер, җыялмам, дип.
Һәм көләр кемнәрдер күреп,
Бу бит сабый һаман, дип.
Йөз хисемдә йөз кат янам
Елның һәр тәүлегендә...
Ә син гел ишарәлисең
Минем сүрәнлегемә.

## Ишим карлыгачы

Ишим суы ташып тынгач,
Бозларыннан арынгач,
Ишим ярларына килеп
Оя корыр карлыгач.

Оя корыр, кунып сайрар
Яр буе талларына,
Карлыгач җыры ямь өстәр
Ишим-су таңнарына.

Сайрый-сайрый ярын табар
Бергәләшеп сайраргa,
Бергә бала үстерерләр
Сайрашып шул ярларда.

Үсеп җиткәч балаларын
Өйрәтерләр очарга.
Очып китеп, өч баласы
Оя корыр өч ярда.

Тик яз саен шушы ярга
Очып кайтыр карлыгач,
Ишим суы ташып тынгач,
Бозларыннан арынгач...

## Чаба тайлар

Чаба тайлар канатлы күк,
Җилне узып, ярсудан...
Җилләр бөтерелә, шыңшып,
Артта калган ачудан.

Чаба тайлар, барабандай
Бәреп дала күкрәгeн.
Тояк тавышы хәтерләтә
Язның тәүге күкрәвен.

Тайлар чаба дала иңләп,
Җилләр белән көрәшеп.
Карыйм да, көрсенеп куям
Шул тайлардан көнләшеп:

Их тайларым, сез дә беркөн
Туктап калырсыз әле,
Яшьлектә узган җилләрне
Көтеп алырсыз әле!

## Чакыру

*Роберт Миңнуллинга*

Искә алдым сине бүген
Алсу таңнар аткач та:
Сагындырдың әллә ничек—
Кил әле бер Балтачка.
Килмә бары тик бер кичкә,
Берүк озакка кала күр—
Мин генә түгел, сагынган
Сине—таныш Каракүл.
Сабан туе ерак әле,
Сабан туен көтмә син,
Кил дә безгә кунак булып,
Бүтән бер дә китмә син.
Куа-куа бу дөньяның
Вак-төяген, чүп-чарын,
Сүнеп бара күңелемдә
Кайнар шигырь утларым.
Кабызырсың ул утларны,
Авыр икән шигырьсез,
Әллә ничек күңелләр буш,
Шигырьсез мин шөгыльсез.
Иелә-бөгелә тыңлар сине
Ялтыра каеннары,
Алар дәррәү кушылырлар,
Син җырла гына бары.
Шигырьләреңне укырсың
Сагына-сагына Илешне,
Сөңгә охшатып карарсың
Безнең Шушма-инешне.
Син бу якны яраттың бит,
Балтачта тумасаң да.
Балтач яклары да матур,
Илеш үк булмаса да.
Искә алдым сине бүген
Алсу таңнар аткач та:
Шигырьгә сусады күңелем,
Кил әле бер Балтачка!

Тауга карап тау булалмам,
Инешкә карап—инеш...
Нигә соң гел уйга калам
Инешкә баккан килеш?

Талга карап тал булалмам,
Таллар бик сыгылмалы.
Йөрәгем дәшә өзелеп:
—Түз әле, сыгылма әле!

Гөлгә карап гөл булалмам,
Гөлләр әле чәчәктә.
Тик гөлләрдән күз алалмам,
Җирдә мең ел яшәп тә...

Илсезләр күп,
Җирсезләр күп,
Аларга, һай, кыендыр,
Шундыйларны, туган җирем,
Куеныңа сыендыр.

Ятимнәр күп,
Үксезләр күп,
Заманалар, һай, кырыс,
Шундыйларга, туган җирем,
Җылы бирергә тырыш.

Моңлылар күп,
Гаҗизләр күп,
Күңелләре гел китек,
Бүлеш аларның моңнарын,
Туган җирем, үз итеп.

Җансызлар да,
Моңсызлар да
Аз түгел, беләм ансын.
Моңлыларны күргәч, тетрәп
Алар да туктап калсын,
Мин дә Кеше ич, дигән уй
Йөрәген телеп алсын...
Йөрәген телеп алсын...

Бу язлар да узып бара инде,
Теләгем шул минем бу яздан—
Чәчәк атсын илем кырларында
Үзем сызган хет бер буразнам.

Шәфәкъләрнең алсулыгы артты,
Дуслар юлда, учак кабызган.
Юлга чыккан якын дусларымнан
Аерма, дип сорыйм бу яздан.

Җыр яңгырый күңел дәртләндереп,
Заман үзе җыр ул—без язган.
Җыр булып кал безнең күңелләрдә,
Үтенечем шушы бу яздан.

Бу язлар да узып бара инде,
Җәйләр килер җиргә бераздан.
Гомеремнең соңгы язы булма,
Үтенечем шушы бу яздан!



# Нәҗибә Сафина

## УТ БЕЛӘН СУ ЕЛГАСЫ...

### Нигә?

**Бу дөньядан китәм дип тә,
Калам дип тә уйладым.
Китәргә риза, туймадым
Сөеп кенә
Дөньяны.**

**Синең яннан китәм дип тә
Калам дип тә уйладым.
Үзем белән алып китәм,
Дип уйладым,
булмады.**

**...Бакыйлыкка китеп барам,
Фани дөньяны алдап.
Юкса инде хәлләремне—
Синең җирдә калганыңны
Торалар бар да
аңлап...**

**Мәхәббәткә бергә кердек,—
Тормышның газабына...
Гүргә нигә бергә түгел,—
Җиткәч тә азагына?
Нигә?**

**...Синсез бу дөньяда яшәү
Барыбер каза гына...**

**Җилләр куса, тиз коела,
ваклана ябалак кар.
Дөнья куса, тиз кыела,
ваклана фани җаннар.**

Нәҗибә САФИНА—*шагыйрә, публицист; берничә китап авторы. Казанда яши.*

Күк кыела, дип әйтмибез,
карлар ява, дибез шул.
Үләннәрне кәфен түгел,
ак кар яба дибез шул.

Кәфен эченнән дә терелеп
шыта үлән яз җиткәч.
Терелегенә инанып,
кәфен өстеннән киткәч...

Никадәр көч үләндә!..—
Кәфенемне эретер дә
әверелермен үләнгә,
«Үлде», диеп, күмгәндә...

## Ярата...

Ах, сөям,—дисең.—Чынмы бу?
Шаярту булса, нигә?
Бүген дә менә, ышанып,
Мин очып кайттым өйгә.

Ах, дисең, бу карашларың,—
Шаяртма, йөрәк бит ул.
Шаяртып кына яраткан—
Коточкыч өрәк бит ул.

Чү! Әле сиңа ни булды?—
Ышанмыйсың?—ярата:
Койма аша күрше кызы
Минем кебек кар ата...

Ярата...

## Мәңгелек шундый...

Галәмнең җаныдыр бу Җир.
Кешенең җаныдыр җыр.
Җирне җырсыз, мәхәббәтсез
Йә, күз алдыңа китер.

Җир, Җыр, Сөю булса гына,
Канатлы була кеше.
Дүртенче тарафта Үлем,—
Бу аның соңгы эше.

Сөю җыры кала Җирдә,
Соңгы чараны җиңеп.
Җыр ага Җир шарын урап,
Калса да кабер иңеп.

Галәмнең җаны—җырлы Җир,
Гөлле Җир, мәхәббәтле!
Фанилыкка буйсынмый тик
Бары шул мәхәббәте!

Адәмнең дә, галәмнең дә
Мәхәббәт икән җаны!
Җан—мәңгелек, диеп, әйе,
Әйткәннәр инде аны!

Үлем юк, юк—сөйгәннәргә,
Утларда көйгәннәргә.
Мәхәббәт—мәңгелек ут,—
Башкача Мәңгелек юк!

## Очрашу...

Кайда очрашкандыр, белмим,
Ут белән Су—Җил купты;
Тирәк толымнарын гүя
Давыллар урап тотты!

Әй тартыла, бәргәләнә
Агачларның башлары.
Хәтта кителеп-кителеп төшә
Каф тавының ташлары...

Ава тирәк, әмма сирәк
Тамыр тотмаганнары.
Өзелгәннәрнең юк бит ул
Утлар йотмаганнары...

Җир астында очрашканнар
Ут белән Су елгасы,—
Сүнгән Утны җәлләп, Суга
Еласы да еласы...

## Сәер бүләк

Назлар көтеп яшьләр койдым,—
Җыелды алар ярга.
Наз—бик сәер бүләк икән,
Бирелми алар зарга.

Наз китерер өннәр башка,
Үксүләр түгел икән:
Наз тулы ярларны тап та,
Шуларга түгел икән...

Язмышыңны саласың бит,—
Язмыш ярың тиләнме?
Гомерлеккә бергә диеп,
Мәхәббәтең кергәнме?

Керә күрмә буш ярга,
Гомерең батар зарга.

## Тәрәзәгә карап

Ачы күз яше ташкыны
җанны кисте.
Йомшак саба җиле таңда
барыбер исте.
Күзем ачып тәрәзәмә
баккан идем,
Мәхәббәткә зур таш һәйкәл
тапкан идем...

Таш булмады,
тоздан икән.
Шулкадәр яшь
түктергәннең
Җаны бары
боздан икән.

Ә ул, әйе, минем иркәм...

❦

Сөю—ләззәт, сөю—газап?
Ә шигърият?
Ләззәттән дә, газаптан да
Авыррак.

Иҗат—ләззәт, иҗат—газап!
Ә мәхәббәт?—
Үзе иҗат, үзе тылсым,
Үзе хәят...

Сөю—ләззәт, сөю—газап,
Сөю—иҗат!
Тылсымнарын белсәң генә
Ит иҗтиһат!

❦

Җаныңа сөю салынса
туганда ук.
Газапларын татырсың—ай
туганда ук.


Ае аның гел сагышка
сарган булыр.
Ә кояшы ут-язмышка
тарган булыр.

Ае—сагыш, кояшы—ут!—
Гашыйк җанга
башкасы—юк!

## Марсель Зарипов

# АГЫМСУ ТАШУЫ

хикәя



*Марсель Харис улы Зариповка быелның октябрь аенда җитмеш яшь тулды.*

*Марсель Зарипов урыс телендә язучы—публицист, тәрҗемәче, хикәяче прозаик. Аның әдәби әсәрләре—хикәя-повестьлары да байтак. Ул ике дистәдән артык китап авторы, аларны исемләп санап тормастан, кызыксынган укучыларыбызга әсәрләрен эзләп табу мөмкинлеген калдырып, шуны гына әйтәбез: публицистик әсәрләр авторы буларак, М. Зарипов Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булган бердәнбер язучы!*

*Инде Марсель Зариповның тәрҗемә эшчәнлеген дә телгә алып китү кирәктер. Ул татарчадан (сүз уңаеннан—татарчаны су кебек эчә!) русчага Әмирхан Еники, Мирсәй Әмир, Ибраһим Салахов, Гариф Ахунов, Туфан Миннуллин кебек күренекле әдипләребезнең әсәрләрен тәрҗемә итте. Аннары ул әсәрләрнең шактыен рус теленнән башка телләргә дә күчерделәр. Мәсәлән, Г. Ахуновның «Соңлап ицгән бәхет» («Балетный мастер») хикәясен М. Зарипов тәрҗемәсеннән алып СССР халыкларының һәм чит илләрнең 18 телендә бастырып чыгардылар, Совет властеның 60 еллык чорында иҗат ителгән иң яхшы хикәяләрнең өчтомлыгына да керттеләр.*

*М. Зарипов—журналыбызның даими авторы. Ул нинди генә мәсьәләләр күтәреп чыкмасын, алар һәрвакыт тирәнтен уйланып, гаять күп мәгълүматлар белән баетылып, еш кына кайнар бәхәсләргә кереп язылган булыр.*

*Төп темасы нефтьчеләр тормышы аның. Бу уңайдан, Мәскәүдә нәшер ителгән бик саллы «Черное сокровище» («Кара хәзинә») дигән икетомлыгын әйтеп китү дә җитәдер. М. Зарипов һәвәскәр умартачы да бит әле—бал кортлары турында да бик тәфсилле китап бастырып чыгарды.*

*Алга таба да иҗади уңышлар сиңа. Каләмең тутыкмасын, һаман да безнең авторыбыз булып яңадан-яңа иҗат җимешләрең белән куандыр!*

* * *

Сәгать иртәнге сигезләр иде инде. Кояш култык өстеннән шактый күтәрелгән, ә Сәгъдиев һаман да әле яр өстендә утыра. Кулдашы Хәким Нуриханов юк, ул елгадан уникe чакрымнар өстәрәк, шәһәрдә яши һәм көн саен шуннан эшкә килеп йөри иде.

Сәгъдиев көймәсен әзерләп куярга өлгерде: әлүмин чүмечнең каерылып чыккан сабын ябыштырып куйды—көймә төбеннән су түккәндә анысы да кирәк бит, койрыктагы какшап беткән утыргычны ныгытты, бүгенгә кирәкле барлык йөкне рәтләп урнаштырды, хәтта тәмәке тартып куйды, ә кулдашы һаман күренмәде.

—Менә бәла!—Сәгъдиев юлга карый-карый яр буенда әрле-бирле йөренгәләде, аннары яр өстенә тәртипсез чыгарып ташланган дымлы, кытыршы бүрәнәләрнең берсенә барып утырды. «Нәрсә булды икән?—дип уйланырга тотынды.—Әллә авырып киттеме икән? Булыр да. Кичәгенәк суга төшкән эт баласы кебек чыланган иде—җил тигәндер».

Сәгъдиев үзләренең чыланып беткән, тунган килеш ташу суыннан бер куянны коткарып алганнарын исенә төшерде, хәзер Хәким Нурихановның хастаханәдә уттай янып, кызышып ятуын күз алдына китерде. Янәшәсендә чибәр шәфкать туташы утырадыр, кулына алагаем зур шприц тоткандыр, сәгате җиткән саен, теге бичараны корсагына әйләндереп, йомшак җиренә укол кадыйдыр.

Гомумән алганда, Сәгъдиевнең ялгыз калгалавы беренче генә түгел. Аның кишәрлеге сазлыклы, су баса торган урында, яз саен унбер скважинасының һәммәсе дә Әзербәйҗанның Каспий диңгезендәге «нефть ташлары»на әйләнә дә кала. Гадәттә, аңа кулдаш булып эшләүчеләр берәр корырак җиргә ычкыну җаен көтеп кенә тора иделәр. Шулай булмыйча соң! Анда су ерып, чыланып йөрисе юк, скважиналарга коры җирдән барып житәргә була, ә операторларның хезмәт хаклары һәркайда бер үк. Суда юеш тычкан баласы кебек чәбәләнсәң ни дә, коры җирдә вахтада торсаң ни.

Агымсу ташып тына төшкән иде бугай инде. Елгадагы бозларны әллә кайчан юып алып китте, төкрек белән генә әтмәлләп куйган күперне дә, уйнап кына дигәндәй, туздырып алып ыргытты, яр буендагы тирәкләрне ябалдаш башларына кадәр күмде дә, инде хәзер ул кадәр кыргый-ямьсез итеп үкерми башлады. Күрәсең, басу-кырларда карлар эреп беткәндер. Озакламый елга үз ярларына төшәр, тугайлар яшел үлән белән капланыр, язгы ташуның бар истәлеге булып агызып-җимереп алып киткән күпер калыр, аны янә көзге бозлар ага башлаганда гына рәтли-сала башларлар, боз каткач, аның беркемгә дә кирәге калмас.

Башка вакыт булса, Сәгъдиев, кулдашым юк дип, тамчы да икеләнеп тормас, көймәсен суга төртеп төшерер дә барлык скважиналарын йөреп-карап чыгарга тырышыр, ә кичен промыселга кайтып, тагын «ятим калуы» турында әйтер иде. Бу соңгы кулдашы исә Сәгъдиевкә ошап куйды бит, бигрәк тә кичәге озын колак-кылый күзне коткарганнан соң, ул аны ярата да башлады шикелле.

Гадәттә аңа кулдашларны кадрлар бүлеге җибәрә торган иде. Андыйлар гадәттә ышанычлы эшче һөнәре булмаган, тизрәк берәр җиргә «эләгергә» тырышкан кешеләр яки айныткычтан чыккан һәм үз гаебен тизрәк юарга тырышкан бәндәләр була иде. Күпмедер вакыт үтә, ул «сары томшыклар» ныклы эшче разряды үзләштергән белгечләр булып китә, штрафлылары төзәлә һәм—Сәгъдиев янә дә ялгызы утырып кала иде.

Хәким Нурихановны Сәгъдиев үзе сайлап алды. Егет караңгы чырайлы бер әзмәвер иде, елмайса да, ул бары тик бәйрәм көннәрендә генә, анда да әле, башкалар күрмәсен дип, качып-посып кына елмаядыр. Ә Сәгъдиевкә аның белән үбешеп яшисе юк. Эшен белсә, ялкау булмаса—ни кирәк тагын? Калганы—пүчтәк кенә.

Узган көз булды бу хәл. Сәгъдиев янәдән ялгыз калган иде, бу юлы башлыклар белән туйганчы әрләшергә дип, туп-туры контора директорының үзенә барып керде. Конторада ул сирәк була, йә җае туры килгәндә яки

нужа куып китергәндә генә килеп чыга иде, һәрвакыт ул күренгән саен коридорда күнелле шау-шу куба:

—Сәгъдиевкә өеп премия биргәннәр! Күрәсез, килеп тә житкән. Контораның коридоры озын, кул биреп исәнләшергә, бер-ике сүз алышырга теләүчеләр күптин дә күп. Сәгъдиев, утә-үтешли, оператор, слесарь, мотористларнын кытыршы каты кулларын кыса-кыса, ниһаять, бусагасы тапталып беткән диспетчер бүлмәсенә барып житкәндә,—шул ук бүлмә директорның кабул итү бүлмәсе дә бит әле!—директор да, өлкән инженер да, АХО башлыгы да каядыр чыгып таярга өлгерә иделәр.

Бу юлы директор урынында булып чыкты, башы түшәмгә тигән йомыкый әзмәвер егеткә вәгазь укый иде:

—Әйт әле, Нуриханов, кайда тыгыйм инде мин сине? Син бит бер жирдә дә тыныша алмыйсың, барысы да синнән баш тарта. Әйт әле, нәрсә житми сина, ә?

—Мин каян белим?—дип, йөзен чытып куйды әзмәвер егет.—Мөгаен, энтузиазм житмидер.

—Менә, күрденме?—директор күнелсез генә көрсенеп куйды.—Ә мин сиңа ул энтузиазмны каян алыйм? Спецовка итеп, складтан яздырып биримме, ә? Әйдә, «үз теләгем белән» дип гариза яза да—дүрт ягың кыйбла. Әлбәттә, сине бераз тәрбияләргә кирәк иде дә, бәлки берәр юнь чыгар иде, ләкин туйдырып бетерден бит инде...

Сәгъдиев, аларның «үзара матур» сөйләшкән чакларында, үз чиратын көтеп урындык читендә генә утырып тора иде. Бу Нуриханов дигән әзмәвер күтәрелеп бәрелер дә, «үз теләгем белән» дигән гаризасын язмас, директор аны берәр статья белән эштән куар яки аның үзенә сылар дип көтте дә, үзе үк тәкъдим ясады:

—Бирегез аны мина,—диде.

Бу хәл көз булган иде. Көннәр гаять тын, яфракларын коеп, каралып калган урман бөтен тавышларны баса, елга өстендә тын гына пәрвез жепләре тирбәлә иде.

Беренче көнне Сәгъдиев әзмәвер егетне юри яр буйлап алып китте, куакларны ера-ера барганда, ана эшнең ни-нәрсәдән торасын аңлатып барган булды. Һәр көнне унбер скважинаны йөреп-карап чыгарга кирәк булачагын төшендерде, бу—бер якка алты чакрым чамасы дигән сүз, бары тик төнлә бер скважинада туктап калмасына ышангач кына кирегә тыйтаклыйсың.

Кулдашы анын артыннан көчкә өлгереп бара, куак-ботакларны сындыра-сындыра, сүгенеп тә куя, ә Сәгъдиевкә шул аяк басмаган, йөрелмәгән агач-куаклар арасыннан үтү кирәк тә иде. Ул, бара-барышлый, елгага сак-сизгер керпеләрнең кайданрак юл салганнарын күрсәтә, куяннарның яшь усак ботакларын кимерергә кайдан килгәннәрен төшендерә, кулдашын тын култык почмагында кай тирәдәрәк кыздырып ашарлык симез кушбашларны бер кармак белән дә тотып алырга булганлыгын аңлата, хәтта бер борылыш ясап, үзенең кеше күзеннән аулак аланчыгына да алып чыга, анда ак каеннар ябалдашы астына март аенда карт көртлек әтәче бер көтү ана көртлекләрне жыячагын сөйли... «И-и-и, шул көннәргә барып житсәк әле, без монда төне буе яшеренеп утырырбыз, таң аткач, язны сагынган көртлекләрнең «жырларын» тынларбыз»,—ди.

—Йә, ничегрәк соң?—дип сорады Сәгъдиев кулдашыннан, вахталарны карап-тикшереп кайткач.

—Нәрсәсе ничегрәк?—дип игътибарсыз гына кабатлап сорады әзмәвер егет.

—Эшне әйтәм. Ошыймы?

—Арыдым, тел әйләндерерлек тә хәлем калмады. Ә болай ярыйсы булыр иде дә, йөрүе күбрәккә китә.

Сәгъдиев ана куяннар, кушбашлар, язгы көртлекләр турында никадәр мавыгып сөйләмәсен, тегесенең сүзе бер булды: «Әй, исең киткән икән!» Ул егеткә үпкәләмәде, ләкин сөйләшүеннән тукталып калды.

Кышны әйбәт кенә үткәрделәр. Язгы ташуга әзер булсалар да, су көтмәгәндә, кинәттән килеп төште. Әле бервакыт, март аенда ук, су буена

төшкән иделәр, исләре китеп туктап калдылар: челтәрләнә башлаган зәңгәр боз өстенә су саркып чыга иде инде. Алар бу ерак почмакта операторлар өчен махсус салынган йортка әйләнеп кайттылар да, складтан алдан ук яздырып алдырылган резин итекләрен киеп, иң аргы скважиналарны карап кайтырга чыгып киттеләр.

Эш ишелеп төште. Барлык моторларны да яңадан ныгытып беркетәсе бар, труба-задвижкаларны, язгы ташу суы ватмасын өчен, карап-тикшереп чыгарга кирәк. Кулдашы белән алар караңгы капканчы скважиналарга йөрделәр. Баштарак Сәгъдиев Хәким сукрана-шыншый башлар дип курыккан иде, өстәмә эш хакы сорар әле дип тә шикләнде, ә аны сиңа кем түли, ди? Артыннан йөреп, аяк киеменңне генә туздырырсың, шул булыр. Әмма егет түзде, аны-моны дәшмәде, эшләвендә булды. Сәгъдиев, дөрес, канәгатьлеген күрсәтмәде, әмма монысыннан да кулайрак кулдаш булуын да теләмәде.

Бервакыт алар караңгы төшкәнче бер көйсез мотор белән азапландылар. Шуннан Сәгъдиев Хәким Нурихановны туп-туры үзе генә белгән теге аланлыкка алып китте. Учак ягып җибәрделәр, кипшенделәр, ипи ашап, шикәр тешләп чәй эчтеләр, караңгы куак арасына куыш корып куйдылар. Иртәнгә таба учакта көйрәп яткан күмер кисәкләрен таптап сүндерделәр дә тын гына көтеп утыра башладылар.

Сәгъдиев кисәтеп куйды:

—Тынынны да чыгармый утыр!

—Әгәр төчкертсә?

—Төчкерәсең килсә дә, тының чыкмасын!—дип кырыс кына әйтте Сәгъдиев.—Юкса, эшне бозачаксың.

Аста, тын куаклар арасында бөтенләй караңгы иде әле, шулай да йолдызлы күк аша каен башлары ачык шәйләнә башлаган иде инде. Кинәт кенә куыш өстендә сак кына тавыш яңгырады:

—Ччу-у ф-ф--шшы-ы-ы!

Сәгъдиев, карана торгач, каен башында сак кына утырган ата көртлекне күреп алды. Ул кесәсеннән үзе ясаган сыбызгы кебек нәмәрсәсен алды да әкрен генә шуңа өрде. Көртлек, шул тавышка алданып, авыр канатларын җинел генә җилпеп җибәрде дә каен башыннан тавыш килгән якка очып төште. Әтәч көртлек нәкъ куыш янәшәсенә килеп кунды, әгәр дә хәзер Сәгъдиев кулын сузса, ул аның янып торган кикригеннән тотып алыр шикелле иде. Көртлек аптырап куыш алдында таптанып торды, аны чакырып аваз салган ана көртлек кая югалды икән, дип уйлагандыр, мөгаен. Сәгъдиев янә чакырып аваз салмакчы иде дә, карт көртлек, аның хәйләсен сизенер дип куркып, дәшмәскә булды. Көртлек кукраеп, коерыкларын кабартып, алан уртасына узды, янә куыш янына әйләнеп килде, туктап, кызыл кашлары белән күзләрен каплады да, чакырулы тавыш белән дәште: бу-бу-бу!

Сәгъдиев әтәчне ник чакырганына үкенә башлады. Яктырып килә, йолдызлар сүнә башлаган иде инде. Шул чакта кайдандыр караеп торган агач араларыннан шаулашып яшь көртлекләр көтүе очып төште, әй тотындылар болар берсе алдында берсе кәпрәеп йөрергә, мин сиңа әйтим! Бары тик беренче төшеп утырган карт әтәч кенә урыныннан кузгалмады. Сәгъдиевнең озак кузгалмый торудан аяклары оеды, туңа башлады, ә кыймшанырга ярамый. Сәгъдиевне бу мизгелләрдә беркем дә, бернәрсә дә урыныннан кузгата алмас иде, валлаһи! Ул ни үле, ни тере булып утыруында булды. Хәзер әтәч көртлек ялганны сизсә—пырх! бөтен көтү очып китәчәк бит.

Карт көртлек таптанып куйды, янадан күзләрен йомып, муенын югары сузып, чутылдарга тотынды.

Сәгъдиев кулдашының колагына пышылдады:

—Түз. Куркытсаң—янадан килмәячәкләр.

Йолдызлар инде эреп беткән, агач башлары яктырган, аланлыкка таң алды иңгән иде. Кар да, агач-куаклар да алсуга манылды. Яшь әтәч көртлекләр уттай кызыл кикрикләрен кәпрәйтеп, бер-берсе белән бәргәләшергә, очакуна сугышырга тотындылар, каты томшыклары белән чукый-чукый, кан чыгарганчы тырыша иделәр. Аланлыктагы бу алсу-кызыл сугыш кызганнан-

кыза барды. Шунда кинәт кенә агач араларыннан шул утлы-кызыл түгәрәк эченә соры ана көртлекләр көтүе белән очып төште...

Бу төндә нефтьчеләребез күз дә йоммады. Сәгъдиев кулдашы өчен шат иде, анда нинди дер гомер булмаган яктылык тойды. Ә инде юеш карга билдән бата-чума кайтканда, ул әле ин зур куаныч ташулар акканнан сон булыр дип хыялланып кайтты. Май урталарында шомыртлар чәчәк атар, су өсте ап-ак булыр, атна буена бер генә яшел тап та күрмәссен.

—Шундый матур гүзәллек!—дип үзе дә тан калып сөйләнә иде Сәгъдиев.—Салкыны да, ташуы да, су басып киткән скважиналары да бер якта торсын! Берсе дә кирәкми.

Сәгъдиев бөтенләй ачылып китте, бер тын белән, үзенен ни өчен бу эшкә алынганлыгын анлатып бирде, чөнки ана әле кеше аягы басмаган урманнар ошый иде, нефть эзләүчеләр шунда беренчеләрдән булып жир бораулыйлар, вышкалар куялар. Мөгаен, ул хәзер дә әле шул эзләнүчеләр белән Ходай Тәгалә вә шайтан үзе дә оныткан почмакларда, Чулман-Кама, Нократ-Вятка буйларында, хәтта исеме дә булмаган инеш-елга буйларында нефть эзләп жир тишеп йөргән булыр иде. Әмма кызлары бар бит... Ана ул яктан бәхет ишелеп төште: хатыны бер-бер артлы тупылдап торган дүрт кыз бала табып бирде. Ул кызлар үсеп життеләр, укытырга кирәк була башлады, күчмә тормышны ташлап, бер урында төпләнергә туры килде. Кысан шәһәр фатирына барып ятарга теләмәде ул, кызларын интернатка урнаштырды да, хатыны белән икәүләп шушы алла каргаган промыселда яшәп яткан көне, һәм зарланмый да.

Башкалар бер агымсу ташуыннан артык тора алмыйлар, корырак жиргә ычкыну ягын карыйлар, ә ул моннан кузгалмаячак та, чөнки белә: теләсә кайсы башка скважиналарда эшли алмаячак, качып китәчәк.

Кулдашы ана ияреп ничектер ачылып китеп йөрде, хәтта ташу суы озак торамы дип сорады, ни өчен ул геологлар шулкадәр башсыз икән—ин унайсыз жирдә жир тишмәсәләр ярамаганмы?—дип тә сукранып алды әле.

—Әй, аларныкын шайтан үзе дә анлап бетермәс!—дип кул гына селекте Сәгъдиев.—Жир тишәсе урын колхоз идарәсе, клуб, яки ферма өстенә туры киләме—сүзләре бер генә: «Бораударга!» Ә авылда дөнья ыгы-зыгысы, жәнжал. Скважина манарасын авыл читенә куеп, кыеклап бораударга туры килә. Ә биредә ташыган су ун-унбиш чакрымга жәелә. Телиләрме-теләмиләрме, манараны су уртасына китереп утырталар, ә без синен белән шулар тирәсендә йөзеп йөрергә тиеш булабыз.

Кулдашына нефть эшенен шундый хикмәтләрен анлаешлырак итеп житкерергә теләп, ул, үзе дә сизмәстән, үз кишәрлекләренен искиткеч матурлыкларын мактарга тотына иде.

Елга бит ул бер ай гына чыгырыннан чыгып ташый, аннары тына, әле кайчан гына болганчык су басып киткән ярларын икенче ташу—ап-ак шомырт чәчәкләре ташуы басып китә, яшелләнеп үлән күтәрелә, сандугачлар сайрар вакыт житә.

Сәгъдиев, мавыгып китеп, без әле синен белән дип сөйли башлый, ә тегесе куаклыклар аша мышный-мышный атлавын белә.

—Ә озак буламы ул?—дип сорап куя.

—Нәрсә?—дип анламый тора Сәгъдиев.

—Сон, шул шомырт чәчәге инде. Ничә көн тора дип сорыйм.

—Бер атна,—дип жавап бирә Сәгъдиев, борылып та карамыйча.

—Шулай гынамы? Ә билдән су ерып ай буе йөре!—Хәким Нуриханов көлмәкче булды бугай, ләкин шундук шапылдап карга батып китте.

Сәгъдиев әйләнеп карады: кулдашы биленнән сулы карга чумган, бер кулы белән таза гына ботакка тотынып өлгергән, икенче кулын Сәгъдиевкә сузып тора иде.

—Ярдәм ит!

—Бер атна булса ни?—диде Сәгъдиев, ана кулын сузып.—Кайсыбер көн елга тора. Кешеләр әнә еллар буе бил бөгә, баш күтәрми эшли, сберкнижкасына акча жыюын белә, ә бераз акча туплагач, ял ала да ин кыргый жирләргә китеп бара. Соловкига баралар—анда черек сазлык, алла

каргаган тын почмак, элек шунда кешеләрне сөргенгә сөргәннәр. Ә безгә шушы оҗмах почмагында эшләгән өчен хезмәт хакы да түлиләр әле җитмәсә.

Кулдашы сулы, көпшәк кар эченнән суырылып чыкты, итекләренә тулган болганчык суны түкте, аяк чолгауларын сыгып яңадан урады, аннары төксе итеп әйтеп куйды:

—Юләрләр беткәнмени? Берәр реформа белән китереп орырлар да—акчалары очар—үт-үт!

—Очса соң. Реформаның монда ни катышы...

Сәгъдиев үпкәләргә җыенган иде, аннары кире уйлады, ап-ак шомырт ташуларыннан соң энҗе чәчәк-ландышлар ачылачагын, аннары үги ана яфракларының вак сары чәчәкләре китәчәген, аннан соң инде җиләкләр, гөмбәләр, чикләвекләр өлгерәчәген сөйләп китте.

Кәефләре сөйләшүгә тарта иде, Сәгъдиев көне буена кулдашына кешеләрнең акылсызлыгы—шушындый матурлыкны ялангач матди мәнфәгатькә әйләндереп калдырулары турында зарланып сөйләде, әйтерсең лә, дөнья шул бер юньсез ун сумлыктан башланган да, шунда төртелеп бетәчәк, диде.

Берничә көн үткәч, су бозны чәрдәкләп бетерде, теге мескен күперчекнең бүрәнәсен бүрәнәгә аерып агызып алып китте, текә яр ягына күтәрелә алмыйча, тугайлы тәбәнәк якны басты. Йөрергә мөмкинлек калмады. Сәгъдиев мазут белән сыланган кара көймәсен түбә астыннан тартып чыгарды, флагшток таякчыгына нечкә генә ике алсу тасма таккан булды, аннары суга төртеп төшерде.

Сәгъдиев кулдашына шатланып бетә алмый иде. Башына бүрек чәпәгән, җиңнәре терсәкләренә җитәр-җитмәстәй үзенә кечкенә брезент нәмәрсә кигән килеш, ул Сәгъдиевкә каршы ишкәктә утыра иде, Сәгъдиевнең бер күз карашыннан кайчан сул ишкәкне каера төшәргә, кайчан уңын иканлеген аңлый, кайда сай урыннар буласын җилкәсе-аркасы белән үкме чамалап, көчле бер талпынуда көймәне алга ыргытып ташлый. Бары тик ул утырган, кибеп беткән карт утыргыч кына аның куәтле гәүдәсе астында шыгырдап-сыгылып куя иде.

Җинел көймә теләсә кайсы мизгелдә капланырга, йә куак араларына кереп буталырга мөмкин иде, әмма әзмәвер егет боларны оста гына җиңеп чыкты. Койрыкта утырган Сәгъдиев тә туп-туры скважина өстенә барып менде, өскәрәк каерды, түгәрәк задвижкалары арматурасы-ние белән тигезләнгәч кенә, аларга барып тотына торган булды. Дулкыннар көймәне җинел генә кагып, торбаларга сыларга тырышканда, ишкәкләрен калдырып, түгәрәк эшермә-задвижкаларны тотып тора, ә Сәгъдиев торбага менеп баса да, һәр мизгелендә суга егылып төшү мөмкинлеген дә онытып, нефть басымын тикшерә, электромоторларны су басып китмәгәнме дип карый, аннары сак кына көймәгә сикерә дә: «Киттек!»—дип боера.

Кулдашы ике кулын көймәне каршы килгән тыгыз су агымыннан читкә этәрә, Сәгъдиев аны дулкыннарга турылап куйган арада, тегесе тиз генә ишкәкләренә тотынып өлгерә.

Бу ташуда ни өчендер, бер генә җан иясе дә очрамады, бары тик кичә генә бер озын колак куянга юлыктылалар. Ул мескен пычранып беткән, менә-менә агып китәм дигән бер өем чүп-агач өстендә утыра һәм котырып аккан суга өметсез карап тора иде. Ничек аны шундый бөтерчеккә китереп керткән, диген? Мөгаен, сутлы яшь кайры ашыйсы килгәндер дә, мавыгып китеп, Робинзон хәлендә калганын абайламагандыр да.

Куян аңгырарак иде булса кирәк. Нефтьчеләр аны бәладән коткарып, көймәгә алырга тели. Кулдашы бар көченә ишә, Сәгъдиев сикереп тора да, кыек күзне озын колагыннан эләктереп алырга тели, ләкин агым көймәне тагын читкә алып китә. Куакларга сугарга да куркыныч, озын колак шундук суга егылып төшәчәк. Сәгъдиевнең түземе бетте:

—Сикер монда, әрекмән колаклы аңгыра!—дип кычкырып та карады. Әмма куркудан коты очкан кылый күз, көймәгә сикерәсе урында, һаман да куырылып, ни үле, ни тере килеш, дигәндәй, шул селкенеп-дерелдәп торган

чүп өемнәрендә утыруын белде, әрекмән яфраклары шикелле озын юеш колаклары белән күзен томалаган булды.

Нефтьчеләребез ул ангырага күптән кул селтәп китеп барган да булырлар иде, әмма агым аларны анын янынннан алып китә башлауга, ул мәхлук шәм кебек тураеп баса, куркынган күзләрендә ялваруга охшаш өмет төсмерләнә. Сәгъдиев түзә алмый, яналан рульгә тотына, куллашына күз карашы белән генә: «Иш»—дип боерык бирә.

Сәгъдиев инде бу ангыра куянны ничек тотарбыз да, ничек көймәгә салырбыз, дип аптырап торганда, тагын шулай ук файдасыз-өметсез бер якын килгән арада, куллашы кинәт сикереп торды да, көймә борынындагы чылбырны тотып, суга атылды.

Һәй, бу сокланргыч атылу иде! Үз җилкәсе аша үткәрелгән чылбырны тотып торган Сәгъдиев анлап та бетермәде—куллашы әллә төпкә бастымы, әллә йөзеп кенә бара идеме,—әмма егет кылый күзгә үрелеп, аны ике колагыннан эләктереп алды да куен эченә тыкты, аннары куакларга тотынып, көймәне үзенә таба тартты.

Сәгъдиев тә, куакларга тотынып, ана ярдәмгә ашыкты. Куллашы куянны көймәгә сузып салды, көймә сыртыннан үрмәләп менде дә, бер нәрсә дә булмаган кебек яналан ишкәгенә тотынды.

Һәрвакыттагыча, алар көне буе су баскан скважиналарны карап йөрделәр, ә куян мескенкәй, дөньяга ваемсыз күзе белән карап, утыргыч астында ятуын белде.

—Котын ботына төшкән идеме?—дип Сәгъдиев ике-өч мәртәбә хәлен белешкән булды.—Син хет күнеллерәк күз кыс, терерәк бул. Синен аркала кеше әнә нинди салкын суда коенып чыкты, ә син һаман ниндидер хәлсез.

Ә кылый күз гамьсез генә юеш колакларын кыймылдаткалап һәм икегә ярылган иренен тырпайтып ята бирде.

«Үлеп китмәсен тагын,—дип уйлап куйды Сәгъдиев куян турында.—Аны коткарыйк дип, күпме мәшәкатьләндек, ә ул жан тәслим кылып куйса, тагын,—дип уйлады.—Өйгә алып кайтып житкерсәм, мич башына утыртырмын үзен, жылынсын шунда».

Көймә ярга килеп төртелүгә, кылый күз дерт итеп кузгалды да, көймә читеннән туп кебек сикереп, судан читкә элдертте.

Сәгъдиев беркавымга аптырап калды, ә куллашы:

—Әл-лә-лә-лә! Мәнә сина кылый күз!—дип кычкырып жибәрде. Үзе житмәсә яр буйларын янгыратып көлә.—Безне жүләргә калдырды бу...—диде. Аннары, елмая-елмая, чиратлаштырып, күн итекләренә тулган суларын түгә, оекбашларын, аяк чолгауларын сыгып куя башлады. Үзенен манма су булып, калтыранып торганына да шат шикелле иде ул.

Сәгъдиев анын янәшәсендә басып тора һәм куллашы өчен чиксез шатлана иде.

Бүген исә куллашы юк та юк. Сәгъдиев әллә ни нәрсәләр уйлап бетерде. Әлбәттә, ин әүвәл теге ангыра куянны тиргәп ташлады: «Кирәк бит ана Робинзон булырга!»—диде. Аннары үзен: «Шул нәмәстә белән маташырга кирәк идеме?»—дип битәрләп алды. Куллашынын хәзер салкын тигезеп, хастаханәнен каты караватында янып ятуын күз алдына китерде. Ә Сәгъдиев нишләргә тиеш? Скважиналарны берүзе йөреп-тикшереп чыксынмы? Промысел конторасына яна куллаш сорап барсынмы? Рәтле көннәр торганда, ул бер үзе дә ерып чыгар, эшен эшләр иде, әмма язгы ташу вакытында—һай-вай...

Куллашы көтмәгәндә генә әллә кайдан матайда тырылдап килеп чыкты. Сәгъдиев куанып бетә алмады, кабаланды-каударланды, хәтта куллашынын мотоциклда һәм, ин мөһиме, чип-чиста, пөхтә киемле булуына да игътибар итмәде.

—Исән-саумы?—дип ташланды ул ана.

—Мина нәрсә булсын?—дип, гыжлавырак жавап кайтарды тегесе, тирләгән, яшьләнгән күзләрен кул аркасы белән сөртә-сөртә.

—Сон... син теге кылый күз артыннан салкын суга чумдын бит. Мин инде, табиблар сине эләктереп алып укол арты укол кадыйлар дип уйлап

тора идем. Алар шундый халык! Авыруга бер ун авырттыра торган укол билгеләү—алар өчен бәйрәм!

—Әй, шундый юк-бардан да авырып ятсаң тагын! Сразы пенсиягә китүең яхшырактыр,—дип көлде әзмәвер.

Сәгъдиев башкасын сораштырып тормады, көймәсенә ашыкты. Юл унаендә жилкәсе аша гына сүз ташлады:

—Кара, кояш синнән дә югарырак инде. Ишә башлыйк, өлгермәвебез ихтимал.

—Ә без ишеп килеп життек инде.

—Нәрсә диден?—Сәгъдиев аптырап әйләнеп карады.

Кулдашы мотоциклын терәткечена куйды да, куенынннан бер шешә аракы белән бер кисәк казылык тартып чыгарды, жыелмалы тимер рюмкалары да пәйда булды.

—Синен сабантуенмы әллә?—дип сорамый булдыра алмады Сәгъдиев.

—Аннан да шәбрәге,—дип, ак тешләрен күрсәтеп көлеп жибәрде кулдашы.—Без синен белән ишәкләндек, житәр. Хушлашырга сугылдым. Әйдә, соң мәртәбә берне күтәрик әле. Беләсеңме, миңа синен белән эшләү бик рәхәт булды. Элек синен ишеләр бер дә очрамаган иде.

Сәгъдиев аптырап калды, янына килеп, сузылган тимер касәне кулына алды.

Кулдашы шешәсенең төбен үкчәсенә бер генә бәрде—бөкесе шундук атылып барып төште.

—Эч,—диде ул.—Аннары гаризама кулыңны куярсын.—Кесәсеннән бөгәрләнеп беткән кәгазь кисәге чыгарып, Сәгъдиевкә сузды. Сәгъдиев зур-зур хәрефләр белән язылган сүзләрне укып алды: «Мине нефть кудырырга куегыз, анда файдам күбрәк булыр дип уйлыйм».

—Ә мин нәрсә языйм?—дип сорады Сәгъдиев.

—«Каршы түгелмен»,—дип яз. Син каршы булмасаң—башкалар да каршы килмәс, күчереп кенә куярлар. Нигә мин эш стажымны югалтырга тиеш ди әле? Һаман-һаман «үз теләгем белән» дип язып торасым килми. Тот, мә!

Шулай дип, кулдашы Сәгъдиевкә кәгазь төртте.

—Кул куймыйм мин,—дип киреләнде тегесе.

—Ә нигә? Кызганасыңмени бер тамганы?

—Кызганмыйм. Миннән башка гына мәтәштер.

—Нинди мәтәштерү инде бу? Кеше матди ягын да карарга тиештер бит?—Кулдашы аның каршысында таптанып сөйләнә торды.—Син мина көртлекләр, сандугачлар, шомырт чәчәкләре турында сайрап-сөйләнеп йөрден. Ә миңа аларның ни пычагыма кирәге бар? Су да су... Бер батасың, ике—радикулит эләктерәсен дә, гомер буе әптик юлыннан кайтып кермисен... Ә нефть кудыргычта баш өстендә коры, яумый-таммый, көн саен сөтен дә биреп торалар, зыянлы эш дип, ун сумын да өстиләр әле житмәсә. Ә синдә нәрсә бар? Шул бердәнбер сандугачларын чыркылдаумы? Мә, эч тә, кул куй. Әйбәт кенә аерылышыйк.

Әзмәвер стаканга аракы агызды:

—Мә, тот тизрәк!

Сәгъдиевнең ачуы кузгалды.

—Ал әле стаканыңны! Мин сине аракысыз да жибәрәм, ычкын күз алдымнан...

Сәгъдиев әзмәвернең гаризасына кул куйдымы-юкмы, хәтерләми. Көймәсен суга этеп төшерде дә, авыр гәүдәсе белән аңа кереп утырды, гадәтенчә ишеп елга уртасына кереп китте. Күңелендә рәнжү кайный иде. Үз-үзенә рәнжү. Кемгә ышанган бит, кем өчен янган-көйгән?

Аның аты-юлы белән авыз тутырып бер сүгенәсе килде, бәлки, эче бушаныр иде, әмма агымсу көймәсен агым уңаена алып китеп бара иде инде, ул бер төкереп кенә куйды да, ишкәкләрен каерып-каерып ишә башлады.

Аптырап калган әзмәвер яр өстендә таптанып торуында булды...

**Марс ШАБАЕВ** *тәрҗемәсе*



## Вәзыйх Фатыйхов

### Мин бит...

Мин бит үзем түзем—
Ат та, тәртә дә.
Балыгы да үзем,
Үзем ятьмә дә.

Мин бит үзгә үзем,
Язын, көзен дә
Ярларым ташый, тик
Калам үземдә.

Мин бит моңлы бала,
Тик елау белмим.
Йөрәк—көл-күмер, тик
Ятка сер бирмим.

Мин бит серле үзем,
Күзләрем—көзге.
Күңел гел язда, тик
Яратам көзне...

Мин бит түзем җанлы,
Хыялда—киңлек!
Йөрәктә гел ташкын,
Җанда—иминлек!

---

Вәзыйх ФАТЫЙХОВ *(1956) - шагыйрь, «Тормыш арбасы», «Тормыш —ормыш» исемле китаплар авторы. Балык Бистәсендә яши.*

Син бар бит ул, Мәңгегә бар,
Шулай язган сине Ходай.
Яннарымда булмасаң да
Инде син минеке бугай.
Инде син минеке бугай.

Сизәсеңме, аңлыйсыңмы:
Күзләр-күзгә күптән дәшә.
Яннарымда булмасаң да
Тоям сине гел янәшә.
Тоям сине гел янәшә.

Синең тавыш ишетелсә,
Дәва алам яраларга.
Яннарымда булмасаң да
Җылылык бар араларда:
Мәхәббәт бар араларда.

## Бушанулар кирәк

Әлсерәгән, ялын күккә чөеп,
Ак күбектә чаба Чулманым...
Ялкынсынган чагың күп күрсәм дә,
Мондый ярсу юктыр булганың.

Ярларыңа типтең кешни-кешни,
Аңлаганга сине, тыймадым.
Бушанулар кирәк сиңа кайчак,
Һәрбер җанга кирәк, Чулманым!

## Серле кое

*(Карт диалогы)*

Көзгесендә ничә буын чагылышы,
Күзләреңнән танып ала һәр язмышны.
Бу коеның су төмендә аермасы,
Чыгырының аермалы үз тавышы.

Безнең кое иң тирәне, иң үзгәсе,
Андый кое дөньясында юктыр әле.
Бала чакның тойгысында сер-хикмәте,
Һич кенә дә иренемнән китми тәме.

...Көч-хәл белән тыеп калдым, чиләк чумды,
Карашымнан серле көзгә уйнап куйды.
—Коекаем, җыерчыгым юдың әллә?
Билләһидер яшәргәнем үзем тойдым!

## Чәчән сулышы

Нинди сулыш бу—кан исе килә?
Нинди язмыш бу—тоташ өермә!
Көн дә бер хәбәр—кемнәр соң алар,
Һәр киселгән баш җанны көйдерә?!

Нинди җилләр бу—тоташ тузанлы?
Атлар өченгә туры юл бармы?
Киселгән өмет тәнне өшетә
Кая куярга белмим бу җанны.

Нинди карлар бу—тынмыйча ява,
Гүя, фәрештәләрнең күз яше тама.

Кара болытлар кояшны талкый,
Сулар да бүген кирегә ага.

Нинди сулыш бу—тыннар кысыла,
Энәдән атлыйм, аяк очында.
Афәт якадан ала түгелме,
Күңел сырхаулы, йөрәк пошына!

## Касәмне күтәрәм...

Җидегән йолдыз ул—Мәхәббәт касәбез,
Төннәрен икәүләп шәрабен эчәбез.
Шаһитка сүрелмәс йолдызлар сайлагыз,
Арага җиде ят кермәсен дисәгез.

Җидегән йолдыз ул—мәхәббәт күзгебез,
Аңарга карашлар сихерле тартыла.
Караңгы төндә дә болытны аралап
Шул йолдыз кабына мәхәббәт хакына.

Җидегән йолдыз ул—төнебез кояшы:
Вәгъдәләр күкләрдә эленеп калмады.
Шәрабләр кулда да, күктә дә чайпалды,
Тик алар читләргә таммады.

Җидегән йолдыз ул—уртаклык билгебез,
Югалтмый яшик яктысын гомергә.
Мин бүген мәхәббәт касәсен күтәрәм,
Мин тугры йолдызлы сөюгә!

## Гомер

Яшәгән саен азая бара,
Азайган саен күпне көтәсең.
Аз нәрсә һәрчак була кадерле,
Ходай бүләге—ни хәл итәсең.

Кимегән саен кадере арта,
Бер тапкыр гына аны сүтәсең.
Үзгәртәм димә, юктыр бер чара,
Ходай бүләге—шөкер итәрсең.

Телисеңме син, теләмисеңме,
Йомгак очына берчак җитәсең.
Бирелгәненә шөкер итә бел,
Ходай бүләге—ни хәл итәсең!

## Халәтем

Йөрәгем тибеше—хыялым җилкәне,
Диңгезем—күңелем чишмәсе.
Ярсулы ташкыннар—кодрәтем,
Кодрәтең булмаса нишләрсең?!

Хыялым җилкәне—ул минем киләчәк,
Кыйбламда—гомерлек оҗмахым.
Күзләрем төсендә—зәңгәр күк яктысы,
Туасы көннәрем—җырланыр җырларым.

Гомерлек оҗмахым—әхвалем, тормышым,
Дусларым—ышаныч канатым.
Барысы янымда, мең шөкер, Ходаем,
Өметле өметем—тезгенсез ак атым.

## *Казан дәүләт педагогика университетына 125 ел*

# ОЗЫН ЮЛ, НУРЛЫ ЮЛ



Университет ректоры, Татарстан Фәннәр Академиясенең мөхбир әгъзасы, Татарстанның атказанган Фән эшлеклесе **Рүзәл ЙОСЫПОВ** белән язучы **Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА** әңгәмәсе

*—Рүзәл Габдуллажанович, 2001 ел—Сез җитәкләгән университетта юбилей елы. Мәгариф өлкәсендә генә түгел, гомумән, республикабыз тормышындагы зур вакыйга бу. Иң элек университетның үткән юлы хакында укучыларыбызга берникадәр мәгълүмат бирәсе иде.*

—Әйе, быел Казан дәүләт педагогика университетының 125 еллыгы. Ул 1876 елның 24 октябрендә «Учительский институт» исеме белән ачыла. Санкт-Петербург һәм Мәскәүдән кала Рәсәйдә мондый типтагы өченче югары уку йорты була ул.

1918 елдан башлап университетның исеме берничә тапкыр үзгәртелә: Казан педагогика институты—1918, Көнчыгыш педагогика институты—1922, Татар педагогика институты—1931, Казан дәүләт педагогика институты—1934, ә инде 1994 елдан—Казан дәүләт педагогика университеты.

Ачылган елында институтка 53 студент кабул ителә. Укырга чыгышлары ягыннан төрле катлам, төрле чин вәкилләре, ләкин егетләр генә кабул ителә. Имтиханнардан тыш катгый бер таләп—укучы югары әхлаклы, ышанычлы кеше булырга тиеш.

Институтны тәмамлап чыгучы яшь мөгаллимнәр, үзләре укыган ун фәннән: рус теле, математика, физика һәм табигать белеме, тарих һәм география, педагогика, матур язу, рәсем, һ. б.—теләсә кайсысын укыту хокукы ала. Соңрак, мәҗбүри булмаган хәлдә чит тел һәм хезмәт укытыла башлый. Тәрбия нигезләре, дидактика, педагогика тарихы фәннәреннән чыгарылыш имтиханнары була.

Казан укытучылар институты 42 ел эчендә 900 дән артык яхшы әзерлекле укытучылар чыгара.

Әйткәнемчә, университетның берничә тапкыр исеме алмаштырылса да, ул һәр дәвердә педагогик белемнең дөньякүләм югары үрнәкләрен бирү өчен тырыша. Мөгаллимнәре Казан дәүләт университетында, Рәсәй югары уку йортларында, Франция, Италия, Австрия кебек илләрдә белемнәрен күтәрәләр. Төрле елларда төрле җирләрдән танылган галимнәр эшкә чакырыла. Күбесе үз эшенә фанатикларча бирелгән, чын мәгънәсендәге галимнәр, фән кешеләре, теге яки бу өлкәне тирәнтен өйрәнеп зур хезмәт салган кешеләр. Ул фидакарь җаннарның күбесенең университет тарихына алтын хәрефләр белән язылырга тулы хакы бар. Алар, күренекле академиклар: В. А. Алоратский, Е. А. Арбузов, Б. А. Арбузов, К. Ә. Вәлиев, Д. Г. Греков, Н. С. Державин, Е. А. Косминский, В. П. Мосолов, С. П. Обнорский, Е. В. Тарле; Россиянен төрле фән академияләре әгъзалары В. В. Богородицкий, Б. М.

Козырев, В. А. Кондаков, И. Е. Тамм, Н. Г. Чеботарев, М. М. Корбангалиев, М. А. Фазлуллин; атказанган фән эшлеклеләре М. И. Абдрахманов, М. И. Әлмөхәммәдов, В. В. Болгарский, Ж. Вәлиди, Н. И. Воробьев, Б. М. Гагаев, М. Х. Гайнуллин, М. З. Зәкиев, О. Д. Кормаев, А. П. Норден, Х. Ф. Сабиров, Г. С. Салихов, Х. Госман, Е. И. Устюжанин, Г. Ш. Шәрәф һ. б.

Кыскасы, Казан дәүләт педагогика университеты 125 ел дәвамында Идел буе, Урал, Себер төбәкләрендәге мәктәпләрне, училищеларны югары белемле укытучылар белән тәэмин итеп тора. Алай гына да түгел, монда укып чыккан кадрлар арасында меңләгән мәгариф отличниклары, атказанган укытучылар, күренекле галимнәр, язучылар, мәдәният әһелләре, дәүләт эшлеклеләре, хәрбиләр, данлыклы спортчылар бар. Университетның тарихи үткәне турында сөйләгәндә аларның исемнәрен шулай ук зур горурлык хисе белән телгә аласы килә. СССР Педагогика фәннәре академиясенең элеккеге президенты В. М. Хвостов, Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты, шагыйрь Муса Җәлил, Социалистик Хезмәт Геройлары С. З. Габдрахманова, Г. К. Гыйматдинов, СССРның халык укытучысы А. С. Сәләхов, СССРның халык артисты Г. А. Шамуков, язучылар Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Сибгат Хәким, Мөхәммәт Мәһдиев, һ. б.

*—Элек һәм хәзер. Моннан 125 ел элек ачылган укытучылар институты белән бүгенге көндәге педагогика университеты арасында җир белән күк аермасы. Шул аермалыкларның кайберләренә тукталыйк әле.*

—Хәзер Казан педагогика университеты Россиядәге иң зур уку йортларының берсе. Бүгенге көндә биредә (Яр Чаллы шәһәрендәге филиалда укучыларыбызны да кертеп), 10 меңнән артык студент укый. Алар 35 белгечлек буенча белем ала. Һәр елны моңсу көннәр кичерәбез. Биш ел буена балаларыбыз кебек кадерле кешеләребезгә әйләнгән меңләгән студентыбызны төрле тарафларга «очырабыз». Университет тормышы шуның белән мавыктыргыч та. Без дә әле генә хушлашкан яшьләребез урынына шунын кадәр үк егет һәм кыз кабул итәбез, тагын яшәрәбез, тагын яңарабыз. Инде аларның сәләтләрен ачарга, аларның талантларын үстерергә тырышабыз.



*Казан дәүләт педагогика университетының төп бинасы*

Бу җәһәттән, физик-тәрбия факультетын (деканы Ринат Абзалович Абзалов) әйтми китеп булмый. Бу факультетның уңышлары безнең университетка гына түгел, бөтен Татарстан республикасына шөһрәт китерә. Мәсәлән, исемнәре спорт тарихына мәңге җуелмаслык итеп язып куелган Олимпия чемпионнары, атказанган спорт мастерлары Наилә Гыйләҗева, Валентина Никонова, Ольга Данилова. Сидней шәһәрендә үткәрелгән Олимпия призеры Денис Капустин—безнең университетны тәмамлаучылар. Дөнья һәм Европа чемпионнары Р. Бакиев, Э. Баянов, В. Московских, Н. Фәсәхов, З. Зарипова, А. Плюшкин һ. б.—шулай ук бездә төрле елларда белем һәм әзерлек алдылар.

Дүрт ел рәттән бу факультетта укучылар «Студент язы» фестивалендә беренче урынга, шушы елның язында исә «Гран-При»га лаек булдылар.

Шулай ук соңгы биш елда педагогика университетының җыелма командасы Татарстан республикасы югары уку йортлары арасында үткәрелгән Спартакиадаларда җиңүче булды.

Бүгенге көн, бүгенге яшьләр өчен тагын бер гыйбрәтле мәсьәлә: факультетның тренерлары, спортчылары бөтен яшьләрне сәламәт яшәү рәвешенә чакырып, наркомания, эчүчелек, тәмәкегә каршы көрәшкә өндәп газета битләрендә мөрәҗәгать белән чыкты.

Югарыда саналган Спартакиадалармы, фестивальләр, төрле бәйрәмнәр,

беренче курсларга яки чыгарылыш кичәләренә багышланган кичәләрме, табигый ки, һәркайсы зур тәрбияви әһәмияткә ия. Шуна күрә, үзешчән сәнгать, драма театры, хореграфия, хор һәм башка коллективларның чыгышларына, алар арасындагы смотр-ярышларның һәммәсенә кирәкле чара итеп карыйбыз.

Сез элек һәм хәзер, дигән сорау куйдыгыз. Элек институт, «Волков йорты» дип аталган бер бинада ачылса, хәзер аның сигез уку бинасы, дүрт тулай торагы, ун спорт, уку, концерт заллары, миллионнан артык китабы булган китапханәсе, төрле лабораторияләре, типографиясе, «Яльчик» спорт сәламәтләндерү базасы һ. б. бар.

Бүгенге көндә университетта 11 факультет, 55 кафедра. Аларда 600 гә якын укытучы, галим эшли. Мөгаллимнәребезнең яртысыннан күбесенең фән белән шөгыльләнүе бик шатлыклы күренеш. 70 фән докторы, профессорыбыз бар. Югары квалификацияле укытучыларыбызның күбесе дәүләт бүләкләренә, мактаулы исемнәргә лаек булды. Төгәлрәк итеп әйтсәк, унөч укытучыбыз Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе, утыз сигезе Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең атказанган укытучысы, унөч хезмәттәшебез Татарстан Республикасының һәм Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе, алтысы Татарстан Республикасының мәдәнният хезмәткәре, дүртесе Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре, тагын дүртесе Татарстан Республикасының халык артисты исемен йөртә.

*—Рүзәл Габдуллаҗанович, Сез ирешелгәннәр белән чикләнеп, кул кушырып утыра торган җитәкче түгел. Туктаусыз—хәрәкәттә, туктаусыз уйда. Соңгы елларда гына да төрле белгечлекләр буенча яңа факультет, кафедралар ачып университетка бик күп яңалыклар өстәдегез. Елның елына уку-укыту, тәрбия планнарын баетып, формаларын үзгәртеп торасыз. Шулар хакында да берничә сүз әйтсәгез иде.*

—Үзгәрешләрне заман үзе таләп итә. 1990 елда, мәсәлән, милли мәктәпләрдә рус теле укыту кафедрасын ачтык. Ә бу еллар, үзегез беләсез, дәүләтебезнең ике теллелеккә күчкән, күпләп татар мәктәпләре, гимназияләр ачылган вакыт. Аларда эшләү өчен яхшы әзерлекле рус теле укытучылары кирәк. Бу эшне тиз арада тормышка ашыру безнең намус бурычы иде. Шулай итеп, ноябрь аенда рус теле кафедрасы кочагыннан мөстәкыйль язмышлы милли мәктәпләрдә рус теле укыту кафедрасы аерылып чыкты. Кафедра җитәкчесе итеп профессор Фирая Юнысовна Әхмәдуллина билгеләнде. Муеннан эшкә чумдылар. База мәктәпләре ачып, төрле тәҗрибәләр үткәреп, телне тиз өйрәнүнең әллә нинди серләрен табып, менә дигән уңышларга ирештеләр. Хәзер үзләре бөтен республика мәктәпләре өчен дәреслекләр, программалар, ярдәмлекләр төзеп, гөрләтеп эшләп яталар. Ун ел эчендә республикабыз һәм тирә-юнь төбәк мәктәпләре өчен 750 югары белемле педагог әзерләделәр.

Үзгәрешләрнең тагын берсе турында әйтик әле. Бервакыт шулай физика-математика факультеты студентлары мең ярымга җитте. Факультетта сиксән укытучы—күп бит инде. Уйлаштык, киңәштек тә 1994 елда физика һәм математика факультетлары итеп, икегә бүләргә карар кылдык. 1998 елда Татарстан тарихы кафедрасы аякка басты. Монысы инде күптән соралып торган дияр идем. Шушы ук елны психология кафедрасы ачылды. Аның канаты астында гамәли психология кафедрасы эш башлады. Көчле коллектив тупланды. Психология, педагогика, философия, инглиз теле, анатомия, кеше физиологиясе кебек фәннәрдән төпле белем бирү нигезләре булдырылды.

Педагогика һәм хокук факультеты да дөньяга яна аваз салучылар исемлегендә. Быелдан башлап юриспруденция белгечлеге буенча укытучылар әзерли башладык. Аларга тәртип бозучы яшүсмерләр арасында эшләү хокукы биреләчәк. Шушы берничә мисалдан гына да күренгәнчә, һәр яңалыкны заман үзе әйтеп, сорап тора. Без исә шуны үтәргә, тормыш кануннарына җавап бирергә генә тырышабыз.

Университетның укыту-тәрбия системасындагы яңалыкларыннан тагын шуны өстәп әйтергә мөмкин, соңгы елларда уку-укыту планына педагогик

осталык, музыкаль тәрбия нигезләре, үз-үзенне тоту әдәбе, сөйләм әдәбе, сәнгать әдәбе, риторика кебек дәресләр кертелде.

Тагын бер шатлыгым—милли мәктәпләрдә эшләү өчен музыка укытучылары әзерләү тулысынча җайга салынды.

*—1994 елда, шәхсән Сезнең зур тырышлыгыгыз белән, Казан педагогика институты Казан педагогика университеты дип үзгәртелде. Исем үзгәрү җисеменә дә, университетның эшчәнлегенә дә егәр өстәде. Бу бигрәк тә нәрсәләрдә чагыла?*

—Яңа статус—ул безнең педагогик кадрлар әзерләү өлкәсендәге хезмәтләребезнең Русия һәм Татарстан хөкүмәтләре тарафыннан танылуы. Илдәге иң өлкән, иң зур югары уку йортларының берсе буларак, безнең университет мәгариф һәм мәдәният өлкәсендә тирән белемле белгечләр әзерләү белән бергә, төрле юнәлешләрдә уңышлы эшләүче галимнәре белән дә дан тота бит. Исем үзгәрү, иң беренче чиратта, әнә шул фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнүчеләр өчен мәйданны киңәйтте. Яшь кандидатлар, фән докторлары төркеме үсеп чыкты. Бүгенге көндә 200 иптәшебез егерме белгечлек буенча фәнни-педагогик эш алып бара, ягъни докторантура, аспирантураларда укый. Эзләнүләр нәтиҗәсе буларак, университетыбыз галимнәренең ел саен дистәләгән монографияләре басыла. Мәктәп һәм югары уку йортлары өчен дәреслекләр, программалар, укыту-тәрбия ярдәмлекләре, төрле кулланмалар дөнья күрә. Димәк, сәләте булган, тирән белемгә омтылган, үз һөнәрен яраткан, ялкау булмаган кешегә яңа сулыш ачылды. Җиңел сызгансын дә рәхим итсен.

*—90 нчы еллардан башлап, университет бик күп чит ил югары уку йортлары белән элемтәдә. Бу аралашуларның файдасы нәрсәдә?*

—Безнең университет Америка, Англия, Германия, Франция, Төркия, Мисыр, Йәмән, Кытай, Япония һ. б. илләрнең югары уку йортлары белән бәйләнештә тора. Студентлар, аспирантлар, яшь мөгаллимнәр, галимнәр арасында эшлекле аралашу, бер-берсеннән өйрәнү, тәҗрибә уртаклашу хөкем сөрә. Аларның мөгаллимнәре безгә килеп эшли—үз телләрен укыта. Аспирантлары, студентлары килеп укый. Күпчелеге бездә үк кандидатлык диссертациясен яклап китә. Һәм, киресенчә, безнең студентларыбызның кайберләре үзләре өйрәнә торган телне шул илгә барып ныгыта. Аралашуның бер төре буларак, укытучыларыбыз төрле халыкара конференцияләрдә катнашалар. Инглиз, француз, немец һәм башка телләрдә чыгышлар ясап, төрле исем, дипломнар алып кайталар. Мәсәлән, узган җәйдә безнең делегация Парижда үткәрелгән X Бөтендөнья конгрессында катнашты.

Саный китсәң, чит телләр факультетының шатланып сөйләрлек эшләре байтак. Бүгенге көндә факультетның дәрәҗәсе югары. Анда укырга керергә теләүчеләрнең саны елдан-ел ишәя бара. Университетта укучы студентларыбызга ун чит тел өйрәнү мөмкинлеге тудырылган. Бу—гаять зур мәртәбә дияр идем.

Бездән бары бер генә теләк: укырга дип килгәннәр икән, укысыннар, бөтен сәләтләрен ачсыннар. Безнең тарафтан мөмкин булган шартлар тудырылган. Читтән килгәннәргә яшәү өчен ремонтланган, җиһазланган дүрт тулай торагыбыз бар. Мохтаҗларга урын җитә.

*—Тулай торак дигәннән, бу мәсьәләдә Сезнең исемгә гел мактау сүзләре генә ишетергә туры килә. Шәһәрдәге уку йортларының тулай торaклары арасында үткәрелгән конкурс-ярышларда, соңгы берничә ел дәвамында, сезнекеләр гел җиңеп чыгып, беренче урынны алдылар. Хәтта башка уку йортларында укучы студентларның ата-аналары балаларына тулай торакларыгыздан урын сорап Сезгә килә икән.*

—Тиешле тәрбиясе, әдәп-әхлак сыйфатлары булмаган кешегә югары белем бирүнең бер мәгънәсе дә юк. Укытучы һөнәрен сайлаучылар өчен бу бигрәк тә шулай. Укытучы иң тәрбияле, иң белемле кеше булырга тиеш. Чөнки ул кеше язмышы өчен һәм бик күп кеше язмышы өчен турыдан-туры җаваплы! Аларның хезмәт юлы XXI гасыр кешесен тәрбияләүгә бәйле булачак. Рухи бай, миһербанлы, чиста кешеләр үстерсеннәр. Ә моның өчен, иң беренче чиратта, үзләре матур күнелле булырга тиешләр. Укырга кабул

итеп алганбыз икән, адәм рәтле яшәүләрен тәэмин итү дә безнең бурыч, дип саныйм мин. Әни куенынннан, әти «йөгәненнән» чыгып киткән яшь-җилкенчәкнең яман шаукымнарга бирелүе бик тиз. Менә шуңа күрә вакыт-вакыт барлап тагын бер кат кузгатып алу—зыян итми. Әлегә шөкер, йөзгә кызыллык китергәннәре юк. Күбесе белән университетны тәмамлап киткәч тә элемтәләребезне өзмибез, дустанә мөгамәләдә, ярдәмләшеп яшибез.

*—Сезнең китапханәдә 1901 елда чыккан, «Казан укытучылар институтының егерме биш еллыгы» дип аталган бик кызыклы китап бар. Анда Институтка кайсы елны ничә кеше гариза биргән, ничәсе кабул ителгән; кайсы төбәк, кайсы губернадан килгән; кем баласы: дворянмы, мещанмы, крестьянмы, солдат яки укытучы улымы, тәмамлаучыларның кайсы кая эшкә киткән, хәтта үлсә кайчан вафат булган—һәммәсе теркәлгән. Әмма шушы исемлектә бер генә татар милләте вәкиле дә, бер генә хатын-кыз да юк. Хәзер исә унар меңләп исәпләнгән студентларның күбесе кызлар.*

*Соңгы вакытта балаларыбыз, гомумән, хатын-кыз тәрбиясенә күчеп бара шикелле. Күпчелек гаиләдә баланы ялгыз ана үстерә. Гаиләдән чыгып балалар бакчасына аяк басуга—хатын-кыз төркеме каршы ала. Мәктәпләргә килсәк, анда да күпчелекне хатын-кыз укытучылар тәшкил итә. Зур тормыш тәҗрибәсе туплаган педагог, үзегез дә әти кеше буларак, баланың бары тик хатын-кыз йогынтысында тәрбия алуына ничек карыйсыз?*

—Без бу мәсьәләдә дә уйланабыз. Соңгы елларда ачылган факультет, кафедраларга карап нәтиҗә чыгарсак, аларның мәгариф эшенә егетләрне тарту максатыннан чыгып та эшләнгәнлеге күренә. Авыл җирлегендә укыткан егетләрнең армия хезмәтенә алынмавы—шулай ук бу мәсьәләнең уңышлы хәл ителүенә бер этәреш. Тик мөгаллимнәрнең хезмәт хакы түбән булу—безнең бөтен тырышлыкны аяк астына сала да таптый.

«Ватан-Ана чакыра!» дәвере үтте. Акчасыз хезмәткә яшьләрнең ургылып килүен көтәргә кирәкми. Килмәгәннәре өчен гаепләргә дә ярамый. Әйткәнемчә, заман башка. Галим, мөгаллимнәрнең хезмәт хакы тиешле дәрәҗәгә күтәрелсә, мәгариф системасында, иманым камил, ир-егетләр бермә-бер артачак.

Ә балага, сүз дә юк, ир-ат тәрбиясе кирәк.

*—Рүзәл Габдуллаҗанович, безнең милләтнең иң авырткан җире—тел мәсьәләсе, дип әйтсәк тә ярый торгандыр. Сез инде Ана телебезгә искиткеч мәхәббәтле һәм хәзер дә бу мәсьәләдә янып яшәүче кеше буларак, университетта татар теле һәм әдәбиятын укытуның куелышы хакында әйтеп үтсәгез иде.*

—Бу факультетның тарихы да, абруе да зур. Ул хәзер татар филологиясе факультеты дип атала. Дөрес, баштагы елларда аның исеме икенчерәк иде. Хикмәте һәм бу факультетның зур бәхете шунда, бирегә гомер-гомергә үз хезмәтенә җаны-тәне белән бирелгән, туган телебезне чын мәгънәсендә яраткан кешеләр эшләгән. Алар республикабызга гына түгел, бөтен төрки-татар дөньясына мәгълүм шәхесләр: Латыйф Җәләй, Шиһап Рамазанов, Мөхетдин Корбангалиев, Мирфатыйх Зәкиев, Мөхәммәт Гайнуллин, Хатыйп Госман, Абдулла Сайганов, Хәсән Хәйри, Гали Халит, Хәмит Ярми, Якуб Агишев, Гази Кашшаф, Фатыйма Вәлиева, Мәдинә Җәләлова, Зөһрә Вәлиуллина һ. б.

Мәсәлән, татар әдәбиятының алтын баганаларын тәшкил итүче, бүген дә поэзия мәйданында ат уйнатучы, төрле елларда безнең университетны тәмамлаган язучы, шагыйрьләр, журналистларыбызны нәкъ менә шушы галимнәребезнең дә хезмәт, иҗат җимеше дип әйтеп булмыймыни? Кабатлансам да, безнең университет чыгарган каләм осталарын, татар халкының талантлы улларын һәм кызларын барысын бергә санайсым килә: Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй, Һади Такташ, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур, Ибраһим Салахов, Баян Гыйззәт, Мөхәммәт Мәһдиев, Әминә Бикчәнтәева, Гариф Гобәй, Илдар Юзеев, Ренат Харис, Энже Мөэминова, Гөлшат Зәйнашева, Лена Шагыйрьҗан, Зиннур Хөснияр һ. б. Татарстан Республикасының дәүләт бүләге лауреаты, тарихчы, шулай ук язу куәсе зур булган Равил Фәхретдинов, филологлар Г. Әхәтов, С. Поварисовлар да биредә укыган.

Кыскасы, әлеге факультет, инде җитмеш елдан артык, республикабызны һәм татарлар яшәгән тирә-юнь төбәкләрне югары әзерлекле татар теле һәм

әдәбияты укытучылары белән тәэмин итеп тора. 1995 елга кадәр факультетта татар теле һәм әдәбияты; рус теле һәм әдәбияты, татар теле, әдәбияты һәм тарих; татар теле, әдәбияты һәм Татарстан тарихы буенча белгечләр әзерләнде. Күргәнебезчә, факультет республикабыз мәктәпләрендә кадрлар мәсьәләсен хәл итүдә бөтен көчен куйды.

1995 елдан башлап биредә татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле укытучылары хәзерләнә башлады. Илдә барган демократик үзгәрешләрнең мәгариф һәм мәдәният тормышында чагылышы буларак, бу гамәл дә республика, халык мәнфәгатьләрен күздә тотып эшләнде. Ачыклабрак әйтсәк, чит телле аудиторияләргә татар телен өйрәтү зарурлыгы килеп туды. Мәсьәләнең икенче ягы—чит тел укытучыларының бигрәк тә авыл мәктәпләрендә җитешмәве искә алынды.

Факультетны бүгенге көндә безнең университетта 1965 алдан бирле эшләүче, үз эшенең остасы, филология фәннәре докторы, профессор Клара ханым Зиннәтуллина җитәкли. Монлый шәхес кул астына, табигый ки, үз эшенә бирелгән чын педагоглар гына туплана ала.

Факультетның әйдәп баручы укытучылары бик күп житди хезмәтләрнең авторлары. Факультетта соңгы елларда ике галим Татарстан республикасының фән һәм техника буенча дәүләт бүләгенә лаек булдылар. Ике хезмәттәшебез: республикабызның Каюм Насыйри исемендәге бүләген алды.

Менә шушындый зур көчкә ия факультетыбыз «Татарстан республикасы халыклары телләре турында»гы законны тормышка ашыру өстендә эшли дә инде.

*—Рүзәл Габдуллаҗанович, әңгәмәбезнең башында Сез университетның горурлыгы булган, зур хезмәт җимешләре калдырган, гыйльми дөньяда исемнәре һәрвакыт хөрмәт белән телгә алына торган укытучы галимнәрне санадыгыз. Ә менә шул исемлекне дәвам итәрлек, университетның, әйтик, 150, 200 еллыгында да алтын хәрефләр белән язылырлык хезмәт авторлары бармы?*

—Бу сорауга төгәл җавапны тарих үзе бирәчәк. Тарихның җиз иләге кемнәрне калдыра—исемлекне шулар дәвам итәр.

Гомумән алганда, фәнни-педагогик кадрлар безнең төп байлыгыбыз. Алар университетның гасырлар буе салынган гореф-гадәтләрен ныгытып, яңартып алга баралар. Халкыбызның рухи байлыгын, акыл хәзинәсен арттырырлык, аксакалларыбызның эшен дәвам итәрлек кыйммәтле мирас калдыралар. Университетның гына түгел, Татарстаныбызның данын еракка алып чыгалар.

Бала тәрбияләү, кешене Кеше итеп балигълыкка чыгару—бервакытта да җиңел эш исәпләнмәгән. Әмма без шушы авыр да, җаваплы да, изге дә эшкә алынганбыз икән, бөтен көчебезне, намус һәм вөҗдан егәребезне салып, Туган җирен ярата һәм саклый белгән, Ана теленең кыйммәтен бәяли алган, белеме—тирән, тәрбиясе—күркәм, иманы—нык, рухи дөньясы бай булган егет һәм кызлар үстерергә бурычлыбыз.



## Миргазиян Юныс

# «ЧИТ ҖИРЛӘРГӘ ЙӨРЕП ГЫЙБРӘТ АЛ...»

КҮП ТАПКЫРЛАР күрергә туры килде миңа Мисыр иленең шәһәрләрен. Хәтердә ки: Искәндәрия шәһәрен аркылыга-буйга гизеп, хисапсыз күп гүзәл бакчаларын һәм сарайларын карап чыкканым булды. Сүәеш каналы аша үткәндә көрванга җыелган корабларның үтүен көтеп, Порт-Сәгыйтьтә чиратта торасың... Ул портның үзендә йөк төягән чакларда, әзгә генә кереп чыккан мәлләр дә булды. Шуңа өстәп, Исмәгыйлия, Тәүфыйкъ, Сүәеш, Күсәер, Думьят, Мерса-Матрух портлары хәтергә килә... Мисыр илен яратмыйлар иде совет диңгезчеләре. Беренчедән, урыста мөселман динен тотучыларга һәм кара тутлы битле кешеләргә карата хаста-хорафат—ксенофобия яши. Шәхесләрдә, фикер ияләрендә, чын зыялыларда түгел, гавамны тәшкил иткән кара халыкта. Чү! «Гавам», «кара халык» дип әйттем дә уйга калдым. Бик катлаулы аның нинди бөндәләрдән торганлыгын аңлату. Ә инде бу катламның рәсми коткы-пропагандага бик тиз җайлашуын исбат итүе бер дә катлаулы түгел. Бу мәсьәләнең асылында тамак гаме ята. Башка мөмкинлек булмагач, шулай яшәүгә күнегелгән.

Яшерә алмыйм, диңгезчелекнең беренче елларында гарәби мөселман дөньясына мин дә өлкән абзыкайлар күзе белән карап йөргәнмендер. Дөрес, балачактан башлап, чәчемне кырып алып солдатлыкка алып киткәнгә кадәр мин гаиләмдә «Йосыф китабы» моңында, әниемнең көндәлек намазы, әтиемнең бәйрәм намазлары тәэсирендә яшәдем. Менә шушы канга һәм күзәнәкләргә сеңгән шифа миңа үз кыйбламәслегемне саклап калырга мөмкинлек биргәндер, күрәсең.

Диңгез порты тирәсендә шытып үскән шәһәрләрдә, нинди генә кыйтгада, нинди генә илдә булуларына карамастан, даими уртаклык бар. Баштарак мин моны аңлап җиткермәгән идем әле. Әйтик, гарәпләрнең «әле яңа гына агач башыннан төшеп, җирдә яши башлаган маймыл табигатле, коерыклы» булуларына ышанып бетмәсәм дә, ул чакта карагруһ (ксенофобик) дәлилне инкяр итәрлек күзәтүләр, фактлар тупланмаган иде минем җанда. Бер мәлне без Мисырга корал

ташыдык. Чимал, товар ташу белән корал ташуның аермасы шуннан гыйбарәт иде: корал төяп килгән корабларны хәрбиләр каршы алалар. Йөк бушату, йөк төяту эшләре белән җитәкчелек итү дә алар кулында. Шуңа өстәп әйтим, алар абруйлырак, баерак; корабның экипажына ярдәм итү, аның гозерләрен үтәүдә дә хәрбиләр сәүдәгәрләрдән юмартрак иделәр. Корал төяп килгән чакларда шәһәрдә йөрергә, Мисырның башкаласы Каһирәгә барырга хәрбиләр безгә автобус бирәләр. Гади диңгезче тарихи һәйкәлләрне, сәнгать шедеврларын, аның үз теле белән әйткәндә, «в гробу видел». Беренче класслы матроска (эйбл боудид) 110 сум, икенче класслыга 95 сум һәм чит илләрдә йөргәндә шул акчаның 3,5 процентын валютага алыштырып түлиләр иде. Матрослар йөк бушатканда, чит ил вәкиле белән берлектә, трюмнан чыгарылып портка бушаткан товарны санап торалар. Шул чакта чит ил вәкиле еш кына матросның аена (күп илләрдә атнага һәм елга) күпме эш хакы алганлыгын сорый торган иде. Мескен матрос визасын ачтырыр өчен андый мәгълүматне бирмәм дип ант итеп, антын имзасы белән беркеткәнен дә белә,—әмма адәм баласы нәрсә әйтсәң дә бары тик кеше генә бит,—ихтыярсыз әйтеп ташлыйлар иде бахырлар һәм үзе белән товар санаучы (диңгезчеләр телендә—«тальман») чит ил кешесен һуштан язарга мәҗбүр итәләр иде. «Бер көнгә шулай түлиләрме?»—дип сорыйлар иде чит ил кешеләре ышана алмыйча. Тукта әле, мин бит Мисырга йөрү турында язарга керешкән идем ләбаса...

Корал төяп Искәндәрия портына килгән саен без, автобуска утырып, Каһирәгә бара идек. Мескен гади диңгезче Мисырның башкаласында чүпрәк-чапрак Искәндәриядәгедән арзанрактыр дип ышанып утыра иде автобуска. Аз акчага әйбер алу чиктән тыш катлаулы һәм газаплы эш бит ул. Каһирәдә әйбер кыйммәтрәк икәнлеген күрү белән диңгезчеләр тизрәк корабка кайту ягын карыйлар иде. Ә мин инде аларны алдарга шактый шомарып беткән идем. Әйтик, Италия портларында, Неапольда яки Венециядә торганда, мәсәлән, исәң-акылың китәрлек музейларга алып барганда, бай экспонатлары арасына «җим итеп» куелган эротика, гыйффәт поясы белән ымсындырам. Каһирәнең Милли музеена мариманнарны мәнә мондыйрак сүзләр белән кодалыйм: «Беләсезме, егетләр, фиргавеннәрнең арба көпчәкләре алтыннан, ә бармакларына кигән йөзекләре тимердән ясалган. Кайчандыр шундый чүчмәкләр яшәгән бу җирдә»,—дим. Һәм мондый «җимне» дә йоталар иде.

Укучы диңгезчеләрне тоташ шундыйлардан торган икән дип уйлый күрмәсен тагын. Мариманнар арасында чын әдәбиятны , чын сәнгатьне халтурадан аера белүчеләр процент ягыннан «җирдә яшәүчеләрдән» күбрәк тә булгандыр әле.

1993 елны мин Мисырга һәм Төркиягә сәяхәт кылган язучылар төркеменә эләктем. Зур авырлык белән, билгеле. Ике тапкыр исемлектән төшеп калганнан соң. Мәскәү язучылары оешмасын җитәкләүче якташым Вячеслав Шугаев ярдәмендә (авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең). Мәнә шул чакта мин Мисыр гарәпләре тормыш-көнкүрешенә дә, Борынгы Мисыр сәнгатенә дә әдиплек позициясеннән карый алдым шикелле.

* * *

МОҢА КАДӘР мин СССР язучыларын корылтайларда, төрле конференция вакытларында, иҗат йортларында гына күзәткәнем бар иде. Ниһаять, мин мәнә аларны көндәлек ыгы-зыгыда, «совоклык» тәрбиясе биләвеннән арына алмыйча чит илләрдә йөргәннәрдә күрәм. Язучыларга бу төркемгә эләгү чиктән тыш катлаулы булса да, безнең группаның яртысы диярлек союз түрәләренең кода-кодачалары, әшнәләре, мәҗлестәшләре иде. Без бит әле һаман өлкән абзыкайлар милләтеннән булган язучыны, кем булуына карамастан, үзебездән, татар әдипләреннән өстенрәк куюдан ни кадәр тырышсак та арына алмыйбыз. Әмма татар язучыларының бер бәхәссез өстенлекләре барлыгын да аңладым мин

шул турйөрүдә: без өлкән абзыкайларыбыздан тыйнаграк та, әдиплерәк тә икәнбез. Арабызда паханнар, гомер буе «халява» эзләп йөрүчеләр булуына карамастан. Дөрес, урысларның да барысын да шаталак дисәк зур ялгышлык булыр иде. Мәсәлән, миңа Борис Екимовның үзен-үзе ничек тотуы ошады. Башка язучылар әле йокы симертәләр. Ә ул таң белән чыгып китә дә гарәп дөньясының уяныш хәрәкәтке килә башлавын күзәтеп йөри. Ят гореф-гадәткә юлыкканда чиктән тыш сак, белгәнрәк кешеләр белән киңәшеп кенә хәрәкәт итә. Язучы-герой, беренче космонавтларга сабак биргән яһүд Марк Галлай да шулайрак. Ул чакта гарәпләр белән яһүдләр арасы чиктән тыш киеренке иде. Ул киеренкелек әле һаман да асылда сүреле, йомшара алмый. Шуңа карамастан, күпме күзәтеп тә мин шул мөхтәрәм язучының гарәпләргә карата бер генә кырын каравын да сизмәдем. Ә бит совет язучыларыннан гарәпләрне мыскыллаучылар, үзләреннән тозлы кәбестә һәм көмешкә исе укшыткыч дәрәҗәдә аңкып торуына карамастан, шәркыйлыкны, мөселманлыкны мыскыл итүчеләр аяк атлаган саен диярлек очрап торды.

Нил ярына бәйләп куелган кораб эченә урнашкан «Гомәр Хәйям» дигән төнге клубта төн уйнатып биюне карап, эротик җырларны тыңлап утырабыз шулай. «Наш современник» журналының әдәбият бүлеге мөдире Александр Сегень өстәл астына качырып чөмергән аракы парлары белән сөремләнгәннән соң кычкырып җибәрде: «Урыс кешесе кайда гына булмасын, нилэр генә күрмәсен, катгый рәвештә «Боже, царя храни» җырын җырларга тиеш». Һәм урыс патриоты абынасөртенә җырны акыра башлады. Сегеньга бүгенге көндә Горький исемендәге әдәбият институтының ректоры (минем сабакташым) Сергей Есин, Константин Ковалев һәм тагын берничә патриот кушылды. Гарәпләр бу хәйванлыкны күрмәделәр дә, ишетмәделәр дә шикелле. Исереклэр җырлап бетергәч, концерт дәвам итте.

* * *

МИСЫР пирамидалары, Борынгы Мисыр сәнгате турында язылган китапларны бергә җыеп өйсәң, тагын бер пирамида хасил булыр иде, мөгаен. Шуңа күрә, мин яңа сүз, яңа фикер әйтә алырмын дип өметләнмим. Әмма бары тик шуны искәртәсем килә: без, татарлар, нигә Мисыр чынбарлыгын, аның культурасын, рухиятен башка халыклардан, бигрәк тә насарилардан, үзгәрәк кабул итәбез, икенче төрлерәк аңлыйбыз соң?! Минем менә шушы мәсьәләне ачыклыйсым килә. Көчем җитәрме, юкмы—әйтә алмыйм...

Мисыр җирендә йөрүче күп төрле туристлар төркемендә аңбелемгә омтылучылар саны, Европа туристлары белән чагыштырганда, күбрәк икәнлеген без Марк Галлай белән фикер алышканда ачыкладык. Димәк, турист халкын Европаның көндәлек тормышы, аның яшәү шартларының шактый югары сыйфатлы булуы ымсындырып чакырса, гарәп илләрен күрергә теләүчеләрне күбрәк тарихи һәйкәлләр, урта гасыр культурасы һәм шәрекъ экзотикасы кызыксындыра. Мәсәлән, Мисыр пирамидаларын караудан туеп булмый шикелле. Беренчедән, алар тетрәндерәләр, ерак гасырлар, киләчәк кеше язмышы һәм адәм баласының сарыф ителгән көч-куәте турында тирәнрәк, тәэсирлерәк уйланырга мәҗбүр итәләр. Шушы илаһи корылмалар белән Борынгы грек галимнәре, Геродотлар чорында ук башланып киткән кызыксыну әле һаман да булса дәвам итә. (Тамак ялы, бигрәк тә власть гаме белән яшәүчеләр турында сүз бармый әлбәттә.) Адәм баласы сәнгать әсәрләре янында үзенең яшәеше, кешелек вазифасының асылы турында кыбырсый башлый. Күп очракта аңлап та бетерә алмый ул үзенең уйлануларының төп сәбәбен, чөнки бу процесс күңел түрендә акылга да, тормыш кагыйдәләренә дә, хәтта ихтыярның үзенә дә буйсынмыйча, кагылмыйча хәрәкәткә килә. Мондый тойгыларның нилектән уянуын, бәлки, психофизиология кагыйдәләренә

таянып кына аңлатырга була torгандыр? Гадиләштереп әйткәндә, без көзгедән үзебезнең тышкы кыяфәтебезне ничек күрә алсак, чын сәнгать әсәрләрен караганда да күңел тирәнлегендә пыскып яткан кичерешләребезне әнә шулай тоя алабыз.

* * *

БУ СҮЗНЕ кабатлап торуның кирәге дә юктыр, бәлкем. Әмма, әйтергә мәҗбүрмен: татар зыялылары өчен бүгенге көндә иң мөһим, иң мотлак мәсьәлә—рухи ирек яулау. Дүрт ярым гасыр җаныбызны таптап торган дагалы итек астыннан чыгып, имгәнүләрдән арыну, дәвалану, үз мохитыбызны табып, үз һавабызны сулап, туган туфракны аяк белән генә түгел җан белән дә тоеп яшәү—бу безнең асыл кыйблабыз.

Казаныбызның Милли мәдәни үзәгендә үткәрелгән күргәзмәләрне зур кызыксыну белән карап йөрим. Татар рәссамнәренең әсәрләрендә Пикассоның, Шагалның, француз импрессионистларының, тагын әллә кемнәренең, әллә нинди юнәлешләрнең йогынтысын күрергә була. Татар сәнгатендә эзләнү чоры бара. Куркытмый мине яшь рәссамнәрнең урыс сәнгате золымы аша атлап чыгып, Европада эзләнеп йөрүләре. Чын талант, ә инде даһи турында сүз дә бармый, кемнән генә үрнәк алып эшләмәсен, кемне генә күчереп ясамасын, җитлеккәннән соң барыбер үз юлын, үз иҗатын табачак. Әдәбиятта да, сәнгаттә дә, гомумән, рухият өлкәсендә без бары тик бер нәрсәдән куркырга тиешбез. Хакимият утырткан җитәкчелеккә тулысынча буйсынып, ул нәрсә кушса, шуны эшләп, ул нинди таләп куйса, шуны кабул итеп «кара алагайлыкны» дәвам итүдән. Рухи азатлык яртылаш кына, хәтта туксан тугыз процентлы гына була алмый. Ул нәкъ әхлак кануны шикелле, йә бар, яисә юк. Бала бит ана карынында яралганнан соң тулысынча туа. Башта аягы, аннан соң кулы, бераздан соң башы «туган» бала турында кемнең ишеткәне бар? Рухи азатлык та, минемчә, нәкъ шулай туа. Туып аякка баскач, бигрәк тә тәпи йөри башлагач, без, татар зыялылары, империя казематында яшәвебезгә карамастан, үз һавабыздан сулыш алып, бер-беребезгә комачаулык китермичә, сынык өчен көрәшмичә яши башлаячакбыз. Империя шартларында адәм



*Мисырның уйга чумган сфинкслары...*

баласыннан чиновник һәм солдат тәрбиялиләр. Бары тик чиновник һәм солдат кирәк Мәскәүгә. Һәм шушы кирәклек шулкадәр көчле ки, солдат һәм чиновник булырга теләмәүчеләр властьның иң каты дошманы. Чын художник, хәтта җаны-тәне белән тырышса да, солдат та, чиновник та була алмый. Чөнки Аллаһы Тәгалә бу һөнәрне, рәссамлык вазифасын ирекле итеп яраткан. Һәм иҗатның җитлеккән җимешләрен бары тик ирекләгә генә бирә.

* * *

МИСЫР СӘНГАТЕН өйрәнүче галимнәрнең күпчелеге диярлек пирамидалар, андагы барлык корылмалар, шул исәптән хәтта сыннар да чиксез зур күләм тәэсирендә адәм баласын шомландыра, куркыта дип исбатлыйлар. Белмим, бәлки чыннан да шулайдыр? Пирамидалар, фиргавен сыннары, аларның дүрбәләре берничә мең елга сузылган тәрәккыят тарихында иң зур, иң күләмле корылма һәм сәнгать әсәрләре булып кала килделәр. Фиргавеннәрнең үзләрен Алла итеп тоюлары, Алла булып кыланулары да, Мисыр җирендә яшәүче XXI гасыр кешесе өчен, кирәксез тоелган һәйкәлләрне салу өчен дистәләгән буынның йөз меңләгән вәкилләрен корбан итүләре дә дөрес бит. Борынгы Мисыр һәйкәлләрен караганда, мин аларны тиранлыкны мәңгеләштерү өчен куелган һәйкәлләр, Ленин, Сталин, Наполеон, Мао, Франко, Саддам Хөсәен, Чаушеску шикеллеләрнең сыннары, алардан калган корылмалар белән чагыштырып йөрдем. Фиргавеннәр күп гасырлар буе династик фиргавен токымыннан яралганнар, халыктан еракта, яшерен, Аллаларча яшәп килгәннәр. Аларга хәтта гади кызга өйләнергә дә рөхсәт ителмәгән. Алар үзләренең сеңелләренә өйләнә торган булганнар. Чыннан да фиргавен сыннарыннан өстенлек һәм власть көче генә түгел, бөеклек һәм чиктән тыш тәэсирле зыялылык (благородство), олпатлык бөркелеп торган. Телисеңме-юкмы, син фиргавеннең үзеңнән өстен икәнлеген һәм шул өстенлекнең асылында хакимият дилбегәсе генә түгел, рухи яктан да, нәсел, кан сыйфаты буенча да бу шәхеснең синнән өстен икәнлегенә инанырга мәҗбүрсең. Шунысы әһәмиятле, фиргавеннең өстенлеген тою мине түбәнсетми, киресенчә, минем дә адәм затыннан булуымны, әгәр туган җирем империя коллыгына юлыгып, халкым колониаль шартларда яшәмәгән булса, бездә дә фиргавеннәргә тиң шәхеслек масштабы булуы мөмкин икәнлеген аңлый башлыйсың.

Чыннан да, Борынгы Мисыр сәнгате мең елларга сузылган камилләшүендә фиргавенне фиргавен, игенчене игенче, колны кол итеп сурәтләргә ирешә алган. Сурәтләү сыйфаты шундый дәрәҗәдә, әгәр син Борынгы Мисыр сәнгатькяре ясаган колны гына очратасың икән, аның кол кулымы, әллә фиргавеннекеме икәнлеген шунда ук аера аласың. Мине иң нык тетрәндергәне шул булды. Борынгы Мисыр коллары да безнең шикелле туганнан алып үлгәнче гел буйсынып, гел боерык үтәп, туктаусыз теге өстәге (аларда—фиргавен, бездә—Мәскәү) хакими аяусыз көчтән куркып яшәгәннәр. Алар да куркып яшәүләрен аңламыйча, бары тик күңелләре, күзәнәкләре белән хокуксызлыкларын тоеп көн күргәннәр булса кирәк? Пирамидалар күтәргән, таштан сыннар юнган Борынгы Мисыр колларының мирасына озак карап йөри торгач, аларның күз карашларындагы өметнең, киләчәккә инануның бездәгедән көчлерәк, ышанычлырак икәнлеген ачык тойгандай булдым мин. Бәлки аларга да озакламый коммунизмда яши башларсыз, сез бүгенгелек өчен түгел, шул коммунизмдагы зур, тоташ бәхет өчен яшисез дип ышандыра алганнардыр? Һәм мисыр колларының коммунизмы безнекеннән якынрак, ышанычлырак булгандыр? Ниһаять, шушы турыда уйлап йөри торгач, мин төшендем: кол буларак, борынгы мисырлылар коммунизм уйдырмасына түгел, үлгәч фиргавеннәр шикелле җәннәт рәхәтлегендә яшәячәкләренә инанып йөргәннәр булса кирәк. Шул инану сурәтләнеп калган колларның кыяфәтендә. Безнең коллык башка шартларда тормышка ашырылып торды. Безне диннән биздерделәр. Динсез калгач, өметсезлек шул кадәр көчәйде ки, бу хәл түзә алмас дәрәҗәгә җитте. Һәм

нишләдек соң без? Күпчелек котылу чарасын аракыдан тапты. Башкача ничек аңлатырга бүгенге көндәге глобаль сәрхүшлекне?

Беләм, минем бу фикерем белән килешүчеләр күп булмас. Безне бит иректән генә түгел, ирек турында хыялланудан, нигә ирексез икәнлегебез турында уйланудан да биздерделәр. Стереотипка буйсынып яшәү күпкә гадирәк һәм җиңелрәк. Башкалар нишли—син дә шулай эшлә. Башкалар нәрсә уйлый—син дә шуны уйла. Безгә алмашка яңа буын килә. Алар арасында да язучылар, сәнгатькярләр булырга тиеш. Һәм алар безнең ялгышлыкны кабатламаска тиешләр. Әгәр киләчәк буын каршындагы җаваплылык булмаса, бу турыда баш ватуның кирәге дә калмас иде...

* * *

ТАТАР ТҮРӘЛӘРЕ, Аллага шөкер, чит илләргә чыгып йөри башладылар. Әз булса да татар байлары да, аларга карап, безнең чорда җитмеш җиде йозакка бикләнгән чикне атлап чыккалыйлар. Нинди генә авыр шартларда, акчасызлыкта, хәерчелектә яшәмәсеннәр, килер бер көн, татар зыялылары да чит илләргә даими чыгып йөрерләр. Егерме беренче гасыр безне бүленеп яшәүдән коткарачак. Бүленеп яшәүнең сәбәбе шул, әлеге дә баягы, Мәскәүнең тоталитар хакимияте чит илләр белән безнең арага тимер пәрдә корып, чикне чәнечкеле тимерчыбык белән әйләндереп алуында иде. Хәзер инде тимер пәрдә дә юк, чик аша чыгу да җиңеләйде шикелле. Бу җиңеллек әле бары тик тышкы яктан гына. Безнең аңыбыздагы, тәрбиябездәге тимер пәрдә, хакимият, «совоклык» кануннары әле һаман исән. Шул күңелдәге богауларны бары тик югары сыйфатлы аң һәм чын белем генә юкка чыгара алыр дип ышанам мин...

Борынгы Мисыр сәнгате колбиләүчелек чорыннан калган. Шулар хакында уйланып Каһирәдә йөргәндә, игенче фәлләх хуҗалыкларын караганда үзләрен шактый тәкәббер тоткан юлдашларым Карнакка килгәч ничектер югалып калдылар. Гарәпләрне артта калган кара халык итеп тою җиңел иде. Үзеңне башкалардан өстен кую, гомумән,



*Карнак храмына илткән юл-аллея*

наданлыктан, карашың чикләнгән булудан барлыкка килә булса кирәк. Чыннан да без Борынгы Мисырның башкаласы Фева җиренә урнашкан гарәп авылы Карнакка янәшә безнең эрага кадәр XY—XIII гасырларда салынган (моннан 3500 ел элек) Амон-Ра алласының гыйбадәтханәсенә якынлашу белән ничектер бәләкәйләнеп калдык. Бер-берсенә якын утыртылган колонна-баганалар колачлап булмаслык юан, ә шул колонналарны үзара тоташтырып торучы антаблимент-матчалар калынлыгы һәм колонналарны каплаган сурәтле язу—иероглифләрнең тылсымы килеп өстәлгәч, чыннан да бу чорналышны ничек бәяләргә, аларның адәм баласы тарафыннан эшләнгәнлегенә ничек ышанырга белмичә катлаулы аптырашка юлыгасың. Техника ярдәмендә эшләнгән корылмаларга без инде күнеккәнбез. Машина һәр очракта кешедән көчлерәк. Ул тимердән ясалган. Аның җаны, тойгылары юк. Ул армый-талмый эш башкара ала, әгәр аның эшен адәм баласы җайга салып, юнәлтеп торса. Ә бит Карнактагы гыйбадәтханәне кул көче белән салганнар. Күпме көч, күпме осталык, күпме түземлек кирәк булгандыр бу кадәр зур, даһи эшне башкарыр өчен? Шушы күз белән дә колачлап булмаслык ташларны юнып эшкәрткәндә, аларны шомартканда һәм сурәтле язулар белән каплаганда кояш нәкъ бүгенгечә рәхимсез кыздырып торгандыр? Кайлардан, ничек ташыганнар бу ташларны? Мондый үзара пропорциональ тигезлекне саклап, ташларны урнаштыру өчен тригонометрия кагыйдәләрен белергә кирәк булгандыр? Без бүгенгедән узган заманнар ягына ераклашкан саен адәм баласының наданлыгы зурая бара дип ышанырга күнеккәнбез. Ә бит мондый корылманы башкарыр өчен математика, архитектура, сәнгать, эш оештыру, табигатьне аңлый белү гыйлемнәре генә дә әз булгандыр? Чыннан да Карнакта йөргәндә шомланып уйланырга, кешелек дөньясының гаҗәеп зур могҗизаларга сугарылган икәнлеген аңларга дәлилләр аяк атлаган саен очрап торды.

Тутмос Беренчегә куелган һәйкәл-обелиск монолит каты таштан юнып эшкәртелгән, нигезеннән алып очына кадәр иероглифләр белән капланган иде. Мисыр французларга, аннан соң инглизләргә буйсынып колониаль шартларда яшәгән чорда бу илдән күпме тарихи һәйкәлләрне ташып Европага кайтардылар. Бу обелиск ничектер исән сакланган. Ә бит Тутмос безнең эрага кадәр 1600 ел элек яшәгән...

Карап йөри торгач Амон-Ра гыйбадәтханәсеннән Нил елгасына төшә торган юлның ике ягына тезелеп сиңа таба карап утыручы сфинкслар янына килеп чыктык. Адәм баласы белән арслан-киекне берләштерүдән, шушы ике җан иясенең көч-гайрәтен, җегәрен, акылын, җитезлеген, матурлыгын бергә кушудан туган сфинкс сыны. Татар зыялылары Петербургка йөрергә яраталар. Нева яры буенда Мисырдан кайтартылган ике таш сфинксны хәтерлим мин. Ә монда, гыйбадәтханә белән елга арасында сфинкслар саны, ялгышмасам, кырыкка якын шикелле. Син шул таш могҗизаларга карап барасың, алар сине яннарыннан уздырып карап калалар. Шушы өч мең ел ярым кояш астында пальма агачлары каплаган гарәп авылы янындагы серле сыннар яныннан узганда, тетрәнмәгән кеше булдымы икән тарихта? Әйттем бит, теге төнге клубта бию карап, җыр тыңлап утырганда карагруһлыклары тышка бәреп чыккан язучылар турында? Карнакта йөргәндә, алар да ничектер югалып калган иделәр. Шундый бөек һәйкәлләр янында көндәлектәгечә сөйләшә башлыйсың да капылт кына тукталып каласың. Безнең сүзләр көнкүрешне каплаган вакчыллыклар, адәм баласының теңкәсен әрнетеп торучы мохтаҗлыкларны сурәтләргә көйләнгәннәр. Дөньяда көндәлектә сирәк очрый торган илаһи күренешләр дә бар икән. Шулар белән очрашканда син, ирексездән, мәңгелек турында уйланып куярга мәҗбүр буласың.

* * *

ӘЛЕ КҮПТӘН түгел генә Мәскәүнең символы саналган Останкино манарасы янды. Парижны хәтерләгәндә иң беренче булып искә төшүче Эйфель каланчасы, Нью-Йоркка килгән корабларны каршы алучы маяк—

Азатлык сыны бар. Аларны очратканда син чыннан да үзеңнең бик тә бәләкәй икәнлегеңне тоеп бер тын карап торасың. Борынгы Мисыр һәйкәлләре янында син үзеңне башкачарак тоясың. Һәйкәл куйган кешеләр юк кына түгел, аларның кем икәнлекләрен хәтерләве дә шактый читен. Мисырда хәзер гарәпләр, ислам динен тотучылар яши. Һәм, ни гаҗәп, шул мәҗүсиләрдән калган мирас сын, рәсем сәнгате белән шөгыльләнмәүче гарәпләрнең тормышына тулысынча сеңеп, берләшкән генә түгел, әкренләп аларныкына әверелгән. Борынгы мисырлылар үзләре дә бит Ибраһим пәйгамбәр токымына кушылып эреп беткәннәр. Бәлки шуңа күрә сыннарны, дөрбә диварларына ясаган сурәтләрне караганда мохиттагы яшәеш уянып киткәндәй була, шул җанлану өч мең ярым ел элек кайнаган тормышка барып тоташа да шул ерак гасырларны тоя башлыйсың.

Шушы мәкаләне язар алдыннан өемдәге китапларым арасыннан Борынгы Мисыр сәнгатенә багышланган хезмәтләрне эзләп карадым. Андый китаплар миндә юк булып чыкты. Хәтердә калганнарга гына таянып язу чиктән тыш катлаулы. Бер башлагач туктыйсы килми. Алар минем күңел күземә бик тирән җуелып калганнар, ялгышлык чыгудан курыксам да дәвам итәргә мәҗбүрмен...

Моннан бер ел элек Мәскәүнең Пушкин исемендәге музейда «Мәскәү-Берлин» дип аталган бер сәер күргәзмә булып алды. Сталин чорында иҗат ителгән сәнгать әсәрләрен Гитлер чорында тудырылган фашист сәнгатькярләренеке белән парлап күрсәтеләр. Совет чорында һәм бүгенге көн пропагандасында фашизмны бары тик сугыш һәм концлагерьлар аша гына яктырта килдек. Без бит әле шушы көнгә кадәр фашистларны ерткыч итеп, кем булуларына карамастан, Сталин боерыгын үтәүчеләрне гуманистлар итеп күрсәттек һәм совет гаскәрләренең бары тик бер сыйфатын, Европаны фашизмнан коткаруын гына аңлата алдык. Бу мәсьәләне сәнгать күпкә тирәнрәк һәм киңрәк яктырта ала икән. Янәшә торган рәсемнәрнең, бергә бастырып куйган сыннарның кайсысы фашистларныкы икәнлеген, кайсы советныкы булуын аерып алу шактый катлаулы, күп очракта мөмкин дә түгел иде. Нәкъ менә шушы канун бүгенге Чечня сугышын, андагы геноцидны аңларга ярдәмгә килә. Зур сәнгать ялганлый алмый. Сәнгатьне сәясәткә дә тоташтырып булмый, җир йөзендә адәм баласы сәнгать аша матурлыкның серен ачарга, гүзәллеккә сәнгать ярдәмендә ирешергә теләп яшәсә дә. Борынгы Мисыр сәнгате ярдәмендә шушы хакыйкатьне аңлый башлыйсың. Пирамидалар, фиргавен сыннары, аларның дөрба-йоклагычлары хакимлекнең көче, аның идарә итү мөмкинлегенең чиксезлеге турында киләчәк буыннарга сөйләргә тиеш булса да Борынгы Мисыр сәнгате сабыйларча самими, йомшак, назлы. Дөрес, мисыр сәнгатькярләре озак еллар, хәтта гасырлар буе камилләшкән катгый канунга буйсынып иҗат иткәннәр. Шул канунны тудыручылар чиктән тыш даһи, искиткеч таләпчән булганнар, күрәсең, шул кагыйдә чикләренең белемәләрендә иҗат итү рәссамнәрнең мөмкинлекләрен һич тә чикләмәгән, киресенчә, шедевр тудырырга ярдәм генә иткән. Художник канунны бозмаска, аның таләпләреннән читкә чыкмаска тырышып эшләгәнлеген тоясың Борынгы Мисыр сәнгатен күзәткәндә. Аның сурәтләү җегәре рәсемен, сынын җанландыруга, эчке рухи дөньяны тирәнрәк, киңрәк итеп тамашачыга ачып күрсәтергә җигелгән. Бер үк алым, шул үк ракурс кабатланып тора шикелле беренче карашка. Ә шул кабатлану сине кат-кат матурлыкка, адәм баласының рухи байлыгын мөмкин кадәр тулырак күрергә, аңларга өнди. Укучы хәтерли торгандыр, бүгенге көндә иң уңышлы эшләүче рәссамнәребезнең берсе Илдар Зариповның иҗатында ат рәсеме шактый еш кабатланып тора. Илдарның аты уйчан, кешелекле һәм бүгенге техника золымыннан интегеп яшәүчеләргә, кешелекслелек, шәфкатьлелек турында аңлата. Менә шушы алым Борынгы Мисыр сәнгатендә чиктән тыш колачлы, кеше кыяфәтенең нинди бөек көч икәнлеген тамашачыга җиткерерлек дәрәҗәдә чагылып калган.

Борынгы Мисыр сәнгатькярләренең әсәрләре арасында фиргавен хатыны Нефертити сыны шактый киң таралган. Аның сурәте рәсемнәрдә

гене түгел, түшкә тага торган брошь, муенса сыйфатында да еш очрый. Уйчан зур күзләр, хискә бирелүчеләрнекенә хас төз борын, матур ирен. Тарих Нефертитинең яшьли үлүе турында сөйли. Нишләп соң өч мең ел ярым вакыт үтүгә карамастан, аны онытмаганнар? Нефертити әле бүген дә матурлыкның югары сыйфатлы өлгесе булып тора ала. Бу хатынның тышкы кыяфәтендә хатын-кызның мәңге югалмас әчке сыйфатлары, наз, аналарча бала язмышын кайгырту, апалар-сеңелләр якынлыгы—шуларның барысын чагылдыра алган борынгы мисыр сынчысы. Рамзес Икенченең сыны безгә ирләрдәге асыл сыйфатларны җиткерә. Аның дүрт аргамак тарткан ике көпчәкле сугыш арбасына басып гексосларга каршы сугышуы, кайгыртучанлыгын, гайрәтен балкытып тәхеткә утыруы—боларның барысы да безнең чор рәссамнәре өчен үрнәк булуын югалтмый.

Безнең чорның сәнгать белеме Европада туып, урыс галимнәре аша, һаман саега, хәлсезләнә барып татарларга килеп җиткән. Без үзләштергән сәнгать гыйлеменең үзәгендә насарилык философиясенә сугарылган евроцентризм посып ята. Шул гыйлемне үзләштергән очракта без телибезме-юкмы, үзебезне кыргый күчмә халыклардан, сәнгатьсезлектән чыккан, бары тик урыс мирасын һәм Европа культурасын үзләштергән очракта гына кыргыйлыктан, томаналыктан арынуга ирешә алырлык татар-монгол варислары булып кала киләбез. Борынгы Мисыр культурасы озак-озын гасырларга сузылган Кояш алласы Атонга табынудан, шуңа җырланган гимн тәэсирендә барлыкка килгән, камилләшкән һәм тәрәккъыяттә очрамый торган зур уңышларга ирешкән. Безнең тәңречелек чорыбыз, Күк һәм Җир алласы Тәңрегә табынып яшәгән чорыбыз, әгәр тирән анализ ясап карасаң, борынгы мисырлыларның омтылышын, безнең ерак бабаларыбызның сәнгате аларның сәнгатен хәтерләтә генә түгел, шушы ике культура арасында тирән уртаклык та бар. Татар рәссамнәре, сәнгать белгечләребез Борынгы Мисыр сәнгатен өйрәнү ягына таба борылсыннар һәм шуның ярдәмендә үзебезнең мирасыбызга мөрәҗәгать итсеннәр иде. Аңлыйм, өндәү белән генә берни майтарып булмый. Уңышка ирешү өчен кемдер бу эшне башлап җибәрергә, үрнәк күрсәтергә тиештер? Үрнәк күрсәтүче безне озак көттермәс дип өметләнәм мин...



*Аменофис II нең олуг сарайлар биләмәсендә*

* * *

ӘЛЕГЕ СӘФӘР барышында гарәпләргә җирәнебрәк карап йөргән урыс совет язучылары Каһирәнең Милли дәүләт музеена кергәч, югалып калдылар. Дөрес, соңыннан монда тупланган сәнгать әсәрләренең гарәпләрнеке булмавы, музейның европалылар тарафыннан оештырылуы турындагы төрттерүләр үзеннән-үзе сүнде, тәэсир итә алмыйча югалды. Луврны, Прадоны, Эрмитажны һәм Метрополитен музейларын күргән кешегә дә Борынгы Мисыр сәнгатенә багышланган Каһирә музее чиктән тыш зур, хисапка буйсынмау дәрәҗәсендә бай иде. Этаждан этажга күчеп карап йөри торгач, тәмам югалып каласың. Хушбуй саклый торган савытлардан алып, хайван сыннары, фиргавеннәр, руханилар, төрле дәрәҗәдәге түрә-чиновниклар, коллар, осталар. Асылташлар җемелдәве, алтыннан койган, чүкеп эшләнгән экспонатларның иге-чиге юклыгы... Мәрмәр, гранит, нинди-дер безгә таныш булмаган төсле ярымасыл ташлар... Борынгы мисырлыларның көндәлек тормышы сәнгатькә әверелеп туплана, саклана килгән шушы зур, иркен залларга кереп урнашып, тамашачыларга яшәешнең чиктән тыш эчтәлекле, буыннарның алмашынып, яңарып торулары, бәхеткә омтылуның Атабыз Адәмнән алып шушы көнгә кадәр һәркем өчен дә уртак булуы, кеше гомере белән чагыштырганда байлыкның да, дан-шөһрәтнең дә, рәсми дәрәҗәнең дә бары тик көнкүреш эзләренә кунып кала торган тузанга тиң икәнлеген сөйли иде шул әлеге әйберләр. Әгәр Каһирә музеена тупланган экспонатларны бүлеп, сыннарны бер музейга, көнкүреш әсбапларын икенчегә һәм шулай бүлгәләп аера башласаң, дистәләгән яңа музейлар ясарга булыр иде. Һәм шунысы тетрәндерде мине. Илленче елларның уртасында беренче тапкыр Мисыр җиренә мин аяк басканда гарәп халкы үз җирендә нокъ безгә, татарларга охшап колониаль шартларда яши иде. Байлык килмешәк колонизаторлар кулында. Җирле халык, хәтта аның зыялылары да культурадан читләштерелгән. Күпме ләгънәт, никадәр янау, куркыту яңгырап торды гарәпләр үз җирләрендә табылган археологик хәзинәләрне чик аша чыгармый башлагач. Гомер әкрен генә уза тора. Гарәпләр хәзер үз җирләренә, үз хәзинәләренә хуҗа булып яши башладылар. Гарәп байларының, гарәп финансистларының исемнәре Европа һәм Америка байлары, финансистлары, хәтта гарәп галимнәренең исемнәре Европа галимнәренеке арасында күренүе табигый тоела башлады. Инглиз принцессасы Диананың үлеме бөтен планетаны тетрәндерде. Егерменче гасырның иң мәшһүр хатынының гарәп әл Файедны сайлавын без, мөселманнар, аңларга тырышырга тиеш идек. Элек колониаль бәйдә яшәгән халыклар ирекле тормыш кагыйдәләрен, аның шартларын үзләштерә башладылар. Гарәпләр артыннан дөнья аренасына төрекләр чыгып килә. Бары тик без, Рәсәй кулы астында яшәүче колониаль халыклар гына әле һаман богауларыбызны өзә алмыйча интегәбез.

Бала чактан алып, СССР таркалганчыга кадәр совет пропагандасы безгә колониализм тудырган коллыкка каршы көрәшүче милли азатлык хәрәкәте турында тукып торды. Милли азатлык көрәшчеләрен без үлеп ярата һәм яклый идек ул чорда. Соңгы елларда азатлык көрәше темасы юкка чыгуы ничектер сәер тоела. Нишләп язмыйлар бу турыда? Нигә Рәсәй совет чорындагы шикелле милли азатлык көрәшенә күтәрелгән халыкларны якламый башлады. Киресенчә, Рәсәй бөтен нәфрәтен, мәкерен милли азатлык көрәшен буугa, аны юкка чыгаруга юнәлтте. Милли азатлык көрәше хәзер урыс телендә «халыкара террористлык» дип атала. Җир йөзендәге иң кабахәт, иң куркыныч нәрсә хәзер яңа исем белән халыкларның ирекә, мөстәкыйльлеккә омтылуы санала башлады. Һәм нигә Рәсәй азатлык көрәшенә каршы чыкты? Көрәш мәйданы хәзер Рәсәйнең үз җире дип игълан ителгән колонияләрендә. Бүгенге көндә без тапкан малны салым итеп җыеп, армиясен коралландырырга, азатлыкка каршы соңгы сулышына чаклы сугышырга әзер әле күптән түгел генә халыкларны колониализмга каршы көрәшергә өндәүче дәүләт.

Мөстәкыйльлек көрәшен без, татарлар, сәясәт юлы белән башкарырга тырышып карадык. Рәсәй—казарма. Бу дәүләтнең һәр кешесе солдат. Татар да солдат. Рәсәй өчен кан коярга, соңгы сулышына кадәр буйсынырга күнеккән Рәсәй солдаты. Бу юл безне куркытты. Көрәшнең иң ышанычлысы—хезмәт, белем, сәнгать юлы. Дөрес, без әле бу өлкәдә эшлибез, тырышабыз шикелле. Ачыкларга кирәк, без әле һаман да туган илебезнең мөстәкыйльлеге өчен чәнчә бармак очы хәтле эш тә майтара алмыйбыз. Без эшчән, эш тулысынча Рәсәй империясен саклау, аны ныгыту, колониаль халыкларны бәйдә тоту өчен башкарыла. Бу эштән баш тарту мөмкин түгел, яки башкача очракта без ачтан үләчәкбез. Ачка үлүдән курку безне империя файдасына, татар халкының мөстәкыйльлегенә, үзебезнең газиз иркебезгә каршы бил бөгәргә мәҗбүр итә. Менә шушы хакыйкатьне Борынгы Мисыр сәнгате белән танышканнан соң баш миең белән генә түгел, тойгыларың, җаның белән аңлый башлыйсың. Борынгы Мисыр сәнгатендә колбиләү хакыйкате, антимеханизмы сурәтләнеп калган. Кабатлап әйтәм, Мисыр коллары бездән ирекләрәк тә, бәхетләрәк тә булганнар. Алар әле колбиләү хакыйкатеннән тыш башка хакыйкать барлыгын белмәгәннәр һәм үлгәннән соң нәкъ фиргавеннәрчә иректә, муллыкта бәхетле яши башлаячакларына тайпылгысыз иманып яшәгәннәр. Ә без, мескеннәр, җир йөзендә иректә, изелмичә, туган туфракларында үз дәүләтчелекләрендә яшәгән милләтләрне беләбез. Бу белү безнең нинди хәлдә булуыбызны ачыклый. Аннан соң безне динебездән яздырдылар, мең еллар камилләшеп килеп, канга сеңгән, күзәнәкләребезгә үтеп кергән гореф-гадәтләребезне, рухиятебезнең йорты, адәм баласы өчен баласыннан да газиз телкөебездән яздырдылар. Борынгы Мисыр сәнгате күзне ачып менә шушы хакыйкатьне аңларга ярдәм итә. Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт укыйм мине шушы бөек сәнгатькә тәкъдиремне китереп тоташтырганы өчен.

* * *

ПОЕЗДГА УТЫРЫП Искәндәриядән Каһирәгә кайтабыз. Без инде бүгенге Мисыр җирен Урта диңгез ярларыннан алып Судан чигенә, Нил елгасының югары агымына кадәр карап чыктык. Абу Сөмбел, Гиза, Карнак, Луксор һәм дистәләгән, йөзләгән башка вак шәһәрләрне, авылларны, чүлгә кара туфрак ташып, җир астыннан су чыгарып чүлне җәннәткә әверелдерүчеләрнең эшләрен күреп сокландык. Мисыр Израилгә каршы сугышта җиңелгәннән соң уйланырга, акыл ияләренең ми сырларын кыймылдатырга мәҗбүр булды. «Без сугышта җиңелдек. Бу инде бик аянычлы, бик тә мөсхәрәле нәрсә. Ә җиңгән булсак, нәрсә эшләр идек?» Менә шушы сорауга дөрес җавап табу хәл итә булса кирәк дәүләтнең язмышын. Икенче бөтендөнья сугышында җиңелгән илләрнең—Германия, Италия, Япониянең мөсхәрәле хәлгә юлыкканнан соң аз гына вакыт үтүгә дөньядагы иң алдынгы, иң бай һәм алга киткән илләр рәтенә барып басулары турында күп язылды. Әмма Рәсәй шартларында бу мәсьәләне ялгыш аңлыйлар һәм ялгыш яктырталар. Җиңелгәннән соң аларга башка юл калмады, бердәнбер дөрес гамәл—көне-төне икътисад өлкәсендә бил бөгү, кәҗә мае чыкканчы эшләү иде дип аңлатырга тырышалар урыс галимнәре. Эшкә тотынганчы бу илләрнең акыл ияләре сугыш турында, гомумән, яшәү турында уйлый башладылар, философиягә мөрәҗәгать иттеләр. һәм аңладылар. Җиңгән дәүләт көчәя, зурая, үзенә көчсезрәкләрне буйсындыра һәм... бар көчен корал ясауга, зур гаскәр тотуга, агрессив сәясәткә исраф итеп яши башлый. Менә шушы тайгак юл заманында галәмне дер селкетеп торган империяләрне юкка чыгарды. Еракларга, тарихның артта калган караңгылыкларына кереп китмичә генә, соңгы гасырның бөек державаларны нишләтүен күзәтик әле. Наполеон чорындагы француз империясе Бөтен Европаны, Мисырны тез чүктерде, Рәсәйгә килеп Мәскәүне алды. һәм нишләде? 1812 елда Париж тар-мар ителгән дәүләтләрнең гаскәрләре кулында иде инде. Икенче бөтендөнья сугышында Германия Европаны

тулысынча буйсындырды. Мәскәүгә килеп житте, Англиянең көлен күккә очыра язды. 1945 елда шул сугышны оештыручыларны Германиянең иң данлыклы каласы Нюрнбергта хөкемгә тарттылар. Икенче бөтендөнья сугышындагы жиңүе белән космосларны яңгыратып шапырынган Рәсәй империясенең таркала башлавын, Украинаны, Кавказ арты республикаларын, Урта Азияне югалтуын аңлатып торасы юктыр. Заманында басып алынган башка халыклар да Рәсәйдән котылырга юл эзлиләр. Чечнядәге кан коюның тукталырлык түгел икәнлеге дә, шушы зур дәүләтнең Көнбатышка түлисе бурычларының иге-чиге юклыгы да һәркемгә мәгълүм. Рәсәйнең сугышта жиңелгән чаклары да аз булмады. Заманында Мәскәүне Алтын Урда ханы Туктамыш та, Кырым ханы Миңлегәрәй дә алды. Рәсәй Кырым сугышы дип аталган сугышта һәм 1905 елда японнар тарафыннан мәсхәрәле рәвештә жиңелде. Менә шушы жиңелүләреннән соң нишләптер, Рәсәй, айнып китеп, илне баета торган, халкына кирәкле эш майтара башлый иде. Кырым сугышыннан соң Рәсәйдә крепостной правоны бетерәләр, Япон сугышыннан соң империянең икътисады кинәт алга китә, байлык туплана башлый. Беренче Чечен сугышы да нәкъ шундый шифалы тәэсир иткән булыр иде, әгәр икенче тапкыр сугыш башламаган булсалар.

Мисыр дәүләте, аның житәкчеләре сугышкан очракта кешечә яшәп булмаганлыкны аңладылар. Без, Рәсәйдән килгән язучылар, шушы илне карап йөргәндә, дәүләт тынычлык белән ләззәтләнеп яши иде. Искәндәриядән поезд белән Каһирәгә кайтабыз. Тимер юл Сүәеш каналы буйлап бара. Яр буенда ватык танклар, чалкан яткан туплар, пехота машиналары тутыга. Сугыш вакытында капчыкка ком тутырып ныгытма өйгәннәр. Капчыклар череп тишелгән, тишекләрдән ком ага. Тутыгып яткан сугыш коралларын Рәсәйдә хезмәт ияләренә түлисе акчага, безнең соңгы сыныгыбызны авызыбыздан тартып алып ясаганнар. Гамәл Абдел Насер чорында Мисыр социализм төзергә керешкән иде. Социализм төзибез дип игълан иткән илләргә СССР корал өләште. Бик күп корал өләшенде. Миллиард, триллион долларга тиң чыгым корал булып Жир шарының төрле төбәкләренә таралды ул чакта. Менә шул СССР тараткан корал бер илдә дә юньләп жиңә алмады, жиңгән очракта да халыкка бары тик зыян, бөлгенлек кенә китерде.

Канал яры буенда тутыгып яткан ватык танкларга карап карагруһ язучылар гарәпләрне сүгәләр:

—Сугышасы урынга, намаз вакыты житү белән, мөселман чуркалары коралларын ташлап намаз укып утырганнар, шуңа жиңелгәннәр алар,—дип аңлата «Наш современник»та эшләүче Александр Сегень.

—Шәригать кануны буенча, сугышта туган илне саклау намаз укудан изгерәк гамәл санала. Сугыш барганда, гарәпләр намаз укымаганнар,—дип аңлатып карыйм.

—Мөселман мөселманны яклый,—дип мине гаепләп ташладылар.

Гарәп офицерларының Рәсәйнең хәрби академияләрендә укып белем алулары, шул белемгә таянып сугышулары турында әйтмим, яшерәм. Урыс белән генә түгел, урыс армиясендә хезмәт итүче татар белән дә Рәсәй һәр сугышта сан ягыннан дошманнан ун-егерме тапкыр күбрәк булган очракта гына жиңә алуы турында сүз көрәштереп булмый. Нәкъ шушы фикерне коммунистларның алласы Фридрих Энгельс әйткән булса да. Мин гарәпләрнең жиңелүендә зур роль уйнаган тагын бер дәлил китерә алыр идем. Бу турыда да әйтмим, яшерәм. Сугыш башланыр алдыннан без Мисырга хәрби инструкторлар (аларның күбесе сугышта турыдан-туры катнаштылар) ташыдык. Кайсы турист, икенчеләре төзүче инженер документы белән килделәр бу илгә. Шуларны каршы алырга килгән гарәпләрнең инструкторны күрү белән кашлары жимерелә иде:

—Тагын яһүдине алып килдегезмени?

Инструкторның исем, фамилиясе урысныкы, бишенче пунктта «урыс» язылган. Урысча әйткәндә, «полный ажур». Гарәпләр исә инструкторларны кыяфәтләренә карап кабул итәләр иде һәм бик сирәк ялгышканнардыр. Димәк, Израил алдан кайгырткан булган. Ул инструкторлар гарәпләргә

ярдәм итәргә җибәрелгән булсалар да ярдәм аһүдләргә эләккән. Бу гынамы соң әле... Тоташ тәртипсезлек илендә бер генә өлкәдә дә тәртип урнаштырып булмый икән ул...

* * *

ЮЛДАШЛАРЫМ ватык танкларны күзәтәләр. Бу күренеш миңа кызык түгел, чөнки ул сугыш коралларын мин үзем ташыдым. Ташыдым гына түгел, Сүәеш каналы ябылып, аны ком басып киткәч, сугыш михнәтен кичереп Һиндстанга, Японияга, Индонезияга барганда, Африканы урап Изге Өмет борыны яныннан үтеп йөрдем. Мин Борынгы Мисыр культурасының тәэсире бүгенгә көнгә кадәр килеп җитүен, аның исәнлеген күреп шатланып барам. Мисыр игенчесе ашлыкны чәчми, бөртекләп утырта. Ул аны көн аралаш диярлек сугарып тора һәм җирдән елына өч тапкыр уңыш ала. Шулай армый-талмый эшләү гадәтен моннан өч мең ярым ел яшәп мәңгелеккә киткән пирамида салучылар калдырганнар. Ни хикмәт, гадәт үлмәгән, сакланган. Искәндәрия каласын күргән кеше белә. Бу шәһәрдә ике бер төрле йорт, игезәк корылмалар юк. Кайбер йортларның яныннан узганда онытылып туктыйсың да матурлыкка хәйран калып карап торасың. Йорт салу, аны матур итеп, мең еллар торырлык итеп салу да Борынгы Мисыр культурасыннан. Культура—зур, чын культура булган очракта, беркайчан да юкка чыкмый. Бер халыкта туган культура күрше халыкларга тәэсир итә, аларда да яши. Культура уңай тәҗрибәне, гореф-гадәтләрне канат астына алып саклый. Культураның иң зур шифалы көче—яшәешне матурлыкка күмеп ташлау, бәхеткә омтылучыларга канат үстерү. Бәлки безгә, татарларга, үз культурабыз турында кайгыртыр вакыт җиткәндер? Безнең бабаларыбызның культурасында Борынгы Мисыр тудырган бөек яуланышларның тәэсире бар бит.



Рафаэль
Сибат

# «ЙӘГЕЗ, БЕР ДОГА!»

ЭССЕ

## Өч аршын уй

Бөек фәйләсуф Аристотельнең: «начар дәүләттә яхшы гражданнар була алмый», дигән фикерен укыганым бар иде. Моннан егерме еллар элек...

Чорыбыз әдибе Аяз Гыйләжевнең «Йәгез, бер дога!» роман-хатирәсен укыгач исә мин «Начар дәүләттә дә, яхшы дәүләттә дә начар һәм яхшы гражданнар булырга мөмкин, әмма яхшысында—яхшылар күбрәк, начарында—начары күбрәк», дигән уйга килдем.



Романны укып бетереп, өстәл өстенә салгач, башыма килгән тәүге фикер иде бу. Әйе, бу әсәрдә авторның заманга-чорга, илгә-дәүләткә, бигрәк тә аның житәкчеләренә карата үз фәлсәфи концепциясе бар. Урыны-урыны белән язучы ашыга да кебек, ләкин бу аклана, чөнки ул барысын да (әйе, нәкъ менә барысын да!) әйтеп бетерергә тырыша. Ул үзенең нечкә-нәфис күңеленә хас булганча лиризмга да кереп китә (монда Аяз Гыйләжев чын мәгънәсендә шагыйрь!), үзенчә усалланып, аяусызланып та ала. Ләкин...

Китапны китап иткән һәм биеккә күтәргән нәрсәләр болар гына түгел. Әйе, аяусызлану бар—ләкин сызлану көчле аның жанында. Менә шушы сызланулар әле тормыш тәжрибәсен дә үтмәгән егетне бик күп төрле уйларга этәрә. Бу уй аерым бер шәхси кеше язмышыннан башланып, халыкларга барып тоташа, аннан ил-дәүләтләргә, тагы гомуми Йортыбыз Жир шарына, Дөньяга һәм—Тәнребез Аллаһыга.

Болар бик ерак, биек һәм бөек уйлар. Шушындый Ак Фикерләү каршына коточкыч Кара Багана булып өч аршын уй баса...

...Нәрсә соң ул өч аршын уй??

Өч аршын уй—Сталин образы...

Ә моны ничек аңларга???

Бик гади генә...

Диктатор һәм тиран Сталинның уйлары күбрәк өч аршыннан артык узмаган, ә өч аршын уй—кабер ул. Әлеге уй шунда гына сыеп бетә. «Халыклар атасы» иксез-чиксез илне каберләр аша гына күргәндер. Әнә бит теге гасырлардагы «өлкән апасы» Әби патша Екатерина II дә Француз философларына язган хатында: «Россия бик зур ил ул, аны демократик юл белән бервакытта да идарә итеп булмый, шуна иң кулае—монархия»,— дигән. Монархларның күбесе шул ук деспот вә тиран, ә Сталин—аларның кече туганы булса да, вакыт-вакыт ул җәлладлыкта хәтта Явыз Иваннан да арттырып җибәргән.

Өч аршын уйның тагы бер символын, олырак форматтагысын да әйтик инде.

Өч аршын уй—илнең төрмәсе, зоналары, концлагерьлары да әле ул. Үтерергә һәм үтерергә шашынган палач, әлбәттә, барысын да алай гына бетерә алмый, чөнки ни генә димә, дөньяда йөзәрләгән илләр һәм халыклар бар. Алар ни дияр?! Моның кадәр законсызлык алдында түзеп торырлармы? Шуның өчен суд-сорау алулар, әвәләштереп булса да, Законның тоныкы үлемтекле йөзен күрсәтергә кирәк. Ә төрмәләрдә ил гражданнарын нишләтәләр—монда инде «бөек житәкче»нең һәм аның яраннарының эше юк!

Әйтергә кирәк, һәр илнең төрмәсе андагы дәүләтнең кечерәйтелгән моделе ул. Илнең Олуг Сулышы киң вә тазамы яисә тар һәм чирлеме—шушы Сулыш төрмәдә ачыграк сизелә. Чөнки төрмә иксез-чиксез дәүләтне ифрат та нык кысып, пресслап кечерәйтелгән бер бина ул. Галәмдә бик нык кысылган йолдызлар бар, алар яктыртудан туктап «Черная Дыра»га—Кара тишеккә әйләнгәннәр. Төрмә, зоналар да шул кара ярыклар, анда ябылганнар исә—әлеге ярыктагы «тараканнар». Шуңа аларга Кеше итеп карау юк. Бәлки шундый караш та булыр иде, ләкин теге өч аршын уй комачаулый.

Шушы тар уй белән Аяз Гыйләҗевнең мәшһүр «Өч аршын җир» повесте геройлары Мирвәли белән хатыны җиргә кысылганнар иде. «Йәгез, бер Дога!» сүрәсенең беренче аятьләрен дә шул повестьтан эзләргә кирәк. Теге ил өстенә менеп баскан Кара Багананың шыксыз карачкысы «Өч аршын җир»дә үк сизелә иде. Лейтмотивта һәм ишарәләрдә...

Ә инде «Йәгез, бер Дога!» романына килсәк, монда ул—китаптагы 448 битле тулы бер Сүрә. Күктән түгел, җирдән-тормыштан иңгән...

## «Акулалар»ның яман эче...

Минем Шаламов, Гинзбург, Аксенов һәм башкаларның Сталин концлагерьлары, төрмәләре, зоналары турында үз күзләре белән күргән мәхшәрне тасвирлаган язмаларын укыганым бар. Солженицынның «Гулаг»ы белән дә таныш. Үзебездән Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре»н дә ике тапкыр укып чыктым.

Эчкерсез, ачык күңел белән, күргән-белгәненне һәм ишеткәненне ихластан язу сизелә аларда. Эчкәрәк кереп, тирәнрәк төшеп карасаң, әлеге әсәрләрдә берничә тенденция тоемлана:

—Менә мине «алдылар» һәм юкка гына рәнжеттеләр, ә бит мин... Мин—гаепсез идем!

—Төрмәгә эләктенме—син кеше түгел, синең киләчәгең дә бик шикле...

—Дөньясына усал караш, күңелгә җыелган эчке нәфрәт.

Әлеге фикер-уйлар алар язганнарда канлы кызыл җеп булып сузылып бара. Чөнки алар сызланган йөрәктән сызылып-сыдырылып кына төшкәннәр.

Инде Аяз Гыйләжевнен «...Дога»сында без өстә санап киткән фикер-тенденцияләр ничек чагыла?..

Әйтергә кирәк, 180 градус ук булмаса да, 90-120 градус капма-каршылык белән:

—Менә мине алдылар һәм юкка гына түгел! Мин бит... Мин бит яшәп килгән Системага каршы кеше идем;

—Төрмәгә эләккәч тә—чын кеше кеше булып калырга тиеш! Бигрәк тә үз күнелен киләчәк белән өзмәсә;

—Дөньяга усал караш белән яшәмә, изге нурны, жылылыкны Аллаһыдан, табигатьтән ал, һичьюгы яхшы кешеләргә тартыл һәм сыен. Алар сине Нәфрәт Күленнән тартып алырлар, шунда батып тончыгырга ирек бирмәсләр...

Әсәрнең беренче бүлекләрендә үк автор үзенен кулга алынуы сәбәпләрен яшерми: Режимга каршы сүзләр ычкындырган. Хәтта бу анын мәктәп чорына ук кагыла...

Әйе, башкалар зарлана:

—Гаепсезгә утырттылар...

Ә Аяз Гыйләжев горурлана:

—Без—совет, партия дошманнары идек. Боларда инде иң беренче Сталинга, аннары «Маркс, Энгельс, Ленин бабайлар»га да ышаныч юк. Әнә бит «илленче елның декабрь азагында» «Свердловскиның атаклы күчеш төрмәсендә» совет хәрби майоры мадьяр Ходяшнын Сталинны мактаган иреннәрен кисеп алганнар. Югыйсә, әле халыклар атасы исән, үз көчендә—югары власть иясе. Инде Казакъстан далаларына килеп эләккәч, аңа Сталин һәм анын Системасын сүгүче, үзе дә грузин Хуродзе очрый. Дөрес, Хуродзенын «халыклар атасы»на каршы чыгуы күбрәк үз рәнжүе вә грузин халкы исеменнән булып тоела. Ә Ростислав Иванович Илечко, Александр Васильевич Мерзленков, Сергей Сергеевич Козлов-Куменский һәм ниһаять—Иван Семенович Велягурский? Болар бит чын мәгънәсендә акыл ияләре, ифрат белемле кешеләр! Илечконың егерме тел белеп тә зонада японча өйрәнүе, ә соныннан татарчага тотынуы гына да үзе үк ни сөйли!



*Аяз Гыйләжевнең Карагандада шахта төзелешендә эшләгән вакыты. 1954 ел.*

Әнә шулар һәм тагы бик күпләр яшь егетне—үзенен уйлары дөреслегенә ышандыралар, фикерләре ныклыгына инандыралар. Мерзленков хәтта аңа татар тарихы буенча «дәресләр» дә биреп ала. Михаил Худяков, Лев Гумилевлар кимәлендәрәк. Шундый Мерзленковлар янында төрмәдә дә тунмыйсын, әлбәттә. Күнелендә Өмет Кояшы саклыйсын. Ә бу гаять мөһим нәрсә. Чөнки:

—Көн жылысы гына нәрсә ул—тән жылысы кирәк!

—Тән жылысы гына нәрсә ул—Жан жылысы кирәк!!

Шунысын ассызыклап китү мәжбүри дип саныйм: автор Системага, анын баш жәллады Сталинга каршы килүен коры сүзләр белән генә расламый, ә фәлсәфи тирәнлек аша күрсәтә. Боларны ул күбрәк Илечко, Мерзленков һәм башкалардан әйттерә, ләкин анын уйлары аларныкы белән параллель. Параллель диюем шуннан, яшь егет алар югарылыгында, «профессорлар» кимәлендә үк фикер йөртә алмый әле. Ул өйрәнә, уйлана, фәлсәфи үлчәүгә салып карый. Ләкин шунысын да искәртик: 1990 елда әлеге «...Дога»сын язган олпат вә акыллы, тормыш тәжрибәләрен ифрат күп туплаган Аяз Гыйләжев та «теге егет» түгел шул инде. Ул Илечко, Мерзленков, Козлов-Куманскийлар югарылыгында фикер йөртә, кирәк

икән—тормышка бәя, шул чордагы вакыйгаларга политик анализ ясауда инде күп яклардан уздырып та җибәрә. Чөнки ул бу романында тормышны, аның күпкырлы якларын тасвирлаучы прозаик кына түгел, ә дөньяны күзаллауда төгәл фикерләре булган, тирән уйлары туган философ язучы да. Авторны тулысынча аңлыйк дисәк, шушы ике образ: зонадагы зек—яшь егет белән алтмышын узган күренекле прозаик арасындагы 40 елны һич тә онытмаска кирәк! Юкса, күп нәрсәләрдә хаталанып, ялгыш бәя бирүләргә дә килүебез бар.

«Патшаларның мәгънәсез дуамаллыгы халыкка һәрчак михнәтләр китерә». Бу сүзләрне борынгы Рим шагыйре Квинт Гораций моннан 2000 еллар элек әйткән. Аны 20 гасыр буе кабатлап килгәннәр һәм Аяз Гыйләҗевнең «...Дога»сындагы һәр мотивта, һәр көрсенүдә, һәр җәбердә, гомумән, һәр сулышта шуны ишетергә була. Моны кабатлауда да автор аяусыз:

—Яхшыны яхшы диң!

—Яманны яман диң!!

Әйе...

Шунсыз алгарыш та, яңарыш та юк. Шунсыз Чын Язучы да юк...

Инде сүзне язучының Системаны кабул итмәвенә һәм фәлсәфилегенә күчергәнбез икән, ул үз әсәрендә Ачыш рәвешендә әйткән, күпләрнең төшләренә дә кермәгән тагы бер якка күз салыйк әле.

Романны укыган укучы беләдер, 1948 елны кулга алынган Казан Дәүләт университеты студенты тоташ уйда яна:

—Мин ярый инде, Сталинны сүктем... Ә башкалар? Мәсәлән, нигә дип утызынчы еллар тоткыннарын җыя башладылар? Ә ни өчен чит илгә китеп, соныннан тагы үз иленә кайтканнарны—репатриантларны—кулга алалар?? Нигә илдәге әтрәк-әләмнәр, караклар-бурлар, һәртөрле ышанычсызлар белән төрмәләрне тутырдылар???

Һәм...—иң авыр, яман сорау:

—Нигә әле аларның барысын да Казакъстан далаларына, Караганда якларына озаттылар да зоналарда, базларда «күмделәр»?!

Әйдәгез, авторның үзеннән сөйләтик:

«Кырык сигезенче дәһшәтле елның явыз эчтәлеген ачарга тырыштым. Кырык сигезенче елны Рәсәйнең җәза сәясәтендә нинди мөһим урын тотканын үзем аңлаганча билгеләп куйдым. Кырык сигезенче ел—Рәсәй империализмының дөньяны яулап алырга әзерлеге планнарының тормышка аша башлау еллары иде. Моңа мисаллар күп, бүген берсен генә аерып язып үтәм. 1950 елның 25 июнендә Корея сугышы башланды. Сталин башлады ул сугышны. Шул сугышка әзерлек көннәрендә Рәсәйнең иненнән-иненә сәяси дошманнардан чистарту, аралау башланды. Рәсәй бу сугышка тикле шикле, куркыныч адәмнәрдән арынырга тиеш иде! Әйткәнемчә, кулга алулар нәкъ кырык сигездә көчәйде дә!.. Корея сугышы хәрбиләр, тарихчылар телендә әле дә: «Секретная война секретным оружием!—дип атала... Сталин үлеменнән соң озак та тормады, илле өченче елның 27 июнендә сугыш тукталды»

*(Аяз Гыйлаҗев, «Йөгез, бер дога!», 341 бит)*

Йа, Алла!

Әле немец фашистлары белән үткән сугышка өч кенә ел узган. Тагы яңа өчъеллык сугыш?? Туярмы бу оятсыз Рәсәй бервакытны канкойгыч, кабахәт, мәгънәсез сугышлардан?! Әллә ерткыч хайван кебек ул кан коймыйча тора алмыймы? Шулайдыр... Чөнки анын дәүләте башында Сталин, Берия кебек ерткычлар утыра ич. Ә аларның ялчылары ил буенча таралган. Иң ерткычлары төрмәләрдә, зоналарда. Болар: офицер погоны таккан хайваннар, Җирән кебек надзирательләр, бер сыңык ипигә анасын сата торган явыз конвой солдатлары. Ул солдатларның вышкада торганнары да, сакка баскан башкалары да кешелек сыйфатларын күптән югалтканнар. Шулай булмаса, алар бу «эшкә» алынмаслар иде дә бәлки. Алай дисәң, үзе үк бер биниһая төрмә булган Рәсәй—СССРда кая барасын?

Үзенне, приказны үтәмәдем диеп, терәп атачаклар бит! Шуна аларны азмы-күпме аңларга да була. Язучы да үз «...Дога»сында әлеге вак балыклардан битәр күбрәк «акулалар»ның яман эчен ача! Әйе—«Акулалар» хәзер дә «акула» шул алар. Укыйк «...Дога»ны, гыйбрәтләр алыйк, сәждәгә калыйк.

## Кешене хайванлаштыру...

Бу әсәрнең бер үзенчәлеге: автор романның агышын төгәл хроникага, вакыт узу тәртибенә көйләмәгән. Кырык ел үзе бер гомер булса да, язучы шул елларда күчмә кошлар, очар кошлар кебек «яши». Ләкин монда берниндн хаос юк, бар икән—ул үзе бер тәртипкә салынган. Менә болай:

—Язучы күнелендә яз икән, ул туган ягына, Казанына кайта. Ул ял йортларына китә, Мәскәүдә, Смоленскида була, Украинага, Кавказ якларына, Балтыйк буена барып чыга...

—Язучы күнелендә көз икән, ул Казакъстан, Караганда далаларына, Актас зонасына, бакыр, ташкүмер базларына «оча»...

—Яз икән!—Олы күлдә ул атаклы режиссер Марсель Сәлимҗанов һәм якташы талантлы актер Наил Дунаев белән кармак салып утыра...

—Көз икән!—аның үзен хайванлаштыру ниятеннән салып таптыйлар...

Әйе!

Нәкъ менә хайванлаштыру ниятеннән. Сталин лагерьларында утырып чыгып, исән кайткан һәм бу хакта чын дөресен язып чыккан бик күп кенә авторлардан үзгә буларак, Аяз Гыйләҗев бу «Хайванлаштыру темасы»на үтә нык игътибар итә һәм аның стилен, механизмын, ысулларын ачып сала. Баксаң, бер караганда бу бик гади генә икән ич:

—Әйтик, дарвинизм яисә кешелек эволюциясе турындагы башка теорияләрдән чыгып карасаң, кеше маймылдан барлыкка килгән. «Бәлки—дип уйлый дүрт класс семинария белемле, дөньядагы «ин даһи җитәкче», «халыклар атасы»ның теоретиклары—эш эшләтеп кенә кешене кире маймылга, һичъюгы берни дә уйламаучы эш колына, ягъни хайванга әйләндереп булмый. Ә менә хайваннарны кешеләр үзләренә ничек «кол хайван» итеп буйсындырганнар соң?! Әһ-һә! Иң беренче ашатмыйча! Тагы? Ачуың килгән чагында күнеленне басу, стрессны киметү өчен тотасың да кыйныйсың. Ул почмакка поса, күзләре коточкыч зураеп шар ачыла, аңа үлем төсе инә. Ул хәтта мөгрәвеннән туктап:

—Кыйнама, Ивашка җаным, ни теләсәң шуны үтәрмен!—дип, кеше телендә үзәк өзгеч оран салырга да мөмкин...

Ләкин кеше бит хайван түгел, аның горурлыгын сындыру өчен тагы ниләрдер эшләргә кирәктер. Монда тагы бер «һәйбәт» юл бар. Ана—«фашистка»—йокларга ирек бирмисең. «...Дога»ның 341 битенә күз төшерик:

—«Урысларның җәза ысуллары үзенчәлекле!—дип язды соңыннан белгечләр.—Йокыдан һәм ризыктан мәхрүм итәләр дә вәссәлам!» Таныш ысуллар, таныш әмәлләр!.. «Ми чистарту!»—дип исемләнә бу яшертен җәзалаулар.»

Менә сезгә кара сөремле урта гасырлар инквизициясен дә (ин шәбе) уздыра язган ысуллар:

1) кыйнау; тоташтан һәм бер гаепсезгә кыйнау;
2) йоклатмау, бигрәк тә карцердагыларны;
3) ачлык, ачлык, ачлык... һәм тагы ачлык.

Һәм...

Юк,—дип уйлый баш җәлладлар, төрмә палачлары. Тагы нидер өстәргә кирәк! Шунсыз хайванлаштыру акрын, ифрат акрын барачак...

—«Әйтик, кеше тәне үз җылысын сакласа, ул үлемгә дә тиз генә бирешми. Температурасы югары икән, ул, димәк, авыру, аны лазаретка,

госпитальгә озатып мәшәкатьләнү була. Ә киресенчә, төшереп карасак? Әйе, әйе! Бу «фашистларны» катырып үтерергә кирәк.»

Искә төшерегез автор сүзләрен:

—«Иң авыры суык һәм ачлык иде»,—ди ул. Ләкин аны «Ачлык язучы да иткән» бит әле. Килеп кергән баракларындагы стеналарга катлам булып ябышкан бәсне автор шулай образ тудыру өчен генә искәртми. Суык—адәм балаларын гомер буе куркыткан Салкын-Карт ул. Аның белән уйнама! Ак төстә булса да, мәсәлән, кар, бәс—ул шикәр түгел!! Ул—кәфен төсен һәм исен ныграк ярата.

—Бандерачылар белән каракларны, караклар белән «политичес-кий»ларны даими рәвештә талаштырып-сугыштырып торырга кирәк. Бигрәк тә бер милләт белән икенче милләтне...

Әнә бит автор нәрсә ди: «Без утырган «особый лагерьларда» дөньядагы барлык милләт вәкилләре бар иде дисәк, ялгыш булмас».

Әнә шулай талашсыннар, сугышсыннар, ырлашсыннар. Баксаң, әлеге төрмә, зона сакчылары, надзирательләр, явыз офицерлар, үзләре күптән хайван икән ич инде! Авторны тыңлыйк: «Пронин—эт иде, кече лейтенант дәрәҗәсен алгач, котырган эткә әйләнде».

Юк, шалишь брат!

Әй, сез, ил гражданнарын хайванлаштыручылар! Үзегез хайван булганга маташтыргансыз икән ләбаса бу эшне!? Ничек инде Илечко, Мерзленков, Козлов-Куманский, Велягурский, Наум Песин, Абдулла Алигази, Галинкер, Иван Лапаев, Касык, Романас, Полачек, Меркис, журналист майор Михаил Столяровларын хайван өммәтенә төшереп була ди?! Хәтта... законлы карак, әмма яхшы күңелле Викторны?? Ул бит «Алексей, Алеша, Аяз!»—дип аны үлемнән алып кала. Рецидивист Юрка белән исеме дә беленмәгән шакшы вә җирәнгеч адәмнәрдән саклап... Ничек инде Актастагы дүрт мең тоткынны хайванга әйләндереп булсын ди?! Төрмә шартларында ифрат бердәм яшәп, зонада чәчәкләр үстергән японнарнымы? Ифрат оешкан бандерачыларны, Кавказ горурларын яисә латыш, эстон, литвалыларнымы? Бәлки Кырым татарларын? Башка йөзләгән-йөзләгән милләтләрнеме?

—Шалишь!!!

Ә бәлки «Совет империясе таркалачак!»—дигән грузин Хуродзенедер инде??

—Юк инде! Юкка интегәсез!!

«...Дога»ны укыганда әлеге йөзләрчә-йөзләрчә тоткыннарны мин үз күзем белән күрдем. Телевизор экранындагы кебек. Хәер, моңа нигә гаҗәпләнергә ди! Аяз Гыйләҗев—портретчы, ул үз героеның төс-кыяфәтен ике-өч җөмлә белән дә сырлап куя ич. Бөек художник берничә сызык вә җинелчә кул селтәнүе белән киндердә җанлы образ—кеше сурәтен тудырган кебек...

## Төрмә мәхәббәте

Алдагы бүлектә без авторның кырык ел вакыт эчендә «арлы-бирле йөргәнен» искәртеп уздык. Әйе! Ул үз гомереннең үткәненә һәм чагыштырмача бүгенгесенә еш кына сикерешләр ясый. Моны әсәрнең фабуласы да таләп итә, чөнки, әйткәнебезчә, автор бүгенге көн күзлегеннән торып яза ич бу әсәрен.

—Күңелендә яз икән—ул бүгенгедә...

—Көз икән—зонада: үткәндә...

—Яз—гөлләр чәчәк ата!!.

—Көз—чәчәкләр шиңгән...

—Яз—Мәхәббәт!!!

Аяз Гыйләжевнең «Йәгез, бер Дога!» романындагы кебек гадәттән

тыш шаккаттыргыч, әле болар өстенә ифрат саф-садә, гади-самими, сабыйлар вә фәрештәләрнекедәй мәхәббәт турында укыганым юк иде. Үзе оялчан да ул, үзе омтылышлы да, үзе дәртле-кайнар да, үзе—аптырашлы да...

Әйдәгез, ашыкмый-кабаланмый гына «...Дога»ның 218 нче битен ачабыз...

«Здравствуй, любимый мой!»

Ни—нәрсә?!

Ялгыш ишетмибезме бу гүзәл сүзләрне? Хайванлаштыру зонасында сина кемдер шулай дәшә икән, бу абзардагы сыерның икенче мал сараенда торучы үгезгә:

—Исәнме, сөйгәнем минем!—дип дәшүе кебек түгелме?

Билләһи!..

Моны шул ук биттә автор болай аңлата: «Илле икенче елга мин шулай, дөресрәге, без шулай, мәхәббәт көймәләренә аерым-аерым утырып, гыйшык дингезенең шаулы-гөрле чагында бер-беребезгә төшләребездә йөзә-йөзә килеп кердек. Нигә кирәк булды икән бу язышу?!»

«Юаныч идеме бу аның өчен, әллә бер-бер уен гына идеме?»

«Ул чакта мин боларны, Ленаның тирәнлеген, фаҗигасенең кискенлеген аңлап бетермәдем, ул тәкъдим иткән мәхәббәт уенына кереп киттем шикелле.»

«Яшермим, аның беренче хатларында беркатлылыгымнан көлү, ирония, чак кына мыскыллау да бар иде!.. Сонра, мәхәббәт алмашып, арада сөю хатлары йөри башлагач, ул да йомшады, биеклектән минем янга төште.»

Тукта!!

Сон, бу яшь зек Дзидра исемле латыш кызы белән дә хат алышты түгелме сон?

Ул үзе дә болай ди: «Әнә ич, Дзидра белән Лена минем аркада чәкәләште».

Хуп! Ә алар сон гүзәл Лена белән яшь Аяз-Алексей бер дә очрашмаганнармыни? Болай булса мәхәббәткә ниндидер күләгә төшәчәк бит. Автор үзе дә «Минем Ленаны күрәсем, күзләр ярдәмендә аның чынлыгын чамалыйсым килде. Мин аңа: «төнге сменага бригада белән чык, очрашыйк!»—дип яздым, ул ризалыгын бирде.»

Очрашу—ярты кавышу инде ул!

Ә бу очрашу...

Бу очрашу бер яктан мәзәк тә, икенче яктан күпмедер дәрәҗәдә фаҗигале дә:

«Биек-биек, киң җилкәле бандеровчылар мине, алабута күмәче, черек бәрәңге кәлҗемәсе ашап орчык буе гына үсә алган кәтәнә татар баласын күз төшәрлек итәргә тырышалар... тәбәнәк-тәбәшәкләр мине урап кала, ниһаять, минем сынарга әзер буем да әз-мәз калкына...»

Ах, каһәре! Кимсетмә үзенне Аяз абый! Татарлыгыннның алама ягын калкытып куйма!!.

«Әнә ул, әнә!» «Күз алдымда текә күкрәкле, уртача буйлы, яп-яшь, сылу ак маңгайлы, бер караганда шом, икенче караганда мәрхәмәт-шәфкать чәчеп торган төпсез күзләр кала.»

Автор әйтмешли, «Сумы шәһәре кызы Лена Иваненко турындагы «мәхәббәт кыйссасын» шушы урында тәмамлыйк. Төрмәдәге «мәхәббәт кыйссасын». Дөресрәге, Актас зонасындагы...

Шунысын да әйтик, менә шундый «мәхәббәт» өчен дә дөньяда күпмедер яшәп алырга ярыйдыр. Мин Аяз абый өчен горурландым! «Тәбәнәк» кенә татар «Биек Мәхәббәткә» менә алган ич. Гыйшык тавына...

Хәтта шушы «Мәхәббәт кыйссасы» өчен генә дә укыйк бу «...Дога»ны...

## Татарлар һәм «татарлык»

Романында аерым кешеләргә бәя биргәндә язучы өч тәлинкәле үлчәүдән файдалана: соклану—кызгану—жирәнү.

Әйтик, Илечко яисә Велягурский—соклану. Кайчандыр мифик рольдә легенда булып йөргән Михаил Столяров—кызгану... Ә Жирән надзирательдән исә жирәнмичә, нишләрсең ди?! Яисә Ревякин һәм Аюкиннан...

Ә менә милләтләргә карашында ул ике генә үлчәү тәлинкәсе белән эш итә: соклану һәм жәлләү.

Японнар—соклану!! Кавказ егетләре—соклану... Балтыйк буе халыклары ике тәлинкәгә дә сыйган: соклану һәм жәлләү. Кытайлар—жәлләү... Немецлар—жәлләү...

Монда бу ике тәлинкәнең берсенә дә сыймаган бер генә диярлек халык бар.

Ул—без, татарлар...

Йа, Алла! Ходаем!!!

Безнекеләр тагы ярык тагарак янындамыни? Аларга «үлчәү тәлинкәсе» дә калмаганмыни соң?!

—Ка-ал-ган!

Ул—үзе дә чын татар булган авторның жанында. Нинди тәлинкә соң ул?? Ул—сызлану тәлинкәсе. Халкың өчен аяусыз сызлану. Аяусызлана-аяусызлана, хәтта ояла-ояла сызлану...

Актаста автор татарларны бик аз очрата. Очраганнары да... «Морт районыннан бер өлкән генә татарны очраткан идем. Сынар күзле, тәбәнәгрәк крестьян иде бу кеше.» «...Куйбышевтан бер яшь кенә, карачутыр татар килеп чыккан иде. Әзрәк «блатнойланган», урыслаша язган бу егет...» Мигдәт Динмөхәммәт улы Сәләхетдинов—бүрәнкә авызлы, киң авыш маңгайлы Ярыслау татары. Маржага өйләнгән... Зонада аны Дмитрий Николаевич дип йөртәләр. Мигдәт асылда татар түгел иде инде». «Фәйзрахман абый... бу татарның чыраена карарга куркыныч иде. Борын очы юк, колак бөтеркәләре өшеп төшкән.» «Тагы бер карт бар иде зонада—Умеров, бусы—Әстерхан татары...»

Әле тагы бирәү... «Егет шәрәтән утыра, оегын салган, яланаяк, чишкән аякчулары бозау чәйнәгән тастымалдай өзгәләнеп «аяк тырнаклары бөгәрләнеп каткан...»

Йә, житәр!

Кайда соң монда Илечко, Мерзленковлар?! Мондый кешеләрдән торган милләт кая барыр?! Арча районыннан Әхмәтзыя Гыйльметдинов белән әнисе татар һәм үзе дә саф татарча сөйләшүче, әтисе чиркәс булган Абдулла Али-казыдан башка юньле татар калмаганмыни Актаста??

И, тарлык—тарлык!

Татарны үлемгә алып баручы тарлык—татарлык...

Бу бит мескен, изелгән, көчсез, юаш, куркак «татарлык»...

Әле боларга автор белән бер вагонда барган «сука татар»ны да өстәсән... Аллам сакласын! Аллаһүммә фәзъна!! Аллаһыбыз, безне туры юлга сал! Аллаһүммә иһдини!!

Кайда бездә япун самурайларындагы кебек кануннар, тәртип кагыйдәләре, таләпләр? Шунсыз бетеп барабыз ич...

Чын Татарлык кануннары вә кагыйдәләре дибез икән, мондый таләпләр куеп булмыймыни:

1. Иң беренче—үз теленне камил бел! Аңа зур хөрмәт белән кара, башкаларны шуңа өйрәт. Онытма: Синең Телең дөньядагы иң камил, иң бөек ундүрт телнең берсе. Теленнән йөз чөергәннең—теле көяр!

2. Жиде буын бабаларыңның исемен бел, шәжәрәсен сакла, алга таба балаларына һәм оныкларына калдыр. Бабасын оныткан—алдагысын оныткан!

3. Атан-анаң сүзеннән чыкма, аларны санла һәм шәфкатьле бул. Картайган көннәрендә ярдәм ит. Туганнарыңны, якыннарыңны ташлама. Атасын сүккән—атсыз калган. Анасын сүккән—ансыз калган!

4. Татар кызына өйлән, татар егетенә кияүгә чык. Балаларына матур-матур татар исемнәре куш, аларны татар рухында тәрбиялә һәм сабый чактан ук туган телеңне өйрәт. Онытма: балаңның рус телен кечкенәдән үк белүе үз ана теленнән читләшүе өчен түгел, ә икетеллелек һәм алдагы тормышы өчен кирәк. Чит ил татарлары дүрт-биш тел белеп тә, туган телләреннән йөз чөермиләр. Туган телеңне белмәү—тудырган анаңнан жирәнү белән бер!

5. Гомерең буе үз милләтеңнең йолаларын сакла, гореф-гадәтләрен үтә. Ата-бабаларың диненә ихтирам ит, иманга кил. Имансыз кеше—ин мәнсез кеше!

6. Үз халкыңның үткәнен бел, аның чын тарихы белән кызыксын. Өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә. Үткәне юкның—киләчәге дә юк!

7. Татар халкы—олуг әдәбиятлы, зур мәдәниятле милләт. Аның әдәбият-сәнгатен үзләштер, даими кызыксынып бар, өйрән һәм башкаларга да шуны сөйлә, өйрәт. Үзенекен кире каккан—үзен кире каккан!

8. Дөньяның кайсы гына почмагына барсаң да яисә торсаң да үз татарың белән туганлашып, оешып, бергә яшә. Үз ишеи—кайда да иш, үз татарың—ярты Ватан ич!

9. Үзенә ничек кенә авырга туры килмәсен, кирәк вә мөһим чакта татар кешесенә һәрвакыт ярдәм ит. Татарның татарга ярдәме—атана ярдәм ул!

10. Эштәге, тормыш-көнкүрештәге тырышлык өстенә—күп белергә тырыш, күп укы, югары белемгә омтыл. Идарә эшләрендә катнаш, бизнеста өлгер бул, әмма һич тә намусыңа тап төшермә, исемең-атың белән рәттән:—Чиста, тәртипле, берсүзле, ышанычлы, белемле, яхшы күңелле, акыллы, тугрылыклы, талантлы, иманлы, милләтпәрвәр Инсан дигән—иң зур орденнардан да, алтын медальләрдән дә кыйммәтлерәк булган Изге Сүзләрне куярлык булсын. Алтын китәр—Акыл китми, гайбәт бетәр—гадәт бетми!

11. Башкаларга түбәнсетеп карама. Хатын-кызны ихтирам ит. Ирләргә түбәнчелекле бул. Дөньядагы барлык милләтләрне хөрмәт ит, аларның теленә, культурасына, йолаларына, гореф гадәтләренә ихтирам белән кара. Булдыра алсаң, берничә чит тел өйрән. Үзен яратканның күзе—көзгедә, башканы яратканның—башкаларның йөзендә!

12. Милли хисең турында кычкырып йөрмә, эчеңдә тот. Аны эштә күрсәт һәм гомерең буе йөрәгеңдә сакла, күңелеңдә үстер, яныңда тот. Күп сөйләшми генә зур эшләр башкар, әмма әйткәнеңне һәрвакыт:

—Мин әйттем!—диң. Безнең бабайлар—бөек ханнар—шулай дигәннәр. Үзеңне һәрчак татар морзасы яисә ханы итеп той. Онытма: һәр татар үз эшендә хан булырга яратылган!! Татар булуың белән мактанма. Әмма Горурлан!!!

И, Татарлар!
Укыйк бу Дога эчендәге доганы...
Гыйбрәтләр алыйк!!
Сәждәгә калыйк...

**Оран**

«Йәгез, бер дога»—үзенә бик күпне сыйдырган әсәр. Әлеге «...Дога»га язучы Аяз Гыйләжевнең 40 ел гомере сыйган. Тагы...

Иманы һәм чын мәгънәсендәге «Татарлыгы» сыйган... Уч белән пычранмаган Хәтере сыйган... Болар өстенә тулы бер империя, йөзләрчә халыклар, меңнәрчә кешеләр сыйган. Мондагы кеше исемнәрен санап

чыксаң да... Руслар әйтмешли, бу—иң «густонаселенный роман!» Тагы—кан белән язылган роман... Монда әле күпме хатлар сыйган...

Әмма мине иң нык гаҗәпләндергәне, юк, миңа иң ошаганы автордагы ике нәрсә булды:

Беренчесе—үч сакламау, җанына нәфрәт тупламау, үзенә начарлык эшләгәннәрне дә гафу итә белү;

Икенчесе—«И-и төрмәнең сөенечле минутлары!»—дигән иң тәүге җөмлә. Хәт-тәр җөмлә!!!!

* * *

Әдәбият белән азмы-күпме таныш кешеләр беләләр булыр: һәр әсәрнең үз моңы-агышы, тоны-мелодиясе була. Ә менә Аяз Гыйләҗевнең «Йәгез, бер дога»сында романның башыннан алып ахырына кадәр барган музыкаль ачышына гаҗәеп бер тирән моң-сагыш чорналган. Чорналган түгел, ә Күктән—сабан тургае тавышыдай!—Югарыдан иңә ул. Чөнки бу Илаһи бер моң-көй. Кемгә ничектер, мин аны китаптагы 448 бит буена ишетеп-тоеп, сизеп-тынлап бардым... Бигрәк тә төн урталарында ачык ишеттем мин аны. Сәбәбеме? Белмим...

Әлеге Көй—«Карурман»...

Ул болай үзе кадр-эпизодлар, хикәят-вакыйгаларга сиздерми генә кушылып бара. Тоткыннар җырласа—тагы да көчәеп китә. Еласалар да...

Һәрхәлдә, мин моны автор эше дип тә санамыйм. Аны бит һәркем ишетми дә. Ул Җан-Рух, Аң Илаһилыгы (Подсознание) аша гына тоела.

Әлеге Көйне—Даһи «Карурман»ны—үзенең илаһи тавышы белән мәшһүребез, даһи моңчыбыз Илһам Шакир индерә килде.



*Аяз Гыйләҗев журналыбызның редколлегия әгъзалары арасында. 1999 ел.*

* * *

Шушы язмамны тәмамлап кына килә идем, Ямул авылында яшәүче апам килеп керде. Минем повестьларыма Минзилә исеме белән кергән Мөнҗия апам. Әдәбият укырга яратучы апам. Әни кебек якын апам...

—Нишләп утырасың, ни язасың?—дип сорады ул, исәнлек-саулык

сорашуга. Энекәшебез вафат булгач, без бу дөньяда бертуганнар икәү генә калдык. Шунамы соңгы араларда бик тә якынаеп киттек. Хәер, без элек тә бик якын идек.

—Менә... Татарда Аяз Гыйләжев дигән бер бик зур язучы бар. Шуның соңгы елларда хәтәр бер китабы чыкты. «Йәгез, бер дога!» дип атала. Шул турында язмакчы булып утырам әле... Синең аны укыганың бармы?

—Һи-и-и!—диде апам сүземне бүлә язып.—Аяз Гыйләжевне белмәскә соң!? Аның «Әтәч менгән читәнгә»сен ике тапкыр укып чыктым инде. Кая монысын да алып китеп укыйм әле,—дип, апам «Йәгез, бер дога»га чат ябышты.

—Апа,—дидем.—Әйткәнемчә, мин бу «Дога» турында язып ятам, дидем ич. Менә язмам төгәлләнсен дә, алып китеп укырсың...

Апам киткәч, мин уйлана төштем. «Нәрсә соң ул Китап? Ә нинәрсә ул Әдәбият?»—дигән үҗәт сорау-шөпшәләр баш миендә гөжләп торды...

Яисә менә Язучы кем ул? Нәрсәдә аның, халык алдында димик—бу гаҗәп зур мәгънәне куптарып карау була—гади укучы алдында иң беренчел абруе? Апам миңа моны бик гади генә аңлатты:

—Һи-и-и! Аяз Гыйләжевне белмәскә соң?!

Аның шушы репликасының төбенә төшеп карагач—хәйрани бер Ачыш ясадым:

—Соң, теге яки бу язучы турында хет ярты мең битле монографияләр яз, аның иҗаты хакында йөзәрләгән китаплар чыксын (ә андый язучылар да бар!), гади кеше, самими китап укучының, халыкның бер әдәбият яратучы садә вәкиленең:

—Һи-и-и! Аяз Гыйләжевне белмәскә соң!?—дип куюы боларның барысына да тора!!!

Язучы бит үз әсәрен монография язучы галимнәргә яисә тәнкыйтьчеләр, әдәбиятчылар өчен язмый—халык өчен дә димик!—әнә шул йөзәрләгән, меңәрләгән Мөнҗияләр өчен яза.

* * *

Япа-ялгызым...

Күңел Күккә тоташа:

—И Тәнрем—Илаһым! Синең колың Аяз Гыйләжев Яшәү һәм Үлем, Яхшылык вә Яманлык, Матурлык белән Ямьсезлек турында Җирдә үз «Дога»сын иҗат иткән. Бу «Дога»ны укып чыксан—күңелдә Иман нуры гына кала. Кабул кыл, Җирдә туган «Дога»ны!

Оран:

—Укыйк!

—Гыйбрәтләр алыйк!!

—Сәҗдәгә калыйк!!!

*Апрель, 1998 ел.*
*Түбән Шөн.*

*Яңа әсәр укыгач*

# «МОГИКАН»НАР КИСӘТӘ

Чаллыда яшәп иҗат итүче Вахит Имамов—проза өлкәсендә актив эшләүче язучыларыбыздан. Узган елның көзендә «Идел» журналында (№ 10) басылып чыккан «Могикан» повесте дә бу фикеребезне аныклаучы мисал. Еш кына борынгы тарихыбызга, ерак үткәннәребезгә күз салып, тарихи шәхесләрнең гаять катлаулы һәм каршылыклы образларын тудырган язучы бу әсәрендә бүгенге чынбарлыкка мөрәҗәгать итә.

Әсәрнең төп идеясенә бәйле аңлатманы редакция болай дип бирә: «язучы туган җир фаҗигасен кеше һәм ат фаҗигасе аша тасвирлый». Сюжетка хәзерге Чаллы һәм автогигант урынында гөрләп утырган бер авылның юкка чыгуы, кешеләренең тышкы сәбәпләргә бәйле михнәт-газаплар, кайгы-фаҗигаләр күрүе, ата-баба җиреннән куылуы турындагы вакыйгалар салынган. Алтыҗиде ел вакытны үз эченә алган хәл-күренешләр Вәлит-Василийның атка, тереклек дөньясына, бөтен табигатькә мөнәсәбәте аша бирелеп, дусты, авылдашы Айрат гәүдәсенең әфган җиреннән цинк табутта кайтарылуы, яраткан аты Могиканның кыргыйларча үтерелүе, ә үзенең кайгы-ачудан, чарасызлыктан читләр тарафыннан салынган йорт түбәсеннән сикерүе белән тәмамлана. Алар артында авторның тормыш-яшәеш, кеше һәм табигать, кеше һәм заман, татар милләтенең бүгенгесе һәм киләчәге, язмыш һәм үлем турында уйланулары ята. Шулай да үзәктә Вәлит һәм аның аты Могикан язмышы, ә ул исә туган җир, милләт язмышына килеп тоташа. Шуңа да кеше, табигать, милләт фаҗигасенең сәбәпләрен эзләү бу әсәрдә төп проблема буларак калка.

Күптөрле милләт кешеләре дус һәм тату, тыныч кына яшәп яткан авылда берзаман мәхшәр куба, чөнки ул сынау мәйданына әйләнә: халыкның башта җирен тартып алалар, аннары алар тормышына империянең төрле төбәкләреннән китерелгән «саранчалар» килеп керә. Алга таба урлау, көчләү, куркыту аша кешеләрнең җанын пычраталар һәм, ниһаять, аларның төрлесен төрле җиргә таратып, авыл һәм ата-баба зираты өстенә завод салып куялар.

Шул чорның газет-журналлары, радио-телевидениесе «гасыр төзелеше» дип билгеләгән автомобиль заводы төзү—аерым кешенең, авылларның, татар халкы күпләп яши торган тулы бер төбәкнең фаҗигасе икән бит! Әсәрдә тарих укытучысы Галәветдин абзый сүзләре аша завод салуның асылда явыз Иван башлаган, шовинистик рух белән сугарылган басып алу, татарны эчке яктан таркату, ахырда юкка чыгару сәясәтенә хезмәт итүе ачыла. Автор җан ачысы белән КамАЗ алып килгән кайгы-хәсрәтне санап китә: уңдырышлы җирләр, саф сулы, балыклы елга-күлләр, болын-урманнар юкка чыгарыла, туган җир табигатенә төзәтеп булмаслык зыян килә; ата-бабаның тире-каны тамган изге урыннар мәңгелеккә югала.

Автор язганча, завод мичендә «ил зираты, хәтер, тарих» яндырыла; халкыбызның борынгыдан камилләшеп килгән яшәү рәвеше бозыла, читләр алып килгән әхлаксызлык әйләнә-тирәне басып ала, яхшы белән начар, «ярый» белән «ярамый» бутала, ата улны, ана кызны белми торган чорга нәҗ шулай нигез салына. Бүген җәмгатьчелек афәт буларак билгеләгән эчүчелек күренешенең чынлап торып тамыр җәюе дә шул вакытларга карый түгелме?

Болар барысы да, нигездә, әсәрнең проблема-идеясенә, эчке мәгънәсенә карый. Әдип аларны нинди юллар белән чишә, укучыга үз карашларын ничек җиткерә соң? Повестьта лирик башлангыч белән публицистик пафос тыгыз үрелеп бара. Әсәр башында сурәтләнгән авыл тормышы, малайларның гади, гадәти эш-гамәлләре, хыял-максатлары, атларга мөнәсәбәтенә бәйле

күренешләр әйбәт тәэсир калдыра. Күрше авыл һәм Чаллы Сабан туйларындагы ат чабышларын тасвирлаган урыннар да авторның оста күзәтүче булуын күрсәтә.

Дөрес, татар әдәбиятында атлар турында шактый күп язылды һәм инде ниндидер үзенчәлекле яңа сүз әйтү шактый кыен. Ничек кенә булмасын, В. Имамов кеше һәм ат мөнәсәбәтен белеп, яратып сурәтли. Аеруча яшүсмерләрнең әлеге акыллы җанияләренә эчкерсез, табигый мөнәсәбәте хакындагы юллар яратып укыла.

Повестьтагы вакыйга-күренешләр, геройларның эш-гамәлләре шактый кискен каршылыкта ачыла. Вакыйгалар гаҗәеп матур елга-күлләр, мәгърур нарат урманы, төрле милләт кешеләренең дуслашып яшәве һәм әхлакый кыйммәтләрнең өстенлек итүе фонында башланып китә. Соңрак исә, тәзелешкә бәйле рәвештә кайгы-хәсрәт килә, тормыш рәвешенә әхлаксызлык үтеп керә, табигатьне юк итү, кеше шәхесен рухи җимерү башлана. Аерым күренешләр белән генә бирелсә дә, тулы канлы, тормышчан образ дәрәҗәсенә күтәрелгән Чингачгук та капма-каршылыкта ачыла. Тарихтан мәгълүм Чингачгук ул—индианнарның кабилә башлыгы, гаҗәеп кыю, гадел, оста һәм тапкыр кеше. Ул халкының азатлык көрәше башында тора. Әсәрдә бу исем авыл советы рәисенә бирелгән. Шулай итеп, бу исемгә салынган мәгънә халык мәнфәгатен кайгыртырга тиешле рәиснең куркаклыгын, түбәнлеген тулырак аңларга ярдәм итә. Әйе, түрәләр халыкны әнә шундый «шәрепләр» ярдәмендә буйсындырып тотты да инде.

Әсәр башындагы Америка индианнары турындагы мәгълүматлар, бердән, малайлар психологиясен ачуга хезмәт итсә, икенчедән, ачык күренеп тормаган, тирәндәрәк яткан мәгънә ачыла: безгә дә шулар язмышы янамыймы? Вәлит яңа туган колынга Могикан дигән исем куша. Әлеге ят-сәер исемгә әсәрдә зур гына эстетик йөк салынган. Аның беренче мәгънәсе юкка чыккан индианнар кабиләсен аңлатса, икенче мәгънә бетеп баручы, юкка чыгучы кабиләнең соңгы вәкиле дигәнне белдерә. Әсәрдә Могикан бу яшәешкә үтеп кергән шау-шуга, тулаем урбанизациягә каршы торып карый, әмма ул да, хуҗасы Вәлит тә—көчсез.

Бер тапкыр да арбага җигелмәгән чабышкы атларның язмышы һәркемгә билгеле: ярышларга катнашмый башлагач, алар иткә озатыла. Могиканны да шул көтә. Әмма әсәрдә аның тәртип саклаучы «саранчалар»ның берсе җитәкчелегендә үтерелүе тирән мәгънәгә ия—чөнки болар милләт тамырын да корытучылар. Моны яхшы аңлаган Вәлит чарасызлыктан, көчсезлектән һәм фани дөньяның пычрак-вәхшилегеннән туеп, «мондый илнең миңа кирәге юк. Телсез бөҗәк булып яши алмыйм...» дигән фикергә килә һәм «туган җиренә «саранчалар» салган беренче иң бөек йорт» түбәсеннән бакый дөньяга атлый.

Әйе, бу образ укучы каршында «ат җене» кагылган, бөтен табигатькә гашыйк малай булып ачылды. Ул сизгер күңелле, матур теләк-хыяллар белән яшәде. Малайның әлеге сыйфатларын Могикан да аңлый, сизә, шуңа күрә аңа тартыла иде. Түрәләрнең кыланышыннан, гади халыкның, авылдашларының кимсетелүеннән Вәлитнең соң дәрәҗәдә рәнҗегән күңеле дусты Айратның әфган иттурагычында һәлак булуын, Могиканның үтерелүен күтәрә алмый һәм ул коточкыч карарга килә.

Егерме яшьләр тирәсендәге егет үзен-үзе үтерүе белән нәрсә әйтергә тели, кемгә нәрсәне расламакчы була соң? Автор: «бу аның әйләнә-тирәсендәге «саранчалар»га, кешелексез җәмгыятькә үзе аңлаганча, үзенең көче җиткәнчә протесты», дип әйтергә тели, күрәсең. Вәлитнең «Һәрбер корбанны да каршылык һәм нәфрәт күрсәтә белмәс җансыз курчак кына диеп санамагыз. Мин үз сүземне һәммәбез өчен дә берьюлы әйтеп салам...» дигән сүзләре дә шуңа ишарәле. Ләкин уйлап карыйк әле: мондый протест нәрсәгә хезмәт итә соң? Кемнең дә булса күзен ачамы, милли аң тәрбиялиме? Янсә әлеге «саранчалар»ны акылга китерәме? Кызганычка каршы, юк шул! Вәлит А. Н. Островскийның «Гроза»сындагы «луч света в темном царстве» булган Катерина вазифасын үти алмый. Г. Ибраһимовның Гөлбануына, К. Тинчуринның Сәрвәренә яки Надирына салынган эстетик йөкләмәне дә күтәрми ул. Тагын шунысы бар: егетнең үзенә кул салуы аның характер сыйфатларына, хис-

кичерешләренә бәйле рәвештә дәлилләнми. Ә бу исә әсәрдәге психологик анализның йомшаклыгын күрсәтә. Без моны атлар чабышын сурәтләгән урында да күрәбез. Финишка җиткәндә Вәлитнең «Минем җиңү кирәк сиңа. Күкрәк сугар өчен, шапырыну өчен...» дигән уйланулары ышандырмый. Бердән, шундый зур ярышта җиңү яулауның даны, беренче чиратта, атка һәм аның җайдагына була. Икенчедән, узыш дәрте белән кызган, психологик гаять киеренке моментта егетнең боларны уйлавы һич тә табигый түгел. Автор ул фикерләрне аңа үзе көчләп тага, шуңа да алар урынсыз булып күренә. Ярыш ярыш инде ул—аның һәрберсен сәясәткә әйләндерү кирәкмәс. Аннары унөч яшьлек малайларның 3-4 чакрымдагы урманга беренче тапкыр гына барулары, аларның урманга карап «уклау йоткандай шаккатулары» да ясалма булып чыккан. Әсәрнең тормышчанлыгын киметә торган мондый җитешсезлекләрне тагы да күрсәтеп була. Мәсәлән, күрше авылга кино карарга баргач, «кунакларны билет кассасына якын да җибәрмәделәр» диелә. Җитмешенче елларда авыл клубында нинди касса ди ул? Икенче бер урында малайларның күлләрне «Тозлы», «Сазлы» исемнәре белән атауга гаҗәпләнүе һәм татар балаларына Рудольф, Рево, Аэлита, Руслан һ. б. «кушаматлар» тагуга борчылулары да ышандырмый. Чөнки керәшен исемнәрен татарчалаштырып, татар исемнәрен русчалаштырып бозып әйтү гадәти күренеш булган җирдә бернинди исемгә дә кешенең, бигрәк тә малайларның исе китми—әле киресенчә, Өммегөлсемне Элизабет дип, Әсмабикәне Аэлита дип атарга мөмкиннәр.

Повестьның тагын бер «йомшак» ягы—теле. Аңа образлы тел, җанлы сурәтләр җитенкерәми. Җылылыгы, бизәклеге белән тел үз артыннан ияртеп бармый. Геройларның сөйләмен индивидуальләштереп биргән урыннарда да чатаклыклар бар. Шулай да табигать күренешләрен лиризм белән сурәтләгән, геройның хис-кичерешләр ташкынын биргән урыннары күңелгә ятышлы.

Гомумиләштереп нәтиҗә ясарга тырышсак, биредә уңай як итеп тема-проблемаларның ачыклыгын, заманча актуальлеген күрсәтергә була. Ә инде безнең хәзерге повесть жанрында еш очрый торган кимчелек—олы характерлар булмау, тел-сурәт чараларының ярлылыгы, хикәяләүче һәм автор төшенчәләренең, ачыкланып бетмәве, сурәтләүдән бигрәк сөйләп баруның өстенлек итүе, психологик анализның йомшак булуы тора.

Бу әсәр татар әдәбиятында билгеле бер урын алыр дип уйламыйм. Ул ел күренеше генә булып калыр шикелле. Шунлыктан ниндидер зур казанышлар турында сүз алып барып булмый. Әмма җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле туксанынчы еллар әдәбиятында урын алган аерым үзенчәлекләр «Могикан» повестенда да ачык төсмерләнә. Алар түбәндәгеләр: В. Имамов аерым кеше һәм халык язмышы белән бәйлелектә туган җир мәсьәләсен җитди проблема итеп күтәрә; кеше һәм ат мөнәсәбәте табигать, аны саклау, рухи матурлык кебек кыйммәтләрне үз эченә алып, югарыдагы мәсьәләгә килеп тоташа; автор ерактагы һәм якындагы тарихыбызны да иңләп ала, аларга үзенең бәясен бирә һәм бүгенгебезне шулар аша аңларга омтыла; повестьта лирик һәм публицистик башлангычлар үзара үрелеп бара һәм әдипнең туган җире, милләте өчен борчылуы публицистик яңгыраш ала.

Һәр әдип үз чоры, заманы белән тыгыз бәйләнештә яши һәм әйләнә-тирә мохиттәге үзгәреш-яңалыклар, вакыйга-күренешләр теләпме-теләмичәме аның иҗатына билгеле бер йогынты ясый. В. Имамов та соңгы елларда милләтебезгә янаган куркынычны җаны-тәне белән тоя, мондый хәл туунын сәбәпләрен эзли.

Бүгенге укучы гаять зур информация басымы астында яши. Ләкин кызганыч: аның рухи дөньясына йогынты ясаучы шартларны без чикли алмыйбыз. Озак еллар дәвамында тыелып киленгән яисә берьяклы гына яктыртылган шәхси теләк һәм иҗтимагый мәнфәгать, җенси мөнәсәбәт, бәхет һәм акча, яшәү һәм үлем кебек үткен мәсьәләләрне дә әдип бүген читләтеп үтә алмый. Әмма язучының максаты—укучыны психологик һәм әхлакый һәлакәттән саклау. Шунлыктан киләчәктә дә гомумкешелек кыйммәтләренең әдәбият үзәгендә калачагына мин шикләнмим.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

# НАЗЛЫ МОҢ

РӨСТӘМ ЯХИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ



*Рөстәм Мөхәммәтҗан улы Яхин (1921—1993)—мәшһүр композитор һәм пианист.*

*РСФСРның (1980) һәм СССРның (1986) халык артисты.*

*Татарстан Республикасының Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1959).*

*Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы.*

*Төп әсәрләре түбәндәгедән гыйбарәт: фортепиано һәм симфоник оркестр өчен концерт; «Идел» кантатасы, 30 га якын фортепиано, скрипка һәм виолончель өчен әсәрләр; 400 дән артык романс һәм җырлар; «Фидаи» балетына язылган музыка.*

## Шәхесне аңларга омтылу

Бер күренекле француз шагыйреннен: «Сәнгать тоткынлыкта туа, көрәш эчендә яши һәм иректә җан бирә»,—дигән тирән мәгънәле сүзләре Иҗатның иң асыл сыйфатларыннан берсен ачып бирә сыман. Чөнки шушындый Илаһи бөеклеккә омтылу гына сәнгатькяргә чын мәгънәсендә Олуг хакыйкатьне табарга булыша һәм гүзәл әсәрләр тудыру юлында таяныч булып тора. Әмма, мәгълүм ки, хәтта чын талант ияләре дә, күп кенә очракларда, үзләре яшәгән чорны «узып» китсәләр дә, алар да кайбер ялган инанулардан һәм эпоханың «йогышлы авыруларыннан» бөтенләй үк азат түгелләр. Юк, алай гына да түгел, эчке кичерешләр өермәсендә туктаусыз көрәштә яшәү сәбәпле, алар кайчак гадәти тормыш вәсвәсәсенә тизрәк бирешүчән булалар.

Ләкин иҗади шәхеснең асыл нисбәтен болар билгеләми, әлбәттә; һәм аның тирәндә яткан күңел дулкыннарын аңлау өчен көндәлек тормышындагы һәм туктаусыз дәвам иткән иҗатындагы эреле-ваклы бик күп детальләрне белү генә дә аз. Сүз дә юк, фактларны белү зур әһәмияткә ия; чөнки алар кешелек тарафыннан кабул ителгән кануни социологик тикшеренүләрдә сәнгатькярнең шәхесе һәм аның сәнгатьне үстерүгә керткән өлеше турындагы фикер-билгеләмәләрнең нигезен тәшкил итәләр. Кызганычка каршы, бу алым, өлешчәдән гомумилеккә килү юлында, күп кенә кимчелекләргә дә ия һәм ул, могаен, объективлыкка дәгъва кылырга да хаклы түгелдер. Бу нәүбәттән кешенең рухи дөньясын өйрәнүче—тышкы эшчәнлек кысалары артында күмелеп калган эчке күңел хәрәкәтен күзәтүче яңа заман фәне—антропософик караш нәтиҗәлерәк сыман тоела. Чөнки антропософик алым—гомумилектән өлешчәгә килү алымы—кеше җанын тирәнрәк аңларга һәм аның рухи дөньясына нинди рухи һәм идея агымнары тәэсир итә дигән сорауга тәгаен дөрес җавап табарга, иҗади шәхеснең югары кешелек идеалларына һәм заман куйган таләпләргә ни дәрәҗәдә шифалы өлеш кертә алуын билгеләргә мөмкинлек бирә. Шул рәвешле күп кенә тар карашлы, «бер каптырмалы» бәяләмәләр төссезләнеп кала; нәтиҗәдә, Кеше дигән бөек затның чын мәгънәсендәге

галәми сурәтен аңлауга юл ачыла. Мондый аңлатуда исә, иҗади уңышлар гына түгел, ә бәлки иҗатчының күңел тирбәнешләрен—рухи камертоннар аша—аңларга омтылу, рухани эзләнүләрдәге газаплар, кешелеккә хезмәт итүдә үз-үзенне аямау кебек төшенчәләр дә зур әһәмияткә ия.

Ихлас ки, бу нәүбәттән олуг композитор Рөстәм Яхинның шәхси гәүдәләнеше һәм аның кабатланмас иҗат юлы шушындый тирән уйлануларга этәрә. Әйе, ул, әйткәнебезчә, олуг композитор, менә дигән талантлы булу пианист, яхшы күңелле кеше булу өстенә, Җанын иҗатка алыштырган Бөек Рух иясе буларак та гәүдәләнә. Композиторның күңелләрне биләп алган гаҗәеп шагыйранә сурәте—бигрәк тә, чорның массакүләм авыруына әйләнгән дөньяны кабул итүдәге чикләнгәнлек һәм меркантиль исәплелекнең капма-каршы аңлатмасы булып тора кебек.

... Рөстәм абый белән безнең дуслык узган гасырның 60 еллар ахырында, мин Гнесиннар исемендәге Мәскәү музыкаль-педагогик институтын тәмамлап Казанга әйләнеп кайткач, Татарстан филармониясендә скрипкаче-солист булып эшләгән чагында башланды. Концерт сезоннары ачылган көннәрнең берсендә Рөстәм абыйның да иҗат кичәләре оештырылган иде; билгеле ки, анда минә да катнашырга туры килде. Аңлашылса кирәк, шуннан соң без еш кына аралаша торган булып киттек. Моның үзенә күрә аңлашыла торган «житди» сәбәпләре дә бар иде: без күршеләр булып чыктык һәм композитор әнисе—Мәрьям апаның якты күңел нуры төшкән чиста-пөхтә, тынычлык һәм уңайлылык хөкем сөргән Рөстәм абый фатирында—ул пианинода уйный, мин скрипкада дигәндәй—бергәләшеп репетицияләр ясый башладык.



*Композиторның әнисе Мәрьям Яхина*

Шушы рәхәтле газаплунулардан соң,—уйлагыз ки, укучы белән маэстро арасында,—Рөстәм абый белән безнең арада дустанә җылы мөнәсәбәт урнашты һәм бу рухи аңлашучанлык аның соңгы көннәренә кадәр дәвам итте. Әмма без әшнәлектән ерак тордык дип исәплим, ә мондый халәте рухия ике арадагы мөнәсәбәтләрдә үзара бәйсез булып калырга мөмкинлек бирә иде, шул ук вакытта без кирәкмәгән артык шартлылыктан да котыла алдык кебек (билгеле бер чиктән чыкмаган хәлдә), әмма бер-беребезгә карата фикерләребезне ачыктан-ачык әйтешүдән дә тайчанмадык. Югыйсә, безнең яшь аермасы да шактый иде ләбаса...

Үткәннәргә әйләнеп карыйм да, Рөстәм ага шәхесе тудырган тәэссоратлар тирәнлегенә кереп адашам. Гаҗәеп мөлаемлылык, йомшак күңеллелек, әдәплелек һәм чын музыкаль сәләт, үтә дә нечкә сәнгати тоем белән өртелгән затлылык—берсеннән-берсе калоритлырак татар зыялылары арасында да әнә шушы сыйфатлары белән аерылып тора иде ул. Шул ук вакытта Рөстәм Яхинның таланты белән аның социаль статусы—«алга киткән социализм» шартларында совет композиторы турында рәсми кабул ителгән рәсми кысаларга сыеша алмау—кайбер даирәләрдә хәтта гаҗәпләнү дә тудыра иде.

Иҗаты гөрләп чәчәк аткан чорда (ана әле 50 яшь тә тулмаган иде) һәм музыкант буларак танылган бер мәлдә ул беркайда да «эшләмәде», бары әсәрләреннән кергән керем хисабына гына яшәде (бу үзе үк бер шәхси батырлык иде). Әйе, ул партия сафларында да тормады; социализмның «бөек җиңүләрен» мактаган симфония, опера кебек эре формадагы әсәрләр дә иҗат итмәде (житмәсә, ул вакытта Рөстәм абый өйләнмәгән дә иде). Болар барсы да гаепкә саналдылар, әйткәнебезчә, рәсми даирәләрдә композиторның дәрәҗәсе монументаль әсәрләр иҗат итүгә карап бәяләнә иде.

Кабатланамдыр, бәлки: ул чорда гадәти фикерләүдән югары торган, тар «араннарга» сыймаган бу ихласиятле талант иясе турында төрлечә фикер ишетергә туры килде. Аны нииндидер чикләнгәнлектә, тормыш агышына җайлаша белмәүдә, кайбер зыялыларга хас булганча, «кояш астындагы җылы урын өчен көрәш алып барудан баш тартуда гаепләүчеләр дә табылмады түгел, табылды. Әмма

интеллектуаллар арасында була торган мондый имеш-мимешләрнен берсе дә. Ходайга шөкер, чынлыкка туры килми иде шул. Композитор белән булган очрашулардан, бергә катнашкан концертлардан сон кабат-кабат шуна инана идем: Рөстәм ага тормышта сирәк очрый торган зирәк акыллы, рухани чиста күнелле, искиткеч сабыр, түземле шәхес иде. Анын тышкы кыяфәте дә шушы образ-сурәткә тәнгәл килеп тора иде: әйе, уртача буйлы, кинчә жилкәле, ачык чырайлы бу кеше күнелдә нәзакатьле-жылы хисләр уята иде.

Икенче яктан, шушындый хиссиятле сәнгатькярләрне , консерватив тирәлек-мохит белән ярашып яши алмавы нәтижәсендә, икеләнүле хисләр өермәсе эчендә яшәде дип тә уйларга мөмкин булыр иде. Ләкин бу караш та хакыйкатькә туры килеп бетми кебек. Дөрестер, бәлкем: Рөстәм Яхин көтелмәгән, башбаштак адымнар ясаудан ерак тора иде; ләкин, кирәге чыкса, ул актив карашлы, үз-үзен якларга сәләтле шәхес тә була белә иде; шул ук вакытта ул менә дигән педагог һәм башкаручы да булып китә алыр иде (яшьлегендә ул моны бик әйбәт исбат итте!). Ижатынын өлгергән чорында ул ирекле сәнгатькяр халәте белән канәгать иде һәм бу анын бәйсезлеккә омтылучан жанына бер таяныч-этәргеч булып тора иде. Дөрес ки, мондый яшәү рәвеше кабул ителгән «идеаллар» белән еш кына каршылыкка та керде һәм мондый хаят, яралanучан күнелле шәхестән, кырыс мохит тарафыннан күрмәмешкә салынылса да, эчке рухи көч сарыф итүне таләп итте.

Рухият турындагы фән күзлегеннән чыгып караганда, монда барысы да анлашыла: көндәлек тормыш ваклыкларына һәм тышкы мохит тәэсиренә бирешмичә, үзеннен жанындагы кыйммәтләрне сакларга омтылу—Олуг сәнгатькярнен яшәеш мәсләге менә шуннан гыйбарәт иде. Юк, бу тормышнын реаль чынбарлыгыннан качарга омтылу түгел иде. Сәнгатькяр рухи кыйммәтләрне башка нәрсәләрдә күрде; кыскасы, кешеләр белән сәнгать телендә анлаша алу ана барыннан да кадерлерәк иде. Анын шушы юнәлештәге эзләнүләре барлык вөжүде, намусы һәм туктаусыз хезмәте белән расланды.

## Рөстәм Яхин—рояль янында

Композитор белән беренче күнегү ясаган вакытта ук,—без анын скрипка өчен язылган «Поэма»сын өйрәнә идек,—мин бер кыен хәлдә калдым: ул көйнен кайбер жирләрендә, бигрәк тә ахырына житәрәк темпны бик нык тизләтергә кушуы белән тәмам шаккаттырды; икенче төрле итеп әйткәндә, мин галәттә музыка укытучылары «каршы көрәш алып барган фразаны йоту» белән шөгыльләнергә тиеш идем. Анлашылса кирәк, мин аптыраудан гажиз идем һәм анын бу тәкъдиме минем тарафтан музыкаль агышны рәхимсез рәвештә тураклау буларак кабул ителде. Дөрес, мин романтик кысалар жирлегендә темп һәм ритмнан бераз читкәрәк тайпылуга да риза идем, әмма, нишлим, автор тәкъдим иткән формада бер генә музыкаль фразаны да профессиональ дәрәжәдә дөрес башкарырдай халәттә түгел идем инде. Кулым да, башым да, дигәндәй, мондый «башбаштаклыкны» кабул итәрлек халәттә түгел иде.

Шулай интегә-интегә төп теманы кабатлау (mesto—трагик) өлешенә килеп житкәч, гажәпләнүем тагын да арта төште. Рөстәм Яхин башкаруындагы иреклелек бернинди традицион кануннарга да сыймас кебек иде һәм, ни гажәп, нотада билгеләнгән метро-ритмик төзелеш бөтенләй яна төсмерләр алып янгырый башлады. Мин, яшь музыкант, түзеп тора алмыйча, кызулык белән бер тактта диярлек кулланылынган (кирәгеннән артык!) тизләнеш музыкаль аһәннен табигый ачыгын боза, анын гомум—бөтен янгырашына зыян китерә, дип исбатлый башладым. Ахыр чиктә: «Дөньяда берәү дә болай уйнамый, болай башкару мөмкин эш түгел»,—дип тә өстәдем.

Менә шушы очракта Рөстәм абый мина мәнге онытылмаслык (онытканым да юк!) сабак бирде дә инде. Юк, ул бәхәсләшеп тормады, бары тик берни булмагандай хиссиятле бер халәттә галәти метроритмиканы үзенчә үзгәртеп, көйне рәттән берничә кабат (дөрес биргән кебек!) уйнап күрсәтте дә, аннары ниндиләр бер тирән хәсрәт эченә чумып, әлеге мин «абынган» өзекне башкарырга кереште. Гажәби вә шаккатмалы хәл: шушыннан сон минем анымда rubato (ягъни, иреклелек-иркенлек) турындагы катып калган күзаллавым челпәрәмә килде. Хәтта шулай әйтергә мөмкиндер, Рөстәм абый Яхин музыкасын билгеле бер тактларга дөрес бүлеп чыгып кына, трафарет

башкаруларнын шаһиты булсам да (мондый очракта иркенлек, импровизация турында сүзнен булуы да мөмкин түгел, ләбаса), берьяклы карашка кунелем белән каршы килә торган булып киттем. Сонрак, пианистка Флора Хәсәнованын Рөстәм Яхин иҗат иткән «Вальс-экспромт» әсәре буенча кунегүләр алып барган вакытында катнашырга туры килгәч, мин дә композитор биргән педагогик алымны кулланып карарга җөрьәт иттем. Һәм мин тагын Рөстәм абыйга хас кодрәтнен башкаручыга нинди көчле унай тәэсир итүен күреп шаккаттым—шушы бер-ике сүз белән фикерләребезне уртаклашкач, Флора ханымга, әйтерсен лә, фәрештәви канатлар үсеп китте: болай да югары профессиональ дәрәҗәдә, эмма «дөрес» башкарылган музыка, аранынннан иркен далага җибәрелгән уйнак чабышкыны хәтерләтеп, йөгерек тә, монсу да төс алып янгырый башлады. Әлбәттә, башкаручынын унышында Рөстәм аганын (бу очракта минем нәкъ шушындый олылау сүзен кулланасым килә) күзгә күренмәс сихри тәэсире дә бар иде.

Беренче музыкаль кунегүләр алып барган көннәремдә үземчә башкачарак ачышлар да ясадым кебек. Аерым алганда, төрледән-төрле пентотоник виртуоз бизәкләргә бай һәм техник яктан тиз башкарылышлы (әйтергә кирәк, анын музыкасы мондый сурәтләргә бик бай) Рөстәм абыйнын уйнау-башкару өслүбе баштарак мина бер дә ошап житмәде. Әйе, ул фортепиано өчен язылган пьесаларында, хәтта скрипка өчен иҗат ителгән «Сүзсез җыр» дип аталган әсәренен ахыргы тактларында, югарыда телгә алынган «Поэма»нын кульминация өлешендә гаҗәеп аһәнле пентатоник бизәкләрне бик унышлы кулланды. Анын башкару алымында ул еллардагы совет фортепиано мәктәбенә хас булган токкато куәтле, гайрәтле янгыраш, гаҗәп ки, житеп бетми иде, әйе, бу шулай тоела иде. Рөстәм Яхиннын бармаклары фортепиано клавишаларына тияр-тимәс кенә кагылып китәләр; юк, әйтерсен лә алар клавишалар өстеннән йөзеп кенә йөриләр һәм шул рәвешле житез, табигый бармак хәрәкәтләрендә ниндидер бер жинеллек, табигыйлек, бердәйлек хасил була. Тынлаучы буларак, бу мине гаҗәпкә калдыра иде, профессиональ башкаручы күзлегеннән чыгып караганда, монарчы яшәп килгән кануннарга каршы килә иде[1]. Вакытлар үтү белән Рөстәм абыйнын уйнау-башкару алымына тәмам кунегеп беттем, хәтта эстетик эзләнүләрнен юнәлеш үзенчәлекләрен ачык тоемлый башладым, шул рәвешле, тора-бара, анын әсәрләрен «җинел кул» белән башкарырга кирәклеген төшендем. Һәм, әйтергә кирәк, ул үзенен әсәрләрендәге катлаулы урыннарны башкарганда, өйрәнчек укучыларга хас дөрес «такылдатуларны» ишетсә бик тә көенә иде, аерым очракларда компромисс рәвешендә җинелрәк вариант тәкъдим итә иде.

Рөстәм Яхиннын башкару стилен антропософик аспекттан чыгып бәяләгәндә, мөгаен, ин беренче чиратта шуна игътибар итәргә кирәктер: традицион күзаллауларга сыеша алмаган иркенлекне һәм өрфиядәй җинел-виртуоз уйнау техникасын бер ук башлангычтан—ин универсаль, эмма шул ук вакытта индустриаль эпоханын ин камил механик-материалистик уен коралларыннан берсе булган фортепианонын механик табигатен рухи өслүбкә буйсындырырга омтылудан эзләргә кирәктер. Әйе, Рөстәм Яхиннын даһилыгы да шуннан гыйбарәт, анын язмышына татар сәнгате өчен бик тә әһәмиятле булган югары кимәлдә фортепиано уен коралын «үзләштерү» туры килә. Чөнки сер түгел ич, бу уен коралы күп еллар дәвамында татар тамашачылары тарафыннан инкарь ителеп килендe. Әйтергә кирәк, композиторнын пианистлык таланты бу киртәне күпмедер күләмдә унышлы үтеп чыгарга ярдәм итте. Оста уенчы кул астында бу уен коралы гүяки жанланып китте, анын тавышына татар рухы иҗдерелде һәм ул төрле катлам тынлаучылар тарафыннан үз итеп кабул ителә башлады.

Рөстәм Яхиннын виртуоз уены сәнгатькяр белән якыннан аралашкан Казан фортепиано мәктәбе вәкилләренә дә шифалы йогынты ясады. Тагын шунсы да әһәмияткә ия, композиторнын орнаментлар белән чигелгән әсәрләренен музыкаль тукымасы үзеннән-үзе бармак йөрешләренен җинеллегенә, табигыйлегенә этәрә. Рухани фән өйрәтүләреннән чыгып бәя биргәндә, болар фикер йөртү сөрешенә дә йогынты ясамый калмыйлар һәм композиторда сыгылмалы, сизгер-нәзакатьле акыл булуы хакында искәртәләр.

---

[1] 80 елларда бөек Америка пианисты В. Горовицнын СССР да үткән гастрольләреннән сон мондый уйнау-башкару алымы безнен илдә дә яшәү хокукы алды.

## Композиторның иҗат «лабораториясендә»

Рөстәм Яхин эшчәнлегенең бу ягы ятлар өчен бөтенләй диярлек таныш түгел. Үзем өчен мин аның яңа язылган әсәрләрен бергәләп редакцияләү һәм эшкәртү барышында, шулай ук уртак кичәләр ачып барганда ача төштем. Ләкин, яшермим, композиторның яңа әсәрләр иҗат итү процессы белән танышлыгым озак вакытлар томанлы булып кала бирде һәм бу хактагы фикерләрем дә традицион музыка белгечләре турындагы гомуми аңлатмалардан читкә чыкмады бугай. Бу яктан караганда, ул заманнан бераз арттарак калган сәнгатькяр һәм 60-70 елларда совет музыка сәнгатендә өстенлек иткән мелодизм тарафдары буларак кабул ителде; музыка белгечләре Рөстәм Яхин иҗатының нигезен Рахманинов традицияләре һәм «беркатлы гадилеккә» корылган халык иҗатына хас пентатоник аһәңнәр тәшкил итә дип билгеләп үттеләр. Композиторның иҗат «лабораториясе» белән якыннанрак танышкач, димәк, иҗат эшчәнлегенең серләрен үз күзләрем белән күргәч, мина бу мәсьәләгә икенчерәк яктан торып карарга мөмкинлек туды.

Бу нәүбәттән «Иске көй» пьесасы белән бәйләнешле бер вакыйга хәтергә килә. Рөстәм абыйның Татарстан китап нәшриятында чыгачак «Яшь скрипкачы» дигән җыентык өчен озак вакытлар берәр әсәр язарга үгетләп килдем. Берничә ел дәвамында берникди дә вәгъдә биреп ышандырмады, бары тик берәр романсын скрипка өчен «җайлаштырырга» тәкъдим ясады. Әмма җыентык басмага әзерләнеп бетте дигәндә, ул мина скрипкамны «кыстырып» үзләренә сугылып чыгарга кушты һәм җыр-бию темаларына корылган пьесаның каралама вариантын уйнап күрсәтте. Аларның икесе дә скрипка өчен бик ярашып торалар иде һәм без тиз арада бу әсәрне басмага хәзерләү эшенә керештек. Мин берничә өстәмә кертергә, аерым алганда, лирик теманы кинәйтеп, тембр бизәкләре өстәп, ниһаять, уйнарга уңайлы булсын өчен пьесаның аһәңен ми бемоль мажордан ми мажорга күчерергә тәкъдим ясадым. Беренче ике тәкъдим белән автор шунда ук килеште, әмма аһәңне үзгәртү мәсьәләсе, сизеп торам, аны кыен хәлгә куйды. Дөресрәге, мондый борылыш аның иҗади «планына» кермәгәнлеге сизелеп тора иде һәм ул беркавым үзенең карашларын ничегрәк якларга белмичә аптырабрак торды. Пьесаның башламын әле бу тональлектә, әле икенче тональлектә берничә кат уйнап карады да кинәт яктырып китеп: «Кара әле, бемоль варианты бөтенләй башкача янгырый икән бит, жылырак та, хислерәк тә»,—диде. Шулай итеп, минем скрипкада ми мажорда ачык кыллар—сызгыч белән генә уйнау сагышлырак та, яңгырашлырак та булыр иде дигән фикерләрем бер минут эчендә челпәрәмә килде. Әйе, Рөстәм абый тональлекне шулкадәр нечкәләп тоя иде һәм йөрәк тойгыларына тулаем ышана да иде. Соңрак тональлекне эчке күңел сизгечләре белән сизүнең хаклы бер күренеш икәнлегенә антропософиягә нигез салучы Р. Штайнерның рухи-фәнни хезмәтләрен өйрәнгәч инандым.

Рөстәм Яхинның романслар иҗат итү алымы белән якыннанрак танышкач, композитор өчен акыл-фикер түгел, ә эчке сиземләү беренчел икәнен аңладым. Бу мәсьәләдә ул, әйткәнемчә, рәсми кабул ителгән «социалистик реализм» методыннан ерак торды, сюрреалистларча эчке тоемга ышанып эш итте. Рухи тирәнлек төшенчәсе, мөгаен, аның өчен ниндидер бер билгесез чонгыл булмагандыр дип уйларга кирәк. Ул, күрәсең, тышкы-маңгай күзе кебек үк, дөньяны ачык күрә алган күңел күзенә дә ия булгандыр һәм шуның ярдәмендә акыл ирешә алмаган нюансларны күрә-тоя алгандыр. Чынбарлыкны музыка аша танып белүдә, әлбәттә, сизгер йөрәк булу да төп шарт булып тора; ул рухны өйрәнүчеләргә хас булганча, җанындагы һәм фикерендәге ак һәм кара якларны дөрес тотып ала белде һәм болар барысы бергә ана сәнгатьчә хакыйкатьне эзләү юлында казык йолдызы хезмәтен үтәделәр, шушылар иҗади фантазиясенә көч биреп тордылар.

Әмма шулай да эчке дөньясын аңлауга ул тиз генә ирешә алмады әле. Бер үк романсның мелодиясен, гармониясен, фактурасын анализлаганда, ул күзгә күренмәс аермалыкларны—орлыкны кибәктән аерып, ул кайвакыт көннәр һәм төннәр бу эшләп утыра торган иде. Тагын шулай да була иде, кайсы вариант отышлырак (?) дигән үтә дә нәзберек сорауга дөрес җавап табу өчен дус-ишләре белән дә киңәш-табыш итешә иде. Күп очракта болар әңгәмәдәшеннән җавап көтелми торган риторик сораулар була иде, әлбәттә. Композиторның эчке газаплар эчендә янганы күренеп тора, ә

мондый чакларда читтән бирелгән кинәш ярдәмче түгел инде ул. Хакыйкать өчен, ләкин, шунсын да әйтеп үтим: кинәшеп арып туктаган әңгәмәдәшнен кинәше, күп очракта, «әсәр барлык вариантларда да әйбәт, тик җөрьәт итеп берсенә генә тукталырга кирәк» дип тәгалләнә иде. Ә чишелеш автор тарафыннан кызык кына хәл ителеп куела иде. Физик яктан тәмам арып туктагач һәм куәтле акылы да томалана төшкәч, композитор хис дилбегәсен кулыннан ычкындырмаган хәлдә, тулаем әчке дөньясына кереп бикләнә иде. Монда чакта, кинәт күк капусы ачылгандай, икеләнүләр юкка чыгып, ана якты акыл, саф идеяләр инә иде.

Сонынннан Татарстан Республикасынын Гимнына әверелгән «Туган ягым» романсын камилләштерү буенча эшләгәндә мин монын шулай икәненә тагын бер кат инандым. Шулай бер репетиция вакытында Рөстәм абый өстәл тартмасыннан ниндидер вокаль әсәрнен каләм белән генә язылган нөсхәсен алды да фортепиано янына утырып төзәтергә тотынды. Ниндирәк әсәр булачак сон ул дигән сорауга җавап рәвешендә композитор әлеге әсәрне ана гына хас булган күтәренкелек белән уйнап күрсәтте дә музыкадан алган тәэсирләребез белән кызыксынды. Фикерләребез белән дим, чөнки биредә җырчы Эмиль Җәләлетдинов та бар иде; ул әсәрне, әлбәттә, күкләргә чөеп мактады. Мин дә анын фикеренә кушылдым, ләкин һәр яна әсәрне тынлаганда була торганча кайбер теләкләремне дә әйтергә җөрьәт иттем: «Рөстәм абый,—дим,— башлангыч мотивны бераз үзгәртергә кирәк түгел микән? Чөнки ул Имре Кальман опереттасындагы «Мистер Икс»нын атаклы ариясенә ике тамчы су кебек охшаган»,— дим. Шушы сүзләрне әйтеп тә бетермәдем, Рөстәм абыйнын уйнау дәртен кабатларга тырышып, ариядән танылган мотивны шыншып күрсәттем: «Мин арыдым инде...»

Күрәсен, композитор өчен бу көтелмәгән хәл булмагандыр. Ул беркадәр кыенсынып калса да, шунда ук башлангыч мотивларны берничә вариантта уйнап та күрсәтте, шулардан берсе, әйтергә кирәк, күнелгә бик тә хуш килде. Шуннан сон композитор, ана гына хас булганча, төрле вариантларны бертуктаусыз эшкәртергә, шомартырга кереште. Хәер, бу юлы әлеге процесс әлләни озакка сузылмады: ул үзенен күнегүләрен бетерер алдыннан, югары күтәренкелек белән, кабаттан беренче вариантны уйнап алды. Һәм барыбызга да анлашылды: башкача булуы мөмкин түгел иде!

Билгеле, мин ул вакытта гасырлар әсәрен тынлавымны анлап житкермәгән идем әле. Ләкин композиторнын гомер сонында, Татарстан гимны өчен яраклы музыка эзләгәндә (мин комиссия әгъзасы идем), бу әсәр белән кабат «очрашырга» туры килде. Гимн өчен чынлыкта «көрәш» ике әсәр—Рөстәм Яхиннын телгә алынган романсы һәм «Шүрәле» балетыннан Ф. Яруллин эшкәртүендәге «Тәфтиләү» халык көе арасында барды. Билгеле ки, алар музыкада ике юнәлешне чагылдыралар. Рөстәм Яхин әсәре Ауропача стилистик үзенчәлекләрне чагылдырса, «Тәфтиләү» исә халык күнеленә якын кичерешләр белән сугарылган. Кинәшү-бәхәсләр барышында, баштарак «бизмән» әле бер якка, әле икенче якка авышты, әмма сонгы утырышта комиссия әгъзалары күпчелек тавыш белән Рөстәм Яхин әсәренә тукталырга карар кылдылар.

Гадәттә фикер йөртү юлы белән сайлап алудагы мондый гадәллеккә җавапны әлеге дә баягы сонгы дәвернен мәшһүр фикер иясе Р. Штайнернын «Музыка серләре» хезмәтеннән дә таба алабыз (анда кеше рухын өйрәтү мәктәпләренен музыкаль башлангыч серләре хакындагы өйрәтмәләренә нигезләнеп фикер йөртелә). Шушы тикшеренү кысасыннан чыгып караганда, «Тәфтиләү» көе (кайбер мәгълүматлар буенча ул «Сөембикә» бәетенә барып тоташа икән) борынгы пентатоник мәҗүсилек мотивларын чагылдырган ТАО (ДАО)[1] белән тыгыз бәйләнештә тора; биредә кешеләр дөнья белән Илаһи башлангыч идарә итә һәм шәхси «мин» мәнгелектә эреп югала дигән идеяләр белән яшәгән ерак үткәннәрнен кичерешләре чагылыш таба.

Рөстәм Яхиннын мажор-минор гармоник системасында иҗат ителгән әсәре башкачарак кичерешләр белән бәйләнгән һәм ул кешедәге индивидуаль башлангычка мөрәҗәгать итә. Мажор терциядән (диатоник гамманын өченче баскычыннан) башланып, әсәр әкренләп төп темага төшеп житә дә аннары кинәт кенә бер октавага өскә сикерә. Антропософик тикшеренүләр нигезендә, кеше индивидуаль хисләре эчендә эзләнеп, киләчәккә, югары идеалларга таба көчле омтылыш ясаганда шушындыйрак халәттә була. Шулай итеп, Рөстәм Яхиннын әлеге әсәрендәге темада заманнын рухи культурасы үсешенә хас яна тенденция, аерым алганда, ТАО

[1]Кара: «Казан утлары», 2000, № 12, 157-169 бб.

мотивлары өстенлек иткән чорда яшәгән кешеләр ирешә алмаслык булган башлангычның галәми рух белән тоташу принциплары тормышка ашырыла.

Рөстәм Яхин иҗатында мондый әсәрнең тууын, аның музыкаль интонацияләр эзләнүләр өлкәсендә—камиллеккә ирешүдә!—чын мәгънәсендә титаник эш башкаруын белгән хәлдә дә, очраклы сиземләүгә генә кайтарып калдырырга ярамый; шул ук вакытта ике лад системасын—пентатоника һәм хроматика (ягъни, Аурупа) системаларының асылына үтеп керү юнәлешендәге табышларны да, кем әйтмешли, бер кая куялмыйсың. Әйтергә кирәк, үтә дә «милли рухлы» композитор тарафыннан кайбер әсәрләрендә урыс һәм украин музыкаль лирикасына хас тулы бер аһәнле рәтләрнең, ачыктан-ачык дигәндәй, кереп китүе күпләрне гаҗәпкә калдыра торган иде. Кайчакта кайберәүләр моны композиторның «җегәре кимү» дип бәяләргә ашыктылар. Ләкин игътибар белән карaганда, бирелә бөтенләй башкача күренешләр тәгаенләнә иде. Мәгълүм ләбаса, ул иҗатның башыннан алып, ахырынача ике төр стильгә дә—пентатоникага да, хроматикага да—игътибар итеп килде һәм, нәтиҗәдә, совет чорындагы татар культурасына «музыкаль интеллектның» гаҗәеп киң офыклары ачыкланды. Рөстәм Яхин туган телен дә, урыс телен дә камил белгән кебек үк, музыкаль стилистикада да шушы омтылышларын канәгатьләндерергә омтылды. Шуна күрә композиторның әсәрләре Глинка һәм Чайковский исемендәге дөньякүләм танылган халыкара конкурсларда еш башкарылып килүен очраклы бер хәл дип кабул итәргә ярамый.

Искәртеп үтик, Рөстәм Яхин «ике телле» музыкант булуыннан бер дә гарьләнми иде, хәтта канәгатьләнү хисләре дә кичерә бугай иде әле. Мостай Кәримнең «Җәяүле Мәхмүт» музыкаль-драматик спектаклендәге скрипка һәм фортепиано өчен язылган «Бию»ендә ул (бу аның иң соңгы әсәрләреннән берсе иде) Аурупа стиленә мөрәҗәгать итте. Һәм менә бу гаҗәпләндермәде дә. Дөрес, алымның анлану-анланмавы хакындагы соравына ул турыдан-туры җавап бирүдән «качты» һәм студент елларында ук шушындыйрак алымда скрипка өчен соната иҗат итүе, аның янача, үзгәртелгән вариантын эшләп чыгарга омтылуы хакында сөйләп китте.

Шул вакыт, моннан егерме еллар чамасы элек үк радиога әлеге сонатаны яздырырга теләк белдергәнлеге хәтеремә килеп төште. Ул чагында, оятыма каршы, мин бу әсәргә тиешенчә игътибар итмәдем, аны урыс романтизмына тартым бер әсәр дип исәпләп, янадан карап-эшләп чыгарга киңәш бирдем. Хәтта атаклы композиторның, татар милли музыкасын әйдәп баручы аһәнсазның үсмер чакта иҗат ителгән әсәрен кабат торгызырга маташу бераз сәеррәк тә тоелган иде.



*Рөстәм Яхин үзенең иҗат кичәсендә*

Икенче яктан анын мондый стильдә язылган әсәрләре мине үзенә җәлеп тә итә иде. Хәтерлим, М. Тажетдинов сүзләренә язылган «Әгәр син китсән...» дип урысчага тартым аһәнле романсын фортепианода уйнап күрсәткәч, музыкаль сурәтләрнен тирәнлеге һәм кин сулышлы булу хакында сүз кузгаттым да берничә генә нотадан, гади генә бер аккордны көйләүдән торган темада эчке кичерешләрнен өрфия дулкыннары чагылыш табуны искәртеп үтмәкче идем дә... композитор рәхәтләнеп бер елмаеп куйды. Шушы кыска гына анлашудан сон Рөстәм абый тыелган китаплар җыю белән шөгыльләнүче «диссидент» кебек серле караш ташлап алды, аннары яшерелгән җиреннән караташ-каләм белән генә язылган нота эскизларын табып алып килде һәм үзенен ул елларда җәмгыять тарафыннан кире кагылган милли кысаларга сыеша алмаган музыка үрнәкләре белән таныштыра башлады. Мондый рухтагы әсәрләре ана бик тә кадерле иде, мондый чакта ул, әйтерсен лә, Изге Китаплардагы «якын кешенне үз-үзенне яраткан кебек ярат» дигән васыятькә якын хисләр кичерә иде.

Безгә анын белән урыс музыкасында да пентаноника билгеләре сакланып калуы һәм борынгы татар һәм славян культураларында күпмедер охшашлык булуы хакында гәп корып утырырга туры килгәләде. Мондый караштан чыгып бәяләгәндә дә композиторнын иҗаты космополитик рухта кузалланмый һәм милли традицияләрне оныту яки ана хыянәт итү буларак кабул ителми. Җитмәсә, Рөстәм Яхин әледән-әле биштавышлы темаларга мөрәҗәгать итеп, чын милли рухлы даһи әсәрләр тудырды (бу очракта мин «Сандугач» һәм «Сорнай моны» кебек җырларны күз алдында тотам), әйтергә кирәк, 70-80 елларда профессиональ композиторлардан бик азлары гына мондый адымнар ясарга батырчылык итте. Бишбаскычлы халыкчан мелодиядә ул, әйтерсен лә, бабаларыбызнын инрәү авазын ишетте һәм аны бозылмаган, чиста хәлендә киләчәк буыннарга тапшырырга омтылды, дини-рухи кыйммәтләрне югалтмый саклаган кебек...

«Бию» әсәренә репетицияләр ясаганда күнелне биләп алган шушындый уйланулар һәм пентатоникага мөнәсәбәтле сөйләшүләр вакытында мин шуна төшендем: Рөстәм Яхин өчен миллилек аһән-көйне ишетүдән югарырак, изгерәк төшенчә икән ләбаса. Моны салкын акыл белән кабул итеп бетерү мөмкин эш түгел иде, әлбәттә, ләкин күнел-хисне алдап булмый шул—без бергәләп башкарган «Бию» дә тышкы билгеләрдән торган бәяләмәдә берниндидә пентатоника өлгеләре юк сыман, ә тирәндә барыбер халык рухи ятканын сизәсен. Күрәсен, татар халкы Рөстәм Яхиннын пентатоникага корылган чын милли рухтагы әсәрләрен генә түгел, башка халыкларнын музыкаль традицияләре дә ачыктан-ачык чагылыш тапкан иҗат үрнәкләрен дә җылы кабул итте.

## Күңел агышы һәм язмыш ыгы-зыгылары

Яшәешнен асылына бәхет турындагы гадәти-тапталган төшенчәләргә таянып кына һәм язмышны үз йөрәген аша үткәрмичә торып шәхесне тулаем анлау мөмкин түгел. Болай дигәндә, бөек алман шагыйре Гетенын рухи эзләнүләрендә чагылыш тапкан: «Хисләр алдашмыйлар, акыл гына ялгышырга мөмкин»,—дигән сүзләре хәтергә килә. Чыннан да, бөек шәхесләрнен эшчәнлеге шуны күрсәтә, кеше күнеленен тирән чонгылларында язмыш тарафыннан бүләк ителгән олуг хыялларны тормышка ашыру теләге һәрвакыт көчле була һәм ул еш кына көндәлек мәнфәгатьләргә каршы да килергә мөмкин; ләкин нәкъ менә алар кеше җанындагы югары башлангычны ачыкларга ярдәм итәләр. Рөстәм Яхиннын тормышы һәм иҗаты шушы кимәлдәге камиллеккә ирешү мисалы буларак кузаллана (Тик кызганыч ки, бүген—җан саклау турындагы фикерләр өстенлек иткән заманда мондый сыйфатлар бик үк югары бәяләнми шул. Болар, имеш, кулай очракта да Рухны өйрәнү мәктәпләре шәкертләренә—«мәгарә» тынлыгында яшәп, дөньядан аерылган кешеләргә генә хас сыйфатлар, тик замана иҗатчысы бу халәттә була алмый, янәсе).

Композитор белән аралашу барышында ин әүвәл күзгә ташланганы һәм мин мөкиббән киткәне шул иде, ул да булса, анын кин күнеллелеге, кешеләргә һәрвакыт ихтирамлы вә игътибарлы мөнәсәбәт саклый алуы иде. Дөрес, кайберәүләр

тарафыннан болар йомшаклык хәтта принципсызлык буларак та кабул ителделәр. Әйтик, Татарстан радиокомитетының сәнгать советы утырышында—ә без анда шактый еллар бергә эшләдек—ул бервакытта да, авторга әсәрен камилләштерү өчен мөмкинлекләр калдыру бәрабәренә, камиллектән ерак торган әсәрләргә дә үтергеч бәя бирмәде; алай гына да түгел, хәтта мактау сүзләре дә таба торган иде. Аңлашылса кирәк, Рөстәм Яхин тирәсендә аның яшәеш мәсләгенә бөтенләй туры килмәгән узгынчы кешеләр дә бөтерелә иде. Алар арасында күзгә карап композиторның югары идеаллары каршында баш июләре хакында сөйләп, ярдәм итү турында вәгъдәләр бирүче, ә чынында исә аңа каршы эш йөртүче ике йөзле бәндәләр дә җитәрлек иде.

Рөстәм абый андыйлар өстенә һичкайчан да гаеп ташламады. Аның мондый карашларында Л. Толстойның: «Кешенең үзе белән түгел, аңдагы начар гадәтләр белән көрәшергә кирәк»,—дигән яшәү принципларына беркадәр охшашлык та бар иде. Ул ачыктан-ачык инкарь итү, гаугачыллык түбәнлегенә төшмәде, әгәр инде үз фикерен белдерергә кирәк булса, әйтик, шулай да була иде, сүз сөрешен бөтенләй башка якка борып җибәрергә җай таба иде. Моны ул аңа гына хас итагатьлелек эшли иде һәм, шаяртып, синең канәгатьсезлеген шәхси ялгышларының нәтиҗәсе яки өлгереп җитмәвеннән сәбәбе түгелме икән дип сорап куя иде.

Кешеләр холкындагы җитешмәгән, йомшак яклар белән очрашканда ул югары идеаллар тарафдары булып кала белде, ә мондый сыйфатларга, гадәттә, көчле рухлы шәхесләр генә ия була. Аңа, барыннан да бигрәк, сәнгати хакыйкать, иҗади ирек кадерлерәк иде. Аның авызыннан мина шундыйрак сүзләр ишетергә туры килде: «Сәнгатьтә безгә тирания кирәк түгел!» Бу—кешеләрне үзенә тиң күргәндә, аларны үз фикере булган ирекле шәхес дип бәяләгәндә, яшәү барышында кеше тормышка карашын үзгәртергә сәләтле булганда гына мөмкин эш, чөнки кеше идея күрсәтмәләренә генә буйсынып яшәми, Рух аннан тирәнрәк тә, катлаулырак та.


*Рөстәм Яхин хәләл җефете Халимә ханым белән*

Ә Рөстәм Яхин катып калган шәхес түгел иде. Мондый сыйфат-холык аңа үз-үзенә читтән карарга да, реаль чынбарлыкта көчле һәм көчсез якларны күрергә, кирәк булса, үз-үзен җиңәргә ярдәм итә иде. Бик соңлап, әнисе вафатыннан соң гына өйләнүен аның шундый җиңүле-көчле адымы дип бәяләргә кирәк. Шушы хәлиткеч вакыйга алдыннан ул үзенең ялгызак-буйдак булып яшәвеннән аруы турындагы фикерләре белән уртаклашты да, өйрәнелгән гадәте буенча: «Син ничек уйлыйсың?..»—дип сорап куйды. Аның хакта озак вакытлар уйланып йөргәнлеге сизелеп тора иде. Тик минем шунысы ачык иде: әйе, аңа холкындагы эгоцентрик башлангычларның көрәшен җиңү җиңел бирелмәгәндер; якынлашып килүче картлык көннәрендә шундый тәвәккәл адым ясау үен эшмени—иҗатта һәм шәхси тормышта бу кире нәтиҗәләргә китермәсме? дигән сорау аны аз борчымагандыр... Әмма ул үзендәге «коллыкны» җиңә алды. Хәзер аның эчке җаны үзе өчен түгел, дөресрәге, үзе өчен генә түгел, ә бәлки яшьлегендә бер очраган, хәзер тагын тормыш юлына чыгып баскан хатын-кыз язмышы өчен күбрәк борчыла иде. Аңлы рәвештә, ихлас күңелдән ясалган мондый адым Рөстәм Яхинның язмышында хәлиткеч роль уйнады. Ул гомеренең соңгы өлешен, җитди сынаулар һәм олы җиңүләр алып килгән бөлемтеген чын ирләрчә җилеп үтә алды. Нәкъ менә шушы елларда аңа күпчелек кешелек сыйфатларын камиллек дәрәҗәсенә җиткерергә, ялган пәрдәләрне тәмам читкә алып ташларга, чын мәгънәсендә тынычланып калырга,ярату бәхетенә ирешергә насыйп булды. Боларда, әлбәттә, аның хатынының өлеше дә юк түгел иде: аның тырышлыгы һәм булышлыгы нәтиҗәсендә композиторның

ижаты зур ижтимагый яңгыраш алды һәм рәсми даирә тарафыннан да танылу тапты.

Рөстәм Яхинны катлаулы һәм шактый катмарлы тормыш юлында нинди рәк эчке рухи чишмәләр туендырып торды сон? Дөрес, дингә ышанучыларга дин күзлегеннән бәя биреп, изгелеккә изгеләрчә караштa торып яшәсә дә (тамыры белән борынгы дин әһелләренә барып тоташа), Рөстәм Яхин тәкъва кеше түгел иде. Аның кайбер туган-тумачасына сабырлык, күңел тынычлыгы һәм тәңгәллек биргән рухи көчләр чыганагы, замана баласы буларак, ана ябык иде шул.

Бәхәссез ки, рухи дәрт-дәрманны ана югары поэтик мәнбәргә күтәргән музыкаль сәләте бирә торды. Рөстәм абыйның җаңга ятышлы шигырьсез, музыкасыз, җанлы бәхәсле әңгәмәсез яши алмавы да шуның белән аңлатыладыр, мөгаен. Ул коры исәпкә корылган карашларны беркайчан да өнәп бетермәде, ә җан җылысы белән өртелгән хисләрне тоюдан балавыздай эреп китә иде. Дөнья чынбарлыкны болай кабул итү үзенең тамырлары белән Шәрекъ культурасына барып тоташа һәм ул хәзерге заман даирә-мохитында да, күпмедер күләмдә сакланып-яшәп килә (шәркый танып белүдә, белгәнебезчә, рухи-хиссеми, спиритуаль башлангычлар алгы планга чыга, материаль дөнья, әйтерсең лә, артка чигенә).

Мондый караш, язмыш нигезен тәшкил иткән очракта, күңел тынычлыгы, гармония, канәгатьләнү хисләре алып килергә һәм шул ук вакытта реаль тормыш проблемаларына һәм каршылыкларына карата игътибарны бераз киметергә дә мөмкин. Рөстәм Яхинның дөньяга карашында да шушына охшаш үзенчәлекләр бар иде. Үз эченә бикләнеп эшләүдән, үз көченә ышанып яшәүдән тәм тапса да (әйе, ул башка дөнья кешесе иде), ул җан җылысына мохтаҗ иде.

Композитор яшәгән «Тегe торгынлык» заманнарында рухи Ирек, Тигезлек һәм Туганлык кебек изге идеяләр (хәер, хәзер бу тагын да ачыграк төс алды) мал-мөлкәт җыю, дан-шөһрәт казану харафатлары астында күмелеп калды. Шушы шартларда, җанны эчтән таркатa торган рухисызлык һәм яраклашудан ваз кичүгә караганда, рухи дөнья белән материаль дөнья арасында тәңгәллек табарга омтылу бик үк актуаль булып күренмәскә дә мөмкин иде. Табигый ки, мондый очракта нинди генә юллар белән булса да рухи культураны саклап калырга омтылган нечкә хисле, тәэсирләнүчән шәхесләрдә кайбер кимчелекләр булуы бик ихтимал.

Сорау туа: дингез төбеннән энҗе-мәрҗән эзләүче гаувас кебек иҗат дөньясына чумган Рөстәм Яхин ул еллардагы сөрелгән социаль-сәяси атмосферадан котылуның башка юлларын күрә алды микән? Кызганыч ки, мона унай җавап бирүе кыен. Рухи табигатенең гадәти булмаганлыгын, эчке чын барлыкның гадәттән тыш көчле агымын тоеп яшәү нәтиҗәсендә, тормыш ваклыклары аның нәзберек җанында авыр тойгылар уята иде. Болар, үз чиратында, тышкы дөньяны кабул итүдә берьяклылыкка китерә. Менә шуннан башлана инде үзенне япа-ялгыз итеп сизү, кирәк түгеллегенне аңлау һ. б. һ. б. Еш кына ипохандриягә сабышу, драматик, ә кайчак трагик вакыйгалар өермәсендә югалып калу да менә шуларның нәтиҗәсе булгандыр, безнеңчә. Заман сәнгате таләп иткән конфликтлылыктан качу, ягъни соната һәм симфоник формаларга мөрәҗәгать итмәү дә шуның белән аңлатыладыр. Ә Рөстәм Яхин тормышта да, иҗатта да «конфликтсыз» шәхес иде! Начармы бу, яхшымы—монысы инде икенче мәсьәлә.

Ләкин Рөстәм Яхин—үзенең барлык вөҗүде, намусы белән татар музыкасына хезмәт итте, аның тугрылыклы кадиме булды. Шуның өчен дә татар халкы аның исемен яд итә, Олуглар рәтенә кертеп, аны сагынып искә ала. Халык тарафыннан Үз Улы буларак танылу, сәнгать кешесе өчен иң зур бәхет ул!

**Шамил МОНАСЫЙПОВ,**
*Татарстанның халык артисты, профессор*

Гэп
Фэн

# ТЕЛЕН БЕЛГӘН—ИЛЕНӘ ЮЛ ТАБАР...

Финляндиядәге татар диаспорасы турында без хәзер шактый хәбәрдар. Мәгълүм булганча, моннан утыз биш еллар элек анда Габдулла Тукай исемендәге мәдәни җәмгыять оешкан иде. Аның эше белән вафатына хәтле Хельсинки университеты профессоры Гомәр Таһир *(1910—1999)* житәкчелек итте. Бу җәмгыятьнең эшчәнлеге хакында «Казан утлары» Г. Таһир белән әтрафлы әңгәмә дә урнаштырган иде *(1986, 4 сан.)*. Соңгы ун ел дәвамында Финляндия татарлары белән Татарстан, Казан арасындагы бәйләнешләр тагын да киңәйде вә тирәнәйде. Аларның этник тарихына, рухи-мәдәни тормышына караган күләмле генә фәнни мәкаләләр басылды *(сүз асылда «Йөртә безне язмышлар» (1992) һәм «Материалы по истории татарского народа» (1995) дигән китапларда дөнья күргән мәкаләләр турында бара)*. Мәдәни бәйләнешләрнең ныгуын раслаган мисалларның бер-икесен генә искә төшерик. Соңгы елларда Г. Камал исемендәге Академия театры Хельсинкигә барып, берничә тапкыр зур уңыш белән үткән спектакльләр күрсәтте, ә эстрада артистларыбыз мәртәбәле концертлар бирделәр. Финляндия татарлары сәнгатькярлары да «әҗәтле» булып калмады, андагы театр сөючеләр «Галиябану», «Асылъяр» пьесаларын Казан тамашачысына күрсәтеп, аның олы мәхәббәтен казандылар; инструменталь уенчылар һәм җырчылар төркеме истә калырлык концертлар бирде.

Бу урында татар диаспорасы тарихы өчен гыйбрәтле бер яңалык турында да хәбәр бирәсе килә. Хельсинкидә туып үскән дүрт татар егете соңгы елларда бер-бер артлы Казанга килеп, башлы-күзле булып киттеләр. Хельсинкигә килен булып төшкән Казан кызлары исә андагы татарларны арттыру өлкәсендә «актив эш алып баралар» дип ишетеп беләбез: бүгенге көндә әлеге яшь гаиләләрдә биш татар баласы үсеп килә икән... Кыскасы, үзара багланышларның һич туктаганы юк, алар төрле формаларда дәвам итә.

Әйтергә кирәк, Финляндиядәге татар диаспорасының тулы канлы милли-рухи тормышка алгысып, күркәм бердәмлек һәм мәгънәви тәртип белән яшәвенә, ата-бабаларыннан калган мөкатдәс традицияләргә тугрылык тойгысы ярдәм итә; шул традицияләрне үзенә туплаган һәм Финляндия татарлары өчен дини-мәдәни бер үзәк булып саналган «Финляндия Ислам җәмгыяте», шулай ук аның канаты астында хәрәкәт итүче «Финляндия төркиләре берлеге» вә «Йолдыз» исемендәге спорт җәмгыяте кебек оешма-хәрәкәтләрнең гаять бай оештыру куәте һәм буыннарны бәйләүче тәҗрибәсе булыша.

Минем бу мәкаләм шактый еллар дәвамында «Финляндия Ислам җәмгыяте»нә житәкчелек итүче Окан Таһир турында. Җәһәттән шунсын да әйтү кирәктер, мәкаләне язу өчен янә бер сәбәп килеп чыкты. «Казан утлары» үзенең бу санында Окан Таһирның Финляндия татарларында имлялар тарихына караган мәкаләсен дә бастыра. Шул уңайдан автор турында язуымны редакция дә форсатлы дип тапты.

Окан Таһир белән безнең беренче күрешүебез 1969 елда Хельсинкидә булды. Танылган тел галиме Искәндәр Абдуллин белән икебезне анда Тукай җәмгыяте исеменнән Оканның әтисе Гомәр Таһир әфәнде чакырган иде. Оканга ул вакыт 22 яшь тулып килә, ул Хельсинки университетының фәлсәфә факультетында укый, тарих, тел, әдәбият фәннәре буенча белем ала, шулай ук хокук факультетында халыкара кануннарны өйрәнеп йөри иде.

Тагын ике елдан соң ул Хельсинкинең төрле хосуси адвокат бюроларында хезмәт итә башлады, мәхкәмәләрдә эш алып барды, аерым вакыфлар һәм фирмалар эшчәнлегендә катнашты. Адвокат буларак, шактый тәҗрибәле белгечләрнен берсе булып санала. Монда шунсын да истән чыгармаска кирәк, Окан Таһир гуманитар фәннәр белгече дә. 1975 елда ул төрки телләр буенча фән кандидаты дигән дәрәҗәгә ирешә. 1991 елдан алып, бүгенгә хәтле Хельсинки университеты каршындагы Азия һәм Африка илләре институтының тюркология бүлегендә татар теле, әдәбияты һәм мәдәнияты тарихы буенча лекцияләр укый, семинарлар алып бара.



*Окан Таһир әтисе Гомәр Таһир белән*

Окан Таһир гуманитар фәннәргә караган унга якын мәкалә авторы. Күбесенең төрле илләрдә үткәрелгән фәнни конференцияләр вакытында инглиз телендә укылган докладлар нигезендә язылган булуын билгеләп үтик.

Бу урында Финляндия татарларының тарихына, бүгенге тормышына бер караш ташлап алу дөрес булыр. Мәгълүм ки, андагы милләттәшләребез шушы илнең уннан артык шәһәрендә таралышып тереклек итәләр. Гомум саннары меңгә дә тулмый. Яртысыннан күбрәге Хельсинкидә, калган өлеше Тампере, Турку, Ярвинпәә, Раума һәм башка шәһәрләрдә гомер кичерә. Тарихи ватаннары буенча һәммәсе дә диярлек Түбән Новгород өлкәсенең Сергач төбәгеннән—мишәр сөйләше вәкилләре. Таралышып яшәсәләр дә, аларны татарлык хисе, туган телгә, милли йолаларга, җырга-моңга мәхәббәт хисе һәм ислам диненә тарафдарлык тойгысы берләштерә.

«Ислам җәмгыяте»нең Хельсинкидә урнашкан идарә үзәге—ул үзәк «Мөтәвәлли хәяты» дип атала—ел саен мәхәллә халкы алдында хисап тота. Ул хисап мөтәвәлли хәятының сигез тармагына караган гамәли эшчәнлек мәгълүматлары нигезендә төзелеп, идарә әгъзалары тарафыннан раслана.

Мәхәллә тормышының кайсы якларын күз уңында тоталар соң ул тармаклар? Санап китик: дини эшләр; социаль эшләр; тышкы эшләр; укыту һәм нәшрият эшләре; матди эшләр; белдерү эшләре; сугыш ветераннары белән бәйле эшләр; каберстан эшләре. Шунсын да әйтик, һәр тармак эшчәнлеген идарәнең берничә әгъзасы бергә оештыра. Күренә ки, яшәешнең һәр ягы төптән уйланган, үлчәнгән. Үзенең иҗтимагый корылышы һәм эшчәнлек тармаклары буенча кечкенә бер мәхәллә зур гына дәүләт-мәмләкәт булып күз алдына баса.

Алда саналган тармаклар башкарган файдалы гамәлләр турында аерым еллар буенча—«Ислам җәмгыяте» оешканга узган ел 75 тулды—этрафлы мәгълүмат бирергә мөмкин булыр иде. Әмма бу хакта тарихи хроника китабы язу сорала. Татар диаспорасы тарихының бай эчтәлекле кыйммәтле сәхифәләрен туплаган андый китапны Финляндиядәге милләттәшләр якын киләчәктә үзләре язарлар дигән өметтә калыйк.

Финляндия татарлары үз тормышларына хас милли-мәдәни традицияләрне барыннан да элек үзләре саклый, бу тормыш белән алар үзләре идарә итә, үз кыйблаларын үзләре билгели. «Ислам җәмгыяте»нең әле 1925 елда кабул ителгән низаннамә (устав) асылында яткан яшәү кагыйдәләренә рух вә куәт бирер өчен гаҗәеп тырышлык, бердәмлек, намус һәм дәрман кирәклеген ата-бабалары тәҗрибәсе аша әйбәт беләләр алар. Шуңа күрә җәмгыяви эшчәнлек,

ягъни үзенә тапшырылган җәмәгать вазифаларын акча хисабына түгел, иман хакына, күңел хисабына башкару Финляндия татарлары арасында изге һәм мәртәбәле бер гамәл булып санала. «Ислам җәмгыяте» идарәсе, икенче төрле әйткәндә, мөтәвәлли хәяты эшчәнлеге мисалында бик ачык күренә бу. Аның хисап-сайлау җыелышлары (идарә өч елга бер сайлана) рухи күтәренкелек шартларында, кайнар бәхәсләр һәм таләпчән тәнкыйть белән үтүләре хакында ишетеп беләм. Аларның эшенә читтән яисә өстән беркем дә тыгылмый, алар ирекле, шул сәбәпле бабаларыннан калган милли-мәдәни мөхтәрият нигезләрен изге мирас буларак какшатмый саклау өчен хәлдән килгәннең барсын да эшлиләр. Аларның акыллы кыюлыгына, хәйран ныклыгына сокланып: «Афәрин, мең яшәгез, милләттәшләр»,—дип алкышлыйсы килә.

Әйе, Окан Таһир мена шушы тынгысыз даирәдә гомер кичерә. Хокук өлкәсендә һәм гуманитар фәннәр буенча алып барган хезмәтеннән, шулай ук укытучылык вазифаларыннан тыш ул җәмәгать эшлеклесе дә. Ул менә ничә ел инде Финляндиядәге төрки-татар җәмгыятенә тугрылык белән хезмәт итә. Окан Таһир «Финляндия Ислам җәмгыяте» эшчәнлегендә 1970 елдан алып катнаша башлый. Баштарак идарәнең урынбасар әгъзасы, аннан хокуки әгъзасы, кятибе, рәис-президент урынбасары буларак эшләр алып бара, ә 1988 елдан башлап «Ислам җәмгыяте»нең рәисе-президенты хезмәтләрен башкара. Җәмәгать тәртибендә алып барыла торган авыр, әмма абруйлы вазифа бу. Аны уңышлы башкарыр өчен гадәти куәт кенә, дәрт кенә җитми, ил-халык тормышын, олы дөнья барышын тирәннән аңлап-фәһемләп эш итү кирәк. Кешеләрне ярата белү, алар хакы өчен игелекле гамәлләр кылырга әзер тору кирәк. Окан Таһир, минем ышануымча, менә бу сыйфатларга ия шәхес. Оканның искә алган күркәм сыйфатлары 1992, 1997 елларда Казанда узган ике тарихи Корылтай вакытында—Бөтендөнья татарлары Конгрессында да чагылыш тапты. Ул бу Конгрессларга Финляндия татарларының делегацияләре башлыгы буларак килгән иде. Шул делегацияләр исеменнән ике Конгресста да чыгыш ясады. Аның чыгышлары татар диаспорасына хас хәзерге вәзгыятьне, читтә яшәүче милләттәшләрнең хәлен вә мәнфәгатьләрен мәгънәви тирәнлеге белән аңлау ягыннан, шулай ук файдалы киңәш-тәкъдимнәре белән истә калды. Шунсын да әйтергә кирәк, Окан Таһир ике Конгресста да аның Башкарма комитеты әгъзасы итеп сайланды. Белүемчә, Башкарма җитәкчелеге «Финляндия Ислам җәмгыяте» эшчәнлеген югары бәяли.

Финляндия—Татарстан бәйләнешләре күзлегеннән бик әһәмиятле булган



*Окан Таһир Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев белән. Хельсинки, 1999 ел.*

бер вакыйганы хәтергә төшерик. Мәгълүм булганча, 1999 елның октябрендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Финляндия хөкүмәте чакыруы буенча шул илдә булып, ике ил арасындагы сәүдә элемтәләрен көчәйтүгә багышланган абруйлы семинар эшендә катнашты. Көннәрнең берендә Татарстан Президенты һәм аның юлдашлары, Финляндия татарларының мөтәвәлли хәяты чакыруын кабул итеп, мәхәллә йортында оештырылган кечке аш мәҗлесендә булалар. Анда Окан Таһир һәм Минтимер Шәймиев сәламләү чыгышлары ясыйлар, кичә барышында Бөтендөнья татар Конгрессы президенты академик Индус Таһиров та сүз тота. Соңыннан «Финляндия төркиләре берлеге»нең һәвәскәр артистлары кунаклар өчен концерт бирәләр.

Күп кенә мисаллар Окан Таһирның җәмәгать эшчәнлеген халыкара күләмдә дә үлчәргә мөмкинлек бирә. Соңгы елларда ул Финляндиядә яшәүче аз санлы халыклар арасындагы этник бәйләнешләр комитетында эш алып бара. Ул анда—мәдәниятлар бүлеге рәисе. Янә дә Европадагы азчылык телләре бюросының фин милли комитеты әгъзасы. Янә дә килеп, Финляндия белән Татарстан арасында узган ел гына корылган сәүдә-эш берлеге комитеты әгъзасы да.

Окан Таһирның күп телләр белүен һәм дипломатик сәләте барлыгын истә тотып, Финляндия тышкы эшләр Министрлыгы аны Финляндиядә уза торган төрле халыкара конференцияләр эшендә катнашырга чакырып тора. Мәсәлән, соңгы 25 ел дәвамында ул шундый алты конференциянең секритариатында файдалы эшләр башкарып, мактау сүзләре ишетә.

Окан Таһирның дөньядагы татар диаспорасы белән бәйләнешләре хакында аерым әйтергә кирәк. Ул Швециядә, Эстониядә, Америкада, Төркиядә яшәүче татарларның иҗтимагый-мәдәни үзәкләре белән тыгыз элемтәләр саклый. Соңгы елларда ул бу илләрнең башкалаларында һәм аерым шәһәрләрдә яшәүче милләттәшләр өчен Финляндия татарларының тарихы вә рухи-мәдәни тормышы турында, аларны саклау өлкәсендә килеп туган ихтыяҗлар турында лекцияләр укып, үзара бәйләнешләрне ныгыту буенча актив эш алып бара.

Окан Таһирның эш сәгатьләре һәрвакыт алдан бүленеп куелган. Ул Финляндиядәге татарлар җәмгыяте өчен генә түгел, үзенә тапшырылган башка вазифаларны да җиренә житкереп башкару өчен ашкынып яши. Халкыбыз мирасында «Ир-егетнең гомер юлын илгә хезмәте бизи» дигән шигъри бер тәгъбир бар. Ул тәгъбир Окан Таһирның тормыш юлын күз алдыннан кичергәндә үзеннән-үзе искә төшә.

**Илбарис НАДИРОВ**

# Окан Таһир

## Финляндия татарларының алфавиты һәм орфографиясе тарихыннан


Вак сәүдә белән шөгыльләнүче беренче татар кәсепчеләре Финляндия җиренә XIX гасыр ахырында Россия империясенең Түбән Новгород губернасындагы Сергач өязенә кергән авыллардан килгәннәр. Тора-бара аларның күбесе мех, кием, тукымалар белән сәүдә итү һөнәрен үзләштереп, үз эшләрен киңәйтү өчен илнең төрле шәһәрләренә урнашып яши башлыйлар. Андый шәһәрләрдән Хельсинки, Турку,Раума, Пори, Вааса, Кеми, Ярвинпәә, Тампере һ. б. атарга була.

Күпмедер вакытлардан соң дин, ана теле һәм уртак гореф-гадәтләр

Финляндия татарларын бер җәмгыятькә туплый, бу илдә яшәүче татарларны милләт итеп танырга нигез сәбәп була. 1917 елда Финляндия бәйсезлеккә ирешкәч һәм 1922 елда Финляндия парламенты диннәргә ирек бирү турында канун кабул иткәч, мондагы татарлар үзләрен рәсми берләштерер өчен «Финляндия Мөхәммәт җәмгыяте»н оештыралар. 1963 елда бу җәмгыять исеме «Финляндия Ислам җәмгыяте»нә алмашына. Якынча 850 кешене берләштергән Финляндия татарлары хәзерге вакытта рәсми теркәлгән вә танылган милли диаспораларның берсе булып санала.

Сан ягыннан Финляндия татарлары күп булмаса да, алар-ның рухи-мәдәни эшчәнлеге төрле өлкәләрдә алып барылган һәм байтак басма китапларда гәүдәләнеш тапкан. Бу эшчәнлек дин китаплары, тел укытканда кирәкле кулланмалар, җыр китаплары бастыруга карый. Басмалар арасында, китаплардан тыш, журналлар, төрле буклетлар булуын да искәртеп үтәргә кирәк. Бу эшчәнлекнең иң актив чоры 1930—1950 елларга туры килә. Әдәби эшчәнлек белән кызыксыну, китаплар чыгару хәзерге вакытта да дәвам итә.

Төрле сәбәпләр аркасында, Финляндия татарларын Финляндия төрекләре дип тә атаганнар. Татарлар Финляндиядә иң күп санлы төрки халык саналган һәм аларга бүтән төрки халыкларның вәкилләре дә кушылганнар. Финляндия татарларының уртак теле булып, татар теленең мишәр диалекты санала һәм Финляндиягә килгән татар сәүдәгәрләренең күпчелеге шушы диалектта сөйләшкән. 1935 елда «Финляндия төрекләре берлеге» исемле мәдәни җәмгыять оеша. Башлангыч мәктәп татарча «Төрек халык мәктәбе» дип аталган һәм ул Хельсинки шәһәрендә 1948 елдан алып 1969 елга кадәр эшләп килгән. Бу мәктәптә укыту эшләре Финляндия мәгариф министрлыгы тарафыннан рәсми рәвештә хупланган уку программасы нигезендә алып барылган. Дәресләрнең бер өлеше, балаларның киләчәктә фин мәктәпләрендә укуларын күз алдында тотып, фин телендә бирелгән.


حالمه!
ترشساڭ سين تابارسڭ ، تاشقا قاداق قاغارسڭ ؛
ترشابق ، ييل ، توغان ، قارا تونله ر آغارسن .
هه ر بر ئشنه بول ترش ، ترشمى بولماس هيچ بر ئش ،
ئه له ر ئشله ترشسه ڭ ، ييڭلنى باغلاب ترش .
ترش بولساڭ آلهاڭ مول ، فايدا بارساڭ توغرى بول ،
باقى كورب ئه يته سن : «دنيهار ، توغان ترش بول !»
فاطمه
تامپه ره ٥-٧-١٩٣٠

*Кульязма шәхси хат үрнәге. 1930 ел.*

Финляндия татарлары башта гарәп хәрефләрендә булган Идел төрки-татар алфавитын кулланганнар. Шушы алфавит нигезендә алар Идел якларында калган туган-тумачалары белән хатлар алышканнар. Араларында гарәп каллиграфиясен ярыйсы гына үзләштергән кешеләр дә булган. Моңа мисал итеп Тампере шәһәрендә яшәүче Фатыйма Вафинаның 1930 елда язган шәхси хатын китерергә була.

1920 елдан башлап 1930 елларга кадәр чыккан китаплар, нигездә, гарәп хәрефләре белән генә басылганнар. Аларның кайберләре—бигрәк тә уку китаплары—татарлар ярдәме белән Финляндия типографияләрендә нәшер ителгән. Шул типография-ләрнең берсе Хельсинкидә урнашкан «Сана» («Сүз») типографиясе булган. Түбәндәге мисалда «Туган тел» исемле шигырь бирелгән. Татар халык шагыйре Габдулла Тукай иҗат иткән бу популяр шигырь 1935 елгы «Уку китабы»нда басылган. «Уку китабы» исә, башка уку китаплары кебек үк, «Финляндия Ислам җәмгыяте»нең дәреслекләр хәяты тарафыннан әзерләнгән.

1930 еллардан башлап, Төркиядә үткәрелгән тел реформасы һәм шул ук елларда Советлар Союзының төркиләр яшәгән өлкәләрендә барган «латин хәрәкәте» (Яңалиф) тәэсире астында латин хәрефләре Финляндия татарлары арасында да кулланыла башлый. Шунсын да әйтергә кирәк, бу елларда басылган китапларда гарәп һәм латин хәрефләре икесе дә тигез хокуклы булып, янәшә кулланылганнар. Моңа мисал итеп, 1935 елда «Финляндия Ислам җәмгыяте» чыгарган «ABC (Әлифба) китабын китерергә мөмкин.

E, e ئـ ـە ـئـ ە



ئەتی ئەنی ئەبی ئەرلەن ئەرسز
ئەرەم اولەن اوسە بولە بولمە تورە
تیشە کیسە ایشە شەم تەم ئەتەج ایلەك
پیلمەن کوبەلەك ایشکەك·

*1935 елда Хельсинкидә басылган «ABC (Әлифба)» китабыннан бер өзек.*

Алфавитның ничек гарәптән латинга күчүен «Мәхәллә хәбәрләре» дигән журнал мисалында күрергә була. Исеменнән анлашылганча, бу журнал—Финляндиядәге төрки-татарларның эчке тормышын һәм тышкы элемтәләрен яктыртып баручы хәбәрләр җыентыгы. Ул 1949 елдан башлап, 1970 елга кадәр ике айга бер мәртәбә чыгып барды. 1949 елда аның беренче саннары гарәп хәрефләре белән генә басылып барса, 1950 елдан соң һәр санның баш битләре латин хәрефләре белән чыга башлый. 1952 елдан алып 1970 елга хәтле журнал, кагыйдә буларак, латин алфавитында гына басыла.

1940 елларда Финляндиядә типографик ысулда коелган гарәп хәрефләрен табу бик авыр булган. Күпчелек басмалар, шул исәптән «Мәхәллә хәбәрләре» дә кулдан язылган гарәп хәрефләре белән чыкканнар. Гарәп хәрефләрендәге китапларны чыгару эше белән Финляндия татарлары арасында беренче булып Хәсән Хәмидулла шөгыльләнгән. Ул бу эш өчен үзенең өендәге бер бүлмәдә китап басу өчен махсус кораллар, буяулар тоткан һәм шулар ярдәмендә башта Кеми, соңыннан Хельсинки шәһәрләрендә бик күп китаплар бастырган. Алар арасында Финляндия татарларының күп тапкыр басылган телефон китабы һәм Хәмидулла әфәнденең төрле жанрларга караган әдәби әсәрләре, истәлекләре бар. Шул ук вакытта баштарак Оулу шәһәрендә, соңыннан Хельсинкидә яшәгән Садри Хәмит әфәнденең дә гарәп шрифтында 1967—1977 еллар дәвамында «Ак юл» исемле журнал чыгарып баруын күрсәтеп үтәргә кирәк.

Түбәндә латин алфави-тының Финляндия татарлары арасында актив кулланышта булган үрнәген күрсәтү өчен бер мисал китерәбез. Ул—«Мәхәллә хәбәрләре»ндә басылган бер язма үрнәге:

Helsinkide 1952 yılgı Olympia.

Olympia münasebetile türlü Islam memleketlerinden Helsinkige kilgen millettaş ve dindaşlerimiz şerefine Finlandiye Cemaatı Islamiyesi tarafından 28.7.52 de Helsinki injinir yurtunın zur zalında bir çay ziyafeti birildi. Mecliste Türkiye, Iran, Mısır, Pakistan, Libnan, Suriye, Marok, Cezairden kilgen dindaşlerimiz, barsı 400 den artık kişi hazir buldılar. Kunaklar arasında Iran Şahinin biraderi Prins Riza Pehlevi Hazretleri de hazir bulıp meclisni şereflendirdi.

Mütevelliler reisi Zuhur Tahir kunaklarni selamlep meclisni uşpu sözler ile açtı:

Pek sayın Prins Riza Pehlevi Hazretleri,
Aziz misafirlerimiz,
hepinizi, Finlandiye Türk Islam Kolonisi namına samimiyetle selamlerim. Hoş geldiniz, safa geldiniz.


*«Мәхәллә хәбәрләре», 1952 ел, 4 сан.*

Финляндия татарларының латин алфавиты төрек латин алфавитына таянып төзелгән һәм бу алфавитның 28 хәрефеннән тора: **a b c ç d e f g h i ı j k m n o ü ö p r s ş t u ū v y z.** Төрек телендә «**ğ**» хәрефе бик сирәк очракларда гына кулла-нылган, ә швед-фин алфавитларындагы **q w x a à ä** хәрефләре ярдәмендә төрек телендә булмаган чит ил сүзләре һәм кеше исемнәре генә язылган, шул сәбәпле алар татар телендәге орфография кагыйдәләренә тәнгәл килмәгәннәр.

Шуны да истә тотарга кирәк: 1917 елдан соң Финляндия татарларының теле бәйсез рәвештә яшәргә мәҗбүр булганлыктан, Идел татарлары теле һәм диалектлары белән элемтәгә бик сирәк керелгән. Ләкин 60 еллар ахырыннан башлап Финляндия татарлары теле белән Казан татарлары теле арасындагы элемтәләр бермә-бер көчәя башлый. Нәтиҗәдә, Казан татарлары теленең кириллицага нигезләнгән орфографиясе Финляндия татарлары теленә дә тәэсирен көчәйтә. Орфографиядә язар өчен иң авыр булган **«е»** һәм **«ä»** хәрефләре бар. Бу хәрефләр төрек телендә аерылмыйлар һәм Финляндия татарлары да баштарак бер генә хәрефне—**«е»** ны кулланганнар. Сонрак бу

хәреф **«ä»** авазын билгеләр өчен генә кулланыла башлап, **«е»** хәрефе хәзерге вакытта **«i»** билгесе белән языла (ноктасыз **«i»** хәрефе).

Финляндия татарлары арасынлда **«ı»** хәрефенең ике төрле кулланышына мисал итеп 40 еллар ахырында язылган бер текстны китерергә була.


Saygılı

Saniye tutaş Ali ve Hamdurrahman efendı Hakimcan nıñ 18. 5. 47 bazarkön saat 16 de bulaçak nikâh meclısıne hazır buluvıngıznı ötınebız.

Saygılarla:
Beşer Ali
Ibrahim Hakimcan

Adrıs: Helsinki
Ravintola Kaisaniemi.

*Никах мәҗлесенә чакыру язмасы. 1947 ел.*

1970 еллар ахырында **«ı»** (арткы аваз) һәм **«i»** (алгы аваз) хәрефләрен аерып язарга тырышу мисаллары да бар. Мәсәлән, cır kiçesi (җыр кичәсе) сүзләрен язгандагы кебек. Әмма практик сәбәпләр аркасында, бу тырышулар бушка киткән һәм орфография яңадан **«ı»** хәрефенең ике төрле кулланышына кайткан. Моны түбәндәге мисалдан күрергә була.




*1980 елда Хельсинкидә басылган «Безнең җырлар» исемле җыентыктан алынды.*

Фин теленең **«ä»** хәрефе Финляндия татарлары балаларына тел дәресләре укытканда кулланылган: täräz- тәрәзә һәм—äle әле сүзләрен язгандагы кебек.

Финляндия татарларының хәзерге орфографиясе билгеле бер дәрәҗәдә төрек әдәби тел нормаларыннан һәм Казан татарларындагы кириллицаны язу кагыйдәләреннән аерыла. Мәсәлән, кириллицадагы «ң» хәрефе бездә «ñ» рәвешендә языла, шунсын да әйтергә кирәк, бу аваз, мәгълүм булганча, төрек телендә бөтенләй юк. Икенче яктан, Казан татарлары телендә норма буларак кабул ителгән һәм күпчелек очракларда гарәп теленнән кергән сүзләрдә һәм кеше исемнәрендә кулланыла торган «g» хәрефе Финляндия татарлары телендә һәм орфографиясендә кулланылмый.: татарча сәгать сүзе Финляндиядә seat—дип языла, төрекчә—saot, татар телендәге—гомер сүзе omır дип, Гали исеме Ali дип йөртелә һәм языла.

Финляндия татарлары Казан татарлары теленең алфавиты һәм орфографиясендә булачак реформа нәтиҗәләрен һәм дөнья тюркологлары тарафыннан 1992 елда тәкъдим ителгән уртак латин графикасына тизрәк күчүне көтәләр.



# ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ДӘҮЛӘТЧЕЛЕК ӨЧЕН КӨРӘШ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**IX-X гасыр башы**–Идел-Чулман Болгар дәүләте төзелү.

**X-XIII гасырлар**–Болгар дәүләтенең үсүе һәм куәтләнүе.

**X гасыр ахыры–XI гасыр**–Болгарда шәһәр цивилизациясе барлыкка килү.

**922**–Болгар илендә Ислам динен дәүләт күләмендә кабул итү.

**1120**–Юрий Долгорукийның болгарларга һөҗүме.

**1183**–Суздаль кенәзе Всеволодның болгарларга һөҗүме.

**1220**–урыс кенәзләренең Ошель шәһәрен яулап алуы.

**1223**–болгарларның Идел буенда монголларны тар-мар итүе.

**1229-1232**–болгарларның монголларга каршы торуы.

**1236**–монгол гаскәрләренең Болгар дәүләтенә басып керүе.

**1238-1240**–монгол яуларына каршы баш күтәрү һәм азатлык сугышлары.

**1257**–Монгол дәүләтеннән Берке Урданың (соңрак Алтын Урда) аерылуы.

**1260, 1277-1278**–Урдага каршы баш күтәрү, Мөңге Тимернең Казанны алуы.

**XIV гасыр**–Болгарда Алтын Урдага бәйле җирле әмирлекләр барлыкка килү.

**XIV гасырның икенче яртысы**–Урта Иделдә Болгар, Казан, Җүкәтау, Кирәнчек һ. б. әмирлекләрнең яшәве.

**1361**–Алтын Урда бәге Булат Тимернең Урта Иделне яулап алуы.

**1360-1370**–урыс юлбасарларының (ушкуйниклар) һәм кенәзләренең Болгар, Казан җирләрен талау һөҗүмнәре.

**XV гасыр башы**–Болгар әмирлекләренең Казан дәүләтенә берләшә башлавы.

**1431**–Болгар шәһәренең Федор Пестрый тарафыннан җимертелүе.

**1445**–Казан дәүләтендә Болгар династиясенең Алтын Урда династиясенә алмашынуы. Тәхеткә Олуг Мөхәммәт улы Мәхмүтнең хан булып утыруы.

**1445-1467**–Мәхмүт хан идарә иткән чор.

**1445-1479**–Казан дәүләтенең ныгуы.

**1467-1470**–Мәхмүт ханның үлеме һәм Мәскәү кенәзлегенең Казан дәүләтенә сугышлар башлавы.

**1467-1479**–Ибраһим хан идарә иткән чор.

**1487**–Мәскәү кенәзе Иван III гаскәрләренең Казанны алуы. Али ханны (Илһам дип тә билгеле) хатыны, балалары һәм анасы белән әсирлеккә (төрмә-крепостька) алып китү. Хан итеп Мөхәммәт Әмин билгеләнү. Казан дәүләтенең Мәскәү кенәзлегенә бәйлелеге (протекторат) башлану.

**1487**–Мәскәү кенәзе Иван III нең Болгар кенәзе дигән титулны да алуы.

**1505-1506**–Казан ханлыгының Мәскәүгә бәйлелектән котылу өчен сугышы.

**1518**–Казан тәхетенә варис Мөхәммәт Әминнең энесе Абдул Латыйфның Кашира шәһәрендә үтерелүе.

**1519**–Мөхәммәт Әминнең үлеме. Казанда Олуг Мөхәммәт нәселенең бетүе.

**1519-1521, 1546, 1551**–Мәскәү ялчысы Шаһгалинең Казанда ханлык итүе.

**1521**–Шаһгалинең Казаннан куылуы. Сәхиб Гәрәйнең Кырымнан Казанга хан булып килүе.

**1521-1524**–Мәскәү кенәзлегенең Казан дәүләтенә каршы сугышлары.

**1524**–Сәхиб Гәрәйнең үз урынына хан итеп туганының улы Сафа Гәрәйне чакыруы һәм Төркиягә китүе.

**1524-1532, 1536-1546, 1546-1549**–Казан тәхетендә Сафа Гәрәй торган еллар.

**1530**–Мәскәү гаскәренең Казанга һөҗүме, шәһәрнең яндырылуы.

**1532-1536**–Казанда Җан Гали хан идарә иткән чор.

**1548, 1550**–Явыз Иванның Казанга һөҗүмнәре.

**1549-1551**–Сөембикәнең Казан ханлыгы белән идарә итүе.

**1551**–урысларның Зөя кальгасын салуы.

**1551**–Сөембикәне Мәскәүгә әсирлеккә алып китү.

**1551**–Урта Иделнең уңъяк ярын Мәскәүнең Казан дәүләтеннән тартып алуы һәм аны үзенә көчләп кушуы.

**1552**–Мәскәүнең Казанны яулап алуы һәм буйсындыруы.

**1552-1557**–Җан Сөет, Сары батыр, Мәмеш-бирде һәм башка батырлар җитәкчелегендә татар, мари, чуаш, мордваларның урыс баскынчыларына каршы азатлык сугышлары. Баш күтәрүчеләрнең Казан тәхетенә хан куюлары.

**1571-1574**–урыс хакимиятенә каршы крестиәннәрнең баш күтәрүе.

**1582-1584**–Явыз Иван сәясәтенә каршы Урта Идел халкының баш күтәрүе.

**1615-1617**–Җан Галинең Мәскәүгә каршы сугыш алып баруы.

**1645**–татар-башкорт крестиәннәренең Минзәлә крепостен яндыруы.

**1661-1669**–татар-башкорт крестиәннәренең баш күтәрүе, Минзәлә, Чишмә, Биләр, Ерыклы һ. б. Крепостьларга һөҗүм итүе.

**1670-1671**–Хәсән Айбулат улы Карачуринның Степан Разинны Казанны патша властьларыннан азат итәргә чакыруы.

**1704-1711**–татар-башкортларның милли азатлык көрәше. Баш күтәрүчеләрнең Минзәлә, Зәй, Яңа Чишмә, Биләр, Алабуга, Мамадыш крепостьларына һәм Казанга кадәр һөҗүм итеп килүе.

**1706-1708**–Казанга хан итеп Солтан Моратны, ул һәлак булгач, Хуҗа Солтанны сайлап куюлары.

**1735-1740 еллар**–татар-башкорт халкының урыс хөкүмәтенең колониаль сәясәтенә каршы сугышы. Шигай һәм Карасакал дигән кешеләрне хан итеп сайлау.

**1755**–Батыршаның баш күтәрүе. Аның урыс идарәчелеген бетерүгә чакырып халыкка мөрәҗәгате.

**1760**–Мулла Морат хәрәкәте. Аның «Болгарны торгызырга вакыт җитәдер» дип халыкка мөрәҗәгать итүе.

**XIX гасыр**–татар җәмгыятенең эчке тормышын яңача үстерү буенча иҗтимагый фикер үсеше.

**1820-1860**–православие диненә көчләп күчерелгәннәрнең яңадан Ислам диненә кайту процессы.

**1863**–мөстәкыйль үзидарә таләп иткән вәисевчеләр хәрәкәтенең башлануы.

**1878-1879**–татар крәстияннәренең урыслаштыру сәясәтенә каршы хәрәкәте һәм баш күтәрүе.

**1889**–муллалардан урыс теленнән имтихан алу турында указга каршы көрәш.

**1893**–кулдан язылган һәм чит илләрдә басылган китап, кулланмаларны юк итү турындагы указга каршы көрәш.

**1905**–зыялыларның Рәшит Ибраһимов җитәкчелегендә хокук таләп итүләре.

**1905**–«Иттифак-әл мөслимин» (Мөселманнар берлеге) партиясе төзелү.

**1917 ел, 1-11 май**–Мәскәүдә Бөтенрусия мөселманнар корылтае үткәрү.

**1917 ел, август**–Бөтенрусия мөселманнарының мәркәз милли шурасы төзелү.

**1917 ел, 20 ноябрь**–Милләт мәҗлесенең эшли башлавы. Мәҗлес «Идел-Урал штаты» төзелүен игълан итә һәм Милли идарә (хөкүмәт) сайлый.

**1918 ел, 11 февраль**–Милләт мәҗлесенең эшен туктату һәм Милли идарәнең бетүе.

**1918 ел, март**–Казанда татар дәүләте (Болак арты республикасы) төзелү.

**1920 ел, 27 май**–Татарстан Автономияле Социалистик Совет Республикасы оештыру турында декрет кабул ителү.

**1920 ел, 25 июнь**–Губерна башкарма комитетының үз вәкаләтләрен ТАССР Вакытлы революцион комитетына тапшыруы.

**1923 ел, 9-12 июнь**–Большевиклар партиясе үзәк комитетының милли мәсьәләләр буенча киңәшмәсе. Милләтләрнең милли үсешенә һөҗүм башлану. М. Солтангалиевне гаепләп хөкем итү.

**1924**–Казанда дәүләт органнарындагы үзара көрәш, большевикларның аларга каршы һөҗүм башлавы.

**1927-1928**–татар алфавитын латин графикасына (Яңалиф) күчерү.

**1930**–автономиянең дәүләти хокукларына большевикларның һөҗүм итүе.

**1936-1937**–СССР күләмендә террорчылык җәелү.

**1938**–татар алфавитын көчләп урыс хәрефләренә (кириллицага) күчерү.

**1944 ел, август**–Коммунистлар партиясе үзәк комитетының Татарстан Республикасында милләт тарихын өйрәнүне тыйган, милли үсешкә киртә ясаган карары игълан ителү.

**1950 еллар**–Диссидентлар хәрәкәте башлану. Татарстанда да репрессияләрнең яңадан көчәюе.

**1950 еллар ахыры**–1960 еллар башы–Иҗтимагый тормышта җанлану.

**1964-1980**–»Җитлеккән социализм» шигаре астындагы сәяси торгынлык. Милләтләрне бетерүгә йөз тоту.

**1970-1990**–татар мәктәпләрен күпләп юкка чыгару.

**1967-1977 еллар**–Татар зыялылары арасында Татарстанга союздаш республика статусын бирү өчен хәрәкәт башлану.

**1977**–Татарстан АССРның яңа Конституциясен кабул итү.

**1988**–Татар иҗтимагый үзәге оешу, башка иҗтимагый оешмалар һәм партияләр төзелү.

**1989**–Татар иҗтимагый үзәгенең I съезды.

**1989-1992**–Милли азатлык хәрәкәтенең көчәюе.

**1990 ел, 30 август**–Татарстан Республикасының дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителү.

**1992 ел башы**–Татарстанның мөстәкыйльлеге хакындагы референдумга каршы Мәскәүнең көчле сәяси басымы.

**1992 ел, 21 март**–Татарстан халкының референдумда суверенлык Декларациясен яклап тавыш бирүе.

**1992 ел, 6 ноябрь**–Татарстан Республикасының халыкара хокук субъекты буларак демократик Конституция кабул итүе.

**1992 ел, 19-20 июнь**–Бөтендөнья татар конгрессының I корылтае.

**1993**–Русия Федерациясе Конституциясен кабул итү.

**1994 ел, 15 февраль**–Русия Федерациясе белән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вазифаларны бүлешү һәм вәкаләтләрне үзара тапшырышу турында Шартнамәгә кул кую.

**1995-2001**–татар милли хәрәкәтенең сүлпәнәюе.

**2000**–Русиянең Татарстанның сәяси хокукларын яңадан тартып ала башлавы.

**2000**–федератив бюджет төзеп, Русиянең Татарстанны кабат талый башлавы.

**2001**–Русия Дәүләт Думасының һәм суд органнарының Татарстан Республикасының Телләр турындагы законына һөҗүм итүе.

Бу тарихи елъязмадан берничә нәтиҗә ясарга мөмкин. Беренчедән, Болгар-татар дәүләтчелеге мең ел буе яшәп килгән, һәрвакыт үзенең мөстәкыйльлеге өчен көрәш алып барган. Икенче нәтиҗә советлар хакимияте чорына карый. 1917-1920 елларда милли хәрәкәт көчле булып, Татарстан кайбер хокуклар алуга ирешә. Ләкин, озак та үтми, автономияле республика ирексез бер административ-территориаль берәмлеккә әйләнеп кала. 1980 еллар ахыры һәм 1990 еллар башында милли хәрәкәтнең яңадан көчәюе нәтиҗәсендә, ул кайбер хокуклар алса да, шул ук Русия составында кала. Русия аның суверенитетын да, Конституциясен дә танымый. 2000 елда Русия Татарстанның мөстәкыйльлекне яклаган законнарына каршы көчле һөҗүм башлый, шуның белән үзенең демократик үсеш юлыннан ваз кичүен һәм тоталитар режим урнашу алдында торуын күрсәтә.

Өченчедән, бу хәлләр башка милли республикаларга да кагыла. Ләкин Русиядә сан ягыннан икенче урынны тәшкил иткән һәм мең еллык дәүләтчелек тарихы булган татар халкы үзе дәүләтчелеген торгызу өчен гадел көрәш алып бара.

**Сәлам АЛИШЕВ,**
*тарих фәннәре докторы.*

# КАЗАН ХАНЛЫГЫНЫҢ ЧИКЛӘРЕ КАЯН УЗГАН?

Тарихи география—татар халкы, татар дәүләтләре тарихында иң аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Казан ханлыгының тарихи географиясе фундаменталь тарихи хезмәтләрдә өстән-өстән генә карап кителә, ә махсус әдәбиятта исә бу проблема теге яки бу халыкның Русия дәүләтенә кушылуы күзлегеннән чыгып кына яктыртылган.

Язма һәм археологик чыганакларга таянып, Казан ханлыгының чикләрен иң беренче булып күренекле урыс тарихчысы М. Г. Худяков билгеләргә тырышкан *(Худяков М. Г. Очерки по истории Казанского ханства.—Казань, 1990.—С. 16—21.).* Ул ханлык биләмәләренә ике төрле җирләрне керткән: дәүләтнең татарлар яшәгән үзәк өлкәсе һәм аңа буйсынган башка халыклар яшәгән өлкәләр. Дәүләтнең үзәк өлешен билгеләгәндә М. Г. Худяков өч төрле чыганактан файдаланган:

1. Мөселман зиратларындагы кабер ташлары; 2. Хисаметдиннең «Болгар тарихы»нда аталган авыл исемнәре; 3. Татарларның бүгенге көндә таралып урнашкан җирләре.

М. Г. Худяков фикеренчә, Казан ханлыгының үзәк өлкәсе хәзерге Татарстан Республикасы биләмәләре белән тәңгәл килә.

Казан ханлыгына буйсынган халыкларның (мордва, чуваш, мари, удмурт) бүгенге көндә таралып урнашкан җирләрен чагыштырып, М. Г. Худяков Казан ханлыгына Татар, Мари-Эл, Чуваш, Удмурт республикаларын, Ульяновск, Пенза, Саратов, Тамбов, Пермь өлкәләрен керткән.

Шулай итеп, Худяков буенча Казан ханлыгы көнчыгышта Нугай Урдасы, көньякта Әстерхан ханлыгы, көньяк-көнбатышта Кырым ханлыгы, төньякта Нократ общинасы, көнбатышта Мәскәү дәүләте белән чиктәш булган.

Казан ханлыгы чикләрен М. Г. Худяков көнбатышта Сура һәм Ветлуга, төньякта Пижма елгасы буйлап көнчыгышка, аннан Воя елгасы тамагына кадәр Нократ буйлап, Чепца елгасының урта агымыннан Чулманның югары агымы буйлап билгеләгән. Көнчыгышта бу чикләр Казан ханлыгына Сарапул һәм Алабуга районнары, Минзәлә районын керткән. М. Худяков фикеренчә, «татарлар яшәгән Бөгелмә һәм Мәләкәс өязләре Казан ханлыгына кергән, ә Самара даласы, чынлыкта, аның буенча күчеп йөргән нугайлар кулында булган. Иделнең уң ягы Царицын шәһәренә кадәр Казан ханлыгы биләмәләрен тәшкил иткән. Монда Хисаметдин әсәрендәге телгә алынган Сембер, Сары-Тау (Саратов) һәм Сары-Тын (Царицын) шәһәрләре булган».

Казан галимнәренең аннан соңгы өйрәнүләре Казан ханлыгы чорына караган кабер ташларының зуррак территориядә таралып урнашуын раслый. Мәсәлән, Гали Рәхим 1927—1928 елларда шул чыганакларны өйрәнеп, Казан ханлыгының үзәге дип Казан артын һәм Тау ягын саный. Шул ук вакытта ул Казан ханлыгына караган кабер ташларының Чулманның көньягында бөтенләй булмавын искәртә *(Рахим. А. Татарские эпиграфические памятники XVI в.—Казань, 1930,—Т. I.—С. 98).*

Н. Ф. Калинин тарафыннан төзелгән һәм «Татарстан АССР тарихының» I томына кертелгән «Казан ханлыгының археологик картасы»нда XV—XVI гасырга караган 67 кабер ташы күрсәтелгән. Аларның күп өлеше (50) Казан артына карый. Бары дүртесе генә XV, калганнары XVI гасыр белән билгеләнә. Кабер ташларыннан тыш картага шәһәр һәм авыл урыннары һәм XVI гасырның

60 елларында төзелгән исәпкә алу кенәгәләрендә телгә алынган авыллар да төшерелгән. Шушы чыганаклар нигезендә автор Казан ханлыгының татарлар яшәгән үзәк өлкәсен билгели.

Казан ханлыгының татарлар яшәгән төп жирләре хәзерге Татарстан Республикасының Чулманның төньяктагы районнарында—Казансу елгасы бассейнында урнашкан булган... Ханлыкка шулай ук Мишә елгасының урта агымындагы һәм Ашыт елгасының югары агымындагы жирләр дә кергән. Көнчыгышта бу жирләр Нократ елгасына барып житмәгән, анда удмуртлар яшәгән, ә көньякта кайбер урыннарда гына Чулман елгасына чыккан. Төп жирләргә Иделнең уң ярын да кертергә мөмкин. Бу жирләр көнбатышта Зөя елгасына кадәр, ә көньята Тәтеш шәһәренә кадәр жәелгән булган *(История Татарской АССР.—Т. I.—С. 100-102).*

Н. Ф. Калинин фикеренчә, шушы «төп жирләргә» Казан ханлыгының башка халыклары (чувашлар, мордвалар, марилар, удмуртлар, башкортлар) яшәгән жирләр кушылган.

Археология һәм язма чыганакларга таянып, Н. Ф. Калинин Казан ханлыгының чикләрен көнбатышта Сура елгасы буйлап үткәргән. Анынча, ханлыкның төньяк чиге тәгәл билгеле булмаган. Андагы мари һәм удмуртларның көньякта яшәгән өлеше Казан ханлыгына, ә төньяктагылары Рус дәүләтенә буйсынган.

Ханлыкның көнчыгыш чикләрен Калинин Нократ елгасы буенча үткәргән. Шул ук вакытта ул бу чикнең Чулман елгасы буенча үтәргә мөмкин булуын искәрткән. Чулман аръягында чик Агыйдел елгасы буйлап үткәрелгән. «Көньяк чик тә бик буталчык булган. Шул ук Герберштейн күрсәтүе буенча,—дип яза Калинин,—Чулман аръягындагы көньяк жирләр нугайлар кулында булган. Әмма Чулман арьягының борынгы болгар жирләре шулай ук, өлешчә Казан ханлыгы йогынтысында булган. Жимерелгән һәм тарих сәхнәсеннән төшеп калган Болгар шәһәрендә Казанга буйсынган аз гына халык яшәгән».

Иделнең уң ягында көньяк чик, Н. Ф. Калинин фикеренчә, Тәтеш шәһәре тирәсеннән үткән. Ләкин шунда ук ул көньякта Самарага кадәрге жирләрнең дә Казанга буйсынган булуы мөмкин, ди. Казан ханлыгының көньяк чикләре турында Худяков белән бәхәсләшеп, Калинин болай дип яза: «Кайбер тарихчыларның ханлыкның уң ярдагы чикләре хәзерге Сталинградка кадәр барып житкән дип раслаулары нигезсез».


Күренекле тарихчы Е. И. Чернышев исәп кенәгәләренә нигезләнеп, анда күрсәтелгән авылларны картага төшереп, Казан ханлыгының чикләрен билгеләгән.

«Казан ханлыгының чикләре көнбатышта Түбән Новгород өязе белән чиктәш булган һәм Сура елгасы буйлап аңа Алатырь елгасы кушылган жиргә кадәр барган. Аннары соң чик көнбатышка таба Алатырь елгасы буйлап үткән, соңыннан Мукшы елгасына күчкән һәм шунын буенча өске агымына кадәр барып көнчыгышка борылган, яңадан Сураның югары агымы буенча барып, Калада елгасы белән Иделгә, Кашпир тирәсенә чыккан һәм инде Идел буйлап Самара тамагына кадәр һәм үткән. Аннары чик көнчыгышка Самара елгасы буенча киткән, Сакмар елгасына күчеп, Агыйделгә килгән һәм аның буенча елганың Чулманга койган урынына кадәр барган. Төньяк чик Агыйдел тамагыннан Чулман буйлап Сарапулга кадәр, аннары көнбатышка Чепца елгасының Нократка койган урынына кадәр һәм урманнар, сазлыклар аша Пижма елгасы белән Ветлугага чыккан. Ветлуга буйлап аның Иделгә койган урынына кадәр барган» *(Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства (по писцовым книгам) // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья.—Казань,—С. 272).*

Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк, Е. И. Чернышев бу очракта бөтен дәүләтнең чикләрен күрсәткән.

Соңгы елларда Казан ханлыгына Урал буендагы Көнчыгыш районнарны да керткән яңа тарихи эзләнүләр дә барлыкка килде. Мәсәлән, Д. М. Исхаков, рус елъязмаларына һәм пермь татарлары этнографиясен өйрәнүләргә нигезләнеп, Тулва, Сылва һәм Ирән елгасы бассейнында яшәгән халыклар да Казан ханлыгына буйсынган дип раслый *(Исхаков Д. М. Расселение и численность пермских татар в XVIII—нач. XX в.в.// Историческая этнография татарского народа.—Казань, 1990.—С. 5—80).*

Күргәнебезчә, төрле елларда тарихчылар Казан ханлыгының чикләрен билгеләргә тырышканнар. Алар монын өчен матди чыганаклар да, язма чыганаклар да кулланганнар. Ләкин тарихи әдәбиятта бу мәсьәлә буенча бердәм фикер тумаган. Моның сәбәбе нәрсәдә соң? Күрәсең, моны чыганакларның азлыгы белән генә аңлатып булмыйдыр. Мөгаен, төп сәбәп чик төшенчәсен билгеләүнең үзендә үк ята. Чөнки дәүләт чиге төшенчәсенең бүгенге мәгънәсе урта гасырдагыдан нык аерыла. Хәзерге сыйфатта дәүләт чиге төшенчәсе бары тик XVIII гасырда Көнбатыш Европада барлыкка килгән. Нәкъ менә шул чордан башлап кына, сәяси-географик һәм хәрби төшенчә буларак чик бәйсез дәүләтнең аерылгысыз билгесе булып китә. Урта гасырларда исә бу төшенчә бик шартлы характерда булган һәм теге яки бу территориянең кайсы да булса бер дәүләткә каравы шунда яшәгән халыкның кайсы дәүләткә ясак түләвеннән чыгып билгеләнгән. Һәм без Казан ханлыгының биләмәләрен, чикләрен билгеләгәндә нәкъ менә аларның шушы шартлы характерыннан чыгып эш итәргә тиешбез, шуңа күрә беркайчан да бу чикләрне төп-төгәл итеп билгели алмаячакбыз. Моны бары тик хәзерге дәүләтләргә карата гына эшләп була.




Ханлыкның көньягында һәм көнчыгышында күчмә тормыш алып барган нугайлар һәм башкортлар яшәгән. Аларда исә дәүләт чиге дигән төшенчә бөтенләй булмаган диярлек. Шул шартны исәпкә алсаң, ни өчен нәкъ менә шушындагы чикләр турында тарихчылар арасында аеруча нык фикер каршылыклары булуы ачыклана. Бу иң мөһим—концептуаль сәбәп. Ләкин, безнен-чә, бердәнбер түгел әле.

Хәзерге көнгә кадәр Казан ханлыгының чикләрен билгеле бер вакыт кысаларында күрсәткән тарихи карта-харитә эшләнмәгән. Ә бит Казан ханлыгынын биләмәсе, нәкъ башка дәүләтләрнеке кебек үк, үзгәреп торган. Шуңа күрә, безненчә, тарихи әдәбиятта Казан ханлыгының чикләре буенча фикер каршылыклары нигезендә һәрбер тарихчының бу чикләрне үзе күз алдында тоткан вакытка карата күрсәтүе ята. Ләкин авторлар бу хронологик кысаны күрсәтмәгәннәр. Нәтиҗәдә, һәр очракта да бу билгеләмә ханлыкның бөтен чорына карый кебек тоела. Без исә, Казан ханлыгы чикләрен күрсәткәндә теге яки бу галимнең кайсы чорны күз алдында тотканлыгын ачыкларга тырыштык. Мөгаен, көнбатыш һәм төньяк чикләргә карата бу эш аеруча файдалы булыр, чөнки монда уртак тормыш алып барылган һәм, шартлы төстә булса да, чикләр тотрыклы характерда булган.

Димәк, М. Г. Худяков һәм Н. Ф. Калинин көнбатыш чикне Сура елгасы буйлап үткәргәннәр, Е. И. Чернышев исә аны Алатырь елгасы тамагыннан көнбатышка бора, Мукшының урта агымыннан башта көньякка, аннары көнчыгышка таба Сурага алып чыга *(картаны кара)*. Мукшы һәм Сура елгалары арасындагы бу җирләр Казан ханлыгына кайсы чорда кергән соң? Бер нәрсә ачык, бу шушында яшәгән мордва халкының кайсы дәүләткә ясак түләве белән бәйле.

Мордва халкының Рус дәүләтенә кертелүенә багышланган махсус эшендә Г. Я. Меркушкин болай дип яза: «1389 елда Мәскәүнең бөек кенәзе Василий

Дмитриевич Туктамыш ханнан Түбән Новгород кенәзлеге өстеннән хакимлек итү турында ярлык ала. Шуның белән ул Мәскәү кенәзлегенә Ока, Идел, Сура һәм Пьяна елгалары буенда яшәгән мордва халкын да куша... Казан ханлыгы барлыкка килү белән, көньяк-көнчыгышта яшәгән мордваларның язмышы башкачарак килеп чыга. Алтын Урданың элеккеге ханы Олуг Мөхәммәд Урдадан куылганнан соң төньяк-көнчыгышка кача, Казанны, шулай ук Сура елгасыннан көнчыгышта яшәгән мордваларны буйсындыра. Соңрак Олуг Мөхәммәд Казан ханлыгы чикләренә якын урнашкан рус шәһәрләренә әледән-әле һөҗүмнәр оештыра.

Олуг Мөхәммәднең җимергеч һөҗүмнәре нәтиҗәсендә, Казан ханлыгы карамагына көнчыгыш мордва гына түгел, ә Сура һәм Мукшыдан көнбатыштагылары да күчә *(Меркушкин Г. Я. Вхождение мордовского народа в состав Русского централизованного многонационального государства // Этногенез мордовского народа.— Саранск, 1965.—С. 79)*. Шунда ук Меркушкин бу халыкның, димәк, шул җирләрнең Казан ханлыгына кергәнлеген исбатлап болай ди: «Казан ханнары хакимлегенә эләккән мордва халкы, Алтын Урда чорындагы кебек, аларга зур ясак түләргә мәҗбүр ителде» *(шунда ук)*.

Димәк, Сура елгасыннан көнбатыштагы җирләрне Казан ханлыгына керткән Е. И. Чернышев хаклы булып чыга! Ләкин ахыргы нәтиҗәне чыгарырга иртәрәк әле. Моның өчен мордва халкының Рус дәүләте составына кертелү тарихын өйрәнүне дәвам итәргә кирәк. Шул ук автордан менә нәрсәләр беләбез: «Рус дәүләтенең көнчыгыш чикләрен һәм монда үзенең сәяси хакимиятен ныгыту өчен, XVI гасырның I яртысында рус хөкүмәте мордвалар яшәгән җирләрдә берничә шәһәр-кальга төзи. XVI гасыр башында Мукшы елгасы буенда иске Наровчат шәһәре яңадан торгызыла. 1523 елда Сура елгасы тамагында яңа кальга—Васильсурск төзелә. Сура елгасының түбәнге агымында чикләрне ныгыту белән бергә, Рус дәүләте елганың сулъяк ярында Алатырь елгасы буйлап кальгалар төзү эшен җәелдерә. 1535 елда Мукшының югары агымында Мокшанск, тиздән Алатырь елгасының Сурага койган урынында Алатырь кальгасы үсеп чыга. 1536 елда Иске Темников шәһәреннән бераз югарырак Яңа Темников кальгасы төзелә.

Яңа рус шәһәрләренә нигез салыну һәм анда рус гарнизоннары урнаштыру белән, бу якларда өстенлек итүче җирле татар кенәзләре бөек кенәз хакимлеген танырга мәҗбүр булганнар. Шулай итеп, мордва җирләренең күпчелеге Мәскәү кенәзлегенә кушылган».

Моны 1517 һәм 1526 нчы елларда Рус дәүләтендә булып киткән алман илчесе Герберштейн мәгълүматлары да раслый: «Мукшы елгасыннан көнчыгышта һәм көньякта зур урманнар очрый, анда мордва халкы яши, алар аерым телдә сөйләшәләр һәм Мәскәү хакименә буйсыналар» *(Документы и материалы по истории Мордовской АССР.—Саранск, 1940.—С. I.—Т. 183)*.

Күргәнебезчә, бу җирләрне Рус дәүләтенеке дип санаган М. Г. Худяков һәм Н. Ф. Калинин да хаклы булып чыга! Табышмакның чишелеше шунда: билгеле бер чорда бу җирләрдә яшәгән мордвалар ясакны Казан ханлыгына бирсәләр, соңыннан Рус дәүләтенә түли башлаганнар. Безгә исә ясакның Казан казнасына килгән чорны гына билгелисе кала. Ләкин бу бик катлаулы һәм махсус эзләнүләр таләп итә торган сорау. Монда без, мөгаен, бу чор якынча 1445 елдан 1525 елга кадәр булгандыр дигән фараз белән генә чикләнәбез.

Шушы ук ысул белән Казан ханлыгының төньяк чикләре мәсьәләсенә дә берникадәр ачыклык кертергә мөмкин. Бу очракта төгәл вакытны да күрсәтергә мөмкин.

Алда әйтелгәнчә, М. Г. Худяков һәм Е. И. Чернышев Казан ханлыгына Нократ, Чепца, Воя елгалары арасындагы җирләрне кертү турында фикерләре капма-каршы килә.

Археология һәм язма чыганаклар күрсәткәнчә, бу җирләрне болгарларның үзләштерә башлавы XIV гасырдан ук башлана. Шул чорда ук Чепца елгасы бассейнында болгарлар яшәгән авыллар барлыкка килә. Ләкин Чепца буенда болгар авыллары салыну Нократ буенда Новгород һәм Устюг колонистлары тарафыннан рус шәһәрләре һәм авыллары (Никулицын, Хлынов, Котельнич) төзелү белән бер вакытка туры килә *(Худяков М. Г. Күрсәтелгән әсәр.—20 б.)*.

Шул чордан башлап бу регионда рус кенәзләре һәм татар ханнарының мәнфәгатьләре бәрелешә башлый. XV гасырда Нократ төбәге Мәскәү һәм Казан арасындагы аяусыз сәяси көрәш мәйданына әверелә. Төбәкнең киск җәнлек тиресенә бай булуы бу көрәшне тагын да кискенләштерә. Шуна күрә бу сәяси генә түгел, ә икътисади мәнфәгатьләр бәрелеше дә була.

Ике дәүләтнең сәяси амбицияләре компромиссы буларак, Нократ төбәгендә үзенчәлекле сәяси берләшмә—Нократ общинасы хасил була. Ул рус һәм татар колонистлары һәм җирле удмурт халкы конгломераты була. Шулай булуга карамастан, һәр ике як та монда үз хакимлеген тулысынча урнаштыру уеннан кире кайтмый. Рус дәүләтенең дә, Казан ханлыгының да эчке һәм тышкы сәүдәсендә кыйммәтле җәнлек тиреләренә сорау арткан саен, бу көрәш һаман кискенләшә, һәм, ниһаять, 1467—1469 елларда ике арада сугыш хәрәкәтләренә китереп җиткерә.

Бу сугышта капма-каршы яклар Нократ общинасын үз якларында файдаланырга омтылалар. Мәсәлән, 1468 елда нократлылар Мәскәү гаскәре белән Казан ханлыгына походка тартылганнар. Ләкин казанлыларның Нократка юнәлгәннәрен ишетеп, кире борылырга мәҗбүр булганнар. Шулай да алар казанлылар һөҗүмен кире кайтара алмыйлар. Нократ кирмәне (Хлынов) татарлар кулына күчә. Шушы уңышлы хәрби операция нәтиҗәсендә, Нократка хан вәкиле куела һәм бөтен Нократ общинасы Казан ханлыгы йогынтысына эләгә. Хокукый яктан бу нейтралитетны раслау рәвешендә генә булса да, чынлыкта, төбәк Казан ханлыгы составына кертелә *(Полное собрание русских летописей.— Москва, 1962-1968.—Т. 26.—С. 224).*

1469 елда русларның Казанга яңа походы оештырыла. Алдагы елда төзелгән килешү нигезендә нократлылар рус гаскәренә түгел, ә татар гаскәренә кушылалар. Львов елъязмасындагы мәгълүмат нәкъ менә шул вакыйгага карый: «Шулвакыт алар янына Казаннан әсир Коломнятин килде һәм Казан патшасы Ибраһим аларга каршы бөтен җире белән, Нократ һәм Сыплин, Костяк һәм Агыйдел, Вотяк һәм Башкорт җирләре белән чыга» *(ПСРЛ.—Т. 20, ч. I.—С. 281).*

«Удмуртиянең Россиягә ирекле кушылуына 425 ел» исемле монография авторлары елъязманың «Вотяк җире» дигән сүзе нәкъ менә төньяк удмуртлар яшәгән җирләрне аңлата дип уйлыйлар. Ә бу җирләрнең үзәген исә безне кызыксындырган Нократ общинасы тәшкил итә.

«Казан ханы шактый көч туплауга ирешә. Аның гаскәренә, елъязма хәбәр иткәнчә, «Вотяк җире» кешеләре дә кергән. Бу чорда «Вотяк җире» Казан ханлыгына турыдан-туры буйсынган көньяк удмуртларны гына түгел, ә төньяк, нократ удмурдларын да берләштергән дип уйларга тулы хокукыбыз бар. Димәк, Нократ җиренең Казан ханлыгына вакытлыча бәйлелеге җирле халыкка да кагылган *(425 лет добровольного присоединения Удмуртии к России.—Ижевск, 1983.—С. 23—24).*

Күрәсең, безне кызыксындырган әлеге төньяк җирләрнең Казан ханлыгына буйсынуы 1487 елда Мәскәү гаскәренең Казан тәхетенә үз иярченнәре Мөхәммәд Әминне утыртканчыга кадәр дәвам иткәндер. Соңыннан, көндәшенең вакытлыча көчсезләнүеннән файдаланып, 1489 елда Иван III гаскәрләре Нократ общинасының башкаласы Нократ шәһәрен (Хлынов, хәзерге Киров шәһәре) яулап ала һәм бөтен төбәкне Рус дәүләтенә тулысынча куша.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, Казан ханлыгы картасын төзегән вакытта башка дәүләтләрнеке кебек үк аның да биләмәләре үзгәреп торуын исәпкә алырга кирәк. Аерым җирләрнең Казан ханлыгына кергән вакытын күрсәткән карта төзү зарур.

Без бу эшебездә шундый ике төбәкне билгели алдык. Бу—1445—1525 елларда Казан ханлыгына караган Мукшы һәм Сура елгалары арасы һәм 1468—1487 елларда Казанга буйсынган Нократ общинасы җирләре.

**Исрафил НАСЫЙБУЛЛИН**



Qөr'әn tatar telendә
Коръән татар телендә

# 15—ХИҖР (ХИҖЫР ИЛЕ) СҮРӘСЕ

**( Хиҗр сүрәсе 99 аятьтән тора. 80-84 нче аятьләрдә Хиҗр исемле җир турында сөйләнә. Сүрәнең исеме шуннан килә.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Әлиф. Ләм. Ра. Болар Китапның—Коръәннең ап-ачык аятьләре.

**2.** *(Кыямәт)* вакыты килгәч, инкарьчылар:
—Их, без дә мөселман булса идек,—дип уфтанырлар.

**3.** Аларны ташла, ашасыннар, истирахәт кылсыннар вә буш өметкә алдансыннар. Ахырда ни булачагын озакламый беләчәкләр. **(4)** Язмышында булмаган, алдан кисәтелмәгән бер генә шәһәрне дә без *(сәбәпсезгә)* харап итмәдек. **(5)** Һичбер халык әҗәлен узып китә алмый, әҗәлен кичектерә дә алмас.

**6.** Әйттеләр:
—Әй, син, үзенә Коръән иңдерелгән Мөхәммәд! Мөгаен, сине җен алыштыргандыр. **(7)** Әгәр син дөресен сөйлисең икән, безгә фәрештәләрне иңдерт,—диделәр.

*(«Борынгы гарәп халкы: шагыйрьләр җеннән илһам ала, дип инанганнар. Нәфис сүзле һәм тәмле телле шигъри әсәрләрдән дә өстен бер Китап (Коръәнне) алып килгәне өчен, Пәйгамбәребезгә «Мәҗнүн, Җенле шагыйрь» кушаматы тактылар».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**8.** Фәрештәләрне Без фәкать *(ихтыяҗ булганга гына)* Хакыйкать белән бергә иңдерәбез. Ул вакытта *(фәрештәләр иңгәч, кяферләргә гөнаһларын юар өчен форсат бирелмәс, фәрештәләр аларның эшен бик тиз бетерер).* **(9)** Коръәнне Без иңдердек. Бу—Хакыйкать. Әлбәттә, аны Без үк саклаячакбыз да. **(10)** Хактыр ки, синнән әүвәл дә Без халыкларга илчеләр күндергән идек. **(11)** Алар *(кяферләр)* үзләренә килгән һәр пәйгамбәрдән көләләр иде. **(12)** Менә шулай итеп, Без *(игелекле кешедән мәсхәрә итеп көлү теләгән)* гөнаһлыларның гадәтенә салабыз. **(13)** Әүвәл яшәгән халыкларның башына килгән җәзалардан сабак алмыйча, алар һаман моңа *(Коръәнгә)* ышанмыйлар. **(14)** Күк капусы ачылып, алар югарыга менсәләр, **(15)** Тагын:
—Күз будылар, дөресрәге: безне сихерләделәр,—дип әйтерләр иде. **(16)** Хактыр ки, Без Күктә байтак кына йолдызлыклар хасил иттек. *(Карап сокланыр өчен Күкне)* шулай бизәдек. **(17)** Аларны таш атып куылган шайтаннан сакладык. **(18)** Колак салып, тыңнанып йөри торган шайтан бар, аның артыннан да ялтырап, ут чыбыркысы атыла. **(19)** Җирне ястык кебек итеп кабарттык. Анда каты токымлы тауларны урнаштырдык, янә анда төгәл микъдарда үлчәүле итеп *(һәрнәрсәне)* үстердек. **(20)** Анда сезнең өчен дә, сез тәрбияләми торган *(кыргый җәнлек, кош-корт, үсемлекләр)* нәрсәләр өчен дә яшәү шартлары яраттык. **(21)** Һәр нәрсәнең хәзинәсе бары тик Безнең ихтыярыбызда. Без аны кирәк микъдарда гына иңдерәбез. **(22)** Без уңдырыш

Журнал өчен **Рабит БАТУЛЛА** әзерләде.

китерүче җилләрне ясадык. Күктән яңгыр яудырдык; шулай итеп, сезнең сусау ихтыяҗыгызны бастык. Ләкин сез ул суларны саклый алмыйсыз. **(23)** Шик юк ки, Без терелтүче дә, үтерүче дә. Һәрнәрсәгә Без варис. **(24)** Хактыр ки, Без сездән элек яшәп киткәннәрне дә, сезнең арттан киләчәкләрне дә беләбез. **(25)** Һичшиксез, Аллаһ аларның барысын да үз янына туплаячак. Ул—хакимдер, галимдер.

**26.** Хактыр ки, Без кешене зыңгылдап торган *(саф)* балчыктан яратып, рәвешле иттек. **(27)** Җеннәрне дә электән үк уттан яралттык.

*(«Җенне, иблисне, шайтанны уттан яралтты» сүзләре кайнар холыклы, ут кебек җитез, буйсынмас һәм тәкәббер, мәгърур кешеләр турында сөйләнгәндә кулланыла, андый тиктормас, гадәттә, кешеләрне ярамаган маҗараларга котырта. «Адәмне туфрактан, балчыктан, җеннәрне уттан» дигән гыйбарәләр, һичшиксез, чагыштырма мәгънәдә кешеләрнең табигатен, холкын сурәтләгәндә кулланыла, сабырлар Аллаһның кагыйдәләренә буйсына, җенле кешеләр һәрвакыт тәртип боза. «Зыңгылдап торган балчыктан» гыйбарәсе башка җан ияләреннән аермалы буларак, адәми затның сөйләшә, җырлый белүенә ишарә икәне күренеп тора. Бу аңлатма Мәүланә Али китабыннан алынды.)*

**28.** Шулай итеп, Аллаһ фәрештәләргә әйтте:

—Мин зыңгылдап торган *(саф)* балчыктан, аңа рәвеш биреп, бер кеше яралтачакмын. **(29)** Аңа рәвеш биргәч, җан өрелгәч, сез аңа сәҗдә итәрсез,—диде. **(30)** Фәрештәләрнең барысы да шундук сәҗдә итте. **(31)** Иблистән башкалары. Ул сәҗдә итүчеләр белән сәҗдәгә егылмады. Баш тартты.

**32.** —Әй, Иблис, нигә син сәҗдә итүчеләр белән бергә түгел идең? Сәҗдә итмәүеннең сәбәбен әйт,—диде Аллаһ.

**33.**—Нишләп мин кибеп беткән балчыктан ясалган бер бәндәгә сәҗдә итим! *(чөнки мин уттан яралтылган затмын)*,—диде Иблис.

**34.** Аллаһ боерды:

—Алайса, кит моннан! Мин сине *(ләгънәт орып)* куамын!—диде.—**(35)**—Хактыр ки, син Кыямәт көненә чаклы ләгънәтләнгән килеш калырсың.

**36.**—Раббым,—диде Иблис.—Алайса, барчасының яңадан терелгәненә чаклы *(җәзамны кичектер)* форсат бир миңа.

**37.** Аллаһ әйтте:

—Чыннан да, син кичектерелгәннәрнең берсе. **(38)** Мәгълүм бер вакытка чаклы.

**39.** *(Иблис)* әйтте:

—Раббым, мине *(тугры юлдан)* яздырганыңа күрә, мин дә Җир йөзендәгеләргә гөнаһларын ләззәтле вә гүзәл гамәл итеп күрсәтермен һәм юлдан яздырырмын. **(40)** Тугры колларыңнан калган барчасын,—диде.

**41.** Шулай боерды:

—Әнә шул юл—Минем тарафка тугры юл булыр. **(42)** —Шөбһәсез, колларым өстеннән синең хакимиятең юк. Азгынлыкка батканнардан тыш. **(43)** Хактыр ки, җәһәннәм алар өчен корылган урын. **(44)** Җәһәннәмнең җиде капкасы бар. Кешеләр *(ни дәрәҗәдә кылган гөнаһларына күрә)* төркем-төркем шул капкалардан керер.

*(«Кайбер дин галимнәренең әйтүенә караганда, беренче төркем Һәвия капкасыннан керер: алар—гөнаһлы мөселманнар. Икенчесе—Сакар: яһүдләр өчен; өченчесе—Сәгыйр: христианнар өчен; дүртенчесе—Җаһим: Кояш, Ай, йолдызларга табынучылар (Сабия) өчен; бишенчесе—Ләза: утка табынучыларга; алтынчысы—Хутамә: пот-пәрәстләр, сынга, һәйкәлләргә табынучылар өчен; җиденчесе: монафикълар өчен».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**45.** *(Аллаһның җәзасыннан куркып, Аның юлында тугры булып тормыш кичергән)* тәкъва мөселманнар, һичшиксез, җәннәт бакчаларында, чишмә буйларында булачак. **(46)** Аларга:

—Иминлек вә сәламәтлек илә керегез,—дип әйтелер.

**47.** Без алар күнелендәге *(хөсетлек, мәкер)* чәнечкеләрне суырып аттык; алар инде туганлашып, кәнәфиләргә кара-каршы утырачак. **(48)** Алар анда беркайчан да *(авыр эш эшләп)* алҗымаячак вә аларны аннан беркайчан да чыгармаячак. **(49)** *(Ий, Рәсүлем)* колларыма Минем ярлыкаучы вә гафу итүче икәнемне сөйлә. **(50)** Мин бирәчәк җәзаның бик тә хәтәр булачагын да белдер. **(51)** Аларга Ибраһим өенә килгән кунаклар *(фәрештәләр)* белән булган вакыйга турында да хәбәр бир. **(52)** Ибраһим өенә кергәч, кунаклар әйтте:

—Сәлам,—диделәр. Ибраһим исә аларга:

—Дөресен әйтим, мин сездән куркамын,—диде. **(53)** Тегеләр әйтте:

—Курыкма, без синең гыйлемле углың туачагы турында хәбәр китердек,—диделәр. **(54)**

—Картлыгым килеп житкәч кенә сез мине *(балаң туачак, дип)* куандырырга килдегезме? Мине нәрсә белән куандырачаксыз?—диде Ибраһим. **(55)**—Без сиңа дөресен сөйләргә килдек, аң бул, өметенне өзмә,—диделәр. **(56)**—Раббымның рәхмәтеннән бары тик юлдан язганнар гына өмет өзә,—диде Ибраһим. **(57)**—Әй, илчеләр, тагын нинди йомышыгыз бар?—диде Ибраһим. **(58)** Әйттеләр:

—Без гөнаһлы халыкларга *(һәлак итәргә)* күндерелдек. **(59)** Лут гаиләсеннән тыш. *(Лутныкыларны)* коткарачакбыз. **(60)** Лутның хатыныннан башкасын *(коткарачакбыз)*. Аны *(хатынны)* без *(җәзага тартыр өчен)* азгыннардан санадык. **(61)** Илчеләр Лут гаиләсенә килгәч, **(62)** Лут аларга:

—Дөресен әйтим, сез мин таныганнардан түгел,—диде **(63)** *(Кунаклар)* әйтте:—Без алар *(кяферләр)* шикләнеп караган нәрсәне *(газапны, һәлакәтне)* алып килдек. **(64)** Сиңа Хакыйкать алып килдек. Без дөресен сөйлибез. **(65)** Төн урталарында гаиләңне юлга чыгар, үзең дә алардан калма. Сак булыгыз, артыгызга борылып карамыйча, боерылган якка китегез,—диделәр. **(66)** Аңа *(Лутка)* шушы хөкемебезне вәхий иттек:

—Таң атканда аларның *(Лутның гөнаһлы кардәшләренең)* юлы, һичшиксез, киселәчәк. **(67)** Шәһәр ирләре *(шәһвәти кытыклану)* куаныч белән *(чибәр егетләр кыяфәтенә кергән)* фәрештәләр янына килде. **(68)** Лут аларга әйтте:

—Болар минем кунакларым,—диде. **(69)**—*(Аларга кагылып)* зинһар, мине оятка калдырмагыз, Аллаһтан *(җәзасыннан)* куркыгыз, йөземә кызыллык китермәгез.

**70.** —*(Безнең бу эшләребезгә тыкшынма)* бөтен мирдән килгән егетләрне өеңә кертеп кунак итмә, димәдекме?

**71.** —Менә сезгә кызларым! *(Алар белән теләгәнегезчә)* кыланыгыз *(кирәксә, өйләнегез, кунакларыма гына кагылмагыз)*,—диде.

**72.** —*(Рәсүлем)* Синең тормышың белән ант итәмен ки, алар *(җенси шәһвәти бозыклык)* исереклек эчендә адашып йөри торган хәлдә иде. **(73)** Кояш чыккан чакта аларны дәһшәтле-куркыныч бер гөрелте басты. **(74)** Шулай итеп, Без алар өлкәсендәге җирнең астын өскә китердек. Башларына яндырылган ташлар яудырдык. **(75)** Хактыр ки, гыйбрәт алучылар өчен монда хикмәтләр бар. **(76)** Алар *(хәрабәләр)* һаман үтеп-сүтеп йөри торган юл өстендә тора.

*(«Лут халкы арасында күтләклек (педерастия) бозыклыгы таралган була. Шул гөнаһлары өчен Аллаһ Тәгалә алар өстенә дәһшәтле-куркыныч гөрелте ишеттерә, гөрелтедән соң җир тетри башлый, башларына таш яудыра, аларның шәһәре хәрабәләргә әверелә. Халык юкка чыга».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**77.** Хакыйкатән, монда *(бу вакыйгаларда)* иманлы кешеләр өчен бер гыйбрәт бар.

**78.** Әйкә халкы да чынлыкта гаделсез-залим кавем иде.

**79.** Без аларга җәза бирдек. Икесе дә *(Әйкә белән Мәдьян халыклары)* күренеп тора торган юл өстендә *(ге хәрабәләр астында)*.

**80.** Менә тагын Хиҗр халкы да пәйгамбәрләрен ялганчыга чыгарды.

**81.** Без аларга могҗизалы аятьләребезне иңдердек, ләкин алар баш тартты. **(82)** Алар иминлек өчен кыя-тауларны тишеп, торак ясадылар. **(83)** Аларны да иртәнге якта куркыныч гөрелте *(һәлакәт)* каплады. **(84)** Җыйнаган байлыклары аларны һичбер җәзадан коткара алмады. **(85)** Без күкләрне, Җирне һәм алар арасындагыларны хаклык белән яраттык. Ул Сәгать *(Кыямәт)*, һичшиксез, сугачак. Хәзердән үк аларга хөрмәт белән бак. **(86)** Дөрестән дә, Раббың бар итүче, һәрнәрсәне белеп торучы. **(87)** Хактыр ки, Без сиңа кабатланучы җиде аятьне һәм изге Коръәнне бирдек.

*(Бер хәдистә бу аятьләрнең җиде аятьтән торган Фатиха сүрәсе икәнлеге әйтелә. Фатиха сүрәсе һәр рәкәгатьтә кабатлана.*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**88.** Сак бул, без аларның бер кавеменә биргән дөнья малына кызыгып бакма, аларга эчең пошмасын вә мөэминнәргә кече күңелле бул.

**89.** Әйт:

—Хактыр ки, мин бары тик *(гөнаһ кылсагыз, җәзаланырсыз, дип)* кисәтүче генә,—диген.

**90.** Фетнә коручыларга Без газап иңдердек. **(91)** Алар Коръәнне вак-вак кисәкләргә бүлгәләделәр. **(92)** Валлаһи, дип әйтәмен ки, без аларны җавапка тартырбыз. **(93)** Кылган гөнаһлары өчен. **(94)** Боерылганнарны яхшы аңлат вә *(Аллаһка)* тиң *(дип ташка, потка)* табынганнардан ерак тор. **(95)** Сине мыскыллаганнарга каршы көрәшергә Безнең ярдәмебез җитәр. **(96)** Алар: Аллаһ белән бер дәрәҗәдә, дип, башка бер уйдырма тәңрегә табына башладылар. Озакламый барысы да ачыкланачак. **(97)** Алар сөйләгәннәргә синең *(күкрәгең кысылып)* җаның сыкраганны да бик яхшы беләмен. **(98)** Син бүгеннән Раббыңа мәдхия укып, тәсбих әйт вә сәҗдә иткәннәр сафында бул. **(99)** Әҗәлең килгәнгә кадәр Раббыңа гыйбадәт кыл.

# 16—НӘХЕЛ (БАЛ КОРТЫ) СҮРӘСЕ

**(Нәхел—Бал корты сүрәсе 128 аятьтән тора. 68 нче аятьтә бал корты турында язылганга күрә, Нәхел исемен йөртә.)**

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1.** Аллаһтан әмер *(Кыямәт көненә кадәр гөнаһ кылганнарга нинди хәтәр җәзалар биреләчәге турында кисәтүче Коръән)* килде. Аны *(Ул бирәчәк җәзаларны)* ашыктырмагыз. Аллаһ кяферләр тәңрегә тиң күргән нәстәләрдән ерак тора һәм Ул алардан өстен *(Аллаһ бөек)*. **(2)** Ул Үзенең әмере белән теләгән колларына *(пәйгамбәрләргә)* вәхий аша фәрештәләрне иңдерде:

—Миннән башка тәңре булмаганлыгы турында кисәтегез һәм гөнаһ кылудан куркыгыз,—дип кисәтү өчен.

**3.** Ул күкләрне вә Җирне Хакыйкать *(нең тантана итүе)* өчен яратты. Ул *(кяферләрнең Аллаһка)* тиң күреп табынганнарыннан өстен.

**4.** Адәмне Ул бер тамчыдан яратты. Шулай булуына карамастан, ул *(Адәми зат)* дошманлаша.

*(Ш. Ногманида: бер тамчы судан халик кыла. Т. Кочигиттә: бер тамчы судан*

*яралтты. М. Алидә: из малой капли жизненной, «малая капля жизненная»—это сперматозоид, находящийся в семенной жидкости.)*

**5.** Малларны *(дөя, ишәк, кәҗә, сарык, сыерларны да)* сезнең файдага яралтты *(атланып йөрергә, яңгыр-кардан саклану өчен йоннарыннан, тиредән җылы кием тегәргә).* Ризыкланыр өчен дә *(итен ашарга, сөтен эчәргә).* **(6)** Кичен абзарга япканда да, иртәләрен көтүгә куганда да сезнең өчен бу малларда матурлык һәм куаныч бар. **(7)** Алар сезнең тауарларыгызны төяп, *(шул йөк хайваннары булмаса, ул араларга барып та җитә алмаган булыр идегез, барып җиткәндә дә, ярты җаныгыз чыккан булыр иде)* ерак мәмләкәтләргә алып бара. Шик юк ки, Раббыгыз ярлыкаучы, миһербан ияседер. **(8)** Атланып йөрер өчен, мәртәбәләр *(тантаналар)* өчен атларны, качырларны, йөкташыр хайваннарны *(дөяне)* яралттык. Сез әлегә белмәгән башка бик күп нәрсәләрне яралтырбыз.

**9.** Тугры юлга бары тик Аллаһ кына күндерә ала. Ялгыш юллагылар да бар. Аллаһ ихтыяр итсә, барыгызны да, һичшиксез, тугры юлга күндергән булыр иде. **(10)** Ул сезнең өчен күктән яңгыр яудырды. Эчәр өчен су бирде, хайваннарыгыз утлап йөрсен өчен үләннәр өстерде. **(11)** *(Аллаһ)* сезнең өчен игеннәр, зәйтүннәр, хөрмә агачлары, йөземнәр вә җиләк-җимешләрнең һәрберсен үстерде. Боларда башында фикере булган кеше өчен, әлбәттә, Аллаһның барлыгына, Аның чиксез кодрәтенә дәлил бар. **(12)** Төнне, көнне, Кояшны, Айны сезнең өчен бар итте. Йолдызлар да Аның әмеренә буйсына. Хактыр ки, боларның һәрберсендә акылы башында булганнар өчен гыйбрәтләр бар. **(13)** Сезнең өчен Җир өстен төрле төстә *(чәчәкләр, үсемлекләр)* яралтты. Үгет алырдай зиһенлеләргә монда, әлбәттә, исбат-дәлил бар. **(14)** Саф ит *(балык)* ашасыннар дип, зиннәтләр *(энҗе-мәрҗәннәр)* чыгарсыннар дип, Ул сезнең өчен диңгезне яралтты. Күрәсеңме, көймәләр *(диңгез суларын)* ярып йөзеп йөри; *(ул көймәләрдә адәмнәр Аллаһның)* рәхмәтен эзләсеннәр һәм *(бар табышларына)* шөкер итсеннәр өчен.

**15.** Сез тетрәп чайкалмасын дип, Ул Җир йөзенә каты токымлы таулар тезмәсен беркетте, елгалар, юллар ясатты. Ихтимал, сез тугры юл буйлап китәрсез дип. **(16)** Тагын әллә нинди галәмәтләр, йолдызлар да аларның юлын дөресләр өчен *(яралтылды).*

**17.** Яралткан белән яралтырга көченнән килмәгән тиң буламы? Шуны да аңлар дәрәҗәдә түгелмени сез?

**18.** Аллаһның бәрәкәтен *(рәхмәтен, байлыгын)* санарга алынсагыз, очына чыга алмассыз. Шик-шөбһәсез ки, Аллаһ ярлыкаучы, гафу итүче. **(19)** Аллаһ яшерен эшләрегезне дә, ачыкларын да белеп тора.

**20.** Аллаһны инкарь итеп, алар табынган затлар *(потлар)* берни дә ялралта алмый. Чөнки алар *(потлар)* үзләре дә *(кемдер тарафыннан)* ясалган. **(21)** Алар җанлы түгел, үлеләр. *(Алар үзләренә табынучыларның)* кайчан терелтелячәкләрен дә белми.

**22.** Аллаһ бер генә. Ахирәткә ышанмаганнар бар, аларның күңелләре инкарьчы, үзләре тәкәббер, масайган кешеләр. **(23)** Шик юк ки, аларның яшергәнен дә, яшермәгәнен дә Аллаһ белеп тора. Аллаһ:

—Мин бөек,—дигәннәрне сөйми. **(24)** Аларга:

—Раббыгыз ни иңдерде?—дип әйтсәң:

—Әби-баба сөйләгән әкиятләрне,—диләр.

**25.** Кыямәт көненә *(аздыручылар)* үз гөнаһлары белән бергә, үзләре юлдан яздырган наданнарның гөнаһларын да үз җилкәләренә төяп алып килер. Аһ, нинди авыр йөк булыр ул!

**26.** Алардан элек яшәгәннәр дә *(пәйгамбәрләренә)* хәйлә корды. Ахырда Аллаһ та аларның йортларын нигезеннән алып, түбәсенә кадәр астын өскә китерде. Бу гарасат аларга көтмәгәндә килеп басты. **(27)** Ахырда, Кыямәт көнендә *(Аллаһ)* аларны бичара итәр һәм әйтер:

—Аллаһка тиң күреп табынган нәстәләрегез аркасында *(мөэминнәр илә)* дошманлаша идегез. Ул нәстәләрегез кайда?—дияр.

Гыйлемле кешеләр әйтер:

—Чыннан да, бүген кяферләр бичара булып, хәтәр хәлдә калды,—диярләр.

**28.** *(Коръән белән гамәл кылмыйча)* үзләренә үзләре яманлык чакырган кешеләрнең җанын алганда алар *(мөшрикләр җан алучы)* фәрештәләргә ялварыр:

—Без бернинди дә яманлык кылмадык,—диячәкләр.

*(Фәрештәләр әйтер):*

—Ялганлыйсыз, Аллаһ сез кылганнарның барысын да белеп тора. **(29)** Бәс, җәһәннәм капкасыннан керегез, сез мәңгегә шунда калачаксыз. Үзләрен *(барча кешедән)* өстен куйганнарның урыны бик тә хәтәр урын.

30. *(Гөнаһлардан)* сакланганнарга:

—Раббыгыз ни индерде?—дигәч, алар:

—Игелек индерде,—дип әйтер. Фани дөньяда игелек кылганнарга игелекле әҗерләр булыр. Ахирәт йорты исә бик тә хәерледер. Тәкъва мөселманнарның йорты, чыннан да, Сәгадәттер. **(31)** Ул урын—арыкларыннан чишмәләр агып торучы Гаден җәннәтләредер. Анда һәр теләгән нәрсә бар. Аллаһ Тәгалә тәкъва мөселманнарны шулай бүләкли. **(32)** Саф мөселманнарның җаннарын игелек белән алганда фәрештәләр әйтер:

—Сезгә сәлам. Кылган игелекләрегезгә күрә, җәннәткә керегез,—диячәкләр.

**33.** *(Кяферләр)* үз яннарына *(җәза)* фәрештәләре килмәс яки Раббының әмере җиренә житмәс, дип өмет итәме? Алардан әүвәл яшәгәннәр дә нәкъ шулай кыланганнар иде. Аллаһ аларга бәла китермәде, алар үзләренә үзләре бәла китерде. **(34)** Ахырда кылмышларының җәзасы үзләренең өстенә төште вә *(пәйгамбәрләрне)* мәсхәрә итеп көлгәннәре *(нең җәзасы)* аларны һәрьяклап камап алды.

**35.** Ялган тәңреләргә табынганнар әйтте:

—Аллаһ ихтыяр иткән булса иде, без дә, аталарыбыз да башка затка табынмаган булыр идек. Аның рөхсәтеннән башка һичбер нәрсәне харамга чыгармаган булыр идек,—диделәр. Алардан алда яшәгәннәр дә шулай кыланган иде. Аятьләребезне ачык-төгәл итеп аңлатудан, кисәтүдән башка пәйгамбәрләрнең бүтән вазифалары бармы икәнни соң?

**36.** Хактыр ки, Без:

—Аллаһка буйсыныгыз һәм Тагуттан ваз кичегез,—дип кисәтсеннәр өчен, пәйгамбәрләр күндердек. Аллаһ аларның *(мөшрикләрнең)* бер кавымын тугры юлга күндерде. Бер кавымын исә адаштырды. Җир өсте буйлап сәяхәт итегез һәм багыгыз, инкар итүчеләрнең язмышы ни белән бетте икән?

*(«Тагут—Хак Тәгаләне танымыйча, инкарь итеп, азган, адашкан һәр кешегә һәм шайтанга карата кулланыла торган сүз».*

Хәйретдин Караман, Садретдин Гүмеш тәфсирләреннән.)

**37.** *(Ий, Рәсүлем)* син аларның тугры юлга басмаганнарына кайгырасың, ләкин син белеп тор, Аллаһ ихтыяр итмәсә, адашканнарны тугры юлга чыгармас. Аларның ярдәмчесе дә булмас *(Аларга тугры юл күрсәтүче дә булмас).*

**38.** Алар үзләренең иң олы антлары—Аллаһ исеме белән:

—Валлаһи, Аллаһ үлгәннәрне терелтмәячәк,—дип ант иттеләр. Юк шул *(алар хаклы түгел),* Аллаһ вәгъдәсендә торачак *(үлеләрне терелтәчәк).* Ләкин бу турыда күбесе белми. **(39)** Бәхәс күтәргән мәсьәләләрне ачыклар өчен, денсезләрнең ялганчы икәнен күрсәтер өчен Ул аларны терелтәчәк.

**40.** Без берәр нәрсә булуын теләсәк:

—Бар бул,—дибез.—Һәм ул әйбер шундук барлыкка килә.

**41.** Рәнҗетүләргә чыдый алмыйча, Аллаһ юлы белән һиҗрәт иткәннәрне Без яхшы җирләргә урнаштырабыз. Белеп торыгыз, Ахирәтнең әҗере аннан

да яхшырак булыр. **(42)** Алар *(ватаннарын, йортларын, малларын ташлап, һиҗрәт иткән мөселманнар)* бары тик Раббыга тәвәккәл иткән чыдам кешеләр.

**43.** Синнән алда да Без пәйгамбәр итеп үзләренә вәхий индерелгәннәрне генә җибәрә тордык. Белмәгәнегезне белгәннәрдән сорагыз. **(44)** Ап-ачык могҗизалар һәм китаплар белән *(пәйгамбәрләрне җибәрдек)*. Кешеләргә, үзләренә индерелгәнне аңлатмак өчен вә уйлый-уйлый аңласыннар дип, сиңа да бу Коръәнне индердек.

**45.** Мәкер тозаклары корганнар: Аллаһ әмере белән безне җир йотмас яки абайламаган яктан өстебезгә һәлакәт килмәс, дип, **(46)** яки *(тормыш мәшәкатьләре белән)* мәшгуль булганда Аллаһның җәзасы тотмас, дип уйлыйлармы? Алар Аллаһны төп башына утырта һәм *(качып котыла)* алмас. **(47)** Яки Аллаһ аларны әкрен-әкрен кимәтә-кимәтә бөтенләй бетермәячәк, дип өмет итәләрме? Шик юк ки, Раббың шәфкатькә юмарт һәм бик мәрхәмәтле.

**48.** Аллаһ яралткан барча нәрсәләрне күрмисезмени? Аларның күләгәләре Аллаһка сәҗдә итеп уңга-сулга чайкала. **(49)** Күкләрдә булганнар, Җирдәге җан ияләре вә бөтен фәрештәләр, тәкәбберләнмичә, Аллаһка сәҗдә итәләр. **(50)** Алар өстән күзәтүче Аллаһның җәзасыннан куркалар һәм үзләренә боерылганны башкаралар. **(51)** Аллаһ боерды:

—Икенче тәңре эзләмәгез. Аллаһ бер генә. Шулай булгач, Минем җәзамнан куркыгыз,—диде. **(52)** Күкләрдә, Җирдә ни булса, Аныкы. Итагать итү дә бары тик Аңа гына. Шулай булгач, Аллаһның җәзасыннан курыкмыйча, башка бер заттан куркасызмы? **(53)** Сезгә нинди генә нигъмәт килсә дә, барысы да Аллаһтан. Ахырда үзегезгә зыян килгәч, бары тик Аллаһка ялварасыз. **(54)** Өстегездән бәла алынгач, бер кавемегез Аллаһка тиңдәш эзли башлый.

**55.** Биргән нигъмәтләргә каршы җавап итеп, алар көферлек кыла. Кәефләнүләрегезне шулай дәвам итегез. Ләкин озакламый ни буласын белерсез.

**56.** Алар һичнәрсәдән хәбәре булмаган потларына Без биргән нигъмәтләрдән өлеш чыгара. Валлаһи, кылмышларыгыз өчен сез җавапка тартылачаксыз әле.

**57.** Алар:

—Аллаһның кызлары бар,—дип гайбәт сата. Әстәгъфирулла! Аллаһ мондый эшләрдән азат. Күңелләренә хуш килгәннәрне *(малайларны)* алар үзләренеке итә.

*(«Хузагә һәм Кинанә кабиләләре: фәрештәләр—Аллаһның кызлары, диделәр. Үзләре яңа туган кыз балаларын туфракка терелэй күмәләр. Янәсе, кыз балалар Аллаһка китсен, ир балалар аларның үзләренә калсын».*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**58.** Аларның берәрсенә:

—Хатының кыз бала тапты,—дип, сөенечле хәбәр китерсәң, үпкәләүдән аның йөзе карала. **(59)** Бу хәбәрне алгач, ул кардәшләренең күзенә күренергә оялып, качып йөри:

—Моны *(кыз баланы)* мескен рәвештә янымда асрыйммы, әллә туфракка күмимме?—дип хәсрәткә бата. Гыйбрәт алыгыз: бу нинди яман гадәт.

**(60)** Ахирәткә ышанмаганнар яман гадәтле була. Иң күркәм сыйфатлар Аллаһта *(юлында)* гына. Чөнки Ул һәрнәрсәдән өстен вә хикмәт ияседер.

**61.** Гаделсезлекләре аркасында кешеләрне җәзаларга теләсә, Аллаһ Җир йөзендә бер генә җан иясен дә калдырмыйча һәлак итеп бетергән булыр иде. Ләкин ул аларны *(җәзаларын)* тәкъдирләрендә язылган вакыткача кичектерә. Әҗәлләре бер сәгать тә иртә килмәс, бер сәгатькә дә соңга калмас.

**62.** Күңелләренә хуш килмәгәннәрне алар Аллаһка сылтыйлар. Үзләре кылган вәхшилекне игелек дип, телләре белән ялган сөйлиләр. Һичшиксез, алар өчен бары тик ут хәзерләнгән һәм алар иң беренчеләрдән булып, утка атылачак.

**63.** Валлаһи, синнән элек яшәгән халыкларга да Без пәйгамбәрләр күндергән идек. Ләкин шайтан аларның *(яман)* эшләрен яхшы итеп күрсәтте *(шуның аркасында алар иман китермәде)*. Менә хәзер ул *(шайтан)*—аларның остазы. Алар өчен әрнетүле газап әзерләнгән.

**64.** Гауга чыганагы булган бәхәсле мәсьәләләрне яхшылап аңлатып бирерсең дип, иман китергән халыкка тугры һәм хәерле юл булсын дип, Без сиңа бу Китапны иңдердек.

**65.** Күктән яңгырлар яудырып, Аллаһ җансыз туфракны терелтте. Хактыр ки, монда тыңлый белгәннәр *(мәгънәле сүзгә колак салганнар)* өчен гыйбрәтләр бар.

**66.** Әлбәттә, хайваннарда да сезнең өчен гыйбрәтләр бар. Аларның эчәкләре белән кан арасыннан килә торган саф сөтне сезгә эчерәбез, *(ул сөт)* сезнең тамагыгызга ләззәтле тәм биреп уза.

**67.** Хөрмә, йөзем кебек җимешләрдән сез ләззәтле эчемлек һәм татлы ризыклар ясыйсыз. Менә боларда уйлый белгәннәр өчен бөек бер дәлил һәм гыйбрәтләр бар.

*(«Эчемлек» мәгънәсендәге «сәкәр» кәлимәсе төрле тәфсирләрдә төрлечә тәрҗемә ителә, төрлечә шәрехләнә. Әйтик, Крачковскийда ул: напиток пьянящий, диелгән. Башка тәфсирләрдә дә күбесенчә исерткеч турында сөйләнә. Аятьтәге «сәкәр» кәлимәсенең башка мәгънәләре дә бар. «Шыра-сыра», ягъни йөзем вә яки башка җимешләрдән ясалган татлы су, ширбәт һәм дә «серкә» мәгънәләренә дә ия икәнлеген искәртергә кирәктер».)*

**68.** Раббың бал кортына әйтте:

—Тауларда-кыяларда, агач куышларында вә кешеләр корган каралты-кураларда үзеңә оялар-умарталар яса. **(69)** Аннан соң җимешләрнең һәрберсеннән авыз ит, Аллаһ күрсәткән юллар буйлап оч,—диде. Аларның эченнән кешеләр өчен шифа булырлык төрле төстәге ширбәт *(бал)* чыга. Бу эшләрдә уйлый белгәннәр өчен бөек гыйбрәтләр-дәлилләр бардыр.

**70.** Сезне Аллаһ яралтты. Ахырда сезне вафат иттерәчәк. Белгәннәрен онытып бетереп, балалар акылы кергәнгә кадәр озак яшәтеләчәк кешеләр дә арагызда бар. Һичшиксез, Аллаһ гыйлем вә кодрәт иясе.

**71.** Аллаһ кайсыларыгызга ризыкны бүтәннәрегезгә караганда арттырып бирде. Мул ризык алганнар үз әмерләрендә булганнарга өлеш чыгармадылар, аларны да үзләре белән тигез күрмәделәр. Бәс, шулай кылгач, алар Аллаһның нигъмәтләрен инкарь итә булып чыга түгелме соң?

*(Ягъни, мөшрикләр: ул ризыкларны Аллаһ бирмәде, безнең потларыбыз бирде яки ул малларны без үз көчебез белән таптык, үзебез теләгәнчә тотабыз, диләр.)*

**72.** Аллаһ арагыздан хатыннар яралтты, хатыннарыгыздан угыллар, оныклар яралтты вә сезне саф азыклар белән ризыкландырды. Алар һаман ялган *(ходайлар)*га ышанып, Аллаһның нигъмәте турында көферлек кылачакланмы? **(73)** *(Мөшрикләр)* Аллаһны инкарь итеп, үзләренә Күктән дә, Җирдән дә бернинди ризык та бирергә көчләреннән килмәгән нәмәстәләргә *(сыннарга, ташларга)* табыналар.

**74.** Аллаһка тиңдәшләр китермәгез. Аллаһ барысын да белә, сез генә белмисез.

**75.** Берни эшләргә дә кулыннан килмәгән, башка берәүнең колы булган бичара белән татлы ризыклар биреп, шул ризыкларны күрсәтмичә дә, күрсәтеп тә сарыф иткән Затны чагыштырыгыз. Алар бертигез була аламы? Хактыр ки, бөтен мактау Аллаһка гынадыр. Ләкин аларның күбесе моны аңламый. **(76)** Аллаһның гыйбрәтле мисалы бар. Әйтик, бер телсез кеше, берни эшли алмый вә хуҗасының сыртында артык йөк булып яши бирә, ди. *(Хуҗасы аны)* кая гына җибәрсә дә эш майтара алмый икән бичара. Инде дә шушы бичара белән туры юлда булып, гаделлекләр-игелекләр кылган кеше тигез булырмы?

**77.** Күкләр һәм Җирдәге яшерен серләрне бары тик Аллаһ кына белә. Кыямәтнең кубуы керфек каккан арада, хәтта аннан да кыска вакытта булуы мөмкин. Хактыр ки, Аллаһның кодрәте кин.

**78.** Берни белмәгән, аңламаган хәлдә сезне анагыз карыныннан чыгарды; бәлки шөкер итәрсез дип, сезгә колаклар, күзләр һәм күңел сиземе бирде.

**79.** Аллаһ әмере илә Күктә очкан кошларны алар күрмиме? Аллаһтан башка аларны беркем дә очырта алмый. Иманлылар өчен монда хикмәтләр бар.

**80.** Истирахәт кылыр өчен, хозурланыр өчен Аллаһ сезгә өйләр ясатты. Урын күчкәндә җиңел булсын дип, тукталышларда яшәргә уңай булсын дип, мал тиресеннән кулай өйләр яраттты, йоннан, ябагаларыннан вә кылларыннан билгеләнгән бер вакытка чаклы файдалансыннар дип, кирәк-ярак яраттты.

**81.** Яралтканнар *(агачлар)*ның күләгәләрен сезгә бирде. Сыеныр өчен тауларда мәгарәләр яраттты. Эсседән саклый торган киемнәр, сугышта *(ярсу орышлардан)* саклый торган калканнар яраттты. Шулай итеп, Аллаһ сездән мөселман ясар өчен нигъмәтләрен тәмамлый. **(82)** Алар инкарь итсәләр *(кайгырма, монда синең гөнаһың юк)*, синең вазифаң бары тик *(Аллаһның әмерләрен)* ачыклап бирү генә. **(83)** Нигъмәтләрнең Аллаһ тарафыннан килгәнлеге турында аларга бик яхшы белдерелде. Ләкин ахыр килеп, тагын инкарь иттеләр. Аларның күбесе кяфер.

**84.** *(Кыямәттә)* һәр өммәттән шаһит *(итеп, үз пәйгамбәрләрен)* чакырачакбыз, анда инде кяферләрнең ярлыкау сорап ялваруларына да, ярлыкауга да мөмкинлек булмас.

**85.** Ул гаделсез залимнәр *(җәһәннәм)* җәзаларын күргәч, *(ялварачаклар, ләкин)* җәза җиңеләйтелмәячәк, *(кичектерелмәячәк, гөнаһларын юарга)* мөмкинлек тә аларга бирелмәячәк.

**86.** Аллаһтан башка тәңреләргә табынучылар үзләренең ялган тәңреләрен күргәч, әйтер:
—Раббыбыз, менә шушылар инде Сиңа тиң күреп, табынган нәрсәләребез.
Тегеләре дә кяферләргә карап:
—Сез *(шыр)* ялганчылар,—дип кычкырырлар.

**87.** Ул көнне барысы да Аллаһка баш ияр. Алар уйлап чыгарган «тиңдәшләр» юкка чыгар.

**88.** Кяферләр арасында кешеләрне Аллаһ юлыннан тайдырганнар бар. Без аларның җәзасына *(фани дөньяда куптарган фетнәләре, гыйсъяннары, бозыклык таратканнары өчен)* тагын өстәмә газап та бирәбез. **(89)** Ул Көнне һәр өммәткә каршы үзеннән чыккан шаһитне чакырачакбыз. Сине дә *(ий, Мөхәммәд)* үз кавеменә каршы шаһит итеп күндерәчәкбез. Бар нәрсәне ачыклап бирсен дип, тугры юлны күрсәтүче һәм рәхмәт чыганагы вә мөселманнар өчен бер сөенче буларак, сиңа бу Китапны иңдергән идек.

**90.** Хактыр ки, Аллаһ гадел булырга, игелекле булырга, кардәшләрегезгә ярдәмле булырга боерды. Җирәнгеч эшләрне, хөсетлекне вә бозык гамәлләрне тыйды. Бәлки дә сез, ниһаять, игә килерсез дип, ул сезне кисәтә. **(91)** Килешү төзегәнсез икән *(сүз биргәнсез икән—сүзегездә торыгыз, вәгъдә иткәнсез икән—вәгъдәгезне үтәгез, ант эчкәнсез икән—антыгызны бозмагыз)*, Аллаһ исеме белән биргән антыгызга, нәзерегезгә бигрәк тә тугры калыгыз, сез Аллаһны үзегез өчен шаһит иттегез. Шик юк ки, Аллаһ сезнең ни кылачагыгызны белеп тора. **(92)** Күзәнәкләрен тыгыз итеп бәйләгән бәйләвен сүтеп ташлаган хатын хәлендә калмагыз. Бер халык икенчесеннән *(сан ягыннан да, байлыгы белән дә)* өстен булырга мөмкин. Ләкин ул өстен халык өстен булмаганын кыерсытмасын. Үз мәнфәгатегезне генә күз уңында тотып, биргән антыгызны хәйлә-мәкер белән бозып, әнә шул хатын шикелле була күрмәгез. Аллаһ сезне шулай сынап бага. Һичшиксез, Аллаһ сезнең парә-парә таугалашканыгызның сәбәбен Кыямәттә ачык күрсәтер. **(93.)** Әгәр дә Аллаһ ихтыяр итсә,

барыгызны да бер өммәт *(бер халык)* иткән булыр иде. Ләкин Ул *(адашырга)* теләгәнне адаштырыр, *(игелек кылырга)* теләгәнне тугры юлга чыгарыр. Кылганнарыгызга күрә, сез җавап тотачаксыз *(җәзасын алачаксыз)*.

**94.** Аякта нык басып торганда таеп егылмас өчен *(Ислам юлы белән барганда көферлеккә күчмәс өчен)*, хәйлә белән килешүләр төземәгез *(мәкер илә ант итмәгез)*. Тугры юлдан тайсагыз, сезнең өскә афәт килер. Сезнең өчен хәтәр газап әзерләнгән. **(95)** Аллаһ исеме белән биргән антыгызны арзанга сатмагыз *(вак-төяк өчен дә Аллаһ исеме белән ант итмәгез)*. Хактыр ки, Аллаһ хозурындагылар сезнең өчен тагын да хәерлерәк икәнен белсәгез икән.

**96.** Сез җыйган *(дөнья малы)* бетәчәк, Аллаһ катындагылар исә мәңгелек. Һичшиксез, сабыр-чыдам булганнарга, иң гүзәл гамәлләренә күрә, яхшы әҗер бирербез. **(97)** Ир кешеме ул, хатынмы, мөселман булып, игелекле эшләр башкарса, аларны, һичшиксез, матур тормышта яшәтәчәкбез. Һәм әҗерләрен дә кылган иң игелекле эшләре буенча бирербез. **(98)** Коръән укыганда шайтаннан Аллаһка сыен *(әгүзү билләһи минәшшайтан ирраҗим, дип әйт)*. **(99)** Иманга килеп, бары тик Раббыга гына тәвәккәл иткәннәр өчен аның *(шайтанның)* һичбер хакимлеге булмас—бу Хакыйкать. **(100)** Ул *(шайтан)* бары тик үзе белән дуслашканнар һәм Аллаһка тиңдәш тапканнар белән генә идарә итә ала.

**101.** Без бер аятьне икенчесе белән алыштырганда:

—Син ялганчы—бу аятьләрне үзең генә уйлап чыгарасың,—диделәр. Гәрчә, Аллаһ үзенең ни кылганын бик яхшы белә. Хәер, аларның күбесе бу турыда белми.

**102.** Әйт:

—Иман китергәннәрнең иманын ныгытыр өчен, Хакыйкать буларак, кулланма һәм сөенечле хәбәр сыйфатында Изге Рух *(Җәбраил)* аша Раббы иңдергән аятьләр ул,—диген. **(103)** Чыннан да, Без аларның:

—Боларны аңа бары тик ниндидер бер кеше өйрәтеп тора,—дигәннәрен ишетәбез. Алар күз алдында тоткан кешенең теле—чит тел. Коръәннең теле ачык мәгънәле гарәп теле бит.

*(Дөньякүләм мәшһүр галимнәр бу аятьтәге «Алар күз алдында тоткан кешенең теле—чит тел» җөмләсен кешеләргә болай ирештерә башлауга ук кяферләр: христианлыктан яңа гына Исламга күчкән, Җаббар, Ясир, Каиса, Гаддәс кебек белемле кешеләр әйтеп торып Мөхәммәдкә аятьләр яздырган, дигән имеш-мимеш тарата.)*

**104.** Аллаһның аятьләренә ышанмаганнар юкмы? Әлбәттә, Аллаһ аларны тугры юлга өндәмәс. Андыйлар өчен әрнетүле җәза хәзерләнгән. **(105)** Бары тик ялганлаучылар гына Аллаһның аятьләренә ышанмый. Менә шулар инде чын алдакчылар. **(106)** Чын күңелдән Аллаһка инанган булып та, көферлеккә *(сүз белән Исламнан баш тартырга)* мәҗбүр ителгәннәрдән башка, иман китергәннән соң да Аллаһны инкарь иткән һәм көферлеккә чумган кешеләргә Аллаһ тарафыннан җәза булыр. Алар өчен хәтәр газап хәзерләнгән.

*(«Гаммәр белән атасы Ясир вә анасы Сөмәйяне Кораеш кяферләре диннән яздырырга тырышты. Нәтиҗәсе булмагач, кяферләр Сөмәйянең ике аягын ике дөягә тагып, урталай аердылар. Ясирне дә үтерделәр. Болар Ислам юлында иң беренче шәһид киткәннәр. Җәзалауларга чыдый алмыйча, Гаммәр теле белән дененнән ваз кичте, Аллаһны инкарь итте. Рәсүлулла әйтте: Гаммәр башыннан аягына кадәр иман белән тулы кеше. Иман аның тәненә, канына сеңгән, диде. Әгәр дә алар сине тагын денеңнән чык, дип җәзалый башласа, алар теләгәнчә әйт: юри генә Аллаһтан ваз кич, диде».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.)

**107.** Бу *(җәзаның)* сәбәбе шулдыр ки, алар дөнья тормышын Ахирәтнекеннән артык сөйделәр. Аллаһ кяферләр өерен һидаяткә ирештермәс. **(108)** Аллаһ аларның күңелен, колакларын вә күзләрен томалап куйды. Шуңа күрә, алар надан һәм гамьсез. **(109)** Шик юк ки, алар Ахирәттә дә зарар күрәчәк.

**110.** Рәнҗетүләрдән соң һиҗрәт иткән, аннан соң сабыр итеп, Җиһадта катнашканнарга Раббың, һичшиксез, ярдәм итәр. Болардан соң Раббың, әлбәттә, ярлыкар, гафу итәр. **(111)** Ул Көнне һәркем килеп, үз җанын коткарырга маташыр вә һәркемгә кылган гамәлләренә күрә, киметмичә әҗере бирелер. Аларга *(гөнаһларыннан)* артык гаделсезлек булмас.

**112.** Гыйбрәт өчен Аллаһ бер шәһәрнең язмышын мисалга китерә: бу шәһәр куркусыз хозурлыкта яши иде, аларга һәрьяклап азык-төлек мул килә. Тора-бара алар Аллаһ биргән нигъмәтләргә кеферлек кыла башлады. Аллаһ та аларга, кылмышларына күрә, ачлык вә курку киемнәрен кидерде. **(113)** Хактыр ки, аларга үзләре арасыннан пәйгамбәр килде, ләкин алар аны ялганчыга чыгарды. Гаделсезлек кылганга аларны җәза тотты.

**114.** Аллаһ биргән хәләл һәм саф ризыкларны ашагыз. Аллаһның юмартлыгына шөкер итегез. Әгәр сез, чыннан да, Аңа гына гыйбадәт кыласыз икән. **(115)** Ул сезгә бары тик үлгән хайванны, кан, дуңгыз итен һәм Аллаһтан башка исем белән бугазланган хайванны *(ашарга)* харам кылды. Мәҗбүр булган кеше *(башка ризык булмаганда)*, артыгын кыланмыйча *(ачтан үлмәс микъдарда)* ашый ала. Хакыйкатән, Аллаһ ярлыкаучы вә миһербанлы.

**116.** Уйлап чыгарылган ялганга таянып, телегез белән:
—Бу—хәләл, бусы—харам,—дисәгез, Аллаһка каршы нахак сөйләгән булырсыз. Аллаһка карата ялган уйдырмалар сөйләүчеләр бәхеткә ирешә алмас. **(117)** Алар өчен *(җыйган байлыклары фани дөньяда)* бик аз файда бирер, аның каравы Ахирәттә аларга хәтәр җәза әзерләнгән.

**118.** Яһүдләргә нәрсәләр харам икәнлеге турында Без сина алда аңлаткан идек инде. Без аларны җәберләмәдек, алар үзләренә үзләре золым китерде. **(119)** Наданлыклары аркасында яманлыклар кылып та, соңыннан тәүбәгә килеп, тормышларын *(Коръәнчә)* рәткә салганнар ярлыканыр. Тәүбә итүчеләрне Аллаһ, һичшиксез, ярлыкар һәм Ул аларга мәрхәмәтле булыр.

**120.** Ибраһим ихластан Хакка инанган, Аллаһка итагать иткән бер имам иде. Аллаһка тиңнәрне ул эзләмәде. Ул мөшрик түгел иде. **(121)** Ул Аллаһ нигъмәтләренә шөкер итүче иде. Аллаһ аны сайлады, тугры юлга күндерде. **(122)** Аңа дөньяда муллык-игелек бирдек. Ахирәттә дә ул изгеләр сафында булыр. **(123)** Сиңа да:
—Тугры юлга басканда Ибраһим тоткан динне ал. Ул мөшрик түгел иде,—дигән идек. **(124)** Шимбә көнне ял итү бары тик шул турыда гауга чыгарганнарга гына бирелде. Кыямәт көнендә Раббың алар гауга күтәргән мәсьәләне чынлыклап ачыклар.

**125.** *(Ий, Мөхәммәд)* син Раббың юлына хикмәтләр һәм матур үгетләр белән чакыр, алар белән бик тә гүзәл рәвештә бәхәсләш. Аллаһ тугры юлдан язганнарны бик яхшы белеп тора, Ул тугры юлга басканнарны да бик яхшы белә.

**126.** Җәза бирсәгез, үзегезгә бирелгән җәза микъдарында гына җәзалагыз. Ләкин *(җәзаламыйча)* сабыр итсәгез, һичшиксез сезнең файдага булыр.

*(«Ухуд сугышында яһүдләр хәзрәти Хәмзәне каты яралыйлар. Борыны, колаклары киселеп, үпкәсе актарылган халдә аны Рәсүлулла (саллаллаһү галәйһи вә сәлләм) күреп: «Валлаһи, әгәр дә мин Аллаһ ярдәме белән җиңү яуласам, агам өчен алып, аларның җитмеш кешесен шулай кылачакмын»,—диде. Шуннан соң бу аять иңдерелде. Рәсүлулла антын бозды, үч кайтармады»*

Садретдин Гүмүш тәфсиреннән.)

**127.** Сабыр бул. Синең сабырлыгың да Аллаһ ярдәмендә. Алар өчен хафаланма. Алар корган мәкерләр сине кайгыга салмасын. **(128)** Шөбһәсез, Аллаһ *(гөнаһ кылудан)* курыкканнар һәм игелек кылганнар янында.



# МОҢ ҺӘМ ТӘҮГЕ МӘХӘББӘТ

### ДӨНЬЯНЫҢ МӘШҺҮР КОМПОЗИТОРЫ СОФИЯ ГОБӘЙДУЛЛИНАГА 70 ЯШЬ

## Балачак мизгелләре

1935 нең җәе иде.

Әлеге җәйнең бер иртәсендә Казан шәһәренең Тельман урамын гармун моңы уятты. Моң тәрәзәләргә чиертеп, кучкардагы лампаның җиделе куыгын да чыңлатып, алар йорты яныннан уза башлады. «Тукта», диде күзләре яшьләнгән сабый, «китмә», дип ялварды, әмма моң, ерагая-ерагая, урамның аргы башыннан ук ишетелә башлады.

Бу аһәңне югалтудан куркып, бала кымшанмады да; әтисе ясаган тимер кыршаулы, нарат исле сәкегә ул әйтерсең лә береккән иде.

Моңның соңгы аһәңе дә тынгач кына сабый айнып китте. Соңгысымы?!..

Бала ябынган җәймәсе белән бергә идәнгә шуды. Тәрәзә янына йөгерәсе килде аякларына киндер җәймә уралды. Шушы мизгелдә ул әнисен күрде. Ачык тәрәзә аша күзәтә иде әнисе. «Мин дә, әнием, мин дә күримче?!» диясе баланың, әмма теле көрмәкләнде.

Ниһаять, ана да кызчыгын шәйләде. Урындыкка үрмәләүче төпчеген тәрәзә төбенә утыртты да: «Әлләкем түгел, кызым, теге дурак Шурка гына икән; каяндыр гармун тапкан, әнә; ә син йокла әле, йокла, бик иртә бит»,— дип сөйләнә-сөйләнә баланың чәчен сыйпады. Һәм шунда ук, сабыеның төсе киткән йөзенә карап, өстәргә ашыкты: «Бөтен кеше дә Шурка дурак дигәнгә күрә әйтүем инде. Ул малайның каян килеп чыкканын да, чын исемен дә беркем белми бит, ә үзе, әнә, нинди моңлы бала икән»,—дип аклангандай итенде.

Юк, кызчыкның күңеленә дурак дигән сүзгә рәнҗү түгел, МОҢ кереп тулган иде. Хәер, ул әле үз халәтен, бу сүзләрнең мәгънәсен дә белми, аңламый иде. «Моңлы бала», «гармун» сүзләре кебек үк бу мәлдә аңа «дурак» дигәне дә тылсымлы, кадерле, изге иде.

Әнә шул тылсымны, моң тудыручы тылсымны югалтудан коты очкан сабый урамга чыгып йөгерде.

Йомшак туфракта ялан тәпи эзләрен калдыра-калдыра кызчык дурак Шурканы эзләде. Урамның әле бер башына йөгерде, әле икенче очына тәгәрәде—юк, күренмәде Шурка, күренмәде.

Аны эзли-эзли бала Казансу янына да төште: теге әкияттәге Алтын балыкны күрәсе, моң тудыручы малайның кайдалыгын сорыйсы килде...

Тик... тик анда, су читендә вак балыклар гына йөзә, сикерешә иде...

Балыклар кызчыкны юатырга теләгәндәй, аның кулларына кагылып-кагылып та, ә нәнирәкләре хәтта бармаклары арасыннан да йөзеп үтә башладылар. Әмма алар арасында Алтын балык юк иде шул, юк иде.

* * *

Шурка урамда бер атнадан гына пәйда булды. Көпә-көндез иде бу. Малай нәкъ кызчык яшәгән йорт янында туктады да гармунын сызып җибәрде. Гармунына җыр белән дә кушылды:

Тау башында бер өй бар,
Тагын, тагынниләр бар?..

Менә шул мәлдә Гобәйдуллиннар йортыннан йомгак кебек тәгәрәп кенә төпчекләре чыкты. Чыкты да Шурканың «тагын, тагын ниләр бар» диюенә канатларын җилпегән «казга әйләнде» һәм каңгылдый-каңгылдый бии башлады.

Тамаша карарга урам балалары агылды, аларга үсмерләр, хәтта зурлар да иярде. Алар Шурканы да, гармун дигән могҗизаны да онытып, «йомгак»ка текәлделәр. Ә «йомгак» инде «үрдәккә әверелгән»: бакылдый-бакылдый алпан-тилпән баскалап бөтерелә иде.

Гармун соравын кабатлый торды:

Тагын, тагын ниләр бар?..

Сабый хәрәкәтләрендә алмалары зурлыгыннан ботаклары сыгылган «алма агачын» да күреп, урам «аһ» итте. Кешеләрне бала хыялының чиксезлеге, музыкаль фантазиясе хәйран калдырган иде...

... Менә шул көнне кызчык өчен тылсым-могҗизалы яңа дөнья туды. Һәм бу дөньяда беркемгә дә, хәтта куркыныч әкиятләре белән бөтен урамны җәлеп иткән Акбабайга да урын юк иде.

Дөрес, Акбабай әкиятләрен тыңларга йөрүдән туктамады әле ул. Көндезләрен энәгә тагылган җеп күк Шуркага тагылды, ә кичләрен, малай каядыр китеп юкка чыккач, Вера һәм Ида апаларына ияреп, бөтен балалар җыелган капка янына, Акбабайның әкиятен тыңларга чыкты.

Әрдәнә өстенә «кунаклаган» кызчыкка инде картның әкиятләре дә әлләни куркыныч түгел иде. Пәриләре белән шәһәр өстендә бөтерелүче диюдән дә курыкмас бит инде! Дию беркайчан да... беркайчан да алар урамына төшә алмаячак. Чөнки... чөнки Шурка гармунының тылсымы төшерми аны!..

Бала шул рәвешле ләззәт кичерде һәм һәр кичне үз дөньясына, гармунлы, моңлы дөньяга «бикләнә» башлады.

* * *

Беркөнне Шурка гармунсыз килде. Килде дә балаларны урманга, җиләк ашарга чакырды.

Ура!.. Урамны шатлык тутырды.

Малай балаларны рәткә тезә башлады: бер, ике, өч, дүрт... Чират кызчыкка җиткәч, Шурка аны читкә этәрде дә, ә син, Соня, бармыйсың, дип әмерен белдерде.

«Бармыйсың!» Ялгыш ишетмәдеме?.. Әгәр алып бармаса, алып бармаса... үләчәк бит ул. Менә күрерсез—үләчәк!..

Баланың халәтен аңлады булса кирәк, малай йомшара төште:

—Йә, йә, бәләкәч, барырсың, барырсың... Тик миннән бер адымга да калмаска!..

Юл бик озын тоелды. Казан да артта калды, әрәмәлекне дә үттеләр, чытырманлыкка да юлыктылар, урманга кергәнгә дә биш былтыр булды...

Кызчык артка калгалый башлады. Ә җиләкле аланга җиткәндә ул тәмам арыган, тәпиләренең инде бер хәле дә калмаган иде. Ярый әле моны Шурка сизмәде. Сизсәме... Шул мәлдә сабый кыяк үләненә абынып, маңгае белән кып-кызыл җиләк тәлгәшенә капланды... Берара ул тын алырга да куркып ятты. Аннары... аннары бер тәлгәштән икенчесенә... өченчесенә шуыша-шуыша иреннәре белән генә җиләк өзде; ашый-ашый хәл җыйды.

Инде аның иң матур тәлгәшләрне өзәсе, иң тәмле җиләкләрне моң тудыручы малайга да ашатасы килде... Һәм кызчык ашыга-ашыга иң-иң пешкәннәрен җыя башлады.

Шурканы ул аланның аргы башында, әрем сабаклары арасында күрде... Кызчык килгәндә малай бик-бик тәмләп сары-шәмәхә чәчәкле үлән ашый иде. Сабый аңа кучтәнәчен сузды да, шәмәхә чәчәкле үләнгә үрелде...

* * *

Сабый җиде көн буена һушына килмәде. Шурканың сары-шәмәхә чәчәкле тилебәрән үләне ашап агуланган көнне үк үлүен дә, әле сигезе дә тулмаган бу «бәләкәй композитор»ны бөтен урам белән җирләүләрен дә белмәде.

... Өметнең соңгы чиге булып инде җиденче төн дә үтеп бара иде. Чегән карчыгы кергәндә балада җан әсәре сизелми иде.

Кортка лампаны күтәреп сабыйның йөзенә бакты. Һәм шундук аңлашылмаган телдә сөйләнә-сөйләнә бала башына нindидер яфраклар яба башлады... Агач тамырларын хәтерләткән бармаклары инде шул яфраклар өстендә «бии», иреннәре дә бертуктаусыз аңлашылмый торган көй көйли иде. Көй уңаена чулпы тәңкәләре дә чыңлап-чыңлап алды.

Нәкъ шул мәлдә ата белән ана могҗиза күрде: әйе, әйе, кызчыкларының кул бармаклары дерелдәп куйды...

Ана чегән карчыгының аякларына егылды.

Карчык инде ишек төбендә иде. «Җаны әлегәчә адашып йөргән; гадәти бала түгел бу, терелгәч үзен денле итәрсез, аның гомере генә түгел, язмышы да Ходай кулында—шуны онытмагыз»,—дип сөйләнә-сөйләнә төн караңгылыгында «эреде»...

Балага чыннан да җан кергән иде. Ләкин ... ләкин аңы... елый-елый, көлә-көлә саташып авыруын белүдән, үзен күкрәгенә кысып, һәркөн саен мәчет белән чиркәү арасында таптанган әнисенең халәтен аңлаудан әле бик-бик ерак иде.

* * *

Быел яз иртәләде, дип сөенде әнисе.

Җылы итеп кояш елмая, өй кыегыннан да тамчылар тама башлаган иде. Әмма кызчыкның бу тамчыларга да, тәрәзә рамнарына кунып сызгырышучы песнәкләргә дә әллә ни исе китмәде. Аның гел ашыйсы килде. Ашыйсы килеп йокыга китте, ашыйсы килеп уянды.

Төшләрендә дә ул гел ризык күрде. Әле дә ул кайнар ипекәй төялгән чана артыннан йөгерә иде... Ул йөгерә, аны күреп алган усал абый да чыбыркылый-чыбыркылый бахбаен куалый. Тәпиләре генә арымасын берүк, барыбер куып җитәчәк бит ул атлы чананы. Менә күрерсез, җитәчәк!.. Аннары әнә шул чанага утырып туйганчы ашаячак та. Ашап та тормас әле, ипекәйнең иң-иң зурысын, тәмле исләре аңкып торганын сайлар да өйләренә йөгерер. Әти-әнисен дә, Вера, Ида апаларын да сыйлар менә...

Кызчык нәкъ шушы урында, тәмле ипи исе борынны кытыклый башлагач кына уянып китте.

Бүлмәдә чынлап та ризык исе бөтерелә икән. Өстәлдә буларын бөркеп бәрәңге көтә. Вера, Ида апалары да өстәл янында. Кызчык утыру белән бәрәңгегә үрелде.

—Ашыкма,—диде әнисе.—Башта апаларың үрелсен—өчегезгә өч бәрәңге менә! Иртәгә тагын өчне пешерсәгез, берсекенгә дә әле өчәү кала. Аннары инде, Ходай кушса, мин дә кайтып җитәрмен. Әтиегез генә Чаллысында булсын!.. Он да, бәрәңге дә әзерләдем дигән. Килеп алырга кушкан, әнә...

Һәм әниләре бәрәңге тәлинкәсе янындагы хатка ымлады...

... Өченче көнне да кайтмады әниләре, дүртенче көнне дә күренмәде. Кызчыкның үлепләр ашыйсы килде. Җитмәсә өйләре дә суык... Юрган астыннан чыкмыйча гына йоклар-йоклар да менә, әниләре кайтып майлы коймак пешергәч кенә уяныр әле!..

Бала хәтта таба чыжлаганын да ишеткәндәй булды. Һәм рәхәт елмаеп йокыга талды.

... Юк, таба да чыжламый, әнисе дә түгел иде бу. Әйе, уртанчы апасы Ида тавышы! Чү, Вера апаларын ачулана түгелме?..

«Эчмим,—ди Вера апалары да,—бу болганчык суны үзең эч, ә минем эчәсем килми, ашыйсым килә...»

«Менә шуңа күрә дә инде эчәргә кирәк, ашыйсы килүне бетерә ул, беләсең килсә. Теге, безнең ике мендәргә бер чиләк бәрәңге биргән чуаш карты әнигә: «Көмешкә китер; көмешкәң әйбәт булса, бер капчык бәрәңге бирермен»,—диде, белдеңме!? Менә шушы суга—бер капчык бәрәңге бирмәкче, аңладыңмы инде?! Бәрәңгедән дә әйбәтрәк су бу, беләсең килсә. Моңа әле әни ипи белән бәрәңге дә кушкандыр... Эч, эч, курыкма! Теләсәң, стаканның яртысын үзем эчәм...»

Һәм Ида апасы эчә дә башлады. Башлады да, тончыга-тончыга, ютәллиютәлли болганчык суның соңгы тамчысына хәтле эчте...

Үзләре буе шешәдән апаларының теге суны зур чүмечкә агызуын да күзәтеп ятты әле ул. Үзенә сузылган стаканны да күрде сабый... Аннары гына... бүлмә белән бергә әйләнә-әйләнә күккә очты...

... Кызчык әнисенең тавышсыз гына үксүенә уянды. Әнисе апаларының әле берсен кочаклап елый, әле икенчесен... Әкрен генә сөйләнеп тә ала: «Утын пүләннәренә әйләнгәнсездер дип котларым очты, җиде көн бит, җиде көн... Ходайга шөкер, исәннәр икәнсез... Көттем шул, әтиегезнең Пермьнән кайтканын көттем. Чаллысы белән Пермь арасы да якын гына ара түгел шул. Аннары боз кузгалды—юлым бүленде... Ярый әле көмешкә булган... Кайсыгызның башына килгәндер, рәхмәтләр яугыры...»

* * *

Баланың бөтен урамга кычкырасы, ишеттегезме... ишеттегезме, миңа рояль сатып алдылар, диясе килде. Әмма кычкырмады. Биш яше тулган «олы кыз» башы белән кычкырып йөрмәс бит инде! Аңа бу яңалыкны инде болай да бөтен кеше беләдер, бөтен кеше шаккатадыр кебек тоелды.

Бала ялгышмады. Яңалык урам өчен дә олы бер вакыйгага әйләнгән иде.

... Көнозын ишек ябылмады. Башта балалар кереп рояльне сыйпап та, «телләре»нә басып-басып та карадылар. Кичке якта олыларның әле берсе, әле икенчесе могҗиза күрергә сугылды.

Кызчык үзе әледән-әле тәрәзә янына йөгерде. Кич кенә була күрмәсен, берүк! Әле бит ул рояль «телләре»нең кайсысы моңлырак икәнен дә белергә өлгермәде. «О-о, Кояш, ашыкма син, ашыкма!?» дип алсулана башлаган офыкка карап та ялварды.

Әмма кояш та баеды, урам да тынып калды. Ида апасы да үзен йокы бүлмәсенә әйдәде. Юк, чыкмаячак ул бу бүлмәдән, чыкмаячак!.. Бала әнисенең итәгенә ябышты һәм: «Мин дә шушында гына, сезнең янда йоклыймчы?!»—дип ялынды.

—Син хәзер дәү инде, Соня. Ә үскән кызлар әти-әни янында йокламый. Рояленң янына иртән керерсең,—диде әнисе.

Барыгыз да йокыга киткәч... йокыга киткәч тә... дип тынычланды кызчык. Һәм Вера, Ида апаларын аптырашта калдырып, «гырлый» да башлады.

Сәкедән идәнгә шуышуын апалары сизмәде дә. Рояльле бүлмәгә дә икеөч кенә атлыйсы иде. Аннары... Әле ярый ишек келәсен төшермәгәннәр. Бусаганы да ул тын да алмыйча үтте. Һәм шунда ук чүкте дә. Биредә әле йокламыйлар иде.

—Син аның күзләрен күрдеңме?—диде әнисе.—Шурка гармунына шулай яна иде. Менә рояльгә дә... Тагын авырмагае дип бик куркам...

Чү! Аның турында сөйләшәләр бит, аның турында... Кызчык рояль ягына борылырга да өлгермичә идәнгә сеңде.

—Борчылма, авырмас,—диде әтисе,—ә теге чакта тилебәрән үләне ашап кына авырды ул.

—Чегән карчыгының «Гадәти бала түгел бу, терелгәч үзен денле итегез» дип искәртүе гел исемнән чыкмый.

—Гел шул турыда гына уйлаганга ул, Феня. «Безнең әни әллә нишләде»

дип хәтта Ида да борчыла башлаган. Соняны җитәкләп, мәчет белән чиркәү тирәсен син көненә ике-өч урыйсың икән...

—Нәзерем тотмагае дип куркам. Ярый ла син командировкаларыңнан кайтып кермисең. Әле Чистайда, әле Чаллыда, әле Пермьдә буласың... Идел, Кама ярларында син тикшермәгән катлам калмагандыр да инде... Миңа менә нишләргә соң? Ничек нәзеремне үтәргә? Төпчегебезне ни рәвешле динле итәргә?.. Мәчеткә дә керә алмыйм, чиркәүгә керергә дә куркам. Дин әһелен өйгә чакыру турында уйласы да юк. Алла сакласын—берәрсе күреп калса... Мулла улы булуыңны яңа баштан күтәрәчәкләрен көт тә тор!..

—Күтәрмәсләр, борчылма. Күтәрсәләр дә тимәсләр. Һөнәрем, үз вазифамны намуслы башкаруым ярдәм итәр һәрхәлдә. Инженер-геодезистлар ил күләмендә дә бармак белән генә санарлык... Шулай да син, Феня, гыйбадәтханәләр тирәсендә әйләнүеңне туктатып тор. Күбрәк балалар белән шөгыльлән. Мәктәпкә әзерлә үзләрен. Безнең бит алар—өчәү. Менә иртәгә үк өчесен дә музыка укытучысына күрсәт. Урам аркылы гына торучы Екатерина Павловна Леонтьева риза булмасмы?! Сәләтле дип тапса үзләрен, бәлки әле өйрәтә дә торыр, укытырга да алыныр. Бик көчле укытучы диләр үзен. Ә чегән карчыгының «денле итәрсез» диюен мин, мәсәлән, белемле, һөнәрле, шөгыльле итегез, дип аңладым. Рояльне дә шуның өчен алдык түгелмени?!..

... Бала, рояль, музыка, мәктәп сүзләреннән бүтәнне аңламаса да, өшеп китте. Бу төнге сөйләшү... пышылдап сөйләшү... әллә нинди шомлы, серле иде...

... О-о, бу көн дә туды!..

Әнисе Аллаһ йорты, Храм дип сөйләнгәндә ул гел музыка мәктәбен күзаллый иде. Һәм менә... хыялларда җәннәт сарае булып сурәтләнгән 1 нче музыка мәктәбе—тылсымлы, изге йорт—хәзер аның үз өе, үз дөньясы. Ачлы-туклы, шомлы дөнья—теге якта, бу тылсымлы йорт бусагасының теге ягында. Ә биредә... бирердә Моң! Бирердә—аһәңнәр дөньясы! Бирердә укытучылар—серле, илаһи затлар—Рубим Львович Поляков, Екатерина Павловна Леонтьевалар. Һәм бу дөньяда аның да, әйе, әйе, Әсгать кызы Соня-Софиянең дә үз урыны булачак. Менә күрерсез, бик-бик тырышуы, гел яхшыга гына укуы белән яулаячак ул аны, яулаячак! Чөнки... чөнки ул бары шушы—диварларыннан да моң саркыган, коридорларында моң тирбәлгән дөньяда гына яши ала. Аның өчен башка дөнья—юк! Юк! Юк!

* * *

... Көннәрдән бер көнне ул Аны күрде. Яңа уку елы башланган гына чак иде. Класска бөдрә чәчле бер пәһлеван килеп керде дә, мин—Нәҗип Гаязович Җиһанов булам, һәм сезгә композиция буенча дәресләр бирәчәкмен—телисезме, диде.



О-о, теләмиләрме соң?!..

Пәһлеван класс белән таныша башлады. Чират Софияга җитте. Урыныннан купкан кыз, үзе дә сизмәстән, исемен «Сания» дип атады. Класс, могҗиза күргәндәй, гүләп алды. Чөнки... чөнки аны Соня-София дип кенә беләләр иде.

—Туктале-туктале,—диде шул мәлдә илаһи Пәһлеван,—сез бөтен укытучыларны хәйран калдыручы Гобәйдуллина түгелме?

Кызның тыны кысылды, теле көрмәкләнде. Аның өчен класс җавап бирде. Әгәр дә менә хәзер Пәһлеван утырырга рөхсәт итмәсә, ул егылачак, һичшиксез егылачак һәм... һәм оятка калачак иде. Кызның күзләрен яшь пәрдәсе каплый башлады. Берни дә сизмәгән Пәһлеван җылы елмаеп, «менә нинди шәкертләрем булачак икән бит әле» дия-дия, утырырга ымлап баш какты...

Тәнәфестә кызлар гел Аның турында гына сөйләнделәр:

Ул—бик тә талантлы композитор—симфонияләр, опералар язучы Маэстро икән...

Ул—Татарстанның композиторлар Союзын тәзергә йөри икән...

Ул—консерватория, опера театры салдырачак икән...

Ул... ул әллә нинди могҗизалар эшләргә сәләтле педагог икән...

... Әнә шул көндә... дәресрәге, Аны күргән мизгелдән үсмер кызга әллә ни булды: тәненең бөтен күзәнәкләрен җылытып, күзләренә яшь пәрдәсе дә элеп, аның музыка дөньясына олы мәгънә, яңа тойгы, өр-яңа хис өстәлде. Һәм бу хис мәһабәт гәүдәле баһадир образында гәүдәләнә иде.

София Җиһанов дәресләрен түземсезлек белән көтеп ала башлады. Аны күргән көнне—канатлар үсте, ә күрмәгәндә—йокысыз төн үткәрде...

... Бүген дә кыз Аны күрергә өметләнде. Белә, бүген Аның дәресләре юклыгын да белә, күрү ихтималы бик аз икәнен дә белә. Елның бу соңгы көнендә әллә никадәр эш-гамәле булуын да чамалый. Шулай да... шулай да ул Аны күрергә тиеш!

Әгәр күрмәсә... О-о, бу мөмкин түгел! Чөнки... чөнки бүген—үзгә көн. Яңа елны каршылаучы көн...

* * *

Эзләргә чыккан әтисе аны ерактан ук күреп алды. Һәм шундук йөрәге чәнчеп куйды: нидер булган кызына!.. Каршыдагы йортның караңгы бер тәрәзәсенә баккан Сонясының күбәләкләр булып яуган карда да гаме юк, йөгерә-атлый үтүче кешеләрне дә күрми шикелле. Баскан урынында кадакланган диярсең.

Нишли ул биредә? Ни калган аңа бу вакытта?.. Берәр иптәш кызын көтә дисәң... ник утсыз-нисез тәрәзәгә баккан? Кемне күзли ул аннан?.. Әллә... әллә берәр малайга күзе төшкәнме?.. Үсмер кызның җанынданиләр барын—кем белсен!?..

Әти кеше сорауларын фаразлаган бу мәлдә кызга кинәт кенә «җан керде»: ул, бер кулын алгарак сузып, очынып-кагынып алгандай итенде. Кар таҗларын «тотуы»мы бу, әллә инде ут алынган тәрәзәгә сәлам юллау билгесе идеме—менә монысын ачык кына күреп тә, тоемлап та булмый.

Ни уйларга да белмәгән арада, теге тәрәзәдә бер шәүлә шәйләнде. Шәүлә тәрәзә өлгесенә якын ук килде.

Йа Ходай!... Рәссам әсәрләренә биргесез бу мәһабәт силуэт, әйе, әйе, Нәҗип Гаязович Җиһановка охшаш иде.

... Кызы серенә шаһит булудан уңайсызланган ата артына чигенде. Хәзер ашыгырга, өйгә кызыннан алдарак кайтып җитәргә тиеш иде ул.

* * *

София өйгә дә очып кайтып керде. Пальто төймәләре ычкынган, шарфы иңнәренә шуган, ә бәхетле күзләрендә йолдызчыклар биешә.

Кыз сумкасын идән буйлап шудырды да, Яңа ел табынына күз дә төшермичә, рояль янына ашыкты. Аның тизрәк өйдәгеләргә дә, үзләренә җыелган күршеләренә дә үз бәхете турында сөйлисе килде.

Бүлмәгә Моң тулды. Тәүге бөреләре ачыла башлаган Мәхәббәт агачының Илаһи кыйссасын бәян итүче Моң!..

Очына-очына, ашкына-ашкына уйнаучы кыз бу мәлдә рояле белән бер җанга, бер образга әверелгән, гүя, рояль сандугач булып та сайрый, тургай булып та җырлый, чишмә булып та челтери, назлы җил булып та сызгыра, серле урман булып та шаулый. Йомшак, җылы моңнары белән назлый, иркәли һәм әллә һинди аңлашылмаган аһәңнәре белән—нидәндер кисәткәндәй, кемгәдер рәнҗегәндәй, сызланып-сагышланып та алгалый...

Бүлмәдә кыз бала халәтен сөйләүче гаҗәеп аһәңнәр тирбәлә.

Әмма моң тыңлаучылардан бу мәлдә берәү дә унике яшьтәге үсмер кызның «Тургай», «Тегермән», «Әпипә» исемнәре белән үзе иҗат иткән тәүге әсәрләрен уйнавын белми әле.

Бу мизгелләрдә София үзе дә... нәкъ менә шушы кичтә дан-шөһрәтле

киләчәген вәгъдә итүче композитор туа башлавын да, татарның моң-аһәңнәре дә салыначак илаһи Музыкасы белән бөтен дөньяга таныласын да һәм... һәм үз исеме белән бар җиһанга Татар дигән изге исемне танытасын да белми иде әле. Белми иде...

* * *

**София Әсгать кызы Гобәйдуллина—дөньяны музыкасы белән таң калдырган композитор.**

**София ханым алтмышынчы еллар ахырыннан «Мемфис төне», «Рубайят», «Җан авазы» («Час души»), «Яктылык һәм караңгылык» («Светлое и темное»), «Татар фольклорына нигезләп» дип исемләнгән 15 пьеса, «Юбиляция», «In croce», «Урман аһәңе» («Звуки леса»), «Шатлык һәм сагыш бакчасы» («Сад радости и печали»), «Җиде сүз» кебек әсәрләре белән танылып, сиксәненче еллар уртасында «Offertorium» («Корбан»— «Жертвоприношение») һәм «Ишетәм... Илаһи тынлык» («Слышу... Умолкло») әсәрләре белән дөньяны яулый. Чит илләрдә бүгенге көндә аның 100 дән артык әсәре яңгырый.**



*«Pour ie Merite» Ордены әгъзалары. Япония.*

**София Гобәйдуллина —«Pour ie Merite» Ордены әгъзасы. Әлеге дәрәҗәгә ирешкән дөньяның мәшһүр дүрт ир-аты арасында—татар кызы!**

**Ул—Швеция Короле Сәнгать Академиясе әгъзасы. Берлин, Гамбург, Бавария Сәнгать академияләре әгъзасы. Россиядән Швеция Короле Сәнгать Академиясе әгъзасы булган 2 генә кеше билгеле: Петр Чайковский һәм София Гобәйдуллина.**

**Америка, Италия, Франция, Австралия, Германия, Япония, Дания, Россия һәм башка илләрнең премияләре лауреаты.**

**Мөселман дөньясында данлыклы Гобәйдия мәдрәсәсе салдырган (Бәйрәкә авылы, Ютазы районы), тирән гыйлемле, затлы хәзрәтләр нәселеннән.**

**1931 елның 24 октябрендә туып, Казанда музыка мәктәбе, музыка училищесы, 1954 елда Казан консерваториясен тәмамлый. Белем алуны Мәскәү аспирантурасында дәвам итә.**

**София ханым хәзерге көндә Германиядә яши.**

**Рәйсә ЮСУПОВА**

## *Әдәбиятыбыз тарихына*

# КЕШЕЛӘР АРАСЫНДА ЯШӘП ТӘ...

Сәгыйть Сүнчәләйнең лирик иҗатында интим хисләрне, табигать күренешләрен чагылдырган шигырьләр шактый күп очрый. Без исә мөһим бер моментка тукталып, аның шигъриятен үтәли сугарган ялгызлык мотивының гәүдәләнеше турында бер-ике сүз әйтмәкче булабыз.

Әйе, реаль тормышта актив эшчәнлеге белән танылган Сүнчәләй шигъриятендә лирик геройның рухи дөньясы еш кына «мин»нең ялгызлыкны тоюы белән бәйләнештә бирелә. Шагыйрьне мондый рухтагы әсәрләр язуга этәргән сәбәпләр күптөрле булгандыр. Шулай да болар арасында иң мөһиме, иң хәлиткече—минемчә, шагыйрьнең катлаулы шәхси тормышында, язмышында.

1908 елда Сәгыйть үзенең абыйсы Шәриф белән хәзерге Пермь өлкәсе Барда районының башта Сараш, аннары Солтанай авылларына дүртьеллык рус-татар мәктәбенә укытучылык итәргә килә. Абыйсы Учительская школаны тәмамлап чыккан булса, Сәгыйть анда бер генә ел укып өлгерә. Сәбәбе—уку өчен түләргә акча җитмәү, 1909 елда ул өйләнә, ләкин алар хатыны Сәлимә белән бер генә ел торып калалар. Анадан ятим калган улы Таһирны Сүнчәләйнең әнисе тәрбияләп үстерә (кызганычка каршы, ул бала да 14 яшендә үлеп китә. Аны югалтуын Сүнчәләй бик авыр кичерә).

Шагыйрьнең укытучылык чорын күз алдына китерергә азмы-күпме Риза Ишморат истәлекләре *(«Гомер сукмаклары», 1987)* мөмкинлек бирә. Ләкин автор ул елларда үзе дә бала гына булу сәбәпле, Сүнчәләйнең катлаулы тормышы ул истәлекләрдә әлләни тирән чагылыш тапмый. Күпмедер мәгълүматны Сүнчәләйгә Тукай язган хатлардан да алып була.

Сүнчәләй 1934 елның 25 сентябрендә Соловкидан өченче хатыны Әминә һәм кызы Таһирәгә язылган хатында болай ди: *«Әбиебездән (Сүнчәләйнең әнисе—М. Р.) хатлар еш алам. Фәриттән сирәк. Мин аңа үпкәләмим. Без үзебез дә аңа хат язмадык, хәтта ул мескенемне уйламадык та. Күрәсең, ул безгә каты үпкәләгән. Аның әнисе дә бик горур булды һәм шөһрәт яратты»*. Икенче хатыны Фәридә белән тормыш катлаулы килеп чыга ахрысы. Алар аерылышалар. Өченче мәртәбә ул 1921 елда гаилә кора. Бу юлы тормыш иптәше—артистка Әминә Милушева була. Ләкин өченче тапкыр да бәхетле язмышка тарымый Сүнчәләй. Асылда алар эпизодик рәвештә генә бергә торалар. Әминә театрга бәйле, Сүнчәләй ул елларда җәмәгать эшлеклесе булып, партия боерыгы белән әле Кырымга, әле Төркиягә, әле Мәскәүгә, әле Уфага җибәрелә. Аларның яшәү рәвешен азмы-күпме сакланып калган хатлары аша гына күзаллап була. НКВД тозагына килеп эләккәч тә ике арада элемтә булып фәкать хатлар кала.

Сүнчәләй хатларын укыганда шуны аңлыйсың: ни сәбәптер, Әминә сирәк язган. Ул Сүнчәләйнең Соловкидан килгән *«бергә килеп минем белән калган срокны авылда яшәргә ризамы?»* дигән сорау-тәкъдименә (шагыйрьнең 1935 елның 13 сентябрендә язган хаты архивында саклана) ризалык бирмәгән. Менә Сүнчәләй болай дип җавап яза: *«Әгәр мине чынлап яратсаң, син, билгеле, минем белән кайда торырга да риза булыр идең. Ләкин син сәхнәне күбрәк яратасың... Мин, билгеле, синең карьераңа, синең иҗади эшчәнлегеңә комачаулар идем.»* Күрәбез ки, шагыйрьгә язмыш шатлыклы, бәхетле минутлардан аз өлеш чыгарган: туганнары, бигрәк тә абыйсы белән киеренке мөнәсәбәт; җан дусты Тукайны югалту; замандашлары белән әлләни дуслыгы булмау... Бу хакта Бабич пародияләре, С. Кудаш истәлекләре, матбугатта чыгып килгән аерым мәкаләләр дә сөйли.

Шуның өстенә Сүнчәләйнең үзенең катлаулы шәхес булганлыгын да

истән чыгарырга ярамый. Бәлки ялгызлыкның төп сәбәбе фәкать шундадыр. Шагыйрьгә тынгысыз җанының теләк-омтылышларын гадәти тормыш, аның иҗтимагый шартлары белән тәңгәл китерү һәрвакыт кыен булган. Шуның нәтиҗәсе буларак, бердән, үзенә һәм кешеләргә карата туган канәгатьсезлек, сагыш, хәтта ачу хисе бар; ә икенчедән, тормыш күренешләрен яңадан бәяләргә, кешеләргә карата сәер мөнәсәбәтен акларга дәртле ихтыяҗ туа, гомумән, тормышны аңларга һәм акларга теләү күзәтелә.

Сүнчәләй, күрәсең, теләсә кем белән ачылып китеп, күңелендәге хисләре белән уртаклашып яши алмаган. Ә үзенең андый ихтыяҗы булган булса кирәк. Моңа дәлилне сакланып калган хатларыннан күрәбез. Хатыны Әминә һәм кызы Таһирәгә юллаган хатларында ул ташып чыккан хисләренә ирек бирә, аларның күбесендә ул үзе дә алардан озын, матур хатлар язуларын сорый.



*Шагыйрь С. Сүнчәләй хатыны Әминә һәм кызы Таһирә белән*

Сүнчәләйнең бөтен иҗаты субъектив тенденцияләр белән сугарылган. Хәтта аның иҗатын көндәлекләр белән чагыштыру да урынлы булыр иде. Ул тудырган образлар—аның эчке киеренкелегенең чагылышы. Субъектив кичерешләренең муллыгы да аның поэзиясен эчкерсез, тынгысыз, бай итә. Кайчак хәтта шагыйрь үзенең нечкә күңеленең сизелер-сизелмәс аккордларына кирәгеннән артык та колак саладыр сыман. Шул ук вакытта аның анализы да камил һәм көчле булуы белән таң калдыра. Ләкин нәтиҗәсе генә әллә ни шатлык китерми: шагыйрь эчкерсез күңеленең нечкә тойгыларын белдерүгә, куанырга, сөенүгә караганда сагышка бирелүне артыграк күрә. Сүнчәләй лирикасын чын мәгънәсендә ялгызлык җыры дип бәяләп була.

*Бу авылда туганнарым*
*Миңа күп ышана алмый.*

*Кача миннән, фәкать курка,*
*Ничек тә дустлана алмый.*

*Үземдә булмаган гөнаһ,*
*Гаепне генә тик эзли,*

*Туры килсәк кара-каршы*
*Икенче юлны тик эзли,*

—дип офтана шагыйрь «Авыр сулыш» *(«Идел» газетасы, 1 июнь, 1910 ел)* исемле шигырендә. Биредә аның туганнары белән булган катлаулы мөнәсәбәтләре күз алдына килеп баса. Бигрәк тә абыйсы Шәриф белән мөнәсәбәтләре киеренке булган ахрысы. Инде Соловкидан да ул аңа 7 ел буена хат язмый, ә хатыны Әминәгә язган хатларында мондый юллар бар: *«Шәриф ничек? Ул инде, билгеле, либерал. Мин аңа язмыйм һәм язачагым да юк. Без аның белән, күрәсең, инде килешә алмабыз шикелле. Хат алышмаганыбызга 4 ел»* (1934 елның 5 октябрендә язылган бу хат шагыйрь архивында саклана); *«Әгәр дә Шәрифнең адресын белсәгез, языгыз ул карт мещанинга, әнине карасын, шундый авыр хәлдә калдырмасын»* (1935 елның 11 октябре—кулъязма шагыйрь архивында саклана). *«Шәриф абыйга хат языгыз, әнине кайгыртсын. Мин аңа үпкәләдем һәм хат язышмыйбыз»* (1936 елның феврапь-марты).

Ялгызлык хисе кайвакыт шагыйрьгә үзен тоткынга тиңләргә нигез бирә:

Ямь табылмый тын гомерд8 саргаям,
Әкрен-әкрен ямь, кызу дәрттән таям.

Тоткын охшатып, зарыктым, кайгырам,
Тик өмет бар, шул өмидкә янтаям.

*(«Ялгызлык», 1910).*

Кешеләр арасында яшәп тә, түзә алмаслык ялгызлыктан котылырга теләп лирик герой алардан кача. Ул төннәрен шәһәрнең караңгы, тыныч урамнарыннан йөри:

Төн буе йөрдем шәһәрдә. Төн гаҗәеп якты иде,
Ялгызым йөрдем. Мина ялгызым яхшы иде,
Бу вакыт—күңлемнен иң хәсрәтле бер вакыты иде.

*(«Төнлә», 1918).*

Хәтта туып килүче көн дә аның күңеленә җиңеллек китерми. Бу шигырьдә контраст алымы көчле. Геройның күңеле никадәр тынычсыз, тормыш белән канәгатьсезлек хисе никадәр көчле булса, аны чолгап алган тормышта да шулкадәр үк капма-каршылык хөкем сөрә *(«И хәят! Ул шат иде, мәгърур иде»)*. Шигырь лирик геройның җавапсыз сораулары белән тәмамлана:

Аллана таң... мин ятып рухаи көям,
Кайда шатлык һәм сәгадәт? Кайда ямь?

Йа Ходая! Ни авырдыр халык арасында яшәү!—

дип ачынып яза шагыйрь. Кешеләр арасында, гөрләп торган шәһәр эчендә яшәп тә лирик герой, барыбер, ялгызлык белән күзгә-күз кала бирә.

Аh, әгәр рухым иман нуры белән нурланмаса,
Һәм гаҗәеп гыйшкы белән бәгърем минем, дим, янмаса—
бер сәгать тә мин яши алмас идем бу дөньяда.

..............................................................

Маржалар шат, урыслар шаулыйлар алар,
Ялгызым утырам караңгыда... күктә кайгылар.
Сикерешеп тә йөгерешеп уйный җегетләр, маржалар,
Ах, ятим күңелем кайчан рәхәт табар, бәхтен табар?

Кайвакыт ялгызлык шундый дәрәҗәгә җитә ки, хәтта шигырьләр дә тумый башлый:

Көләлмим, шатланалмыйм мин.
Яшим ялгыз. Язалмыйм да.

*(«Кояш күрмим», 1916).*

Ахыр чиктә шагыйрьнең актык һәм шул ук вакытта бердәнбер чарасы булып иҗат итү теләге кала. Шигырь—ялгызлыктан күпмедер дәрәҗәдә котылу чарасы, юану чыганагы: ул аларны «сердәшләрем», «нурлы фәрештәләрем», «җеннәрем», «алтыннарым» дип атый.

Гасыр башы әдәбиятында Дәрдмәндтән кала фәкать Сүнчәләй генә салкын, рәхимсез дөньяда яшәргә мәҗбүр булган шәхеснең ялгызлыгы трагедиясен үз иҗатында шулкадәр тулы, дәртле көч белән тасвирлап бирде. Әйе, ялгыз кеше—ирекле һәм бәйсез, ләкин шуның белән бергәттән, ул—тормышта үз урынын таба алмаган, мәңгелек дәрвиш тә. Аның яшәү рәвеше ике дөньяның чиге буйлап йөрүгә тиңләшә: ул бертуктаусыз күңел тынычлыгына ирешергә тели һәм дөньяның да камил булмавы аркасында үз максатына ирешә алмый кала.

Ялгызлык—Сүнчәләй шигырьләрендә төп темаларның берсе булып калды һәм ул безгә әнә шуның белән кызыклы да.

**Рәйсә МУСАБӘКОВА**

*Юмор-сатира*

# Камил Кәримов

## Үзем турында үзем...

*Мине үземнән дә әйбәтрәк белүче юк!*

*Шәледә тудым, эшчеләр арасында яшәдем, Мәдәният институтында укыдым, 8 ел буе Язучылар оешмасында, 12 ел «Чаян»да эшләп киттем. Егерме ел буе хикәяләр, юморескалар, повестьлар язып бастырдым. «Казан утлары»нда «Ком сәгате» дигән роман чыгаргач кына (1999 ел. №№ 8-9): «Карале, син язасың икән бит!»—диделәр.*

*Көндез мин җаныма урын табалмыйм.*

*Кичләрем сәхнәдә үтә.*

*Төннәрен—романның икенче китабын язам.*

*Сәхнәгә чыккач кына, үземне кемгәдер кирәкле кеше итеп тоям.*

*Сәхнә—иҗат кешесенең Азатлык мәйданы.*

*Бер хикәя укып кайтыр өчен, татар тамашачысын эзләп, мең ярым чакрым юл үткән чаклар да булды.*

*Җырчыларга алкышлар кирәк, миңа алкышлар гына җитми—залга җыелган халыкның елмаюын да күтәм.*

*«Казан утлары» журналы минем өчен мәртәбәле сәхнә. Бүген мин сезгә сәхнә өчен язылган биш әсәремне тәкъдим итәм. Кемгә нәрсә ошый—сайлап укырсыз! Чөнки бу әсәрләрнең кайсысы әйбәтрәк икәнен үзем дә белмим...*

*Автор*

## Козел белән баран

*Тукайга ияреп*

Габдулла Тукайның "Кәҗә белән Сарык" әкияте моннан бер гасыр элек язылган. Ләкин андагы вакыйгалар безнең көннәргә бик тә туры килә. Тукай ул-Әүлия—бүгенге базар реформасын алдан ук күреп бара, әкият белән үреп бара:

> "Борын заман бер Ир белән Хатын торган
> Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган..."

Нәкъ безнең тормыш инде бу!..

Г. Тукай һәр гектардан 68 шартлы центнер уңыш җыеп ала белә торган Арча районын ташлап, хәерче Казанга күчеп килә(!) Шуңа күрә аның әсәрләре үзе кебек ярлы халыкны яклау хисе белән сугарылган...

Әкияттә ачлы-туклы яшәп яткан Ир белән Хатын, тоталар да Кәҗә белән Сарыкны урманга куып чыгаралар... Ышанасы килми! Соң, егетләр, кайсы гына хәерче, һәр килосы айлык пенсия хакына торган ике түшкә итне курәләтә урманга чыгарып ташласын?! Юк, куып чыгармаган! Кәҗә белән Сарык үзләре чыгып качкан, хуҗаларының изүенә түзә алмыйча! Ник качмасын бичара хайван? Сарык, мескен, үзен шашлык итеп ашаганнарын көтеп ятсынмы? Кәҗә дә кача—көнгә бер тапкыр ашатып, көне-төне имиеңне кармалый башласалар—чит илгә чыгып качарсың! Әле дә ярый, Кәҗә халкы урлаша белә. Урлаша белгән хайваннар әйбәт яши безнең илдә! Сарык та, батыраеп, Кәҗәгә ияргән, тукта чү, кешечә яшәп булмасмы дигәндер инде...

Халык әйтә: Кәҗә тәкәсенә Сарык иярмәс, ди. Ә бу әкияттә киресенчә

–Тукайның Кәҗә белән Сарыгы ничек кавышканнар соң? Хәер, шагыйрь чын әкият остасы. Әкиятләрдә бар да мөмкин... Аккошны яратсан–сылу кызга әверелә. Бакага өйләнсәң–Хан кызы булып чыга. Камырдан әвәләп батыр малай ясыйсын... Ә чынбарлыкта исә, бөтенләй киресенчә... Хан кызы дип өйләнсәң Аждаһа булып чыга; Асыл егет ир булгач Дуңгызга әверелә; Ә малай ясаганчы әле тугыз ай буе камыр әвәләргә туры килә...

Г. Тукай әкиятләрне яратып яза. Ул демократлар кебек алдый, коммунистлар кебек куркыта, президентлар кебек юата. Аның әкиятләре күп түгел. Тукай чамалы белә. Юкса, матур киләчәк турында күпме әкият сөйләргә була инде халыкка?!

Ярый, сүз башына әйләнеп кайтыйк... Кәҗә белән Сарык, ямаулы капчык асып, спонсор эзләп киткәннәр. Капчыктагы бүре башын да ачыкларга кирәк. Каян килгән ул?

Монарчы, татар әдәбияты тарихында бүреләрне суеп ашап, башларын капчыкка салып йөрү очраклары юк иде. Минемчә, бүгенге бизнесменнар, рекетирлар, диллерлар һәм киллерларга охшарга тырышып кына Кәҗә белән Сарык теге капчыктагы бүрене терелэй тотып ашаганнардыр. Нишлисен бит, базар урманының үз законы бар... Тукайның чак кына әүлиялыгы житеп бетмәгән: Татарстан байрагында бүреләр нәселе–Ак барсны күрә торып, теләсә кайсы Сарыктан Бүреләрне обижайть иттермәскә иде...

Әкият дәвам итә. Кәҗә белән Сарык бер аланга килеп чыга. Алан уртасында зур учак. Ә учак тирәсендә өч-дүрт бүре 8 март көнен бәйрәм итеп утыра. Асылмалы казанда ботка пешә. Ләкин ботка итсез! Г. Тукай монда бүгенге мафиозникларның саранлыгыннан әче сарказм белән, ягъни итсез ботка белән көлә!

Боткага ит булды дип сөенәсе урында Бүреләр мафиясе Кәҗә белән Сарыкны ташлап кача. Ни өчен? Тукай үзе бу сорауга болай дип җавап бирә:

"Асраганнар бер Кәҗә берлә Сарык–
Болар булган берсеннән-берсе арык"

Ягъни, Казан тирәсендәге колхозларда мал-туар бүреләр куркырлык арык булган дияргә тели автор. Һәм ялгыша. Бүре сөяктән курыкмый, иптәшләр. Әкиятне алга таба укысак без чын җавапны да табарбыз:

"Микикики, микикики,
Капчыктагы Бүре башы бит уникe..."

Аңлагансыздыр, Кәҗә белән Сарык рекетирлар була! Алар, шушындый янау белән, бүреләрне куып, урман хуҗалыгын бер үзләре хосусыйлаштырып куя.

Тукай Кәҗә белән Сарыкны олылап әкиятнең буеннан буена исемнәрен баш хәрефләр белән яза. Шагыйрь ни әйтергә тели?

Бүреләр мафиясенең боткасын татыгач, Кәҗә белән Сарык өйләренә, ягъни элеккеге хуҗаларына кайтырга һич теләми. Алар хәзер үзләре хуҗа. Талау кәсебе белән көн итә башлагач, Кәҗә белән Сарык хәйран баеп, Кәҗәбез "Козел", сарыгыбыз "Баран" булып, кысык күзле машиналарга гына утырып йөрерләр. Идел буенда бюджет акчасына өч катлы коттедж күтәрерләр. "Сарык" акционерлык җәмгыятендә Кәҗәбез генераль директор булыр, хайваннар җыенында сайлауларда катнашыр. Һәм без алар каршына буш капчык күтәреп киләсе кешеләр...

Кәҗә белән Сарык әкиятенең азагы юк. Ул кинәт өзелә. Бүгенге көн турында язылганга күрә цензура кискәндер инде. Шунысы билгеле, тора-бара Кәҗәнең кулы артык озынайгач, налог инспекциясе хезмәткәре Былтыр аны бүрәнә ярыгына кыскан...

Хәер, монысы инде яңа әкият...

## Каты шелтә

*Нотык*

Мөхтәрәм укытучылар, Август киңәшмәсендә катнашуыма аптырамагыз–без сезнең белән коллегалар–мин дә маллар тәрбиялим.

Шөкер, бушлай эшләсәләр дә укытучыларыбыз күп икән әле–зал

тулы! Димәк, укырлык балаларыбыз бар дигән сүз. Хәер, соңгы ун ел эчендә минем Казан урамнарында йөкле хатыннар күргәнем юк. Реформага чаклы туган балаларны тәрбиялисездер инде... Хатыннарны бөтенләй йөк күтәрмиләр дип әйтеп булмый—кирәк чагында безнең укытучы апаларыбыз, алпавыт мунчасы чаклы биштәр күтәреп, Мәскәүнең Лужники стадионыннан Казанның колхоз базарына хәтле җәяү кайта алалар. Укулар башлангач мәктәпләребез кытай базарына әверелә.

Балалар саны кимегәнгә бер дә борчылмагыз сез. Кеше саны кимегән саен проблемалар да кими. Кеше әзәйгән саен, димәк, эшсезләр саны, ачлы-туклы яшәүчеләр, фатир сораучылар һәм әйтергә кирәк, җинаятьләр саны да кими. Алар барысы да безнең укучыларыбыз бит, мөхтәрәм коллегалар! Укучыны тудыру һәм тәрбияләү хатын-кыз эше. Шулай булгач, бүгенге сәяси һәм икътисади мәхшәргә сез—хатын-кызлар гына гаепле!

Уку елының беренче сентябрьдән башлап тугыз ай буе дәвам иткәнен бик яхшы беләбез. Ләкин бөтен бала да тугыз айдан тумый. Менә минем үземне әнием җиде айдан тудырган: өченче чирек бетеп, каникулга чыкканнан соң... Минемчә, Рәсәйнең бүгенге реформаторлары, гомумән, биш айдан ук туган булырга тиешләр.

Юньле бала бишектән егылып төшеп, мәктәпкә килеп җиткәнче, искиткеч катлаулы вә мәшәкатьле юл үтә. Җиде ел эчендә бала 7565 тапкыр елап уяна; 7565 тапкыр ашарга сорый; 12220 тапкыр колготкиена «пес» итә; 2500 тапкыр үлемнән кала һәм елга 365 тапкыр: «Минем әтием кем?» дип теңкәгә тия. Галимнәр әйтә, ана карынында бала тугыз гына ай түгел, ә җиде ел үсәргә тиеш ди. Ул чагында баланы ясле-бакчага да йөртеп торасы булмас, роддомнан алып чыгасың да, Әлифбасын тоттырып, туп-туры мәктәпкә илтеп куясың. Әлегә бу чынга ашмас хыял гына... Балалар болай да хәзер ана карынында ук институт бетереп туа. Һәм аның нинди институт бетереп тууы әти-әнисенең кайда эшләвенә бәйле: укытучыдан хәерче укытучылар династиясе туар; эшсездән —эшсез, начальниктан—начальник, депутаттан—депутат, бизнесменнан мафиозниклар династиясе туа... Әйе, укымышлы бандитка караганда надан депутат лутчырак...

Мәктәпләрдә реформа үткәрәсе бар. Әйтик, хезмәт дәресе урынына «эш эзләү серләре» дигән яңа фән кертергә кирәк. Эше булмагач, хезмәте нигә кирәк инде аның. Сез мине дөрес аңлагыз, мөхтәрәм коллегалар, кешенең акылы башында түгел, кешенең акылы кесәсендә!.. «Манимани»ен булса тиз үсәрсең... Бала институтка кергәндә хәзер өч кенә өстәмә сорау бирәләр: «Әти-әниең кайда эшли? Дача төзи беләсеңме? Сыерыгыз бозауладымы?..»

География укытучылары да зарлана: глобуслар һәм дөнья карталары кырык ямаулы. Җир йөзеннән авыллар, шәһәрләр, илләр югала. Яңа карталар сатып алырга мәктәпләрнең акчасы юк. Иске картадан Санкт-Петербургны эзләп аһ итәбез. Сталинград шәһәренең исеме карта өстендә кызыл кара белән дүрт тапкыр төзәтелгән. Элек бөтен исемнәр дә үз урынында иде, карталардан ут сүндереп эзләсәк тә таба идек. Таба алмасак география укытучысы Габдулла абый башыбызга имән указкасы белән суга иде. Шуңа күрә без география дәресләрендә җәен дә кышын да каеш бүрек киеп утыра идек.

Математика дәресләрендә дә программа яңарыр дип өметләнәм. Әйтик, тапкырлау таблицасының валюта коридорын киңәйтергә кирәк. Бер килода чынлап та мең грамм буламы? «А» пунктыннан «Б» пунктына поездлар һаман йөриме? Бер метр юанлыктагы торбалардан бушлай нефтебез һаман агамы?

Химия дәресләре бүген урамда гына узарга тиеш. Шөкер, Менделеев таблицасы эчендә яшәп ятабыз... Агыйделгә фенол түгеп мингерәтәләр, Иделдәге аммиакны иснәтеп һушыбызга китерәләр...

Балаларга бары укырга, укырга һәм укырга гына кирәк! Чөнки укыган чакта эш эзләү кайгысы юк...

Мөхтәрәм коллегалар!

Без хәзер Мәскәүнең иң өлкән укытучысы—Сталин сыман мыеклы, Хрущев сыман пеләш, Брежнев сыман кашлы, Ленин кебек кечкенә булырга тиеш дибез... Ә бүгенге Ил башлыкларының тәртипсезлекләре өчен аны укыткан педагогларга каты шелтә бирелдерәсе генә кала.

# Мәхәббәт харап итте...

*Хикәя*

–Сез кем буласыз әле? Гафу итегез, соравым кинәтрәк килеп чыкты. Ләкин үзегез беләсез, хәзер документ күрсәтеп турысын әйтеп сөйләшә торган заман.

–Мин "Ватан" газетасының хәбәрчесе, иптәш председатель. Килә-килешкә үк, сезнең "Коммунизмга" колхозын айкап, җан тетрәндергеч фактка юлыктым.

–Анысы шулай, хәбәрче кешене һәр үзгәреш тетрәндерергә тиеш инде ул. Тыңлыйм, журналист дускай, йә күземә карап әйт – кайсы ягыбызны ошатмадыгыз?

–Сез председатель булып сайланган елны колхозыгызда алты авыл булган. Ә бүген ул өчәү генә: Яхшы, Саклан, Алан авыллары юкка чыккан. Политик карталарда исемнәре язылган, чынлыкта исә ул авыллар инде җир йөзендә бөтенләй юк.

–Политика ул, иптәш член-корреспондент, политика ул... юк әйберне дә бар итеп сөйләргә ярата. Чит ил радиоларын йокы алдыннан тыңлап ятасындыр: безнең СССР турында булмаганны бар итеп күпме ялган сөйләделәр алар! Имеш, капитализм ул – оҗмах, капитализм ул – хөррият, демократия, муллык. Имеш, социализм ул – коммунистлар утопиясе... Позор! Ә бит үзләренчә тоже политика.

–Иптәш председатель, сез читкәрәк киттегез, сүз башыбыз илләр арасындагы политика турында түгел иде.

–Анысы шулай, безнең колхоз Европа белән Америка арасына урнашмаган, без бераз гына читтәрәк яшибез, шуңа күрә читкәрәк китеп сөйләшү кирәк тә. Энгельс бабаң нәрсә ди – политика белән шөгыльләнгәнче башта тамак туйдырырга кирәк, ди. Сез юлдан килгән кеше, ач карынга... Ач карынга иптәш член-корреспондентлар һәрвакыт усал була... Алло, Мәчтүрә апай, ике гурлалык кына кабымлык әзерлә әле, хәзер киләбез... Алло, Сәкинә апай, бүген кичкә теге мунчаны ягып куй, көтү кайткачрак килеп житәрбез... Алло, Гайфулла, теге игезәк бәрәннең берсен аксеркәгә батыра тор әле, яме, тозын күп салма, суганын мулрак тураг ыз!

–Гафу итегез, иптәш председатель, вакыт юк. Газетага срочно мәкаләне өлгертәсе бар. Туры соравыма туры җавап бирегез дә хушлашырбыз. Әйтегез миңа, кая куйдыгыз сез ул авылларны?!

–Ниме, иптәш член корреспондент, калада тормышлар ничек соң? Балаларыгыз көр үсәме, хатыннарыгыз үзегездән бик зарланмыймы? Һи, туганый, хатыннарны сөендерим дисәң колхоз председательләре белән дус бул инде син! Быел еллар авыр килде кәнишне, ну безнең колхоз муеннан бурычка батса да алай бөтенләй үк хәерче түгел, хатыннарны сөендерерлек кенә карабодай да җыеп алдык, умарта кортларыбыз да коммунистик хезмәт ударниклары кебек эшләде, сарыкларыбыз да ходайның рәхмәте, икешәр бәрән китерде.

–Иптәш председатель, сез минем сорауны юри ишетмәмешкә сабышасыз. Мин юл уңае сезнең халык белән сөйләшеп кайттым, сез ул авылларга радио кертмәгәнсез, кибетләрен яптыргансыз, клуб белән мәктәпне утынга саткансыз, кешеләр көн саен алты чакрымдагы үзәк усадьбага йөреп эшләргә тиеш булган ди?

–Син энем, күптән эшлисеңме әле?

–Быел диплом алдым гына, бу беренче иҗади командировкам.

–Ә-ә-ә, шулаймыни?! Әйтәм аны сорауларың кешечә түгел... Алло, Мәчтүрә апай, ашыңны суыт. Хәбәрчебез Казанга кайткач ашармын ди... Алло, Сәкинә апай, мунчаңа су салмый тор әле, яме, онытып җибәргәнмен, бу атнада көн саен мунча керелгән ләбаса: хакимиятнең урынбасары да, налог инспекциясеннән дә, сельхозхимия кешесе дә, главврач та, райпо бухгалтеры да шөкер, мунча өчен үлеп торалар... Алло, Гайфулла, бәрәннәргә тимә әле, яме, бераз үсә торсыннар, зурайсыннар дим, зуррак кунакка җитәрлек булсын.

Хәбәрчебезнең шашлыктан колагына кызыл тимгел чыга икән... Да, син кайсы стена газетасыннан диден әле үзеңне?

—"Ватан" газетасыннан, махсус хәбәрче...

—Внештатный значит...

—Юк, махсус...

—Махсус килгәннәр өчен махсус җавап әзер безнең. Әйе, әйтик, Яхшыр авылы юк инде. Ләкин аны син әйткән сәбәпләр түгел, ә мәхәббәт харап итте.

—Мәхәббәт... харап итте?!.

—Әйе. Ун ел элек башланды бу хәл. Иң әүвәл авылдан солдат Нури китте, армиядән кайтып килешли үк юл унае калада бер марҗа кызы белән танышкан икән, шуңа өйләндем диде. Паспорты кулында — китте. Нуриның ике ел буе хат алышкан Мөршидәсе бар иде. Егетнең өйләнүен авыр кичерде, тәмам сулды. Бетте бит бу кыз дибез. Ярты ел үтмәде, Нурины барыбер аерып алам, аннан башка яшәрлегем юк дип, китеп барды. Нури армиядән кайтканчы Мөршидәгә Яхшырның шәп кенә бер егете Хәкимҗан бәйләнеп йөрде, шаяртып түгел, яратып. Ышанасызмы, юкмы, Мөршидә авылдан китеп егерме дүрт сәгать тә үтмәде, Хәким анын артыннан чыгып качты, паспортны да бер айдан соң гына кайтып алды әле ул. Ну шуннан кул китте безнең: Хәкимгә күз салып, башкаларга сер бирмичә генә Нәкыя йөргән икән, юк хәйләләрен бар итеп китте бит теге. Ә Нәкыя өчен җанын бирергә әзер булып Гыйлаҗи йөри иде, кәнишне Гыйлаҗине беркем тыя алмый, китте Нәкыясен эзләп. Гыйлаҗинең әти-әниләре Шаһидәнең әти-әниләре белән туй турында сөйләшеп йөриләр иде, тикмәгә генә булмаган икән, китте Шаһидә. Ну Яхшырда Гарәф атлы бик тә булган егет бар иде. Шаһидә кайда — мин шунда дип, китте бит тәки. Гарәфине эзләп Әнисә, Әнисәне эзләп Мөхәммәт, Мөхәммәтне эзләп сразы дүрт кызыбыз чыгып качты...

—Бу киткән кешеләр гаилә кора алганнармы соң?

—Хикмәт тә шунда. Берсе-бер кияүгә чыкмаган. Нигә, дисәң, Нури марҗа кызы белән рәхәтләнеп яшәп ята. Нурины аерттыра алмагач, Мөршидәсе ялгыз картаерга сүз биргән. Мөршидәне ала алмагач, Хәким буйдак калган. Хәкимсез Нәкыя тилмергән, Нәкыяне көтеп Гыйлаҗи картая, Гыйлаҗисез Шаһидә, Шаһидәсез Гарәфи, Гарәфисез Әнисә, Әнисәсез Мөхәммәт, ә Мөхәммәт өйләнмим дисә, үзегез беләсез, сразы дүрт кыз тол кала... Әле мин бер өлешен генә сөйләдем, иптәш юнкор, бик теләсәң әлеге исемлекне туксан хуҗалыкка хәтле санап күрсәтә алам.

—Рәхмәт инде, мин сезнең легендагызны бик ошаттым. Шунсы гына аңлашылмый, киткән кешеләрнең Яхшырдагы туган-тумачалары кая?

—Балалар кайда туганнар, шунда инде ул... Туган-тумачасыз яшәр чакмы? Балаларны институтка кертәсе бар, эшкә урнаштырасы, дачасын төзеп бирәсе, машинасын-фатирын юнәтәсе. Һичьюгы фатирдагы бала-чагаларга күз-колак булып торсаң да файда. Хәзер аерым яши торган заман түгел. Менә шулай итеп, Яхшыр авылы бөтенләе белән китте дә барды.

—Ярар, Яхшыр авылын мәхәббәт харап итте дип саныйк. Ә Саклан белән Алан кая киткән?!

—Сакланны көнчелек харап итте, ә Аланы хыянәт корбаны булды. Бик теләсәң тәфсилләп аңлатып күрсәтәм...

—Сөйлисе әкиятегезгә алдан ук ышанам. Калганын үзем уйлап чыгарырмын, фельетон язганда.

—Хуш иттек, яшь иптәш, калага кайткач редакторыңа миннән сәлам әйт!

—Ә сез иртәгә газетаны укырга онытмагыз.

* * *

Иртәгесен, эшкә килүенә приказлар тактасында хәбәрчене редакторның яңа әмере көтеп тора иде инде:

"...Коммунизм" колхозына бәрәңге чүпләргә җибәрергә!..

## Котлы–ботлы

*Уртәү*

Коммунизм үпкәләде безгә — төялде дә китеп барды, хәерче балалары гына өелеп калды. Сайлаулар житте исә, менә кайтыр, менә кайтыр, дип өметләнәбез. Коммунизмны кире кайтарып була. Моның өчен күп кирәкми, кем нәрсә урлаган — китереп бирсен, үзе кайта ул! Көнчыгыш илләрендә шундый кырыс йола яшәп килә — әгәр кеше бер урласа, аның бармагын кисәннәр, ике урласа — кулын, өченчесендә — аягын... Әгәр бу жәзаны безнең илдә куллансанмы?! Түрәләр арасында бер исән кеше дә калмас, аяксыз-кулсыз һәм дә ки башсыз йөрерләр иде. Баш дигәннән, иптәшләр, татар халкы бик акыллы ул, пчаму, птамушты аның ким дигәндә өч мие бар: арка мие, баш мие... Һәм Минтимер Шәймие...

Иптәшләр! Без урысны сүгеп күтәрелдек! Суверенитетны да урыстан әжәткә алып тордык. Аны түлисе бар әле, нефть сатып. Түли алмасак — кире тартып алырлар. Урыс булган жирдә татар эт асрый... Хотя, без, татарлар, үзебез дә урыс инде, просто татарча сөйләшкән генә булабыз. Хәзер исә, бер-беребездән тел яшермик: давай откровенно, если ты русский — докажи, если ты татарин — покажи... паспортыңны!

Бу сәхнә кешесе дөресен әйтә микән соң дип, аптырап утырмагыз. Артык дөресен сөйләү — ялганның бер төре. Үзең генә ялганласаң — шаярта, диярләр, ә инде күмәкләшеп ялганласаң — сәясәт була ул, иптәшләр. Сәясәт дигәннән, депутатларга да эш авыр, сигез сәгать буе телевизор каршында ике кулыңны күтәреп утырып кара әле син! Бәпкәгә утырган каз да оядагысын көнгә дүрт-биш тапкыр әйләндерә. Безнең депутатлар ничек түзәләрдер?!.

Иптәшләр! Сайлаулар бик кыйммәтле уен. Бәлки киләчәктә безгә депутатларны чит илдән генә сатып алыргадыр, ни дисәң дә чит ил әйберсе арзанрак та затлырак һәм матурырак та.

Фәнни коммунизмның истәлеге булып бездә ике генә чират калды: берсе аның фатир чираты, икенчесе телефонныкы. Бу чиратларның икесен дә хәл итеп була — моның өчен, иптәшләр, бөтен сайлаучыларның да үзләрен депутат итеп сайлап куярга кирәк. Биш ел эчендә үзен генә түгел, бөтен туган-тумачаларын да фатирлы һәм телефонлы итеп өлгерәчәк ул. Өлгермәгәннәрен икенче срокка сайлап куярбыз. Аннан соң, ни өчен әле без аларны биш елга сайлыйбыз, өч елда да өлгерәләр алар

Иптәшләр, безнең илдә колхоз житәкчеләре бик бәхетле! Тырыша торгач алар авыл халкын бушлай эшләргә өйрәтеп житкерделәр. Мондый казаныш башка бер илдә дә юк. Хәтта череп баеган америкалылар да атнадан атнага зарплата сорап килә.

Агымдагы елда ит һәм сөт житештерүне арттыру нияте белән Голландиядән көнгә сиксән литр сөт бирә торган сыерлар кайтарткан идек. Ашау житкереп булмады... Чит илнең хайваны да комсыз түлке. Менә алар, безнең корчангы Холмогорлар кебек, бернәрсә дә ашамаган килеш көн саен уникешәр-уналтышар литр сөт биреп карасыннар!..

Авыл халкы шәһәргә качып бетмәсен өчен билет бәяләрен арттырырга исәплиләр. Юл йөргән өчен билет бәясен кешенең санына карап түгел, ә авырлыгына карап түләтәчәкләр. Әйтик, син илле килолы икән—бер билет аласың; йөз килолы булсаң — ике билет. Утыз биш килолы ирләр өчен льготалар булачак. Ә инде тәвәккәлләп Казанга килеп чыксагыз — туп-туры Кремльгә килегез. Казан Кремлен музей-комплекс итәләр. Анда утырган кешеләрне тарихи экспонат итеп калдырачаклар — күрәсең килсә билет алып керерсең.

Түгәрәкләп кенә әйткәндә, безгә шундый итеп яшәргә кирәк — Сабан Туйларыбызга Мәскәү президенты үзе килерлек булсын.

Бәйрәмнәр күп, килсеннәр генә.

Әле менә Республика көнен олылап бәйрәм иттек.

АО Россиянең ООО Татарстанына унбер яшь тулды! Унбер яшь — гүя без әле бишенче сыйныф укучысы гына Мәскәү укыта әле безне, укыта!

Бәйрәмнәрегез котлы, мәҗлесләрегез — тортлы, банкетларыгыз — ботлы булсын...

# SÜZLƏRDƏN ÇƏÇƏKLƏR

FƏXRİ ƏSĞƏTNEŅ TUUINA 100 YIL

*Mirsəy ağa Əmir səyli ide: «Minem Qazanğa kilep, sənğət texnikumına uqırğa kergən çağım ide. Berençe awır xəbər şul buldı: Fəxri Əsğət digən tatar yazuçısı wafat bulğan ikən... Bez anı isən çağında kürmi də qaldıq. Əmma cenazasına bardıq—ul üpkə çirle bulğan ikən. Bik yəşli, yegerme biş yəşe tular-tulmastan, bu fani dənyadan kitep barğan... Min anıŋ «Süzlərdən çəçəklər» kitabın əllə 1927, əllə 1928 yılda ğına uqıdım. Uqıdım da taŋ qaldım—şundıy talant ni əçen şulay irtə dənyadan kitərgə tieş ide. Anıŋ şiğri canı, ul çordağı awır açı xəsrətle tormış anı da izgənder, dip uylıym... Min, anıŋ xikəyə-nəserləren uqıp, üz yazğannarıma da küp ürnəklər aldım...»*

*Bu süzlərne Mirsəy ağa Əmir Yazuçılar klubında Fəxri Əsğətneŋ tuuına 70 yıl tulu uŋayınnan ütkərelgən kiçədə səyləgən ide.*



*Kem bulğan soŋ ul Fəxri Əsğət digən ədibebez? Şəxsi kitapxanəmdə anıŋ «Süzlərdən çəçəklər» digən kitabı da (1958 yılğısı buğay) bar ide. Fatirdan fatirğa küçkəndə yuğalğandırmı, taba almadım... Yarar, xəyerle bulsın!..*

*İnde Fəxri Əsğətneŋ biografiəsenə küz salıyq. Ul (Əsğət Yosıf ulı Fəxretdinov) 1901 yılnıŋ 13 oktəbrendə xəzerge Tatarstan Respublikasınıŋ Əlki rayonı Alpar awılında tuğan. Şul awıl məktəbendə uqığannan soŋ, ul Qazanğa kilə həm «Məxəmmədiə» mədrəsəsendə uqıy.*

*Süz uŋayında, əytep ütik: Alpar urta məktəbendə xəzer muzey bülməse bar. Anı uqıtuçı Qadir Sibayıv oyıştırıp cibərgən. Şunda, iŋ berençe bulıp, Fəxri Əsğətkə qağılışlı əyberlər quyılğan. Bu məktəptə uqıp soŋğı yıllarda ədəbiatta tanılğan şəxeslərdən şağir Şamil Mannapov, Mədərris Wəliev isemnəren telgə alu da citəder. Məsələn, Şamil Mannapov: «Minem berençe parça-xikəyələrem turıdan-turı Fəxri Əsğət xikəyələre yoğıntısında tudı», —dip səyli.*

*Qızğanıç ki, üze isən çağında F. Əsğətneŋ nibarı ber yuqa ğına kitabı nəşer itelep qala. Anıŋ iŋ küləmle kitabı «Tormış qoçağında» isemle. «Süzlərdən çəçəklər» (96 bit!) kürenekle ğalim-ədibebez Ğazi Kaşşaf kereş süze belən Tatarstan kitap nəşriatı tarafınnan 1977 yılda nəşer itelde. Şunnan birle bu üzençəlekle yazuçınıŋ kitapları dənyağa çığa almadı şikelle...*

*Fəxri Əsğət, əytkənemçə, bik irtə—yegerme biş yəşe tulmastan dənya quya. Ləkin anıŋ qısqa icat ğəmerendə yazılğan az sanlı xikəyə həm nəserlərе əle xəzer də onıtılmıy, alar, tatar ədəbiatınıŋ ber keçkenə cəwhərlərе bulıp yəşilər həm ozaq yıllar yəşəyəçək əle. Qısqası, F. Əsğət beznеŋ ədəbiatıbızda yuğalıp qalırğa tieş şəxes tügel.*

**Mars ŞABAYIV**

# Fəxri Əsğət

## Batırlar

Çirmeşən yılğası buylap sibelgən tirə-yaq awıllarda Ğəynetdin kerəşçene işetməgən keşe, belmim, bar mikən. Anıŋ keçlelege, kerəşergə ostalığı tirə-yaqta dan alğan. Awılnıŋ səykemle qızları, cilbəzək yegetlərə genə tügel, üz ğemerlərendə küpne kürgən ap-aq saqallı qartları da anıŋ belən maqtanalar.

—Beznen Ğəynetdin, nibuç, sınatmas, əyle-şəyle malaylardan sırtın cirgə tidertməs,—dilər.

Çınlap ta, ul nəseldən kilgən kerəşçe. Atası Sələy, babası Əxmüş qartlar ilneŋ ataqlı kerəşçeləre, batırları bulğannar. Alar kerəş məydanına ayaq basu belən bütən awıllarnıŋ «min kem!» dip kəperenep yergən batırları tizrək xalıq arasına şılalar, küzdən yuğalalar ikən. Hər saban tuyında, əz dıgəndə, utız-qırıq kerəşçene əyləndərep sala torğan bulğannar. Küp waqıtnı alarnı saban tuylarında kerəşkə qatnaştırmıylar. Yəş kilennərdən, buyğa citkən qızlardan cıyılğan qızıl başlı ozın səlgelərne, iŋ matur itep çigelgən yawlıqlarnı birep, rizalatalar ikən.

Sələy qart əle də isən. Yəşe altınçı unğa çığuğa qaramastan, cen kebek taza, anıŋ keçle qulları, əle xəzer də suqsa timer ezərlek.

—Sələy denyağa bireşmi, Sələy əwxətendə əle,—dilər anıŋ yəştəşləre.

Zamanında tirə-yaqnı tetrətep torğan Sələy monnan küp yıllar elek saban tuylarında kerəşüne taşlağan, üzeneŋ urının ulı Ğəynetdingə qaldırğan bulsa da, anıŋ dərtle yerəge tüzmi, ul hər saban tuyına çığa; qulına qalın qarama tayağın totqan kileş, məydan taralğançı kerəşçelərne tamaşa qılıp tora. Üzeneŋ yanına cıyılğan yəş-cilkençəkkə:

—Bu malay kerəşnen solın belmi, kerəşü eçen keç kenə citmi şul, cayın belergə kirək, cayın. Kürəsezme, qullarıŋ niçek quyğan. Menə qarap torığız, üzen yon yomğağı təgərətkən kebek təgərəterlər,—di.

Yegetlər anıŋ süzləren ixlas küŋel belən tıŋlıylar.

—Ə-ə... kürəsezme, bu niçek asqa kerep aldı. Qulı-başı yatıp tora bu yegetneŋ. Baş aşa ırğıtırğa mataşa,—di.

Ul əytep tə betermi, ikençe yeget, küz açıp küz yomğançı, baş aşa təgəri.

—Menə niçek yığalar anı!—dip quya Sələy qart. Ul, kerəşçeneŋ selkeneşenə, qullarıŋ quyışına qarap, ciŋelü-ciŋelməwen aldan əytep quya. Hərwaqıt diərlek təcribəle qartnıŋ süzlərə dores çığalar.

Bügen awılda saban tuyı. Şuŋa kürə awılnıŋ yəşe, qartı, xatını, qızı basu qapqa təbendəge çirəmgə cıyılğannar. Sələy qart ber terkem yəşlər urtasında qarama tayağına tayanıp, kürşe awıldan kilgən kibetçe Mostafa malayı Cəlkəy batırnıŋ kerəşkənen bik centekləp qarap tora. Cinsez qara kamzul estennən bilenə qızıl puta bəyləgən kiŋ cilkəle, təbənək gəwdəle Cəlkəy çıqqan ber kerəşçene ozaq yertmi, keçle qulları belən kütərep ala da, eç-dürt mərtəbə zınldatıp əyləndergəç, ayaq estennən seltəp cibərə. Aŋa qarşı çıqqan batırlar yomıçqa kebek oçıp teşələr.

Küp batırlarnı kürgən Sələy qartnıŋ küzlərə aldamıylar. Awız eçennən:

—Malay şoma qaynaştıra...—di.

Küzgə kürengən rətlerək batırlar betep baralar. Yuğarı oçnıŋ Ğələwi də, kürşe awılnıŋ Tərci malayı da yığıldılar. Çıqqanı berse təgərilər genə.

Cəlkəy belən bergə kilgən iptəşeneŋ itəge, uŋı-sulı Cəlkəygə birelgən büləklər, selge-tastımal həm yawlıqlar belən tuldı. Cəlkəy yıqqan sayın, ber urınğa cıyılğan anıŋ awıldaşları qıçqırışalar, şawlıylar.

—Menə şulay! Ay-yay həybət saldıŋ!

—Təgərət, Cəlkəy dus, təgərət!

—Batırları belən bik küp maqtandılar inde, həmməse cirgə teşə!—dip quyalar, Cəlkəygə keç birep, küŋelen kütərep toralar.

Axırğı emet—Pakrıy malayı Xəyri də yığıldı.

Awılnıŋ yəşlərə genə tügel, qartları da qurquğa teştelər. Çenki axırğı terək, soŋğı bağana Sələy malayı Ğəynetdingə çirat citte. Ğəynetdin qul kerəşeneŋ genə tügel, sıynfıy kerəş, grajdannar suğışınıŋ da batırı: 1918-

1920 yıllarda Qızıl ğəskər safında, qanlı frontlarda yərep qaytqan keşe.

Məydannın urta ber cirenə çügələgən Cəlkəy xəl cıya.

— Beznen Ğəynetdin bireşməs.

— Ul çuyın bağana, anı tiz genə awdara almas, — digən maqtawlar astında qaldı, şılt itkən tawış işetelmi.

— Nərsə bula? Kem cinər? — dip küzləren batırlarğa terədelər.

Cəlkəy belən Ğəynetdin ber-berenə yaqınlaştılar. Elek sınaşqan şikelle berniçə minut qaraşıp tordılar, cirdən ielep, bersen berse totıştılar. Alar əkren həm awır adımnar belən tügərək eçendə talpınalar. Ğəynetdin üzenen ğədətençə əzrək kütərep alıp, sul yaqqa yanbaş ırğıturğa uylağan ide, əmma yarım aç, yarım yalanğaç kileş suğış məydannarında yərülər anın keçen sırğannar. Ul da bulmadı, Cəlkəy qısqa ber talpınu belən kinət anı kütərep aldı. Xalıq üzenen küzenə ışanmıyça torğanda, Cəlkəy anı zırıldatıp əyləndərde-əyləndərde də bar qüətkə ırğıttı. Tirə-yaqnın ataqlı batırı Ğəynetdin eç adım çitkə oçıp təşte.

Xalıq arasınnan kemder berəw:

— Ax!.. — dide.

Cəlkəynen awıldaşları bəten hawanı yanğıratıp qıçqırırğa, Cəlkəyne qul estendə çəyərgə başladılar.

— Xərəmləde, xərəmləde...

— Cəlkəy ayaq çaldı!

— Yanadan kerəşsennər, yanadan! — dip qıçqırğan tawışlar işetelsə də, ozaqqa barmadı.

Yıgılu bik şoma, bik deres bulğanğa daw həm cəncal quptarırğa urın yuq ide.

Tərkem əzrək tınğan sıman buldı.

Barlıq batırlardan esten çıqqan, həmməsen də cirgə tüşəgən Cəlkəy, kükrəgen alğa kierep, manğayınnan, cilkələrennən aqqan ere tir bertekləren sertep, məydan urtasına çıqtı. Erelənep tügərəkne ike rət əyləngəç, nəq urtağa kilep tuqtadı. Qalın, keçle tawış belən:

— Yə, tağın kemnər bar? Çıqsınnar, — dide.

Məydanda tınlıq. Xalıq ezlənep yaq-yaqqa küz salsa da, çığuçı kürenməde. Cəlkəy ətəçlənebrək tağın kütərenkerək tawış belən:

— Nu, tizrək bulsın, kem bar?! — dide.

Xalıq urtasınnan kemder aralap çığıp kilə.

— Qızılərmis Ğəynetdinnen atası, Şəxmi qartnın ulı — min bar! — dide berəw.

Bu tawışnı işetkən keşelərnen tənnəre çımırdap kitte. Altınçı unğa ayaq basqan, kerək kebek ap-aq saqallı Sələy qartnı məydan urtasında kürgəç, qurqıp, aptıraşıp qaldılar. Qartnın tışqı küreneşe, yəze tınıç kürenə. Tik kerfeklərenə salınıp təşkən aq qaşlar astındağı sorı küzlər qurqınıçlı yaltırıylar.

Sələy qart ulı taşlap qaldırğan şaqmaqlı tastımalnı əkren genə cirdən kütərde. Üz-üzenə ışanğan nıq tawış belən:

— Əydə! — dide.

Cəlkəy elek qartqa məsxərəle qaraş taşlağan bulsa da, qartnın tınıç qiəfəte, yalqınlı küzləre, prikaz rəweşendə əytelgən «əydə» anı şaqtıy qawşattılar. Tənendə, muskullarında keçsezlek, nindider awırlıq sizgəndəy buldı.

Xalıq, küpme yıllardan birle kerəşməgən aq saqallı Sələy qartnı iməndəy taza, narat kebek yanıp torğan ber yegetkə qarşı kerəşkə çıqqanın kürgəç, ni əytergə belmi aptırap qaldı.

Qart aşıqmıyça ğına, osta ber xərəkət belən şaqmaqlı tastımalnı Cəlkəynen bilenə saldı. Alar əkren genə yərilər, ber-bersen sınaşalar. Şaqtıy ozak yərdelər. Xalıq niçek ikənen də kürep elgerə almadı, Sələy qart Cəlkəy batırnı baş aşa oçırdı, Cəlkəy məydandağı qomğa başı belən barıp qadaldı...

Tüzemsezlek belən alardan küzen almıyça torğan xalıq, şaşqın tawışlar belən qıçqırırğa, yat tawışlar belən ükerergə, sikerergə totındı.

Cəlkəy berniqədər waqıt selkenmi yattı. Anı iptəşləre kütərep aldılar.

Qart kerəşçe Sələy üzenə kitergən ber qoçaq selge-tastımallarnı, yawlıqlarnı, eskəterlərne də almadı. Ozaq waqıtlar gerləp torğan şaşqın ükerülərgə, qıçqırularğa da qolaq salmadı. Üzenen awır həm basınqı adımnarı belən Çirmeşən yılğasının tekə yarı buyına salınğan keçkenə eyenə yünəlde.

*1924*

## Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
## Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### РЕСПУБЛИКА БӘЙРӘМЕ

30 августта Республикабыз суверенитетының 11 еллыгы һәм мәркәзебез Казан көне, алдагы еллардагыча, тантаналы рәвештә бәйрәм ителде. Бу матур аяз көнне казанлылар һәм башкалабыз кунаклары шәһәребезнең төрле почмакларында үткән күнелле һәм мавыктыргыч тамашаларда, концертларда, бәйгеләрдә катнаша алдылар. Бәйрәмнең финалы, гадәттәгечә, Үзәк стадионда булды, дүрт сәгатьлек тамаша-шоудан соң, Казан күге фейрверк балкышларына күмелде.

### МАТБУГАТ ҺӘМ ӘБҮНӘЧЕ

Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева республика газета-журналлары мөхәррирләре һәм Элемтә министрлыгы вәкилләре белән киңәшмә үткәрде.

Ул 2002 елның беренче яртысына матбугатка язылу башлану унаеннан әлеге компаниягә бәйле проблемаларга багышланды. Сөйләшүдә элемтә хезмәтләренә бәяләрнең нык артуына һәм бер үк вакытта өстәмә кыйммәткә салым кертелүгә бәйле рәвештә килеп чыккан хәл тикшерелде, газета-журналларның тиражын саклау бурычы бик мөһим икәнлеге әйтелде. Киңәшмә эшендә элемтә министры Ринат Җәләлов катнашты.

### КАЗАН КРЕМЛЕ ТӨЗЕКЛӘНӘ

Казан Кремленең элеккеге юнкерлар училищесы бинасында тиздән төзекләндерү эшләре башланачак. Биредә Татарстанның табигать музее һәм рәсем галереясы урын алачак.

Бинада биек арка белән бүленгән ике керү урыны ясалачак. Кремльнең үзәк урамыннан үткәндә, аның аша Кол Шәриф мәчетен күреп булыр. Ә элеккеге губернатор сараеннан ерак түгел Сарай чиркәве бинасында татар халкы һәм Татарстан дәүләтчелеге музее оештырылачак. Биредә бинаның алгы ягы төзекләндереләчәк.

### ТАГЫН БЕР ЯҢА ЖУРНАЛ

Башкалабызда «Казанская афиша» исемле яңа журнал чыга башлады: аның 1 нче саны 30 август алдыннан дөнья күрде. Бу журналда мәдәният яңалыклары, театрлардагы тамашалар, музейлардагы әдәби кичәләр, күргәзмәләр, кинотеатрларда бара торган яңа фильмнар, мәдәният сарайларындагы күңел ачу чаралары, спорт тормышы, гастрольләр һәммәсе чагылыш табачак. Бу журналда, шулай ук, әдипләр, күренекле шәхесләр белән әңгәмәләр дә бирелеп барылачак. Басма заманча итеп, төсле фотолар, рәсемнәр белән бизәлгән.

Журналны Казан хакимияте һәм аның мәдәният идарәсе гамәлгә куйган. Яңа елга кадәр айга бер, аннары ике тапкыр чыгар дип көтелә.

### СӘЙДӘШ АЛАНЫНДА

18 август көнне Югары Ослан районының Кызыл Байрак авылында бөек композитор Салих Сәйдәшев истәлегенә сәнгать бәйрәме булып үтте. Казаннан махсус теплоход белән әдәбият-сәнгать зурвәкилләренең төркеме килде. Тирә-як авыллардан да күп кеше җыйналган иде. Тантана барышында—Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин чыгыш ясады. Соңыннан сәнгать осталарының берничә сәгатькә сузылган зур концерты булды. Киләчәктә мондый мәдәни бәйрәм, Кырлайда һәм Яуширмәдә уза торган Тукай һәм Исхакый көннәре кебек, һәр ел саен үткәреләчәк.

### ЯШЬЛӘР БЕЛӘН ОЧРАШУ

25-31 августта Казан янындагы «Идел» халыкара яшьләр лагеренда уникенче тапкыр «Татар яшьләре көннәре» уздырылды. Казакъстан, Башкортстан, Удмуртия, Чувашия республикаларыннан, Төмән, Иваново, Оренбург, Самара өлкәләреннән, Мәскәүдән һәм Казаннан—җәмгысы кырыктан артык республика һәм өлкәдән килгән егетләр һәм кызлар бүгенге сәяси вәзгыять, татар әдәбияты һәм сәнгате турында галимнәр һәм җәмәгать эшлеклеләренең чыгышларын тыңладылар. Бер көн тулысынча «Казан утлары» журналына багышланды. Баш редактор урынбасары, язучы Ф. Латыйфи һәм бүлек мөхәррире, язучы М. Закир яшьләрне журналның тоткан мәсләге, бүгенге татар әдәбияты һәм аның перспективасы белән таныштырдылар.

### ТУКАЙ МУЗЕЕНДА

Габдулла Тукай музеенда «Татарстан Республикасы: яңа тарих» дигән күргәзмә ачылды.

Биредә XXI гасырның соңгы еллары белән бәйле булган вакыйгалар—сәяси

партияләр һәм хәрәкәтләр митинглары, Татарстанның Югары Советы, Дәүләт Советы сессияләре утырышлары, халык депутатларының чыгышлары сурәтләнгән фотографияләр куелган.

Экспозициядә республиканың Милли музее фондыннан алынган үзенчәлекле экспонатларны да күрергә мөмкин. Алар—Татарстанның флагы һәм гербы, Конституциясе, Татарстан халыклары съездлары материаллары. Шулай ук биредә Татарстан Республикасының беренче Президенты Минтимер Шәймиев кабинетыннан җиһазлар—өстәл, кресло һәм башка истәлекле әйберләр.

## ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

Танылган язучы, фронтовик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Әдип Маликовка 80 яшь** тулды. Олы юбилее уңаеннан шагыйрьне республика җитәкчеләре, киң җәмәгатьчелек вәкилләре котлады.

«Татнефть» каршында оештырылган «Рухият» нәшрияты да юбилярга зур бүләк әзерләде: язучының «Гомер мизгелләре» дип аталган истәлекләр китабын бастырып чыгарды. Китапны Әдип Маликов үзенең тормыш иптәше—танылган шагыйрә Саҗидә Сөләймәнованың якты истәлегенә багышлаган. Бу әсәр ин әүвәл безнең журналда дөнья күргән иде.

## АТАКЛЫ КВАРТЕТ ГОЛЛАНДИЯДӘ

3-10 сентябрь көннәрендә Голландия башкаласы Амстрдам шәһәрендә Татарстанның дәүләт кыллы квартеты башкаруында танылган композиторларыбызның заманча көйләре яңгырады.

Татарстанның халык артистлары Шамил Монасыйпов, Марат Зарипов, Камил Монасыйпов, Альберт Әсәдуллин квартеты Светлана Зорюкова һәм Рәшит Кәлимуллин, шулай ук чит ил композиторлары Мартин Чиба (Нидерланд) һәм Матиас Лизелл (Швеция) әсәрләрен башкарды. Халыкара музыка атнасын «Gaudeamus» заманча көйләр үзәге оештырган.

## СОҢЛАП БУЛСА ДА

Каһарман милләттәшебез, Берлинны алганда рейхстагка беренчеләрдән булып байрак кадаган **Гази Казыйхан улы Заһитовның тууына 80 ел** тулды һәм, ниһаять, сугыш тәмамланып, 56 ел үткәч, ана Герой исеме бирелде.

Башкортстанның Миякә районы Янагыш авылында сугыштан соңгы елларда герой яшәгән өйдә мемориаль такта ачу тантанасы үтте. Тантанада район һәм авыл хакимиятләре башлыклары, геройның якыннары, яудашлары, авылдашлары катнашты. Гази Заһитовның каберенә чәчәкләр салынды, авыл мәдәният йортында батырга багышланган кичә булды.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ

Байтак еллар буе килгән традиция буенча, быел да 25 август көнне Муса Җәлилне һәм аның көрәштәшләрен искә алу өчен Җәлил һәйкәле һәм барельеф янына митингка халык җыелды. Митингта Президент Аппараты җитәкчесе Әгъзам Губәйдуллин, мәдәният министры Илдус Тарханов, мәгариф министры Фарис Харисов, Язучылар берлеге рәисе Фоат Галимуллин һәм күп кенә язучылар катнашты.

Быел ерак җирләрдән дә кунаклар килгән иде: Алматыдан шагыйрь Равил Гозәеров, Марий-Эль республикасыннан Билал Журиев, Равил Хөсәенов... Кунаклар арасында Муса Җәлилнең кызы Люция, Абдулла Алишның улы Алмаз да бар иде.

Хәтер җыены Муса Җәлилнең фатир-музеенда дәвам итте. Анда язучы Рафаэль Мостафин белән очрашу булды.

## ЛАЕКЛЫ ТАНЫЛУ

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры **Ислам Галиәхмәт улы Әхмәтҗанов «2001 ел директоры»** дигән мактаулы исемгә лаек булды.

«Алгарыш өчен хезмәттәшлек» халыкара программасының координацияләү комитеты иң яхшы предприятие җитәкчесен сайлаганда бертавыштан шундый фикергә килде. Ә «Идел-Пресс»ның үзенә исә «Алтын стандарт» сертификаты бирелде.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Президенты Указы белән сынлы сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен рәссам **Фәтхетдинов Әхсән Сәрим улына** «Татарстан Республикасының халык рәссамы» дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

2001 елның 22 августында 75 яшендә шагыйрь, педагог, сугыш һәм хезмәт ветераны, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре **Әзһәр Сәмигулла улы Габидуллин** (Әзһәр Габиди) вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Башкалабызның «Казан нуры» мәчете.
*Н. Исмәгыйлев фоторәсеме.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** әдәбият галиме Фәрит Хатипов.

## ЯҢА ЖУРІ




Чаллыда яңа журнал чыга башлады. «Мәйдан» дип аталган әдәби-нәфис, иҗтимагый журналның беренче саны сентябрь аенда дөнья күрде. Басманың оештыручысы—Чаллы шәһәр хакимияте. Шулай ук Татарстан Язучылар берлеге дә журналны оештыруда катнашучы исәпләнә. Журналның баш мөхәррире—күренекле язучы Факил Сафин (Факил Әмәк).

Беренче сынау саны күренекле авторлар катнашында бай эчтәлекле итеп, тормышыбызның төрле якларын яктырткан язмалар белән бизәп чыгарылган. Бу санда катнашкан авторлар арасында—А. Хәлим, Ф. Бәйрәмова, В. Имамов, Р. Бәшәр, Ф. Дунай, Р. Хисмәтулла, Н. Мәдияров... Казан шагыйрьләреннән М. Әгъләм, Ә. Баян, Р. Вәлиев һәм башкалар бар. Журнал—Чаллы шәһәре хакимияте башлыгы Р. Хәмәдиевнең фатиха-кереш сүзе белән ачыла. Журнал адресына ТР премьер-министры урынбасары З. Вәлиева, ТР Дәүләт Советы урынбасары, шагыйрь Р. Миңнуллин, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ф. Галимуллин, «Казан утлары» журналының баш мөхәррире, Татарстанның халык шагыйре Р. Фәйзуллин котлау-тәләкнамәләр юллаганнар. «Без—гасырга якын дәвердә халкыбызның төп әдәби басмасы булып килгән «Казан утлары» журналында эшләүчеләр—«Мәйдан»ны үзебезнең әдәби туганыбыз дип санаячакбыз, кулыбыздан килгәнчә ярдәм итәргә әзербез. Күңләшеп укырлык әсәрләр генә чыксын—сөенербез» диелә Р. Фәйзуллин юлламасында. Журналның редколлегия әгъзаларының берсе булып «Казан утлары»ның баш мөхәррире урынбасары, язучы Ф. Латыйфи да сайланган.

*Хәерле юл сиңа, «Мәйдан»! Укучыларың ишле булсын! Егерме беренче гасырда татар халкының рухи елъязмачысына әверел!*

Индекс 73210



Фәрит Хатипов

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)